Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Г. Ибраһимов исемендәге
Тел, әдәбият һәм сәнгать институты

# РУХИ МИРАС
## эзләнүләр һәм табышлар

5 нче чыгарылыш

Казан

2018

Институт языка, литературы и искусства
им. Г. Ибрагимова
Академии наук Республики Татарстан

# ДУХОВНОЕ НАСЛЕДИЕ

## поиски и открытия

Выпуск 5

Казань

2018

УДК 801.82(082)
ББК 63.2:80я43
Д 85

*Печатается решением Ученого совета*
*Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова*
*Академии наук Республики Татарстан*

Проект реализуется Центром письменного и музыкального наследия
Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова
Академии наук РТ – Мирасханэ

**Редколлегия:**
И.Г. Гумеров (руководитель проекта и ответственный редактор),
З.З. Рамеев, А.М. Закирзянов, А.К. Бустанов

**Составители выпуска:**
Л.Ш. Гарипова, Г.М. Ханнанова, Н.Ш. Насибуллина

Д 85 Духовное наследие: поиски и открытия: Вып.5 / под ред. И.Г. Гумерова; сост.: Л.Ш. Гарипова, Г.М. Ханнанова, Н.Ш. Насибуллина. – Казань: ИЯЛИ, 2018. – 280 с.
ISBN 978-5-93091-254-8

Сборник продолжает традицию публикаций малоизвестных письменных источников и изучения произведений, составляющих основу духовного наследия татарского народа, для знакомства читателей с новейшими исследованиями в изучении татарских текстов.

Очередной выпуск серии посвящен жизни и творчеству классика татарской литературы, драматурга, крупнейшого национального политического деятеля, публициста, издателя Гаяза Исхаки (1878–1954). В сборнике представлены художественные произведения, дневники писателя, его публицистика, доклады; воспоминания современников о Г. Исхаки, рецензии на его выступления и труды, архивные документы. Тексты впервые предлагаются вниманию читателей в переложении на кириллический алфавит.

ISBN 978-5-93091-254-8

© Институт языка, литературы
и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ, 2018

# КЕРЕШ СҮЗ

Татар әдәбияты классигы, танылган җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакый (Мөхәммәтгаяз Гыйлаҗетдин улы Исхаков, 1878–1954) – XX гасыр төрки-татар милли-сәяси тормышында тирән эз калдырган, аның рухи-мәдәни үсешенә көчле йогынты ясаган күренекле шәхес.

1990 елларда илдә сәяси һәм иҗтимагый-мәдәни үзгәрешләр башлангач, мөһаҗирлектә гомер кичерергә мәҗбүр булган әдипнең язма мирасын барлау һәм халыкка кайтару эше башланып китте. 1991 елда Татарстан Республикасының Чистай районы Яуширмә авылында Гаяз Исхакыйның мемориаль музее ачылды, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Язучылар берлегенең Гаяз Исхакый исемендәге премиясе булдырылды.

Әдипнең тормыш юлы, иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге, әдәби мирасы, фәнни яктан шактый җитди өйрәнелеп, аерым хезмәтләрдә чагылыш тапты. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре тарафыннан Гаяз Исхакыйның унбиш томлы «Әсәрләр» җыелмасы әзерләнде. Әлеге басманы чыгаруда катнашкан галимнәр коллективы 2016 елда фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт премиясенә лаек булды.

«Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар» китабының бишенче чыгарылышы да Гаяз Исхакый мирасын туплау һәм өйрәнү юлындагы фәнни эзләнүләрнең дәвамы булып тора.

Биредә әдипнең тормышын, иҗтимагый-сәяси эшчәнлеген, иҗатын яктырткан язмалар, бүгенге укучыга таныш булмаган архив материаллары укучылар игътибарына тәкъдим ителә. Аларның күбесе гарәп һәм латин графикаларыннан гамәлдәге язуга күчерелеп, беренче тапкыр нәшер ителә.

Китапта материаллар дүрт бүлеккә туплап бирелде. Беренче бүлек, Гаяз Исхакыйның тәрҗемәи хәлен, эшчәнлеген тулырак күзалларга мөмкинлек биргән язмалардан гыйбарәт булып, аның төрки-татар дөньясы көнүзәк мәсьәләләренә багышланган публицистик мәкаләләрен, чыгышларын үз эченә ала. 2008 елда, язучының юбилее уңаеннан, Төркиянең «Аяз Таһир (Төркестан-Идел-Урал)» фонды җитәкчесе Түләй Дуран Гаяз Исхакый мирасының бер өлешен ватанына кайтаруда зур ярдәм итә: милләтпәрвәр әдипнең сирәк документларының, язмаларының, хатларының электрон күчермәләре ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Язма һәм музыкаль үзәгенә тапшырыла. Язучының мөһаҗирлек дәверен яктырткан әлеге материаллар арасында Г. Исхакыйның көндәлек дәфтәрләре дә гаять зур әһәмияткә ия. Җыентыкта укучы әлеге дәфтәрләрнең кайбер сәхифәләре белән, башлыча, мөһаҗирлек чорының башлангыч елларын чагылдырган өлешләре белән таныша ала.

Мәгълүм булганча, 1912 елда язучының «Фамилия сәгадәте» исемле хикәяләр китабы нәшер ителә. Анда аның «Башкорт бәхете» исемле хикәясе дә кертелә. Бу әсәр 1914 елда, Г. Акчурин тарафыннан русчага тәрҗемә ителеп, «Восточный сборник» (XIII чыгарылыш) китабында Мәскәүдә дә басылып чыга. Бу бүлектә әлеге әсәрнең тексты белән танышырга һәм аны тәрҗемә итүче Г. Акчуринның үзе хакында да тулырак мәгълүмат алырга мөмкин.

Икенче бүлектә Гаяз Исхакый турында замандашлары, аны күргән-белгән кешеләр тарафыннан язылган истәлекләр туплап бирелде. 1979 елда язучының кызы Сәгадәт Чагатай, аның ире Таһир Чагатай тырышлыгы белән «Ayaz Ishaki.

Haүati ve faaliүeti» (100 dogum үili dolaisiүla») («Гаяз Исхакый. Тормышы һәм эшчәнлеге. Тууына 100 ел уңае белән») исемле китап әзерләнә һәм ул Әнкараның «Ayyildiz Matbaasi» ширкәтендә басылып чыга. Әлеге китапның төп өлешен Гаяз Исхакыйны язучы, журналист-публицист һәм иҗтимагый эшлекле буларак югары бәяләгән мәкаләләр алып торса, аны якыннан белгән кешеләрнең җылы хатирәләре дә китерелә. Әдип турында үз сүзен әйтергә омтылганнар арасында Төркиягә килеп төпләнгән татар зыялылары, галимнәре (Али Акыш, Әмрулла Аги, Фатыйма Бугра, Әхмәт Таһир, Абдулла Баттал-Таймас, С.Чагатайлар) генә түгел, язмышларын башка илләр белән дә бәйләгән шәхесләр, башка милләт вәкилләре (Т.Дәүләтшин, Б.Мусабай, Густав Бурбиель, Мәдинә Салиәхмәт, М.Ә. Рәсүлзадә, Сәед Шамил һ.б.) дә бар. Мәкалә һәм язмаларның һәрберсе диярлек укучыны бу шәхеснең тормышына һәм иҗади, сәяси-иҗтимагый эшчәнлегенә кагылышлы кызыклы фикер, фактик мәгълүматлар белән таныштыра. Биредә әлеге китаптан шуларның берничәсе Институт фәнни хезмәткәрләре Б.К. Миңнуллин, Р.Ф.Мирхәев, Г.С. Хаҗиева-Демирбаш тарафыннан төрекчәдән татарчага тәрҗемә ителеп бирелә.

«Әдәбият мәйданында хәзер иң шәүкәтле вә иң бөек урында карт реалист Гаяз әфәнде тора» дип яза Галимҗан Ибраһимов, «Кем ул бу милләтне күтәргән кеше?» дип, аңа шигъри мактауларын багышлый бөек шагыйребез Габдулла Тукай. «Гаяз үзенең әдиплегендә, … бөтен мәгънәви хәятында сүнә белми торган бер ялкыннан… гыйбарәт бер мөхәррир…» дип олылый Фатих Әмирхан милләтебезнең бөек шәхесен. Чынлыкта да, әдәби-гыйльми җәмәгатьчелек Гаяз Исхакыйга үз вакытында ук гадел, дөрес бәя бирә. Шуның белән бергә туры сүзле, үткен фикерле, халык алгарышы өчен үзен кызганмый көч куйган, замандашлары, каләмдәшләре арасында төрле бәхәс тә уяткан, хәтта ки каршылыкка да кергән язучының иҗатын төрле яклап чагылдырган, фикерләрен хуплап яки, киресенчә, кискен каршы чыккан мәкаләләр күпләп

язылa. Г. Ибраһимов, И. Акчурин, Ш. Әхмәдиев, Н. Думави һ.б.ның бәяләмә-рецензияләре белән китапның өченче бүлегендә танышырга мөмкин.

Җыентыкның дүртенче бүлегендә Гаяз Исхакыйга юлланган хатлар урын алды. Аларның кайберләре үз заманында матбугат битләрендә дә дөнья күргән. Бу хатлар, башлыча, «Әлгасрелҗәдид», «Милли юл», «Яңа милли юл» журналларыннан алынды, калганнары Татарстан Республикасы Дәүләт архивыннан, Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Язма һәм музыкаль мирас үзәгенең Гаяз Исхакый фондыннан әле беренче мәртәбә тәкъдим ителә. Җир йөзенең төрле кыйтгаларыннан килгән әлеге хатлар кыйммәтле чыганак булып, әдипнең тәрҗемәи хәленә яңа фактлар өстиләр, шәхсиятен ачалар, шул чор атмосферасын тулырак күзалларга ярдәм итәләр. Хатларда, Гаяз Исхакыйга, аның иҗатына җылы мөнәсәбәт чагылу белән бергә, халыкны, милләтне борчыган проблемалар, зур мәсьәләләр күтәрелә. Аларның күбесе бүгенге көндә дә актуаль яңгырый.

Җыентыкта урын алган текстлар, аңлатмалар Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге, текстология бүлеге фәнни хезмәткәрләре И.Г. Гомәров, Л.Ш. Гарипова, Г.М. Ханнанова, З.З. Рәмиев, З.Г. Мөхәммәтшин, Ф.Г. Фәйзуллина, Э.М. Галимҗанова, Г.А. Хөснетдинова, Г.Н. Зәйниева, Казан федераль университеты фәнни китапханәсенең Сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлеге хезмәткәре Р.Г. Шәрәфиева, Казан дәүләт мәдәният институты профессоры Н.И. Таиров, Окан университеты (Төркия) доценты И.Р. Рәмиева тарафыннан гамәлдәге язуга күчерелде һәм фәнни шәрехләнде.

*Ләйлә Гарипова*

## *Кем ул?*

*Кем ул бу милләтне күтәргән кеше?*

*Кем ул аңа тел биреп, тавышын яңгыраткан кеше?*

*Безгә хайван түгеллегебезне күрсәткән кем?*

*Вәхшәтне төбеннән бозган кем?*

*Дошманнарыбызга кемлегебезне күрсәткән кем?*

*Бу моңлы милләтне шатландырган кем?*

*Караңгыда идек, «Таң»ны аттырган кем?*

*Безне бер көлдереп, бер елаткан кем?*

*Узган көннәребезне уйлаткан кем?*

*Һәм «Инкыйраз»ны исебезгә төшергән кем?*

*Тирә –яктагыларның игътибарын җәлеп иткән кем?*

*«Татар» ләфзын «тотар»га әйләндергән кем?*

*Безнең өчен бөтен зәхмәтне үзенә алган кем?*

*Соңыннан рәхмәтен уртак иткән кем?*

*Г. Тукай*

## ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ИҖАТ МИРАСЫННАН: КӨНДӘЛЕК ДӘФТӘРЛӘРЕ, ӘСӘРЛӘРЕ, ЧЫГЫШЛАРЫ

*Татар халкының күренекле улы, талантлы прозаик, драматург, җәмәгать эшлеклесе Г. Исхакый мирасы ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгенә археографик экспедицияләр нәтиҗәсендә, шулай ук аерым кешеләрнең ярдәме белән туплана башлый. Алар нигезендә 1990 нчы елларда язучының шәхси фондын оештыру да мөмкин була һәм шул елны Әдибә Сабирова тарафыннан аның беренче тасвирламасы да төзелә (135 нче фонд). Соңрак, Г. Исхакый мирасының халкына кайтарылуы, гомумән, язучының тормышын, иҗатын яктырткан материаллар күпләп басыла башлагач, аларның күчермәләре дә үзәккә туплана бара. Шулай ук 1995 елда галимә Лена Гайнанова әдипнең мөһаҗирлектәге тормышына кагылышлы кыйммәтле документлар күчермәсен бүләк итә. Алар да фондны баетып җибәрә. 2008 елда, язучының юбилее уңаеннан, Төркиянең «Аяз Таһир Төркестан Идел-Урал» фонды җитәкчесе Түләй Дуран Г. Исхакыйның зур мирасының бер өлешен ватанына кайтаруда зур ярдәм итә: олуг ватандашыбызның сирәк документлары, язмалары, кайбер мәкаләләренең, хатларының электрон күчермәләре Институт Мирасханәсенә тапшырыла. Язучының мөһаҗирлек дәверен яктырткан әлеге материаллар арасында Г. Исхакыйның көндәлек дәфтәрләре гаять зур әһәмияткә ия.*

*Көндәлекләр 1919 елның апрель аеннан башланып, 1953 елның 10 нчы ноябренә кадәрге вакыйгаларны, ягъни Г. Исхакыйның мөһаҗирлектәге хәятен үз эченә ала. Алар гарәп язуында гади укучы дәфтәренә язылганнар, күләмнәре ягыннан төрлечә. 1919 елдан 1921 елга кадәр алып барылган көндәлекләр үзләре 22 дәфтәрдән гыйбарәт булып, һәр көн булып үткән вакыйгаларга җентекле анализ ясалып барыла. Ләкин шуннан соң көндәлек алып бару эше тукталып кала һәм 1930 елларда гына дәвам ителә. Әлеге еллардагы хатирәләр бер дәфтәргә тупланган. Аннан тагын, ягъни 1932 елдан 1942 елга кадәр вакыт аралыгында тынлык, өзеклек. Яңадан көндәлек алып бару соңрак, бары 1943 елда Төркиядә яңартыла. «Истанбулдагы хатирә дәфтәрләрем» дип аталган әлеге истәлекләр үзләре 19 дәфтәрдән гыйбарәт, бу – 1943 елның 13 августыннан 1953 елның ноябренә кадәр вакыт арасы. Биредә шул көндәлекләрнең берничәсе гамәлдәге язуга күчерелеп тәкъдим ителә.*

*Г. Исхакый үз әсәрләренең башка телләрдә дөнья күрүе хакында да кызыксына. Бу аның М. Горький белән язышкан хатларында ук ачык күренә. Иң беренчеләрдән булып, «Современник» журналының 1913 елгы 4 санында «Шакирд аби» («Шәкерт абый» – «Дядя-шакирд) басылып чыга, берничә елга сузылган сөйләшүләрдән соң Санкт-Петербургта 1912 елда чыга башлаган «Заветы» журналында «Брачный договор» («Алдым-бирдем») әсәре Г. Свердлов тәрҗемәсендә дөнья күрә. Мәскәүдә «Мулла бабай әсәренең бер өлеше брошюра рәвешендә (В. Гордлевский тәрҗемәсе) 1914 елда нәшер ителә. Шушы ук елны Мәскәүдә язучының тагын бер әсәре «Башкорт бәхете» дә, Г.Акчурин тарафыннан тәрҗемә ителеп, басылып чыга (Түбәндә әсәрнең тексты китерелә). Язмалар оригинал орфографиясен һәм пунктуациясен саклап басылалар.*

## Мәшһүр әдибебез вә бөек юлбашчыбыз Гаяз әфәнде Исхакый җәнабләренең кыскача тәрҗемәи хәле вә иҗаты

*(әдиплегенә 40 ел тулу уңае белән, 1897–1937)*

*Ерак Шәрык Идел-Урал төрк-татар мөселманнарының дини-милли мәркәзе мәгариф шөгъбәсе нәшрияты*
*Мукден*

Саф ана телебездә язылган хикәя, роман вә театр әсәрләре белән милли әдәбиятыбызны баеткан, мәшһүр язучыбыз Гаяз Исхакый, Яуширмә (Казан губернасы, Чистай өязе) авылының имамы Гыйлаҗеддин хәзрәтнең углы булып, 1878 елны 10 февральдә (яңа хисап белән 23 февраль) дөньяга килә. Беренче тәхсыйлен[1] Яуширмәдә алып, бераз зуррак булгач, Чистай мәдрәсәсендә укый, аннан соң Казанда Гәлам хәзрәт мәдрәсәсендә укуын дәвам итә. Мәдрәсәне тәмам иткәч, «Татарская учительская школа»да укый. Мөгаллимлек итә. Кирәкле имтихан вә рәсмиятләрдән соң имамлык вазифасын үтәр өчен указ ала. Вә соңрак елларда Петербург университетының хокук шөгъбәсендә[2] лекцияләр тыңлый.

1897 нче елда үзенең беренче әсәре – «Тәгаллемдә сәгадәт» исемле хикәясен яза. Шул елдан игътибарән[3] бөек әдибнең язучылыктагы беренче адымы башлана. Русия ихтиляленә[4] кадәр түбәндә исемнәре бирелгән әдәби әсәрләре матбугат дөньясына чыга:

1. «Тәгаллемдә сәгадәт». Хикәя 1897 нче елда язылган, 1899 нчы елда Казанда басылган.
2. «Кәләпүшче кыз». 1898 нче елда язылган, 1900 нче елда Казанда басылган.
3. «Бай углы». Роман. 1899 нчы елда язылган, 1903 нче елда Казанда басылган.

---

[1] Тәхсыйль – уку, гыйлем алу.
[2] Шөгъбә – бүлек.
[3] Игътибарән – башлап.
[4] Ихтилял – революция.

4. «Өч хатын белән тормыш». Драма. 1900 нче елда язылган, 1900 нче елда Казанда басылган.
5. «Ике гыйшык». Биш пәрдәлек комедия. 1900 нче елда язылган, 1903 нче елда Казанда басылган.
6. «Теләнче кыз». Роман. 1901 дә языла башлап 1908 дә тәмам була. Өч бүлектән гыйбарәт. Өченче бүлеге 1914 тә басылган.
7. «Очрашу». Хикәя. 1902 нче елда язылган, 1911 нче елда Казанда басылган.
8. «Ике йөз елдан соң инкыйраз». Хыялый хикәя. 1902–1903 нче елда язылган, 1904 нче елда Казанда басылган.
9. «Җыентык». Хикәяләр. 1905 нче елда язылган. Ничәнче елда басылганы мәгълүм түгел.
10. «Мөгаллим». Драма. 1906 нчы елда язылган.
11. «Зиндан». Хикәя. Чистай төрмәсендә 1906 нчы елда язылган.
12. «Алдым-бирдем». Драма. Казан төрмәсендә 1907 нче елда язылган.
13. «Тартышу». Дүрт пәрдәлек драма. Сөргендә 1908 нче елда язылган, 1911 нче елда басылган.
14. «Кыямәт». Өч пәрдәлек комедия. Петербургта 1909 нчы елда язылган. Ничәнче елда басылганы мәгълүм түгел.
15. «Җәмгыять». Комедия 3 пәрдәдә. Петербургта 1909 нчы елда язылган. Ничәнче елда басылганы мәгълүм түгел.
16. «Тормышмы бу?». Хикәя. Истанбулда 1909 нчы елда язылган.
17. «Мулла бабай». Роман. Финляндиядә 1910 нчы елда язылган. Дүрт бүлектән гыйбарәт. 1912 нче елда басылган.
18. «Фамилия сәгадәте». Хикәяләр. 1911 нче елда язылган. Кайчан басылганы мәгълүм түгел.
19. «Сөннәтче бабай». Хикәя. Истанбулда 1911 нче елда язылган. Кайчан басылганы мәгълүм түгел.
20. «Шәкерт абый». Хикәя. Истанбулда 1911 нче елда язылган. Кайчан басылганы мәгълүм түгел.
21. «Зөләйха». Драма. Биш пәрдәдә. Истанбулда 1911 нче елда язылган. 1917 нче елда Казанда басылган.

22. «Бер тоткарның саташуы». Хыялый роман. Сөргендә 1912 нче елда язылган, 1914 нче елда басылган.
23. «Солдат». Хикәя. Сөргендә 1912 нче елда язылган, 1916 нчы елда басылган.
24. «Кияү». Хикәя. Сөргендә 1912 нче елда язылган. Кая басылганы мәгълүм түгел.
25. «Мөгаллимә». Драма, өч пәрдәдә. Финляндиядә 1913 нче елда язылган. Петербургта 1914 нче елда басылган.
26. «Остазбикә». Хикәя. Мәскәүдә 1914 нче елда язылган. Кайчан басылганы мәгълүм түгел (1915).
27. «Ул икеләнә иде». Хикәя. Мәскәүдә 1915 нче елда язылган, 1916 нчы елда басылган.
28. «Ул әле өйләнмәгән иде». Хикәя. Мәскәүдә 1915 нче елда язылган, 1916 нчы елда басылган.
29. «Юлсызлар». Драма. Кызылъярда 1917 нче елда язылган. Басылмаган.

**Мөһаҗирәткә чыккач язылган вә бүгенгә кадәр басылмаган әсәрләре**

30. «Дулкыннар эчендә». Драма, биш пәрдәдә. Парижда 1920 нче елда язылган. (1934 нче елда Кобеда, Харбинда куелды).
31. «Ике ут арасында». Драма, 4 пәрдәдә. Берлинда 1921 нче елда язылган. (Беренче Ерак Шәрык корылтае вакытында Мукденда куелды).
32. «Өйгә таба. Хикәя. Берлинда 1922 нче елда язылган.
33. «Өйгә таба, яки Миралай Миргали». Берлинда 1923 нче елда язылган.
34. «Көз». Хикәя. Берлинда 1923 нче елда язылган.
35. «Локман Хәким». Хикәя. Берлинда 1923 нче елда язылган.
36. «Олуг бәйрәм». Хикәя. Берлинда 1923 нче елда язылган.
37. «Җан Баевич». Комедия. 4 пәрдәдә. Берлинда 1923 нче елда язылган. 1934 нче елда Харбинда, Хайларда куелды.
38. «Утыз еллыгым». Истанбулда, Варшауда 1927–1928 нче ел-

ларда язылган.

Гаяз Исхакый әдәби әсәрләре белән милли әдәбиятыбызда яңа бер җәрәян[1] ача. Ул садә һәм җиңел телдә яза. Аның өслүбе үзенә махсус бер өслүб.

Гаяз Исхакый үзенә махсус бер өслүб белән җиңел һәм садә телдә язганга, милли әдәбиятыбызда яңа бер җәрәян ача. Ул коры сәнгатькяр язучы гына түгел. Аның әсәрләре – әхлакый, иҗтимагый әсәрләр. Ул үзенең әсәрләре белән милли иҗтимагый тормышыбызны төзәтергә, житешмәгән җирләрен күрсәтергә тырыша. Бу көнгә кадәре матбугатка чыккан бөтен әсәрләре, башыннан алып иң соңгысына кадәр, халыкның сәгадәте[2], юлындагы фикер вә төшенчәләрне җанландыру белән аерылалар. Шуның өчен кызыл руслар көенә биергә мәҗбүр булган Татарстан «тәнкыйтьчеләре» Гаяз Исхакыйны буржуа язучысы, динче, милләтче дип сүгәләр. Гаяз Исхакый – беренче әсәре «Тәгаллемдә сәгадәт»тән үк башлап җәдидче, тәрәкъкыйчы, милләтчелек гаясының[3] каһарманы («Тәгаллемдә сәгадәт», «Кәләпүшче кыз», «Ике гашыйк», «Өч хатын белән тормыш», «Инкыйраз»). Төрк-татар милләтенең үзенә-үзе хуҗа булу, үсү, күтәрелү гаясының көзгесе («Теләнче кызы», «Солдат», «Зиндан», «Җыентык»).

Милли иҗтимагый хәятебезнең ямьсез якларын бетерү юлында көрәшүче («Тормышмы бу?», «Шәкерт абый», «Мәдрәсә җимешләре»), муллалар, шәкертләр, мәдрәсә вә авыл халкы тормышын җанлы рәвештә тасвир итүче («Мулла бабай», «Сөннәтче бабай», «Остазбикә»).

Гаяз Исхакыйның әдәби әсәрләре, өслүбенең яңалыгы вә фикерләренең җанлылыгы, халкыбызның уяну дәверенең иң дулкынлы вакытларында язылуы аркасында аның әсәрләре дөньяга чыгу белән бик күп сүзгә, тәнкыйтькә сәбәпче булалар. Күбесе бер ел эчендә өч-дүрт мәртәбә басыла вә күп таралалар. Театр әсәрләре мәшһүр «Сәйяр» труппасы тарафыннан Идел буе шәһәрләренең бик күбесендә кат-кат уйнала. Гаяз Исхакый көчле вә истигъдадлы[4] язучыларыбызның берсе булганлыктан, аның әдәби әсәрләренең

[1] Җәрәян – агым.
[2] Сәгадәт – бәхет.
[3] Гая – теләк, максат, омтылыш.
[4] Истигъдадлы – сәләтле.

бик күп парчалары дәреслек, кыйраәт[1] китапларына кертелә, сарыф-нәхү дәреслекләрендә аның әдәби әсәрләреннән әллә ни кадәре парчалар алынып, мисаллар бирелә.

Югарыда кыскача гына кагылып киткән әдәби әсәрләреннән башка, Гаяз Исхакый Идел буе төрк-татар милли матбугатында үзенең мөхәррирлек вә журналистлыгы белән бик зур роль уйный. Аның тәшәббесе[2] вә иҗтиһады[3] аркасында түбәндә исемнәре вә чыгу еллары күрсәтелгән гәзитәләр мәйданга килә. Ул боларның бик күбесендә баш мөхәррирлек итә, сәяси вәзгыять имкян[4] бирмәгән вакытларда ачыктан-ачык мөхәррир була алмаса да, гәзитәдә язышa, гәзитәнең барышы вә рухы өчен мәсъүл[5] язучы булып килә вә шул ук вакытта милли хәрәкәтебездә бик зур урын тоткан вә вакытында зур шау-шуга һәм рус хөкүмәтенең дошманлыгын кабартуга сәбәпче булгач «Таңчы» яшерен сәяси оешмасының җитәкчесе була. Бу хәрәкәт русларның эчен пошырганга, Гаяз әфәнде кулга алына вә Архангелга сөргенгә җибәрелә. 1908 елның җәендә сөргеннән качып кайтып, Петербург, Финляндия вә Төркиядә тора. Петербургта яңадан кулга алынып, иске җәзаны тутыру өчен яңадан Архангелга озатыла вә аннан 1913 нче елның 4 нче апрелендә кире кайтарыла. Рус хөкүмәте төрк-татарларның рус истилясенә[6] каршы күтәрелүләрендә Гаяз Исхакыйның тоткан урынын күреп торганлыктан, сөргеннән кайткач аңа Казанда торырга рөхсәт ителми.

1913 нче елдан башлап Гаяз әфәнде әле Петербургта, әле Мәскәүдә торып гәзитәчелек, әдиплек хезмәтендә дәвам итә.

## Гаяз Исхакыйның баш мөхәррирлек иткән вә якыннан торып язышкан гәзитәләр:

1. «Таң йолдызы» гәзитәсе. 17 нче майда 1906 нчы елда чыга башлый, сентябрьдә хөкүмәт тарафыннан ябыла.

---

[1] Кыйраәт – уку.
[2] Тәшәббес – инициатива.
[3] Иҗтиһад – тырышлык.
[4] Имкян – мөмкинлекләр.
[5] Мәсъүл – җаваплы.
[6] Истиля – басып алу.

2. «Таң мәҗмугасы». Атналык. 1906 нчы елның ноябрендә Казанда чыга башлый.
3. «Тавыш» гәзитәсе. 23 нче апрельдә 1907 нче елда Казанда чыга башлый. Августта ябыла.
4. «Ил» гәзитәсе. 22 нче октябрьдә, 1913 елда Петербургта чыга башлый. 27 нче мартта 1915 нче елда ябыла.
5. «Сүз» гәзитәсе. 13 нче декабрьдә 1915 елда Мәскәүдә чыга башлый. Сентябрьдә 1915 елда ябыла.
6. «Ил сүзе» гәзитәсе. 10 нчы ноябрьда 1916 нчы елда Мәскәүдә чыга башлый.
7. «Ил» гәзитәсе. 23 нче мартта 1917 нче елда Мәскәүдә чыга башлый. 11 нче апрельдә 1918 нче елда большевиклар тарафыннан ябыла.

## Мөһаҗирлектә:

1. «Маяк» гәзитәсе. 7 нче декабрьдә 1918 нче елда Кызылъярда чыга башлый.
2. «Төрек йорды мәҗмугасы». Әнкарада (1925 нче ел).
3. «Милли юл» мәҗмугасы. 23 нче декабрьдә 1928 нче елда Берлинда чыга башлый вә бүгенгә кадәре дәвам итә.
4. «Милли байрак» гәзитәсе. 1 нче ноябрьдә 1935 нче елда Мукденда чыга башлый вә бүгенгә кадәрле дәвам итә.

Гаяз әфәнде Исхакый әдиплек вә журналистлык хезмәтләреннән башка халкыбызның үз милли байрагы янында тупланып, югалткан истикъялялен[1] кире кайтару юлында да бик күп хезмәт итә. Русия ихтиляленнән[2] соң Мәскәүдә 1917 нче елның маенда тупланган Бөтенрусия мөселманнарының корылтаенда иштирәк[3] итә вә корылтай тарафыннан Милли идарәгә әгъза уларак сайлана. Вә Милли идарә тарафыннан Версаль солых конгрессына күндереләчәк һәйәткә[4] әгъза итеп тәгаен ителә. Русия хөкүмәт идарәсе большевиклар кулына төшкәч, илебезне большевик баскынынnan

[1] Истикъялял – мөстәкыйльлек.
[2] Ихтилял – революция.
[3] Иштирәк – катнашу.
[4] Һәйәт – комиссия.

саклауда аруны-талуны вә каршына куелган киртәләрне белми хәрәкәт итә. Большевиклар «Ил» гәзитәсен ябып, матбагасын талап, аның баш мөхәррире Гаяз әфәндене хөкемгә бирәләр. Гаяз әфәнде большевик хөкемен көтмичә, Милли Идарә белән бергә Кызылъярга китә. Анда «Маяк» гәзитәсен чыгара башлый. Большевик дулкыны Кызылъярга да килеп җиткәнгә, шуннан 1919 нчы елда Аурупага Версаль солых конгрессына, Япония аркылы Аурупага юнәлә. Аурупада да милли хәрәкәт юлында дәвам итеп, Берлин шәһәрендә «Туран» җәмгыятен мәйданга китерә. 1925 нче елда Әнкарадан «Төрек йорды» мәҗмугасының баш мөхәррире вазифасын үтәргә чакырылып, Төркиягә бара. Вә Төркиядә вакытында башка төрек гәзитәләрендә дә язышa. Яңадан Аурупага барып «Идел-Урал истикълял комитеты»н мәйданга китерә. Вә бу хәрәкәтнең нашире әфкяре[1] булган «Милли юл» мәҗмугасын 1928 нче елда чыгара башлый. «Идел-Урал истикълял комитеты» тарафыннан «Прометей клубы» башкармасының әгъзасы уларак тәгаен ителә. 1931 нче елда Коддестә тупланган Диния Ислам конгрессына Идел-Урал төрк–татар мөселманнары исеменнән иштирәк итеп, илебездә большевикларның динебезне кысуларына каршы протест итә.




Г. Исхакый кызы Сәгадәт белән. Истанбул. 1926 ел

1933 нче елда Ерак Шәрыктагы таркау мөһаҗирәтебезне бер кыйблага карату нияте белән, Ерак Шәрыкка килә. Ерак Шәрык ил хуҗаларына дини, милли үзлегебезне саклау вә хәрәкәтебезнең асыл максатын аңлатканнан соң, 1934 нче елның маенда Ниппон императорлыгы күләмендә Идел-Урал төрек-татарларының корылтаен туплый вә 1935 нче елның февралендә Бөтен Ерак Шәрык корылтаен җыеп, Ерак Шәрык дини-милли мәркәзен мәйданга китерә вә бу ике корылтай тарафыннан

[1] Нашире әфкяре – фикерләр таратучысы.

сайланган мәркәзгә гомерлек рәис сыйфатында интихаб[1] ителә. Ерак Шәрыктагы мөһаҗирлегебезне милли кыйблабызга каратып, милли матбугат белән («Милли байрак») тәэмин иткәннең соңында, 1936 нчы елның 1 нче мартында Аурупадагы эшләре янына юнәлә.

Милләтебезнең иң мәшһүр язучысы, журналисты вә милли истикълял хәрәкәте юлбашчысы Гаяз әфәнде Исхакый җәнаплары әдиплегенең 40 еллык юбилее, туган көнен бердәнбер кызы доктор Сәгадәт ханым вә кияве доктор Таһир Шакир бәк, Алманиядәге кардәшләре без һәм милли истикъял дәгьва җәбһәдәшләребез[2] янында Берлин шәһәрендә каршы аладыр.

*Ерак Шәрык Идел-Урал төрк-татар мөселманнарының*
*дини-милли мәркәзе мәгариф шөгъбәсе.*
*Мукден*

---

[1] Интихаб – сайлау.
[2] Җәбһәдәш – фронтташ.

# ӘДИП КӨНДӘЛЕКЛӘРЕ

## 2 нче дәфтәр
## 1919 ел (26 апрель – 6 май)

Бүген иртәдән үк, 26 сында апрель 1919, музейлар карарга сәнаигълыг выставкасы карарга китәмез. Иң әүвәл японларның музыка мәктәбләренә керәмез. Бакча уртасында агачдан бина иделгән зур-зур өйләр һәммәсе дә бик биек, һәммәсе дә бик якын. Эчләре бик тәмиз[1], пакь, һавасы күп. Аерым-аерым бүлмәләрдә берәү-икәү япон кызлары пианинода, скрипкада уйнап яталар, сыйныфларның кайберсендә көйләргә өйрәнәләр, кайберсендә музыка, нота хакында дәрес алалар. Укучыларның аның иң күбесе – кызлар. Монда без, беренче мәртәбә уларак, кершән ягынмаган кызлар күрәмез. Беренче мәртәбә, имчәкне үсдермәс өчен, күкрәкне бик каты юып, арка ягыны бик ямьсез итдереб, горбун чыгарыб куя йөриләр. Кушаксыз кызларга очраб, беренче мәртәбә аякларына агач башмак кимәгән япон кызларын күрәмез. Төсләре дә, буйлары да, моңынчы күрмәгәнгә, башка. Матур булмасалар да, җирәнгечләр түгел. Гади генә... Безнең алда да мәктәб шәкердләре, күбе кызлар, аз кыйсме егетләр зур бер залда бергәләшеб йырлыйлар. Нимес бик оста итдереб, тамак берлә йырлый торган япон балаларын Яурупа ысулынча йырларга өйрәткән. Зур гына сәхнәнең өстенә тезелеб утыралар. Кызлар бер-ике тарафда, егетләр карачыга каршы якда бергә йырларга тотыналар. Араларында бик матур кыз тавышлары, бик көчле ир тавышлары бар. Һәммәсе нимес мөгаллименең күзенә осторожно генә караб утыралар. Бер көйне йырлыйлар, икенче көйне йырлыйлар, бик матур хиссият уяталар. Без мәктәбнең төрле тарафларыны караб, рәхмәт әйтеб чыгыб китәмез. Мәктәбдә укучылар һәммәсе японлар булса да, мөгаллимләрнең күбесе нимесләр икән. Һәм дә тәгаллем[2] лисаны нимесчә икән. Андан туб-тугры сәнаигъ выставкасына китәмез. Зур залда

[1] Тәмиз - чиста.
[2] Тәгаллем- өйрәнү, белем алу.

дүрт-биш йөз таблолар тагылган. Иң күбесе табигать манзаралары, икенче рәсемдә кошлар сыйганлар. Өченче рәсемдә адәм рәсемләре, гомумән караганда, бөтен рәсемләрдә әллә нинди буяу җитми. Рәсемләр бер караганда бер йире тулмаган кебек хис итeлә. Эшләп йитмәгән хәятене калдыра. Әллә нәрсәсе тонык, әллә нәрсәсе җитмәгән, әллә нәрсәсе ким. Үзе тулы түгел. Япониянең чәчәге, чәчәкнең иң зур бер хасияте булган исдән мәхрүм булган кебек, мондагы рәсемләр дә рухдан, җанлардан мәхрүмләр. Гомумән, адәм сурәтләренең һич бер җаны юк. Бите тонык, күзе боегъ, ирене үлгән. Табигать манзаралары матурлар, тулыраклар, ләкин аларда да буяулар бер төслерәк, аларда да әллә нинди җитлекмәү бар, алардан җанлылыг, йылы исеп тормый. Иң оста эшләнгән рәсемләрен без кошлар рәсеме вә, гомумән, хайванлар рәсемен боларны япон рәссамләре фәүкылгадә[1] бер мәхәббәт берлән эшләгәнләр, бик нечкә итдереб аңлаб, аларны җанландырыб ут тотканлар. Йөри-йөри берничә бүлмәләрне үтеб киткәндә бер картның рәсемен күрәмез. Бу җанлы ук булмаса да, хәрәкәтле. Йөзләре, озын кашлары, сирәк сакаллары бик күб нәрсә сөйли. Йөри-йөри тагын моңардан да остарак эшләнгән бер картның рәсеменә очрыймыз. Монысы, хакыйкатән, Яурупа мәгънәсендә рәсем. Бабайның бөтен әхвале рухиясе кәгазьгә килгән дә алга баскан. Выставканың бер кыйсмен бетереп, икенчесенә керәмез. Анда тагы берничә җанлы рухлы сөйли торган кеше рәсемләренә очрыймыз. Гомумән караганда, япон рәссамләре үзләренә бер юл кулланалар икән. Рәссамлыкда иң авыр булган осталык, адәм баласының бөтен әхвале рухиясен бирә торган йөз, күзне тасвир итү әле мөяссәр булмаган[2] икән. Әле япон рәссамы бөтен кайгыны, бөтен шатлыкны, бөтен тәэсиратны бергә җыеп йөзгә бирер дәрәҗәгә кадәр үсмәгән икән. Андан соң без тарихи музаханәгә китәмез. Андый тарихи музаханәләрне мин бик күп күргәнем бар. Мондагы нәрсәләр әһел өчен бик кадерле, тарих голямәсе өчен бик кыйммәтле. Безнең кебек сәясәтчеләр өчен музейлардән булган бер музей. Барлыгы – аяклы дәлилләр. Ләкин аерым-аерым искитәрлек нәрсәләрне без күрми-

[1] Фәүкылгадә – гадәттән тыш.
[2] Мөяссәр булмаган – мөмкин булмаган.

мез. Сүз арасында гына әйтеп китим: иске япон савыт-сабалары арасында бик матур комганлар бар. Болар нәрсә дип сорагач, су савыты дип җавап бирәләр. Музаханәнең искиткеч бер йире булса, ул да бинасының пөхтәлеге, яктылыгы. Көтебханәгә керәмез. Көтебханә бик зур түгел. Петербург көтебханәсенә караганда күп кечкенә, ләкин алай да бара. [...] биш йөз меңләп җилд китап бар икән. Иске кытайча, кореяча китаплар да бик күп икән. Иске төрк китаплары юк, гарәп-фарсы әсәрләре юк дип белешәмез, фәкать бер данә «Мөгаллим-сәни» дигән китапка гына очрыймыз. Монда әле тюркология фәне бер дә куелмаган булырга кирәк. Үзләренең әйтүенә караганда, китабларының илле мең җилде генә әҗнәби Яурупа телендә булса да, күзгә күренүгә караганда, бик күбесе, инглизчә булырга охшый. Йөри-йөри арып беткәч, бер бакчага кереб, бераз тамак ялгаб чыгамыз да, тагы китәмез. Хайванат музәханәсе бар икән, шуны эзләп табамыз. Гади хайванат музәханәсе, ләкин, ни өчендер, төя берлә маймыл бик күп. Шуңарга башка искитәрлек нәрсә юк. Япониянең ярты хәяты балык берлә низагга үтсә дә, ни өчендер аквариумлары бик зәгыйфь. Сәгать тукызда киткән кешеләр фәүкыльгадә[1] арып, биш ярымда гына номерга кайтамыз. Башлар япон музыкасының көйләре, япон рәссамларының таблолары, тарихи мең төрле нәрсәләр, әллә ничә төрле телдә китаплар, дөньяның бөтен кыйсемендәге хайваннарның сурәтләре тулып беткәнгә, бик зур ару итәмез. Көн никадәр иртә булса, яңадан чыгарлык көч хис итә алмыймыз. Бу көнне шуның берлән тәмамлыймыз.

### 24 сендә

Бүген якшәмбе көн урамларда халык бик аз. Магазинларның күбесе ябык. Урамлар рәтләп әчелмәгән. Японлар бәйрәм итәләр. Якшәмбе көнне бәйрәм итәләр. Без Русиянең эчендә, христиан галәменең уртасында, үземезнең бәйрәмемезне саклар өчен, христиан бәйрәмен олугъламас өчен, озын еллардан бирле Русия хөкүмәте, Русия халкы берлән талашып, кычкырышып киләмез.

[1] Фәүкыльгадә – гадәттән тыш.

Японлар мөстәкыйль дәүләтле күбесе японлар үзләрендән-үзләре христиан бәйрәме якшәмбе көнне бәйрәм итәләр. Дәүләт мөәссәсәләре[1] ябык, мәктәпләр укымый, завод-фабрикалар эшләми. Христанлык тәэсире никадәр зур. Буш көндән истифадә итәр өчен бәхрия нәзарәте[2] янындагы музәханәгә китәмез. Зур сарай кебек мөкаммәл бинаның өч каты рус-япон сугышында алынган ганимәт маллары берлә тулган. Сугыш көймәсеме дисең, коралмы дисең? Диварларда диңгез сугышларының рәсемләре. Менә Русиянең шәрыкка таба атлавына беренче зарбә[3] булган Сутим сугышының[4] манзаралары. Менә аның башы, менә аның иң каты вакыты, менә япон флотының галибәсе[5]. Шыгрым тулган япон балалары көлә-көлә йөриләр. Көлә-көлә берсе-берсе берлә хиссиятләрен бүлешәләр. Диварлар сугышта батырлык күрсәткән офицер-солдатларның рәсемләре белән туп-тулы. Шкафлар руслардан алынган көймәләрнең сыныклары берлән шыгрым тулы. Музәханәнең йортына да иске туплар тезелгән. Барысы да Русиядән алынган. Барысы да Русиянең 904 нче елгы ахмаклыгының аяклы дәлилләре.

Озын итдереп карап бетергәч, вакытымыз барлыгыны белеп, мазарстандагы музәханәгә китәмез. Монда яңгы нәрсә күб юк, хәзер дә күрелә торган нәрсәләр. Сәфәрнең төрле кораллары – җәяүледән башлап автомобильләргә кадәр, начар киемдән башлап бу көнге көнге дәвереңлегенә мең кеше сыйдыра торган парахудка кадәр – һәммәсенең моделе бар. Монда да пакьлек, пөхтәлек, тәмизлек.

### 28 ендә

Бүген без иртәдән үк мәктәпләргә башлыймыз. Безне, беренче уларак, ибтидаи, игъдади, гали дәрәҗәләргә бүленгән хосусый

---

[1] Мөәссәсәләре – оешмалары.
[2] Бәхрия нәзарәте – морское министерство.
[3] Зарбә – сугу.
[4] Цусима сугышының.
[5] Галибәсе – өстенлеге, җиңүе.

бер мәктәпкә җибәрәләр. Мәктәб Токиянең читендәрәк, зур бер бакча эчендә, биналар аерым-аерым салынган. Күп өйләр аерым-аерым торалар. Мәктәп биналарының күбесе агачдан. Һәммәсе дә дә бик киң, зур итдереп эшләтелгән. Сыйныфлар зур, биек, якты. Тәрәзәләр киң һәм зур. Сыйныфлар, мәктәп эче бик пакь, тәмиз. Без барганда тәнәфес вакыты. Йортта беренче сыйныф балалары уйнап йөриләр. Хәлфәләре яннарында. Икегә бүленгәннәр дә икесенә дә ике бик зур туплар биргәннәр, бер гөруһысының тубы кызыл, бер гөруһының ак, малайларның да башларына киң вә киемләре бер бүлекнеке ак, берсенеке кызыл. Уен шундан гыйбарәт: мәйданның уртасында ике малай байраклар күтәреп торалар, ул байрак агач саблары берлә җиргә кадалганнар. Малайлар икешәрләб тубны (берәмләп тәгәрәтергә көчләре җитми) тәгәрәтеп, бер мәгълүм даирәне әйләндерәләр дә үз сафларындан икенче икегә йибәрәләр, алда тагы үз кизүләрен үтәләр дә, өченчеләргә бирәләр. Шул вакытта туп ычкынып китә, малайлар куып җитә алмый яисә, тотам дип сузылгач, егыла. Шуны дикъкать берлә җентекли торган кырыклап бала санадык, кайсы гөруһның балалары һәммәсе тубын элекрәк тәгәрәтеп китсәләр, шул бүлек узган була. Звонок була. Мәктәп эченә кергән сыйныф урындыклары һәр балага аерым эшләтелгән. Балалар һаман уен халендә: бере сөйли, бере көлә, берсе сикерә. Мөгаллимнәр тик торалар, һич тыймыйлар. Менә мөгаллим бүрекләрене салырга куша, һәммәсе бердән салып, парталарындагы тартмаларга куялар. Мөгаллим рәсемләр уласына игълан итә, бик зур тавыш берлән үзләренең шатлыкларыны изһар итәләр. Шундан соң зур кулда мөгаллимләре берлә бергә алынган рәсемләр өләшәләр. Беренче кергән елда балаларны мөгаллимләр берлә бергә рәсемгә төшерәләр икән, үзләренә бирәләр икән һәм дә, тәмам иткәч, шуны икешәрлиләр икән, шуның берлә мәктәпнең тәрбиясенең сәмәрәсене баланың күз алдына утыртып куялар. Бу сыйныф әле балалар бакчасыннан аз аерыла, уку бик аз, балалар бик яшь, җиде-сигездә, әле берсе дә китап укый белми. Икенче сыйныфга керәмез, анда кыйраэт бик авыр гына өстерәп

маташалар. Өченче сыйныфда һәм дә кыйраәт анда инде балалар тәмаман укый белә башлаганнар. Япун әлифбасы бик авыр булганга, тәмамән сәвадлы[1] булыр өчен өч йыл укырга мәҗбүрият бар икән. Өченчедән дүртенче сыйныфка керәмез. Анда бер малайлар укыганны хикәя итеб сөйләб тора. Балалар бик ихласы берлә тыңлыйлар, бәгъзе йерендә кычкырыб көләрләр, бәгъзе йерендә йөзләренә хәсрәт чыга, битләре-йөзләре дикъкатькә баткан. Бишенчедә хисап эшлиләр, ләкин цифрлары йапунча булганга, бер-бер нәрсә аңлый алмыйбыз. Япунлар гарәб цифрларын кабул итмәгәнләр икән. Алтынчы сыйныфда җәгърафия укыталар. Шуннан бирле ибтидаи мәктәб тәмам була. Балалар шул хосусый мәктәбкә яисә хөкүмәтнең игъдидасына керә алалар. Анда укулар биш йыл. Без берәм-берәм гимназияне караб чыгамыз. Укынулары шул рус гимназиясендәге фәнләр, фәкать инглиз теле артык. Аны бу мәктәбкә тәмам укырлык-сөйләрлек, әдәбиятындан файда итәрлек ясаб чыгаралар икән. Гимназиянең физика бүлмәсене, нәбатат, хайванат бүлмәсен аерым-аерым карыймыз, һәммәсе бик бай итдереб эшләнгән, һәммәсе бик пакь, тәмиз. Андан соң гали кыйсменә – университет ягына чыкамыз. Монда безне төркем-төркем студентлар каршы алалар. Һәммәсе үзенең хезмәтен тәкъдим итде. Элек безне көтебханә бүлмәсенә алыб керәләр, зур бер бина. Осуле мигъмарисы[2] бик матур: өч катлы манаралаб салынган, аның уку бүлмәсене, китаб саклана торган әйберләрне – һәммәсен карыймыз. Илле мең җилддән артык китаб бар икән. Шул бинаны бер йапун үзе салдырыб, мәктәбкә вакыф иткән икән. Манараның берсенә чыгамыз. Ни күземез берлә күрик: мәктәбне чолгаган зур бакчаның бер тарафында җәйрәб диңгез йата. Соңра, һаваланыб, төтенне җибәримме-юкмы дигән кебек, зур диңгез параходы кереб килә. Без бу манзараны озак тамаша кыламыз. Андан соң университетның дәресханәләрене карарга керәмез. Университет кыйсемендә хокук, тыйб, әдәбият һәм сәясәт һәм икътисад. Мәҗмуг студент дүрт мең чамасында икән. [...] ләрдән

[1] Сәвадлы – укый-яза белерлек.
[2] Осуле мигъмарисы – төзү-архитектура стиле.

ике йөзләб чинлы, унбишләб корeяле генә бар икән. Дәресханәләре бигүк [...] түгел. Болар инде шактый искергәнләр. Лаборатория, физика бүлмәсе, хайванат-нәбатат бүлмәләре бик тулы. Караб бетереб, мөгаллимләргә, студентларга рәхмәт укыб, китәргә чыгамыз. Университет мөдире безне көтеб тора диләр. Профессор каршына китәмез. Анда утызлаб профессор, күрешәмез, сөйләшәмез. Чәй тәкъдим итәләр. Сыйланыб, рәхмәтләр укыб чыгыб китәмез.Бу мәктәб мондан алтмыш йыл элек бер мөгаллимнең дәрде берлә хосусый өйдә генә башланган. Шундан бирле тәрәкъкый итә. Япониянең иң зур гыйлем йортына әйләнгән. Хәзер бөтен сыйныфларында җиде мең шәкерд бар. Дөнья кадәр биналары бар, үзенең гәзитәсе бар. Гали кыйсмендә генә алтмышлаб профессор бар. Укучылардан йылына гына утызар иен алыб укытса да, йылына өч йөз мең иен мәсарыф тота икән. Бу мәктәбкә караганда моның тәррәкъкый тарихын күздән кичергәндә, бик тирән уйларга китәсен. Ник безнең Шиһаб хәзрәтнең мәдрәсәсе бүгенге көндә шул гыйлем йорты дәрәҗәсен алмаган да, ник «Мөхәммәдия» шуның юлына басмаган, ник «Хөсәения» шул эзгә кереп китмәгән дә, агач башмаклы японнарның алтмыш ел элек башлаган ибтидаи мәктәбләре, җиде мең шәкердләре Яурупада урын тота торган гыйлем йортына әверелгән. Бу сөальләр тугрысында уйларга ярый... Безгә тагы бер бинаны күрсәтергә булсалар да, вакыт юк, шуңарга күрә өйгә кайтып китәмез. Безгә тагын япон осуле мигъмарисында бер бинаны күрсәтергә булсалар да, вакыт соңга күрә, өйгә кайтып китәмез. Кызлар мәктәбен дә күрәсемез килсә дә, алар да ябылганга, анысын да икенче көнгә калдырырга мәҗбүр буламыз.

**29 апрель**

Бүген көн иртәдән үк тулы башлана, иң әүвәл иртә торуга безгә япон газетасы кертәләр. Бу газетада безнең өемезнең дә рәсемләремезне төшергәндә тәрҗемә хәлемезне дә язган. Япончадан тәрҗемә итдереп карыймыз. Гади газета. Биргән

мәгълүматы милли ноктаи-назардан караганда файдалы. Икенче вакыйг – Йокоһамада (Токиодан утыз-кырык чакрымда Токионың порты) зур бер янгын булган. Өч мең дә ничә йөз өй янып беткән. Егерме мең халык урамга актарылган. Илле миллион иенлек мал-мөлкәт харап булган,ягъни Истанбул янгынларына охшаган бер нәрсә булган.

Өченче вакыйг. Безгә иртүк Токиода француз теле мөгаллиме булып бик озак хезмәт иткән бер мөселман көрд хатын берлә зиярәткә килдек. Хатын япон кызы булса да, ислам кабул иткән, гарәпчә шәп сөйли. Мисырда бер ел калган. Бик күңелле хатын. Гадәтләре берлән яурупалашкан – башында эшләпә, аякда ботинка. Аркасында горбун юк. Фазылбәк үзе фарсыча-гарәпчә оста сөйли, Мисырда да, Сүриядә дә гарәпчә укыган. Төрекчәсе бик зәгыйфь, французча бик яхшы белә, егерме ел Франсәдә калган, инглизчә дә сөйли. Япониядә 14 елдан бирле, япончa да сөйли. Ләкин ни өчендер үзенең мәгълүматындан халыкны истифадә итдерү юлын куя алмаган. Үзенчә гыйззәткә бирелгән. Тик тора. Хәзерге сүзләренә караганда, бик мөселман кебек күренә, бәлки хакыйкатьдә шулайдыр, ләкин без Яурупа тәгълиме күргән кешеләрдән лөзүмдән артык мөселманлык күрсәк, шөбһәгә төшә башлыймыз, самимият, иманымыз кими. Хасиятләре, мөселманлыгы күб ясалма бер нәрсә түгелме дигән карарга киләмез. Монарда ул хис уянмады... Адашкан кешенең үз өен сагынуы, үз йортын сөюе кебек кенә хис калдырды. Бәлки бу фикерләр тугрыдыр да, бәлки түгелдер. Чөнки бер-ике күрүдән кешене белү бик авыр. Һәр нә исә бу кешенең рухында зур бер фаҗига бар. Андан соң рәсми итдереб эшне юлга куяр өчен Америка сәфарәтханәсенә китәмез. Сәфирнең үзен күрер өчен карточкаларымызны бирәмез. Сәркатиб чыга, сәфирбәк хәзер генә чыгыб киткән. Мөһимрәк мәсьәләләрдә ул үзе кабул итә, шуңарга күрә сезнең килү хакында мин аңарга сөйләрмен дә, иртәгә вакыт ягын әйтер, диде. Без шуны муафикъ күреб чыгыб китдек. Барачак мәмләкәтемез Франсә булганга, аның сәфиренә китдек. Ләкин вакыт соң булганга, безне сәфирнең

мөстәшары[1] гына кабул итде. Мәсьәләне аңлатдык, кулдан килгән ярдәмне итәрмен, ләкин үзем генә катгый җаваб бирә алмыйм. Сәфир берлә сөйләшеб җаваб бирермез, диде. Ашдан соң безне «Һуш Шимбон»(?) газетасының мөхәррире идарәләренә чакырды. Артымыздан кеше килгән. Китәмез. Безне берәү каршы ала. Идарәнең кабул бүлмәсенә алыб керәләр. Берничә мөхәррирләр килеб күрештеләр. Безне зур өстәл янына утыртыб, чәй тәкъдим итәләр. Чәй башлангач да, газетаның мөәссисләрендән[2] бер әфәнде килеб керә. Картрак кеше. Граф Окуманың каршында тиҗарәт министры булган кеше. Хәзер матбугат берлә генә мәшгуль. Хөкүмәткә оппозициядә Япониянең исляхында роль уйнаган картлардан; кыяфәтләре, битләре берлә башкорт старшинасына бик ошый, ләкин зур яшендә әллә никадәр тәҗрибә-гыйлем, гайрәт сакланганы күренеб тора. Шундан соң мөхәррирләрән берәү редакция исемендән, безгә караб, инглизчә алдан хәзерләнгән бер адресны укый. Безгә кардәшлек, игътибар итү һәм дә тарихда зур урын тоткан Чыңгыз ханның балаларының, бабаларының мирасына наил[3] булуларына ышанудан гыйбарәт. Аңарга каршы мин татарча җаваб бирәм, мәгънәсе мондан гыйбарәт: безне хәзер тарих уңайсыз бер вазгыятькә куйды. Мәсәлән, мәдәниятемез, тарихымыз хәтердә (хатирәдә). Муаффәкъ җәгърафиямез буенча руслар берлә багланганга, мәсьәләләремезне аерым хәл итә алмыймыз. Ләкин руслар үзләре хәзер башкорт булдылар, мәмләкәт мәсьәләсен үзләре хәл итә алмаячаклары Русия мәсьәләсе бәйнәлмиләл бер мәсьәлә булды һәм шуңарга күрә без мәгънәви ярдәм сораб, сезгә япон милләтенә беренче килдек, кардәшлекне искә төшереб, беренче сәламнәр сезгә бирдек. Сез безгә, иншалла, кардәшлек ярдәме итәрсез. Мин үзем әһле каләм булганга, сезгә каләм ибдәшләрем безгә илтифатыңыз өчен, безнең эшемезгә ярдәмгә кул сузуыңыз өчен татар-төрк матбугаты исемендән рәхмәт укыйм. Шундан соң төрле сөальләр башланды. Иң әүвәл безнең

[1] Мөстәшары – ярдәмчесе.
[2] Мөәссисләрендән – оештыручыларынан.
[3] Наил – ирешкән.

тора торган йиремезне сорадылар. Харитә буенча кайдалыкны күрсәтдек. Монда кулымызда үземезнең харитәнең булмавы зур зарар иде. Томскида шуны эшләтергә тотынган идем, кешесе булмады. Тупраклы мохтарият һәятенең шул хакда бер нәрсәсе дә милли идарәгә килмәгән. Алар я булмаган, я, булса да, милли идарәгә килмәгән. Андан соң гореф-гадәтемез хакында озын-озын сөальләр бирделәр, без канәгатьләндерерлек җаваблар бирдек. Ләкин ахырга таба боларның Русия таләбен бер дәлилләүләре мәгълүм булды, шуның өчен дә хәзерен, барлыгын Русиядәге тартышның барышын, безнең урынымызны күрсәтдек. Шулай итеб ике сәгать сөальләшеб утырдык. Шул вакытда тагы рәсемемезне чыгардылар. Шундан соң матбагаларын карарга чыкдык. Биналары бер чатны әйләндереб алган. Газета әхваленә бина ителгән икән. Мөшрикләрнең саны ике мең дә биш йөзгә җиткән. Араларында граф Окуманың зур кешеләре бар, матбагасы бик зур, мөрәттибләр бүлмәсенә керәмез. Шыгрым тулган мөрәттибләр хәреф җыеб торалар, ләкин хәреф тартмалары (кассалары) безнеке төсле түгел, кыеграк койма кебек өелгән тартмаларга хәрефләр утыртып куелган. Бер-берсенә алдындагы кассасының биеклеге ике аршин, озынлыгы дүрт-биш аршин, япон хәреф галәмәтләре ике мең данәгә җитә икән, шуңарга күрә хәреф җыю бик авыр икән һәм дә акрын эшләнә икән. Боздә, мәсәлән, урта мөрәттиб[1] газета юлын сәгатенә 25, 30 юлны җыйганда, боларның мөрәттибләре биш-алты юл да җыя алмый икән. Андан машина кыйсмен күрәмез. Анда сигез ротационный машиналар дөбердәб эшләп ята. Күрше бүлмәсендә хәрефләр куялар. Тагы бер бүлмәдә фотограф эшләп ята. Безгә үземезнең хәзер генә алган рәсемләремезне күрсәтәләр. Бу газета Токионың оста бер газеталарындан саналса да, өч йөз мең нөсхә басыла. Үзе иртәнле-кичле булып, ике мең нәшер ителә икән. Андан йортларына чыгамыз. Андан автомобильләр, арбалар газетаны таратырга хәзер торалар. Без редакцияне, корректорлар бүлмәсен, конторраны, телеграфханәсене (махсус) – җөмләсене

[1] Мөрәттиб – хәреф җыючы.

үземез күздән кичерәмез. Җыю эшендә сигез йөзләп кеше хезмәт итә икән. Бик зур рәхмәт укып, күрешеб аерылышамыз. Бүген өйдән беркая бармыймыз. Кичне өйдә генә үткәрәмез.

**30 апрель**

Бүген ике сәфарәтханәдән телефон көтеп ятамыз. Телефон өйләгә кадәр дә юк, өйләдән соң да юк. Без моңарга бераз гаҗәбкә каламыз. Шундан зур мөэссәсәләр вәгъдәләрендә торырга тиешләр иде. Ахырдан бүген Япониянең вәли гаһед бик балигъ булу мөнәсәбәте берлә хөкүмәтнең бәйрәме икән. Шул мөнәсәбәт берлә парад да булган. Ихтимал, зыяфәт дә булгандыр да, вакыт да булмагандыр. Рус-япон җәмгыятендән телефон, иртәгә бәйрәм булганга, мәктәбләр ябык дип хәбәр бирәләр, димәк, безнең көнемез буш, шундан файдаланыр өчен көрд Фазылбиккә барамыз дип, мәктүп җибәрәмез. Көн ягмурлы, һава юеш, минем ягмур пальтом да юк, зонтик да юк, башка пальто да юк. Шуңарга күрә көнемне дә өйдә үткәрәм. Күңеллерәк бер мәсьәлә булса – акча курсының бераз рәтләнүе, Гомәр[1] әфәнде кич мең сумга йөз дә биш иена алып кайтды. Өч кенә көн элек мең сумга фәкать җитмеш кенә иена бирәләр иде. Икенчесе, минем ашказаным бер төрле юлга куела башлады, һаман әле әүвәлге хәленә килмәсә дә, баш авыртулар бетде. Петропавлдан һичбер хәбәр юк, Харбиндан һичбер хәбәр юк. Берничә хат яздык, җаваб һаман юк, почта озак йөри. Цензор озак тота. 1 нче хат. Бүген японларның сугышда үлгән каһарманлар көне дигән бәйрәмләре. Махсус гыйбадәтханәдә гыйбадәт укылыб, гаскәри парадлар була икән, ләкин көн ягмурлы, һава матур түгел. Шуңарга күрә мәктәбләр укуы, мөэссәсәләре эшләре. Без бер кая да бара алмыймыз. Вакыт буш булганга күрә, Фазылбиккә кунакга барамыз. Ул Йокоһаманың читендә, бер авылда тора икән. Диңгез буе, бик матур йир. Аңарда кунак буламыз. Хәяте – япон хәяте. Хатыны – япон кызы. Безне сыйлыйлар, хөрмәтлиләр, шунда Давыд исемле берлә танышамыз. Ләкин ул гарәбчә дә, фарсыча

[1] Гомәр – Гомәр Терегулов (1883–1938), хокук белгече, сәясәтче һәм журналист.

да, төркичә дә белмәгән, инглизчә генә, тәрҗеман аша гына сөйләшәмез. Гади бер мөселман, башка бер нәрсә юк. Көн буе кунак булып, кичен өйгә кайтамыз.

**2 нче май**

Беренче эшемез Франсә сәфарәтенә барып әйтү. Безгә телефон кагарга вәгъдә бирсәләр – телефон булмады, шуңарга күрә без икенче кат китдек. Баргач, бездән гафу үтенделәр һәм дә Парижга сезнең хакда сәфирбәк телеграмма бирде, шуның җавабы алынмаганга күрә, сезне чакырмаган идек. Җавап тиз булыр, диделәр. Бу сөендерде, димәк, безнең эшемез рәсми юлга куелды һәм дә сәфарәтханә үзе телеграф берлә хәбәрләшүне өстенә алгач – эшкә әһәмият бирелде. Без сөйләшеп кайтамыз. Америка сәфарәтханәсенә баруны соңгарак калдырамыз. Өйгә кайтуымызга безне газета мөхбирләре көтеп тора, аларның бетмәгән сөальләренә җаваблар бирәмез. Ләкин сөальләр бик күп, вакытында бик мәгънәсез булганга, аптырап та каламыз. Мәсәлән, бүген татарлар алланы нә-ничек таныйлар, дип сөаль бирделәр. Моңарга ни дип җаваб бирергә кирәк. Алламыз бардыр, бердер. Артда да юкдыр, алда да юкдыр, зур да түгелдер, кечкенә дә түгелдер. Күзле түгел, күзсез дә түгелдер, һәр нәрсәне күрәдер. Һәр нәрсәне ишетәдер, ләкин колагы юкдыр дип җаваб бирергәме, бу кадәресене һәр газета язучы белергә тиеш. Әле «Алла» мәгънәсенең фәлсәфәсен исламның вөҗүде улып, галим мәүҗүдат хакындагы фәлсәфәсе асла тугрымы. Мәгънәсе хакында, әлбәттә, бер-ике сөаль берлә канәгатьләндерергә, җаваб да биреп дә булмый. Моның мөхбирләргә кирәге дә юк. Бу тарих идеал, бу тарих фәлсәфә сөальләре. Барысы да татарлар иртә белән сәгать ничәдә йокыдан тора дип сорыйлар. Я, менә моңарга җавап тап. Ничә дисәк, ялган булмас. Яисә татарлар иртә берлән ни ашый дип сорыйлар. Пәрәмәч ашый диикме. Безнең хакда күп нәрсәләр яза торган бер газетаның ике мөхәррире безне ашка алып, керәмез, берсе безне бик беләсе килә, бик ихласлы. Үзе бик самими күренә. Көлгәндә тәмамән безнеңчә

самими итдереп эчендән көлә. Без японлардан эчдән көлгән кешене беренче очратамыз, озын сөйләшәмез. Әллә ни кадәр сөальләргә җавап бирәмез. Яшьләремезне кат-кат сорыйлар. Монда яшь мәсьәләсе мөһим мәсьәлә микән, әллә газета язганда һәрвакыт безнең яшьләремезне язмый калдырмыйлар. Очрашканда һаман сорыйлар. Ләкин Гомәр әфәнденең 36 да булуына ышанмыйлар. Чәче коелып беткән, ул картдыр дип куялар. Эшдән соң безгә бер карточка бирәләр. Карточкада язылган рус исемләре тагылган булса да, ул безгә Сеулда очраган япон офицеры булып чыга. Ул безне зиярәткә килгән. Аның берлә озын итдереб сөйләшәмез. Ул русча белгәнгә, аңлашу җиңел була. Безгә монда хәрби даирәләр берлән күрешергә берничә кешене күрсәтәләр. Мәсьәләнең астындан-өстендән күп мөзакәрәләргә кереп китәмез. Икенче бер көнне тагы килергә вәгъдә биреп китә.

**3 нче май**

Без бүген иртүк дарелмөгаллиматны һәм дә хатынлар гимназиясен карарга китәмез. Зур бер мәктәб бинасы. Уртасы бакча берлә тулган. Сыйныфлар өчен биналары урам буен уратып алган. Үзендә гимназиясе, үзендә ибтидаи мәктәбе, үзендә балалар бакчасы, үзендә музыка сыйныфы, үзендә гимназист сыйныфы, үзендә гали-дарелмөгаллимат. Сыйныфдан сыйныфга керәмез. Һәммәсе пакь, тәмиз, һавасы күп. Анда-монда укучы кызлар тулган, күбесе яшь кызлар, яисә ханымлар. Өсләрендә һәммә бер төрле, япон хатынларында булган акшарга буяну юк – һәммәсе әдәпле, инсафлы. Очраганда бик түбән иелеп сәлам бирәләр. Аякларында ботинкалар. Аркаларында теге ямьсез нәрсә юк. Безне хәйранга калдырган нәрсәнең иң зуры: физика, нәбатат, хәйванат бүлмәләренең байлыгы. Монда өйрәтү тәмамән күзгә күрсәтү ысулы куелган. Сыйныфларда укыб утыралар. Лаборатория гамәлият ясап яталар. Бер бүлмәгә керәмез, монда мөгаллим булачак ханымлар кием-салым тегәргә өйрәнеп яталар. Икенчесенә керәмез. Анда чигешләр өйрәтеп торалар. Өченчесенә керәмез. Анда эш

остасы абыстай кызларга киезләр таратып, балыклар кискәләп, аш бизәргә өйрәтә. Ашханәләренә керәмез. Егерме-утыз туташ ак алъяпмалардан аш хәзерләп маташалар. Ашау бүлмәсенә керәмез. Монда озын өстәлгә һәрбер кешенең алдына бер тарелка балык, бер савыт куелган. Һәр табынга зур бер табак берлә пешкән дөге китерелеп куелган. Элмәк-фәлән һич юк. Гимнастика бүлмәсенә керәмез. Зур-зур туташлар махсус киемләрдән сикереп, йөгереп, югары атылып, уйнап яталар. Мәктәп йорты шау килә. Анда әллә ничә йөз вак кына балалар: бер йирдә туптан уен, бер йирдә агачга, баганага менеп маташа. Бер почмакда шакмаклардан өй ясап уйныйлар, бер йирдә балчыкдан кирпечләр, кошлар оештыралар. Бер бүлмәдә алларына зур дәфтәрләрдәге балыкларны, кошларны төрлесен төрле буяуга буяп торалар. Һәр йирдә фәгалият, һәр йирдә хәят. Зур бер дәресханәгә керәмез. Бер-ике йөз кыз утырганлар да бик зур дикъкать берлә тыңлыйлар. Профессор акрын гына, вәкарь берлә генә әллә нәрсә сөйли. Мөдәррисләр, мөгаллимләр, профессорлар берлә сөйләшәмез. Мәктәп, хөкүмәт, мәгарифенә бина ителгән инде, кырык ел дәвам итә. Урын дүрт сыйныфлы. Монда дарелмөгаллимат яисә гимназия тәмам итгән кызларны алалар, уку-укыту бушлай, күбрәк керүчеләр мөгаллимләрнең балалары була. Янында пансионы да бар. Читдән килгәнләр шунда торалар, ләкин ашау-эчүләре үзләрендән. Күпмегә төшә, мәктәп шул кадәр ала. Хәзер хәят бик кыйммәтләнгән, шуңарга күрә кызларга ашау-эчү өчен аена җитмешәр иена түләргә туры килә ди. Тормышлары безнеңчә, ятак бүлмәсе безнең мәдрәсәләр кебек – идәнгә камыш намазлык җәелгән. Аның өчен мәдрәсәдәге кебек тәбәнәк өстәлләр тезелгән. Шәкерд шунда тезен бөкләп утырып дәрес укый. Кием берлә астына көрпә җәеп ятып йоклый. Тәһарәтханәләр бик зур, әллә ничә йирдә казан, әллә ничә йирдә зур агач су савытлары. Кызлар шуларга кереп коеналар. Дәресләр бөтен Яурупа мәктәпләрендәге кебек, шуның өчен ике төрле тел укытыла, берсе – инглиз, берсе нимесчә. Бер якдан сөенеп, үземездә шундый мәктәп юклыгына көенеп чыгып китәмез. Хәзер

без тагы кызлар мәктәбенә барамыз. Ләкин бусы демократиянең фәкыйре өчен. Бу мәктәп-һөнәр мәктәбе. Монда аена өч иен алып тегәргә, чигәргә, кисәргә, үрергә-бәйләргә, чәчәк ясарга өйрәтәләр. Сыйныф бүлмәләре шыгрым тулган, мәктәбдә мәктәбчә йөз кыз укый. Сыйныфда мөгаллимләр. Берсендә тегәләр, берсендә, бик күп киргеләр киереп, идәнгә утырганлар да чигәләр. Берсендә, озын өстәлләргә кискән чүпрәк-чапракны салганлар да, эшлиләр, берсендә алларына машинкалар куйганлар да шуларда кечкенә генә тимер коралларны кыздырып торып, шуның берсе берлә чәчәкне язалар, берсен-берсе йомшартып, үзләндереп чәчәкнең сабын бөгәләр. Бер бүлмәдә кош сурәтләрен, урман, ялан манзараларын чигәләр. Шундагы кошларга, хайванларга җан өрәләр. Мондагы иҗтиһад, мондагы тырышлыкны күргәндә бу халыкның алтмыш ел эчендә шул кадәр зур адым атлавының мәгънәсен дә аңлыйсын. Сөендерә беләсез – монда хатынларны эш кешесе итдереп чыгаралар. Монда хатынларга уенчык, курчак, ирләренең хәятен төрлеләндерүче дип карау кермәгән. Монда алар да ирләре берлә бергә эшләүчеләр, туйдыручылар.

**4 нче май**

Без көнемез буш булганга (якшәмбе көн), Токионың читдәге бер йиренә китәмез. Токиодан илле чакрымлы йирдә, диңгез буенда. Поезд икенче классда, бер сум да тугыз тиен (япончa) ала. Үзе бер сәгать дә ун җиде минут бара икән. Исеме Камакура диңгез ярында, монда бик күп комлык (пляж), шуңарга күрә монда диңгез коену бик шәп була икән. Диңгез буйлап зур авыл утырган. Биегрәк йирләргә бик матур дачалар бина иткәнләр. Бик зур парк диңгезгә карап ята. Үзенең әтрафында матур урынларына электрик трамвай йөри, бик күп матур урынларны карап менгәч, диңгез якасына салынган бер өстәлгә кереп, чәй эчәмез. Зур бер өстәл, халык шыгрым тулган, һәммәсе дә коеныргa, кәеф алыpга килгән. Яурупалыларның иң күбесе америкалылар... Ләкин америкалылар дигәнең дә иң күбе америка яһүде, Русияле дигәнең

шулай рус яһүде. Монда, гомумән, яһүднең күблегенә хәйран калмаслык түгел. Болар һәр нә кадәр төрле-төрле исемләрдә американы, франсале, русияле дип йөриләр дә, милләт ягыннан һәммәсе яһүдиләр. Безнең авылның халкын милләткә бүлгәндә иң зур күпчелек яһүдиләрдә булачак. Кайдан Япониядә тынычлык булганын аңлап җиткән, кайдан акча җыеп өлгергән. Кайдан килеп җиткән. Чәйдән соң номер карыймыз. Дача урынында булса да, номерның бәһасе бассейн берлә Токиодагыча тугыз-ун иен, хәзерге рус акчасы берлә йөз сум. Ләкин бүлмәләре бик чиста. Манзара бик күп. Утрау бик матур. Әле коену башланмаганлыгына, буш номерлар күп, кичкә таба һава бераз юешләнеп китә. Ягмур башланганда монда бик юеш була торгандыр дип, бүлмәләр алудан ваз кичәмез. Тиздән монда ягмур ява башлады. Кич берлә өйгә кайтсак, безгә Харбиндан мәктүб бар. Яңа хәбәр юк. Саулык-сәламәтлек ахыр мәсьәлә, һаман рәтләнмәгән һәм дә Петропаулдан һаман хәбәр алмаган. Бүген шулай үтә.

### 5 нче май

Бүген иртүк безгә бик күп еллар Япониянең баш министры булып торган, әле быел кыш көнә генә истифа итеп,[1] Харага[2] урынын биргән маркиз Окумага зиярәткә барамыз. Безне маркизның янындагы сәркатибләре, үзенең университетындагы профессорлары (хосусый университет бар) каршы ала. Килеп кергәч дә ике ягыннан тотып, маркиз Окуманы чыгаралар. Япониянең ихтилялы вакытында алтмышынчы елда маркиз Окума революционер булып, сугышып, аягын сындырган, шундан бирле аның аягы аксак калган. Зур, таза бер карт. Киң маңгайлы, ачык күзле, зур башлы. Өстенә японча җилән кигән, бай авыл ахунларына охшаган. Күрешәмез дә утырышамыз. Маркиз: «Мин күбдәндән бирле татар милләтенең

[1] Истифа итеп – отставкага китеп.

[2] Хара – Хара Такаси (1856–1921), Япониянең дәүләт һәм сәясәт эшлеклесе. 1918–1921 елларда премьер министр булып тора. Бу вазифага ул Сигэнобу Окумадан соң түгел, ә 1916–1918 елларда Япониянең премьер-министры булган Масатакэ Тэраутидан соң килә. Г. Исхакый бу урында төгәлсезлек җибәрә булса кирәк.

вәкилләрен күрергә зар булып тора идем, сез килгәнен ишеткәч дә күрешәсем килде» – ди. Без дә кардәш кыламыз да, шундый олуг кешеләрнең булуы, халык өчен шул кадәр хезмәт иткән кеше күрергә мөяссәр булуымыз өчен шатлыгымызны изһар итәмез[1]. Шундан соң безнең туп-тугры итеп сөйләү башлана. Маркиз безнең килүнең сәбәбендән хәбәри булса да, бездән дә сорый, ачык итдереп бәян итәмез, бик дикъкать берлә тыңлыйлар. Шундан соң үзенең фикерен сөйли. Фикере шундан гыйбарәт: төрек кавемләре дөньяның тарихында бик зур роль уйнаганлар. Истанбул,


Окумо Сигэнобу (1838–1922) –
Япониянең дәүләт
һәм сәясәт эшлеклесе

Мәскәү аларның кулында булган. Төрек кавеме гаҗәеб бер кавем, баһадир кавем, сүзе тугры, үзе хакны сөя. Ләкин ни өчендер соңгы елларда эшләре түбән китте. Сез үзегезнең ханлыкларыгызны буйсындырдыгыз. Төркестан истикълялын[2] югалтды, госманлы төрекләре зур бер дәвер кичерәләр. Моның сәбәбе нәрсә дип уйлыйсыз, ди. Мин: «Без төрек кавемләре Яурупага таба киткәндә бик эчкә кергәнмез. Үземезнең илемездән, бердән, Төркестан үземезнең кардәшләремез монголлар вә сездән ераклашканмыз. Шуның өчен без анда дошманга караганда зәгыйфьләнгәнмез. Икенчедән, без бер якдан Яурупаны җиңүче бер халык бер булып кергән кебек, икенче якдан Яурупага икенче дин кертүче, ислам таратучы булып танылганмыз. Шуңарга күрә үземезгә каршы бөтен христиан дөньясыны дошман ясаганмыз. Безгә каршы дүрт-

[1] Изһар итәмез – белдерәбез.
[2] Истикълялын – бәйсезлеген.

биш гасыр мөхарәбәләре[1] дәвам иткән, шуларның һичберсендә дә мәгълүб булмасак[2] да, гонсырымыз[3] азалган[4], шундан соң без русларга каршы госманлы төрекләренә, Яурупага каршы мәгълүб булганмыз, максадыңыз нәрсә?

Русия әхвале хәзер бәйнәлмиләл[5] бер хәл алды. Русия халкы үзендән-үзе үз мәсьәләсене хәл итәчәк түгел. Русиянең идарәсе Русиядәге милләтләрнең хокуклары Яурупада хәл ителәчәк, шуның өчен – утыз миллионлы төрек кавеменең теләген ишеттерер өчен беренче уларак сезгә килдек. Сезне кардәш дип, кайгымызны сөйләргә килдек, андан Яурупага китәчәкмез. Максудымыз – киләчәкдәге Русиянең төзелешендә безнең тавышымызны ишетдерү, милли гаямезне[6] вөҗүдкә чыгару. Милли гаямез бу: Төркестан, Казакстан, Кырым, Кавказ, Идел буе өчен аерым-аерым штатлар ясау һәм дә шулар арасында берлек тәэмин итү. Без – бер милләт. Кабиләләремез аерым булса да, тарихымыз, телемез, әдәбиятымыз бер. Русиядә безнең зур урынымыз бар, шуңарга муафикъ хокукымыз булырга тиеш. Шул мәсьәлә хакында озын-озак сөйләшәмез, өч, өч сәгать ярым утырып каламыз. Фәүкыльгадә, гакыллы һәм дә бик күп мәгълүматлар безнең тарихдан, безнең халәтдән – һәммәсендән хәбәре бар. Ахырдан бергә рәсем чыгартырга чакыралар. Маркизны уртага утыртып, рәсем чыгартамыз. Киткән вакытында бөтен кулымдан килгәнне эшләргә хәзер, без алда ярдәмдә булынырмыз, ләкин мин хәзер сәяси кеше түгел, гади кеше. Безнең мәктәбләремез безнең балаларга ачыла. Мәдәният җәһәтендән якынлашу, иншааллаһ, җиңәрбез, дәүләт яңадан туар, ди. Бик самими күренсә дә, рәхмәтләр укыб чыгыб китәмез.

Маркиз Окума Япониянең – бәхетле картларындан. Ул үзе иштиракъ итешеп[7], Япониядә революция ясашкан. Шундан соң,

---

[1] Әһле салиб мөхарәбәләре – тәре йөртүчеләр сугышлары.
[2] Мәгълүб булмасак да – җиңелмәсәк тә.
[3] Гонсырымыз – токымыбыз.
[4] Азалган – азайган.
[5] Бәйнәлмиләл – халыкара.
[6] Гаямезне – төп теләгебезне.
[7] Иштиракъ итешеп – катнашып.

даими уларак, кырык-кырык биш ел милләтенең хезмәтендә булынган. Берничә мәртәбә төрле нәзарәтләрдә министр булып, ахыргы вакытларда иң мәсъүлиятле[1] эшләрдәге хезмәтләр аңарга йөкләтелгән. Рус-япон сугышындан соң Русия берлә Япония арасындагы солых мөзакәрәләренә[2] ул рәис итеп күндерелгән һәм дә рус-япон могаһәдәсенә[3] ул кул куйган. Шундан соң озын вакытлар яшь министр булып торган. Хәзер дә зур бер партиянең башы Хара кабинеты төште исә, маркиз Окума кабинет төзеячәк диләр, халкына гыйлем берлән дә хезмәт юлына кергән, үз акчасына зур бер дарелфөнүн бина иткән, шунда бөтен факультетларны вөҗүдкә китергән[4]. Хәзерге көндә аның дарелфөнүнендә укучы шәкердләрнең саны гына алты меңгә якын диделәр. Маркиз Окума әфәнде эшләгән эшләренең йимеше йитешкәнен үзе күргән, ул үзенең милләтенең зур бер милләт булуын күзе берлә күргән, үзенең милләтенең олуг дәүләт булуын үзе күргән, шуның олуглыгының соңындан үзе файдаланган.

Бүген өйләдән соң күбдән күрешергә йөргән миллионер Асананың япон стилендә бина ителгән өен барып карыймыз. Өй, хакыйкатән, бик нечкә итдереп эшләнгән. Бөтен стиле тарзы мигъмарисы[5] иске японча, бүлмәләренең диварлары япон рәссамләре тарафындан Япониянең тарихи манзаралары рәсем ителгән. Түшәмләр күпертеп сипләнгән. Рәсемләр берлән зиннәтләнгән. Диварга, дивар буйларына бик күп япон асаре гатикасы[6] берләшдерелгән. Беренче катта зур бер зал Яурупа ысулында. Икенче катта тагы зал, япон ысулында. Өй баскычы биек итдерелеп салынган. Икенче каты беренчесенә караганда артка таба да чыгып тора, икенчесенә караганда өченчесе артка табарак чыккан, дүртенчесе каты зур кыялыкга барып терәлгән. Иң югары манарасындан бик күп манзара ачыла. Бер якда, уч өстендә

[1] Мәсъүлиятле – җаваплы.
[2] Солых мөзакәрәләренә – килешү җыелышларына.
[3] Могаһәдәсенә – килешүенә.
[4] Вөҗүдкә китергән – булдырган.
[5] Тарзы мигъмарисы – архитектура ысулы.
[6] Асаре гатикасы – борынгы әйберләре.

диңгез, икенче якда Токио. Бу кеше зур пароход ширкәтенең хуҗасы икән. Сугыш вакытында бик зур файда иткәндә шулай итеп сәнаигы нәфисәне[1] бергә җыйган. Өйнең алды бик зур бакча. Үзе тау итәгендә утырганга, тауның кыялары аска зур ташлар берлә тоташып, бик мәһабәт тора. Бер ягыннан сонгый[2] шарлавык ясагандан, су бик каты агып, дәһшәтле бер тавыш биреп тора. Уң ягына күл ясаган. Күлгә каршы бер таш өстенә үзенең һәйкәлен куйдырган. Әле үзе исән булса да, бу һәйкәлне үз акчасына үзе эшләтеп куйдыруны мәслихәт тапкан. Монда андый эшләр гаеп саналмый булырга кирәк. Гомумән, Япония халкының әхвале рухиясендә эшләгән кешеләрнең исемләрен мәңгеләштерү бик зур урын тота булырга кирәк, монда һәр урамда, һәр бакчада һәр зур мөәссәсә алдында һәйкәлләре куелган, барысы да соңгы утыз-кырык ел эчендә милли каһарманлар. Хәтта исән кешеләргә дә һәйкәлләр бар.

Бүген безгә теге Сеулда очрашкан япон тагы ашка килде. Хәрби даирәләрдән берничә кешеләргә тәкъдим кәгазьләре язып китергән. Үзе Русиядә шактый торганга, Русияне белә, Яурупа хәятен алышкан. Япониянең садә[3] хәятендән бик үк разый түгел кебек күренә. Сүзләре, фикерләре, кыланышлары берлән «Аурупадыр, әфәнде» дип авыз суы түгә торган төрек бәгенә бик охшаган. Бу кешене без әле Япониядә беренче мәртәбә күрәмез.

Бишенче май бүген, бөтен Япониядә бер милли бәйрәм – малайлар бәйрәме. Бүген бөтен Япония халкы шул малайлар бәйрәмен итә. Һәр йирдә сазан балыгы төсле итдереп, материядан эшләтелгән флаглар аскан. Бакчаларда төркем-төркем кечкенә малайлар, зур кәгазь фонарьлар күтәреп, берәр йыр йырлап йөриләр. Хөкүмәт мөәссәсәләре ябылмый икән – кешеләр сату итә. Ләкин урамда яңарак киенгән ир малайлар бик күп. Сазан балыгы байрагы күтәрүнең мәгънәсе мондан гыйбарәт икән: япон халкы атау халкы булганга, алар күпдән диңгез берлә күп

[1] Сәнаигы нәфисәне – матур сәнгатьне.
[2] Сонгый – ясалма.
[3] Садә – гади.

эш итәләр. Аларның хәятләрендә балык бик зур урын тота. Балыклар арасында иң батыры сазан икән. Ирләрдә иң зур сыйфат – батырлык. Шуңарга күрә бөтен япон халкы ир балаларымыз сазан кебек батыр булсын дип, сазандан байрак күтәрәләр. Искечә әйткәндә, сазанга табыналар. Монда кызлар бәйрәме дә була икән. Анысы сентябрь аенда, ди. Махсус байраклар була, ди.

**6 нчы май**

Без бүген Америка сәфарәтханәсенә һәм дә Англия сәфарәтханәсенә бармакчы буламыз. Ләкин иртәдән үк безне бер япон зиярәт итә. Гаҗәбе шул: бу япон төрекчә сөйләшә, исеме Кочи, фамилиясе Окубо[1]. Төрекчә тәмамән аңлаша ала. Үзе игъдади[2] мәктәбдә алман теле мөгаллиме икән. Китаплар аша оста гына төрекчә өйрәнгән. Монда яши торган бер әрмән һәм дә бер төрек ярдәм иткәнләр. Хәзер тәмамән үзенең теләген төрекчә аңлата. Үзе дарелфөнүн бетергән. Махсус төрек тарихы белән мәшгуль була. һәм дә японлар арасында тюркологияне бер фән итдереп кую филология җәһәтендә күп тәдкыйкатьдә[3] булынган. Япон теле берлә төрек арасында бик күп мөштәрәк сүзләр тапкан. Мәсәлән, безнең су японча «сый» икән, безнеңчә «кара» аларча «коры» икән.




Гаяз Исхакый төрки телләр галиме
Кочи Окубо белән.
Токио, 1934 ел

*Текстны басмага Ләйлә Гарипова, Зөфәр Рәмиев,*
*Гөлчирә Ханнанова, Венер Усманов әзерләде*

[1] Кочи Окубо – япон тюркологы. Озак еллар Маньчжуриядә, төрки-татар эмигрантлары арасында яшәве билгеле.

[2] Игъдади – хәзерлек.

[3] Тәдкыйкатьдә – тишеренүләрдә.

**3 нче дәфтәр**
**1919 (6 май – 17 май)**

Безнеңчә «бар» мәүҗүд дигән сүз аларча «ар» икән. Моңарга башка ул бик күб сүзләрдә мөштәрәк[1] лөгатьләр, мөштәрәк төпләр тапкан. Аның берлә сөйләшү бик күңелле була. Берничә сәгать бергә утырамыз. Монда японча укырга килгән Митрофандан Ибраһим хакында бик начар фикердә, тәрбиясез икәндер, безгә күб зарар иткән диб сөйли. Тәүфикъ исемле бер төрек егете булган икән, аның хакында бик яхшы фикердә. Франсәле хакында сорыймыз. Теләр-теләмәс кенә җаваб бирә. Ахырдан мин аның берлән дуст түгел, безнең аның берлән низагымыз чыкды, монда Вафа исемендә бер татар баласы бар иде, шуның тәрбиясе хакында низаг чыгды. Ул баланы Ибраһим алыб килгән иде, ул үзе качыб килгән дә без тәрбиясенә башладык. Махсусан, Токиодагы әрмәндән зур ярдәм дә булынды. Малайны мәктәбкә бирдек, ләкин Фазыл малайны алыр өчен күб хәйләләр корды. Ахырдан малайны алды һәм мәктәбдән чыгарды. Хәзер ул малайны күрсәтмәенчә тота, диде. Ул малай хакында без инде берничә кешедән ишетәмез, үземез берничә мәртәбә Фазылга малайны күрсәт, дисәк дә, һаман күрсәтмәде. Арада бер сер булырга кирәк. Бу япон әдәпсез кеше. Шуның өчен мәктәбдән чыгарылды, ди. Теге татар баласы, мескен, шунда юкга әрәм булыб ята күрәсен. Ул киткәч, без кызуланыб, сәфарәтханәгә китәмез, иң әүвәл Америка сәфарәтханәсенә барамыз, анда секретарь безне күргәч дә: «Сезгә сәфирбәк җомга көн вакыт тәгаен иткән иде, шуны номерыңызга әйткән идем, ник килмәдегез», – ди. Безгә номерда әйтмәгәнләр, бу бик күңелсез булды. Инде тагы белешим, диб китде. Килеб: «Хәзер сәфирбик кабул итә алмый. Беренче көнгә, мәгъкуль теләсәңез, сәфарәтнең башка әгъзасы кабул итә, аңарга фикерләреңезне сөйләгез», – ди. Без разый буламыз. Безне бер бүлмәгә алыб кереб, бер яшь кенә әфәнде берлән танышдыра. Фикерне-максадны

[1] Мөштәрәк – уртак.

сөйлимез, бик ихлас берлән тыңлый, бик күб сөальләр бирә. Асылда икътисад-җәгърафиямез хакында изахлар сорый, бер-ике минут сөйләшкәннең соңында бер мәсьәлә хакында сәфирбик берлән киңәшләшеб алыйм әле, бәлки ул безне үзе кабул итәр диб чыгыб китә. Кайткач, аягүрә генә, сәфир хәзер кабул итә алмый, аның сәяси мәүзугъка, мондый мәсьәләләр хакында сөйләшергә мөсагыйд[1] түгел. Аурупага бару булды шул! Йокоһамада консул аша телеграмма биреб, рөхсәт сорыйсыз, кеше башына җаваб өчен йөзәр акча куясыз, ди. Без бу мәгълүматка ихтыяҗымыз юклыгын белдереб, безгә Америка ригаяи милләтләр иттифакы дигән сәфарнең хамисе[2] кебек күренгәнгә, сезгә шул милләтнең вәкиле диб мөрәҗәгать иткән идек. Сезнең хакда газеталарда язылган хәбәрләр дөрест түгел икән. Сезнең дә сәясәт Яурупа дәүләтләре кебек вак милләтләргә аяк чалу юлына куелган икән. Яңлыш адрес берлән мөрәҗәгатемез өчен гафуларымызны үтенәмез.

Егет кызарыб кала, без дә күңелсезләнеб чыгыб китәмез. Фәкать Америка сәфарәтханәсенең бу мөгамәләсенә бераз гаҗәбкә каламыз. Андан туб-тугры инглиз сәфарәтханәсенә китәмез. Анда безне бик тиз бер инглиз кабул итә. Кыска гына максудымызны аңлатамыз. Зур күзле, зур тешле. Ашарга хәзерләнеб тора торган кебек кыяфәтле бер инглиз бик дикъкать берлә тыңлый. Кулга-аяк азык эләкде, авызыма җим төшде дигән кебек, авызларын тәмлеләндереб, селәгәйләрен агызыб куя, шундан соң бер-ике көндән сезне чакырамыз, озаграк сөйләшәмез диб, адресны языб ала. Без мондан күб разый булмасак да, беркадәр канәгатьләнеп чыгамыз. Өйләдән соң Нияз әфәнде акча алышдыру өчен Йокоһамага бара. Токиода алышдыручы юк. Кичкә таба эт булыб арыб, кәефсезләнеб кайтыб килә. Акчаны алышдыра алмаган. Рус акчасының егермелек, кырыклыкдан мөрәккәб[3] мең сумга утыз иен. Бер хөкүмәтнең меңлегенә дүрт сумдан игътибар итеб кырык иен. Яшел меңлекләргә алты сумдан игътибарән алтмыш

[1] Мөсагыйд – рөхсәт.
[2] Хамисе – яклаучысы.
[3] Мөрәккәб – җыелган.

иен. Бу эш безнең кәефне бик боза. Безнең җыйган акчаларның иң зур кыйсме себер акчалары иде. Аларның бер кыйсмен Омскида, Красноярда, Харбинда алышдырдым, ләкин алай да кулда сиксән мең сум себер акчасы калды. Калганлары меңәрлек керенкаларда. Аларын николаевскига алышдырырга өлгерә алмадык, чөнки курс һаман кыйммәт торды. Харбин сәүдәгәрләре һәм дә милли идарәнең әгъзасы Латыйф әфәнде Яушевлар өчен акча алышдырыб булыр диб вәгъдә бирделәр. Безнең бәхетсезлекгә каршы, алар да алышдыра алмадылар. Курсда һаман николаевскига менгәндән менә. Харбинда иенга алышдырырга мөмкин булса да, әле дә эшли алмадык, чөнки безнеңчә иеннең курсы күтәрелә башлады. Элгәре 7,50 булды, андан сигезгә чыкды. Сәүдәгәрләр һаман мәслихәт күрмәделәр, төшәчәк, диделәр. Ниһаять, без киткәндә унга-унбергә менде. Сәүдәгәрләр, мотлакан, төшәчәк дигәнгә, без кулымыздагы бер мең иенны күтәреб, Японияга китдек. Без киткәч, курс тагы төшде. Шуңарга күрә без мең иенымызны бик кысыб, сум күтәрелгәнчә җиткерү нияте берлән сакладык. Һәр нәрсәнең бит чиге бар. Безнең акча да үзенең чигенә җитде. Без акчасыз калдык. Үземез берлән берәр мал алыб килгән булсак да, эш ул кадәр булмас иде, ләкин Харбин сәүдәгәрләре товар алыб баруны мәслихәт күрмәделәр дә, без акча күтәреб китдек. Инде ул акчаларны иенгә алышдырырга кирәк, чөнки монда һәр мөгамәлә иенгә. Аңарга банклар алышдырмый, фәкать яһүд спекулянтлары гына шул эш берлән мәшгуль. Солых мәҗлесенең рус акчасын бөтен дөньяда кабул итмәскә дигән карары безнең акчаның курсын Япон вә Кытай базарының кәефенә баглады да куйды. Аларга рус сумы никадәр төшсә, шулкадәр файдалы булганга, әле төшерә генә баралар. Шуның өчен минем ихтыярымдагы йөз туксан мең сумлаб акчаның бик зурысы чүбкә әйләнеб калу ихтималы бик зур. Әгәр ул бәлагә очрасак, әле Яурупага да чыга алмаячакмыз, монда да бер эш эшли алмаячакмыз. Минем үземнең рус акчасына иманым бик зәгыйфь булганда һәрбер шәһәрдә сәүдәгәрләр берлән киңәшләшә килдем, ләкин мөһим бер шәһәрдә дә безгә

акчаны малга әверергә яисә алтынга әверергә киңәш бирмәделәр. Иркутскида сатыб алыб була иде, ләкин аны алыб бару бик авыр, юлда тоталар, атыб үтерәләр, диделәр. Безгә үземез берлә бергә акча алыб барырга да кушмадылар. Без акчамызны да калдырыб килдек һәм дә банк аша перевод эшләтдек. Харбингә килгәч дә берникадәр мал алыб булыр иде, ләкин акча күб булмаганга, мондагы сәүдәгәрләр берлән киңәшләшеб, илле мең сумына товар алырга һәм дә Америкада сатдырырга булдык. Калган акчаларны алышдырырга булдык. Ләкин сәүдәгәр халкы акча эшен бездән күб белә диб ышанганга, иенгә дә алышдырмадык, алтын да алмадык. Килгәч үк ваклаб николаевскига алышдырырга кушсак да, аны да Харбин сәүдәгәрләре эшләб бетерә алмады. Шуңарга күрә акча мәсьәләмез бик мөшкелгә әверелде. Петропаулда мин бик күб акча җыйганны белү берлән бу акча бик күб булды. Монардан мөмкин кадәр күбрәк кеше файдалансын дигән кебек, эшнең әһәмиятен аңламаганга, өч кеше тагы сайлаганлар һәм дә Әхмәд бик берлән Садри әфәндегә шулар арасына керергә кушканлар, димәк, җыенымыз җыелыб җитсә, шул акчага караб, алты кеше Яурупага чыгыб китәчәк. Бу акча хәзерге курс берлән хисаблаганда (барысы өч йөз утыз мең булырга тиеш) егерме ике мең, күб булса, егерме өч мең булырга тиеш. Алты кешегә бүлгәндә, өчәр мең дә биш йөз иен төшә. Шул акчага болар Яурупага барырга кирәк, Яурупада торырга кирәк, анда милли мәсьәләне мәхкәмәгә куйдырырга кирәк, анда дүрт-биш ай калырга кирәк, андан кайтырга кирәк, бу мәхкәмәне хәзерге Яурупа хәятендә бер вәкил аена мең иендән ким тора алмый. Бару-килү тагы биниһая кыйммәт, шулай булгач, бу эш бөтенләй вәкил җибәрү эшен сүтеб ташлау дигән сүз була. Тагы ни өчен анда ул кадәр әле тел белми торган кеше кирәк. Солтанбәк Мамлиевның[1] анда нинди кыйммәте була? Әхтәмов анда ни эш эшли ала. Фуад Туктаров без эшли алмаган нинди эшне башкара ала. Болар һәммәсе дә ахмаклык. Оятсызлык, имансызлык, эш таба алмаган имансыз [...]. Инде алар кайчан киләчәкләр? Кайвакыт

[1] Солтанбәк Мамлиев – Петроград Эшче-солдат депутатлар советы әгъзасы.

чыгачаклар? Алла белә. Менә мин шуларны көтеп, Япониядә сумны печатьсез алтын иенгә алышдырыб ятарга кирәк. Киләчәк шулкадәр караңгы булганга, күңел күтәрелми, акча түбән булганга, бик күб эшләр акчага бagланыб кала. Хәерле булсын. Инде ике атналык ашауга бирмәдек. Иртәгә япон вәли гаһеденең[1] балигъ булу көне, аны карайа чыгамыз. Бу көнгә тәмам 7сендә, 8 ендә, тукызында монда зур бәйрәмләр. 7 сендә Япониянең вәли гаһеднең балигъ булу, унсигез тулу бәйрәме булды. Моңарга японлар бик нык хәзерләнделәр, бөтен урамларын зиннәтләб бетерделәр. Хосусан, күбесе ал да гөл булды.

Зур урамдагы ике күпернең ике ягыны да камышлардан бик пөхтә итдереб, баганалар рәвешендә дүрт почмаклы колонналар эшләделәр. Аларны тышкы якдан яшел нарат чыбыклары берлән уратдылар. Алар еракдан ук ямь-яшел булдылар. Югарысына дүрт якга карый торган тәрәзә ясадылар, башына бик кызыл кояш сурәтле байрак асдылар. Шулай итеб, бу күперләр теремок капкалары хәлен алды. Сарай алдына шундый капканың тагы зурысын ясадылар. Бу капкаларның һәммәсенә дә «Чук яшә» дигән сүзләр яздылар, урамларның бөтен ягындан баганалар утыртыб чыкдылар, аларның өстләренә бездәге капка башларындан аз гына тарайтып, такта берлән капладылар. Шулар койманың бөтен агачларын бер буе кызыл, бер буе ак материя берлән чолгаб алдылар. Төбләренә бик пөхтә итдереб, капка төсендә рәтләр бер чәчәк берлән алкалаб чыкдылар. Шул киртәләргә бик еш итдереб кәгазь фонариклар элеб чыкдылар. Биналарга, магазинлар, өйләргә бик күб зур һәм кечкенә флаглар берлән бизәделәр. Программа мондан гыйбарәт. Вәли гаһед иң элек үз сараендан атасы-анасы сараена барачак, аларны зиярәт итәчәк. Анда чыгыб, бер мәйданлыкда гаскәргә рәсми кичә ясалачак. Андан соң бер йирдә мәчетханәгә барачак, гыйбадәт кылачак, андан соң [...] кабул итәчәк, андан сараена кайтачак. Без боларның һәммәсене күрергә диб хәзерләнеб торсак да, вәлигаһеднең сарайга баруы, рәсми кичәләр ясавы иртә берлән

[1] Вәли гаһед – варис.

сәгать җидедә үк беткәнгә, аны күрә алмадык. Гыйбадәт итә торган урыны бик ерак булганга, анда да китә алмадык, фәкать сәгать дүртләрдә вәли гаһед сараена кайткан вакытка юлына чыкдык. Урам тулы халык, бер якдан гаскәр тезелеб тора. Икенче як буш. Менә туп атылды. Халык: «Сарайдан чыкды», – диде. Озак үтмәде – атка атланыб юлны [...] үтде. Еракда гаскәргә әмер булды, солдатлар сәлам турысында мылтыкларын күтәрделәр. Еракдан гына музыка ишетелә башлады. Әллә нинди укалы киемләрдә атларга атланган бер егермеләб гаскәр уртача гына чабыб үтделәр. Алар артындан тагы бер егермеләб үтде, алар артындан ачык каретада карт бер түрә үтде.

Аның артындан тагы егермеләб самурай, тагы бер арба, анда тагы карт генераллар. Анда тагы утызлаб самурай, тагы арбасында вәли гаһед утырган. Аңарга каршы карт кына бер кеше утырган. Анысын тәрбиячесе диделәр. Артдан тагы егерме-утыз атлы. Халык башларын алды, музыка якынлашды. Кычкыру, кул чабу мөһиме юк. Вәли гаһед дә халык таба бер ишарә дә кылмады. Шулай итеб бер-ике минутда үтделәр. Музыка безнең ал ягымызда уйный башлады. Безнең алдагы гаскәрләр мылтыкларын төшердерләр, шуның берлән тәмам. Шунысын оныткан икәнмен: падишаһлар үткән чакда тәрәзәдән карау-фәлән һич ярамый икән. Иске заманда микадолар[1], гомумән, халыкга күренеп йөреми дә икән. Алар япон халкының игътикады буенча рухани да, рәис булганга, адәм баласына ошый торган күб эшләрне эшләми икән. Инде Япониянең исляхатендән соң ул гадәтләр күб үзгәргән. Кич берлә бөтен урам утка батды. Фонарьның, лампаның һич иге-чиге юк. Утка бу кадәр юмартлыкны һичбер караб бетерер хәл юк. Мисла, дүрт катлы почмакдагы бер өй, дүрт дивар арасында электрика лампалары бизәкләп бетергән. Бөтен лампаның саны берничә меңгә җитә торгандыр. Кайбер вагонлар көндез чәчәкләргә өртелгәнләр иде. Кич берлә һәрбер чәчәк астында бер электрик лампасы килеп чыкды. Вагон йөрегәндә төрле төскә иңгән ут тавы хәрәкәт итә

[1] Микадо – хан титулы.

кебек хис ителә. Күпер башларында зур прожекторлар дөньяны ялтырата, урам почмакларында төрле төсдәге лампалардан оешдырыб ясалган фонарьлар тегермән канаты кебек әйләнеп ята.

Урамда халык. Хатынлар, ирләр, балалар, ирләр, хатынлар, балалар. Һәммәсе японча киенгән, һәммәсенең дә аягында агач башмаклар, һәммәсе шат күңелле. Ләкин көнләр коры булганга, тузан бик күб. Сигезенче майда шул бәйрәм дәвам итә. Ләкин тукызында Токио шәһәренең тәхетбай булуына илле ел тулганга тагы зур бәйрәм булачак. Шәһәр урамы, паркларда зур чатлар корыб, хәзерлек күреп ята. Җидесе шуның берсе тәмам. Кич берлән кайтыб, нарзан эчеб утырганда безнең берлә ике рус егете килеб танышды. Берсе Дашик фамилиясендә. Русларның алпавытларындан. 13 нче елларда Кассо берлә скандаллары да булган иде. Сарай даирәсенең зур түрәләренең углы. Үзе гвардия офицеры икән. Хәзер бер япон магазинында приказчик. Рухы бик күтәренке түгел. Бүген безнең отельдә бал бар. Токиодагы бөтен Яурупалы хатынлар, егетләр, кызлар бииләр. Ләкин бу егетнең биисе бик килсә дә, киеме юкга, безнең берлә утыра. Дөнья бу, өйрәтә. Ул өченче елларда кадерле малай булганда, бу, безне белсә дә, күрмәмешкә салыныб китәчәк иде. 15 нче, 16 нчы елларда гвардия офицеры булганда очраса, бәлки – молчать диб кычкырачак иде. Икенчесе – немец фамилияле, немец нәселендән булырга кирәк. Бусы татарча укый белә һәм дә яза белә. Сөйли белмим, ди, ләкин сүз арасында күб җөмләләрне татарча әйтә. Бу егет Петроградта әлсинәи-шәркыя1 мәктәбен тәмам иткән икән һәм дә Петроградта гимназиядә укыганда Йосыф Әхмәров дигән Казан егете берлә бергә булыб, анардан татарча өйрәнгән икән. Японча белә икән. Япон хәятендән бик күб нәрсә белә, бик күңелле егет. Гакыллы, уңган. Киеме дә бар, танцевать дә итә белә. Бүген шуның белән тәмам.

8 ендә бәйрәм дәвам итә. Ләкин безгә артык кызык юк күрдек. Инде беренче эш итдереб Йокоһамага икәүләб акча алышдырырга китәмез. Йокоһама үзенә аерым шәһәр. Бу Токиодан утызынчы

[1] Әлсинәи-шәркыя – көнчыгыш телләре.

чакрымларда, лəкин ике арада электрик поезды йөреп торганга, бер шəһəр кебек, бер сум утыз тиенгə барыб килеб була. Поезд да шул ике араны илле минутда йөри.

Йокоһамада порт, Йокоһамада əйберлəр күбрəк, шуңарга күрə акча алышдыру анда гына мөмкин, лəкин акчаның курсасы бик начар булганга һəм дə рус халкының кадере бер дə булмаганга, без ояла-ояла гына йөримез. Алышдыручының иң күбе кытайлар, андан кала Русия яһүдлəре. Болар бөтен эшне үз кулларында тотканга, бик үк алдамас өчен элгəре япон банкасына керəмез, акчалар алышдыра дигəн өстəленə килеп сорыймыз, лəкин рус акчасыны сатамыз, диб сорыймыз. Банкада без рус акчасыны алмыймыз да, сатмыймыз да дип җаваб бирəлəр.

Кытайларга керəмез. Алар сөйлəшми дə, не надо гына, ди. Русско-азиятский банкга керəмез, без алмыймыз, ди. Соң алай булгач, ник аңарга русский дигəн сүзне такканлар. Телəр-телəмəс яһүдлəргə мөрəҗəгать итəмез. Алар ала. Аларның алмаган нəрсəсе, сатмаган малы юк, фəкать бəһасендə генə килеш. Бəһасе очсыз түгел – йөз сумга 3 иен.

Биш йөзлекгə тукыз иен. Йөримез-йөримез. Һич артмый. Ахырдан еларга йитешеб, ахырдан николаевскиларны йөзне ун иенгə, яшел меңлене йөз алыштырамыз. Боздə алмасалар, нишлисез соң. Əгəр Русиядə товар китереб булса иде, товар алыр өчен алышдырырлар иде. Лəкин себер юлы тəмам хəлдə булганга, товар да китереп булмый. Шулай итеп без бер уч кəгазь күтəреб, ач калу ихтималымыз бар.

Андан кайтуга безне көтеп торалар, японларның əһле гыйлем, əһле калəм тиҗарəт галименең сəфирлəре, безгə японча бер ресторанда зыяфəт бирəлəр. Чəй эчеп шунда китəмез. Элгəре поезд берлəн, андан трамвай берлəн, андан ары тагы трамвай берлəн, андан ары җəяүлəп барып, зур бер суның якасына килеп җитəмез. Шунда зур бер ресторанга керəмез. Безне көтеп торалар икəн. Япон кызлары бик иелеп-бөгелеп каршы алалар (хезмəтчелəр хокукында ашханəлəрдə кызлар) аякларымызны салып, камыш намазлыклы бүлмəлəрдəн үтеп, озын коридорлар кичеп, югарыга менəмез.

Анда безгә махсус бүлмә хәзерләнгән, миндәрләр салганлар. Кич суыкмы булгангамы, кечкенә генә хәтфәләр куйганлар. Без аякларымызны бөкләп утырамыз, японлар тезелеп, безнең болай утыра белүемезгә гаҗәпләнәләр. Бездә дә шулай икәнне сөйлимез. Шуннан соң кунаклар берлә күрешәмез. Берсе Америкада һәм Берлинда дарелфөнүн бетергән. Бер хокук галиме. Хәзер бер якдан мөдәррис, икенче якдан тиҗар. Берсе зур-зур акционерное обществоның башы, Америка, Русия, Кытай берлә зур сәүдә итүче. Берсе - бер газетаның мөхәррире, башкалары рус-япон мохитендә күргән газета мөхәррирләре. Һәммәмезгә аерым-аерым подносляр берәр япон кызы чәй китерәләр. Чәйләре сары чәй. Шикәрсез, безгә, өйрәнмәгән кешегә, тәмле түгел. Әмма бераз эчәмез, шундан сүзләр башлана. Америка, Берлиндан кайткан кеше инглизчә яхшы сөйли.

Башкалар берлән сөйләшергә русча белә торган бер япон тылмачлык итә. Безнең хәл хакында сорашалар. Профессор гыйльми-мәдәни якларга әһәмият бирә. Мәдрәсә күпме, мәктәп күпме, әдәбият зурмы, матбугат баймы. Сәүдәгәр сату-эшенә әһәмият бирә. Нинди маллар чыга, кай шәһәрләрдә зур сәүдәгәрләр бар. Алар берлә ничек эш итеп була. Без монда японларның сәүдә мөнәсәбәтләренә кергәнлекләрен бик белгәч, үземезнең Харбин, Владивостокдагы сәүдәгәрләргә хатлар язып, монда килә алмыйсызмы, зур эш эшләргә мөмкин дип чакырдык. Ләкин безнең сәүдәгәрләр бик акрын хәрәкәт итә торган кешеләр булганга, килә алмадылар. Һәммәсенә дә бик күп изахлар бирәмез. Шундан соң ашлар бирелә башлый. Төрек ашларына бераз охшаган, ләкин саусызлары бик көчле һәм дә әчеле нәрсә бик күп, сөзеп балыкларын гына ашыйм, шулпалары тәмле түгел. Шундан соң бер хатын гитара кебек нәрсә күтәреп керә. Аның янында тагы берсе бар. Икесе дә картрак гыналар. Шунда төрле буяулар, аллыгөлле киемләрдә ике япон кызы керәләр дә элгәре сәламлиләр, андан безгә карап сәҗдә кылалар. Болар сәҗдә кылгандан гына без Алла булып китмимез, алар безгә сәҗдә кылгандан гына безнең

җарияләргә әверелмиләр. Ләкин без ни кушсак, шуны эшләргә хәзерлекләрен белдерәләр. Безгә хәзер бию башлана, диләр. Теге абыстайның берсе кылдан бал күзәнәге кебек ясалган нәрсә берлә чиртеп-чиртеп гитарасында уйный башлый. Икенчесе арнау йырчылар кебек тамак эчендән алып йырлый башлый. Кызлар биергә керешәләр. Ләкин бию гади бию түгел. Теге абыстай йыр берлән бер хикәяне сөйли. Гитарадагысы хикәядә әхвале рухияне әйтә. Болар шундагы кылынышларны уйнап күрсенәләр. Сүз берлән, хәрәкәт берлән, селкенү берлән. Аякларның гына түгел, кулның, йөзнең, битнең – бөтен әгъзаларның биюе берлән вакыйганың мәгънәсен әйтеп бирәләр. Биюләре бик матур, нәзек, нечкә генә. Хикәяләре бик мәгънәле булырга кирәк. Бик моңсу, кайгылы. Менә тәмам. Тагы гейшалар тезләнәләр, тагы безгә сәҗдә итәләр. Без рәхмәт укыймыз, кул чамамыз. Бер аш тагы ашыймыз. Тагы гейшалар тагы тезләнәләр, тагы сәҗдә итәләр. Болары бик яшьләр. Берсе бала гына – 12, 13 яшьләрендәдер. Тагы музыка башлана, тагы теге абыстай йырларга тотына. Тагы гейшалар оялып биергә тотыналар, болар тагы оста бииләр, тагы матур хәрәкәтләр тудыралар, тагы матуррак фигуралар ясыйлар. Шулай итеп дәвам итә. Без япон музыкасының безнең музыкага охшаганны – япон моңы берлән безнең моңымыз арасында бик зур якынлык барлыкны сөйлимез. Бездән татарча йырларга үтенәләр. Гомәр әфәнде «Ашказар» көен йырлый, гаять хушланып китә, икенче мәртәбә үтенәләр. Икенче йырлаганда шундагы бер япон кушылыб йырлый. Шундан соң бер мөхәррир иске япон хикәясендән Чыңгыз ханның маҗараларын шигырьләр берлән йырлый. (япон легендасы буенча Чыңгыз хан япон имеш. (моның хакында махсус хикәяләре бар, башка урында язармын). Гомәр әфәнде шул көйгә кушыла. Бәгъзе йырлар, тавышның дулкынлануы икенче тарафка борыла. Кан якынлыгы хакында бик күп сүзләр сөйләшеп, сәгать унбергә кадәр утырамыз. Ашаган-эчкән чакда сугындыру ысулы бар икән. Үзенең касәсенә салып су алып бирү зур кадер-ихтирамдан санала икән. Безне дә сугындыралар, без дә сугындырамыз. Мәҗлес

японча вакыт җиткәч, хөрмәтләре өчен мин бер хотбә сөйлим һәм дә төрк милләте берлән япон милләтенең дустлашуы өчен мәмнүниятдә булам. Аурупалы, америкалылар хәзер сезнең берлән бергә мәнфәгать төсле күренсәләр дә [...] чыкган. Сезне үзләре берлә күргәндән килгән эш түгелдер, фәкать сезнең куәтеңез, көчеңездән курыкгандан килгәндән нәрсә генә. Шуңарга күрә безнең төрк галәменең дөньяда дустлары булмаган кебек, сезнең дә дустларыгыз юк. Әхвалнең китеше буенча без Аурупалыларның шул дошманлыкларына корбан булдык. Сез әле вазгыятеңезне саклый аласыз, ләкин безгә килгән тәһлекә[1] сезгә мөмкиндер. Шуның өчен бу ике милләт бер-берсе берлә дуст булырга һәм дә берсенең берсе хокукын мөхафәзә итәргә[2] тиешдер. Азияле әкъвам бүгенге көндә Яурупаның аяк астында аның аурупалы, америкалыларның кәефләренә баглы, фәкать сезгә үзегезнең хокукыңызны мөхафәзәгә [...]. Ләкин бөтен Азия әкъвамы[3] шул золымны Аурупа, Американың золымын аңлый. Моңардан чыгарга юл эзли. Бу юл табылачак. Фәкать шул вакытда сезнең япон милләтенең безнең берлән, җәберләнгән милләтләр берлән бергә булуы лязем. Азия азиялеләрнеке дигән сәфәрнең зур байрагын сез күтәрергә тиеш. Минемчә, без шул фикердә дип җавап бирәмез. Бүген кич тәмам була.



Гаяз Исхакый фикердәшләре белән. Токио, 1919 ел

[1] Тәһлекә – куркыныч.
[2] Мөхафәзә – саклау.
[3] Әкъвамы – халкы.

**9 нчы май**

Бүген Токионың тәхетбай булуына илле ел тулу бәйрәме. Шәһәр зур бәйрәм итә. Микадо сараендан чыгып, әллә нинди бер гыйбадәтханәгәчә барачак. Мәктәб балалары урамларда байраклар күтәреп йөриячәк. Самурайлар үзләренең иске гадәтләре буенча рәсми кәмит ясыйлар. Мәгълүм ки, Япониянең халкын өч сыйныфка бүленмеш. Берсе кенәзләр, падишаһлар. Икенчесе самурайлар. Безнеңчә мирзалар, бәкләр, өченче сыйныф – халык. Милләтнең идарәсе, гаскәрнең идарәсе әнә шул самурайлар кулында булган. Аларның үзләренең зур оешмалары булган, үзләренең аерым гадәтләре булган, үзләренең аерым хокуклары, аерым вазыйфалары булган. Бу якдан караганда болар төрекләрнең ике бәйрәме бераз охшаганлар. Алтмышынчы елларда шул самурайларны руханилар тәрбиясендән алып, дөньяви тәрбиягә әһәмият биргәнләр һәм дә микадолык дәүләтен дөньяви бер падишаһлык хәленә китергәнләр вә сарайны руханиларның тәэсирендән чыгарыр өчен Киото шәһәрендән күчереп, Токиога китергәнләр. Шуның өчен бу сыйныф халык Япониянең элгәреге идарәсендә генә түгел, Япониянең асыл лөгатендә дә, Япониянең хәятенең Яурупалы ысулына күчүендә зур роль уйнаганлар. Ләкин шундан соң самурайлар сыйныф уларак куәтләрен гаиб иткәнләр, тугры юлга чыгарып, идарә эшендән ваз кичкәнләр. Менә шул Токионың пайтәхет булуының илле ел, самурайларның шул милли галәбәләренең дә илле ел булганга, алар да бәйрәм итәләр. Һәммәсе аерым-аерым байраклар берлән паркга баралар. Микадо үзе дә беренче самурай булганга, ул да бара. Киемләре үзләренә аерым. Байраклары хәзерге байракга бер дә охшамый, читдән караганда озын саплылар, пумалалар гына, ләкин янына барганда болар һәммәсе дә ат кылындан ясаган. Мәгълүм ки, иске төркләрнең байраклары ат койрыгындан булган. Шул койрыкны озын агачка кагып, шуны күтәрә торган булганлар. Төрле кабиләләрнең төрле төсдә булса, ат кыллылыгында һәммәсе дә мөштәрик булганлар. Икенчеләрнең байрагы җиде ат койрыгындан ясалган булган.

Менә самурайларның да хәзерге көндә пумала төсле күренгән нәрсәләр шулар. Димәк, бу төр безнең төрек кабиләләрендә генә түгел, монгол кабиләләрендә мөштәрик булган (хәзерге көндә Төркстанда шундый ат кылы эләктергән таякларны зиярәт өсләренә куялар). Үзләренең гыйбадәт кебек нәрсәләре бик кызык, ләкин янымыздагы япон һичбер төрле аңлата алмаганга, язу бик авыр. Болар, бер якдан караганда, төрекдәге мәүләвиләр бәйрәме кебегрәк нәрсә. Моны озын итдереп, тәфсилле итдереп күрә алмыймыз.

Урамда халык бик күп. Һава бик җилле, бик тузанлы, барырга бик ерак, трамвайлар йөрми. Автомобиль алырга мөмкин, ләкин ул да бүген бик кыйммәт. Безнең акчаның курсы бүген бигрәк очсыз. Шуңарга күрә ярты-йорты мәгълүмат берлә генә каламыз. Микадоның киемен дә күрә алмыймыз. Ул әллә кай вакыт үтеп өлгергән. Мәктәп балаларының кечүләре күңелле, һәммәсендә байраклар, һәммәсендә бәйрәм киемләре. Ләкин музыка юк. Гомумән, шул зур бәйрәмләрдә иң күзгә ташланган нәрсә – музыканың булмавы, булса да бик азлыгы. Шулай итеп өч көнлек бәйрәм үтеп китә.

### 11 ендә якшәмбе көн

Бүген Япониядә атналык бәйрәмен итәләр. Мөәссәсәләр ябык. Без барон Минатоны күрер өчен япон җәмгыятенә барамыз. Анда аны күрә алмаенча, дүшәмбе көнгә вәгъдә алып кайтамыз. Японларның еллары, айлары, көнләре Аурупа ысулынча түгел, аларда уникe ел бер дәвер, уникe ай бер ел, уникe көн бер атна. Елларның исемләре безнең иске төрек ел исемләренә бик охшаган.

Беренче ел – тычкан елы, икенче ел – сыер елы, өченче ел - барс елы, дүртенче ел – куян елы, бишенче ел – дракон елы (аждаһа), алтынчы ел – елан елы, җиденче ел – елкы елы, 8 нче ел – куй елы, 9 нчы – маймыл елы, унынчы – тавык елы, 11 нче ел – эт елы, 12 нче – кабан дуңгызы елы. Айларның саны цифр берлә генә йөри: беренче, икенче, өченче, дүртенче... Көнләр дә ел рәвешендә һәм еллар исемендә йөриләр. Шуңарга күрә аларда айны атналарга бүлү

булмаган. Ел японларча ай берлә сайланган. Язу да сәнәи шәмсия дә, сәнәи камәрия дә йөргән. Соңгы елларда Америкага тәкълидән якшәмбе көн бәйрәм итә башлаганлар. Бүген көн әһәмиятсез генә үтә. Милли идарәдән хәбәр юк.

Акча курсы начар, Франсәдән дә җаваб килми. Тагы шул көнләрдә Нияз әфәнде дә китәчәк булганга, без бөтенләй кулсыз-аяксыз каламыз. Мин инглизчә укыр өчен мөгаллим эзләсәм дә, таба алганым юк.

**12 нче май**

Бүген безнең эшләр бик күп, берсе бүген безне инглиз сәфарәтендән мәктүп язып чакырдылар, икенчесе бүген безгә барон Минато вәгъдә куйды, өченчесе Гомәр әфәнде Йокоһамага акча курсын белергә китде. Нияз әфәнде тиз китәчәк булганга, без беренче эш итдереп, тагын автомобиль алып, Франсә сәфарәтханәсенә барамыз, анда тагы яңа хәбәр юк, җавап көтәмез, килергә тиеш иде. Килде исә җавап бирәмез диләр, андан саубуллашып чыгып китәмез, туп-тугры барон Минато берлән күрешергә китәмез. Ул да безне көтеп тора икән. Мәсьәләне аңлатамыз. Безнең Аурупага чыгуымызга японлар ярдәме дә булсын иде димез һәм дә япон пароходларында урын табу җиңеләйтсәгез иде дип үтенәмез. Барон пароход мәсьәләсе зур түгел, тегесе хакында уйлашыйм әле, тиз генә җавап биреп булмый, мин сәясәт дөньясындан түгел, кулдан ни килә, шуны эшләрмез, ди. Андан да эшне бетереп кайтамыз, Гомәр әфәнде дә кайткан, шатлыклы хәбәре бар. Бүген рус акчасының курсы сумына бер тиен күтәреләчәк, ягъни рус акчасының сумы җиде тиенгә хисап ителеп алына башлаган, без һәрвакыт начар хәбәр ишетергә өйрәнгән кешеләр, моңарга да сөенәмез. Аштан соң чакырылган мәктүбне алып, инглиз сәфарәтханәсенә китәмез, анда безне сәфарәтнең мөстәшаре кабул итә. Аңарга мәсьәләне аңлатамыз. Беренче мәсьәләдә Русиядә без русларга баш дип белмиләр, анда бездә утыз миллион төрек халкы бар, безнең дә мәнфәгатемез бар, без дә Русиядә тынычлык телимез, ләкин үземезнең мохтәриятемезне мөхафәзә шарты берлән.



Гомәр Терегулов (1883–1938)

Безнең теләкләремез – Төркестан, Казакстан, Кырым, Кавказ, Идел буена мохтәрият алудыр. Моны билфигыль[1] алган да идек, ләкин большевиклар җимердерләр. Хәзер большевик белән сугышып ятамыз, икенче якдан Колчак хөкүмәте дә безнең мохтәриятләремезгә каршы килә, аның берлән дә тартышамыз. Шуның өчен Русиядә бер-бер хөкүмәтне тану дигән мәсьәлә тора, безнең шул хокукларымыз игътираз итү шарт ителсен иде. Икенчедән, без – солых әгъзалары. Русиянең хәле Яурупада хәл ителәчәк булганга, Яурупага чыкмакчы булып килдек. Яурупага китү хәзер бик авыр икән, шул юлда ярдәм итүегезне үтенәмез. Сәфарәт кешесе бик күп сөальләр бирде. Җаваблар бирдек, безнең хәят хакында гына түгел, Русия хакында да мәгълүматы бик зәгыйфь икән. Безнең мәукыйг җәгърафиямезне бик яхшы итдереп, Идел буе, Кавказ, Төркестан дип әйтеп бирсәк, сез диңгез мәмләкәтендәнме дип, әллә ничә сорады. Ахырдан рус сәфарәтханәсендә булындыгызмы, диде. Хәер, булынмадык, лөзүме дә юк, чөнки ул сәфарәтнең һанги хөкүмәтенең сәфарәте икәне безгә мәгълүм түгел, дидек. Сез безнең берәр кешемез берлән күрештеңезме, диде. Хәер, күрешә алмадык, чөнки ул эш мәгълүм булса, Колчак хөкүмәтенең казаклары атып үтерү ихтималы бик якын иде дидек, шундан соң без сезнең хакыйкатән шул кешеләр икәнегезгә иманымыз тулы булса, сезгә визаны тиз ясар идек, хәзер хөкүмәтдән рөхсәтсез ясап булмый, шуңарга күрә телеграф берлә җавап сорыймыз диделәр. Шундан мин бу хосусый кешеләр өчен эшләнә торган юл, без – милләт вәкилләре, безгә мөгамәлә

[1] Билфигыль – чынлыкта.

башка булырга тиеш иде, дидем. Сезнең мандатларыңыз бармы, диделәр. Бар, дидем. Ләкин һаман шул иске сүзләрендә калдылар, шундан мин сезнең Русияне белүчеләрегездән профессор Тани (?) һәм дә Һарвард Уильямс (?) яхшы белә, дидем. Шундан соң мәктүбләр берлән җаваб бирергә булдылар. Без күрешеб чыгыб китдек. Нияз әфәнде бүген китә. Ул иртәгә иртүк китәчәк. Мин кич буе милли идарәгә мәгърузә[1] яздым һәм дә Харбингә, Иркутскига, Томскига мәктүбләр яздым. Бүген бераз төрекчә белә торган бер япондан инглизчәгә дәрес алырга башладым. Ләкин япон булганга, үзенең тәләффызы[2] начар, *р* хәрефен бер дә тәләффыз итә алмый. Шуңарга күрә канәгатьләнмәдем. Хәерле булсын.

**13 нче май**

Бүген Нияз әфәнде иртүк китде. Без үз башымызга калдык. Бераз авыррак булыр инде. Фазылбәк килеп, безгә үзенең дәрес бирүгә теләвен тәкъдим итде һәм дә Йокоһамага күчәргә кирәк дип тәүсыядә[3] булды. Без үземез дә Йокоһамага күчү уенда торамыз, ләкин сәфарәтханәләр берлә монда безнең эшләр багланган.

Гомәр әфәнде эшдән соң Йокоһамага барып, бүлмә эзләб кайтды. Таба алмаган, ләкин булачак кебек күренгән. Анда китүдән беренче максад – хәятне очсызландыру. Монда бик һәйбәт булса да, монда шактый бәһале, мин ашау-эчү берлән ун иен түлим, Гомәр әфәнде тукызны. Бу акча да хәзер безгә күп төсле күренә, чөнки акча аз, шуңарга да күз теккән кешеләр бик күп шикелле, соң халык шундан булгач.

Беренче мәртәбә чит дәүләтләргә вәкил күндергәндә фәкыйрь, рәзил[4] булмаслык итдереп эш кубардылар. Бу отельдә әлегә кадәр Америка фирмаларының приказчиклары торалар, көнләп кенә түгел, айлап, еллап торалар, тора алалар. Без – олуг бер

[1] Мәгърузә – доклад, проект.
[2] Тәләффызы – сүзне әйтүе.
[3] Тәүсыядә булды – киңәш бирде.
[4] Рәзил – түбән, начар.

милләтнең олуг йомыш берлән җибәрелгән вәкилләре – көненә ике-өч сум файданы расход, читкә чыгарырга мәҗбүрмез. Бүген дә рус акчасының курсы кими-кими. Бәгъзе йөз сумына бер иен күтәрелгән. Көн шулай үтә.

**14 нче май**

Бүген һичбер яңа эш булмады. Фазылдан гына безне иртәгә чакырып мәктүп алдык. Бүлмәләр тапкан. Ләкин миңа әле күчәргә муафикъ түгел, эшләр бераз бар. Монда кеше күрү дә уңай. Бүген Харбиндан беренче май рус газеталарын алдык, бик кичегеп килә, цензор тота булырга кирәк. Кич берлән йөрергә чыккан идем, кызык бер вакыйгага очрадым. Бер кеше зур урамдагы телефон баганасының иң югарысына чыкган да, әллә ниләр сөйли. Урамга дүрт-биш йөз кадәр халык җыелган. Теге кулын бутый, йырлый, әллә ниләр сөйли. Түбәндәге халык шарык килеп көлә. Халык янына бик күп городовой җыелды, ләкин халыкга һичбер сүз әйтми. Урамга халык тулгандан-тула бара. Трамвайга йөрергә бик авыр. Трамвай бик акрынлап үтә, автомобильләр чират көтә. Халык һаман җыела. Теге җүләр һаман сөйли, йырлый, көлә. Түбәндән аңарга кул да чабалар. Менә бер эшче кыяфәтендәге кеше баскыч берлән тегенең янына менә, төшәргә чакыра булырга кирәк, ике арада мөназарә китә, халык һаман шаркылдый. Ахырдан теге чакырырга менгән кеше бер ни эшли алмый төшеп китә. Теге җүләр тагы шәбәя, ул, азан әйтергә хәзерләнгән кебек, аягүрә баса, кулы белән бутана, әллә ниләр көлдерә. Аны чакырырга икенче кеше менә. Аңардан көлеп төшереп җибәрә. Ахырдан үзе җиләнен рәтләп, билбавын рәтләргә тотына, җил берлән чабулары ачыла, үзенең штаны да юк икән. Халык тагы шаркылдый. Шундан бик җидди кыяфәт алып ,бик тиз тимерчыбыкдан тимерчыбыкга маймыл кебек әләгеп, тырмашып төшеп тә китә. Ләкин төшү берлән үзен халык чормап ала. Полиция каядыр алып китә.

Иң гаҗәбе шул – шул җүләрнең кылануына ун-унбиш минут

халык да түзеп тора, полиция дә бер эш дә эшләми. Кем булгандыр, мәгълүм булмады яисә исерекдер, яисә бер җүләрдер. Ләкин, кем булса да, унбиш минут буенча шул урамны рәхәтләндерде.

### 15 нче май

Бүген мин бик каты авырып уяндым. Тәрәзәне ачык калдырып яткан идем дә, төн суык булган, ахырда суык тигән. Кәеф бик начар булганга, иртүк торып, алмаш әйберләр алырга базарга чыкдым. Минем һич бер төрле пальтом юк. Сатып алырга акча кызганыч. Әлегә кадәр анда-монда зуррак йиргә барганда Нияз пальтосын киеп бара идем. Инде ул да китде, шуның өчен пальто алырга мәҗбүр булдым һәм дә яңа пальто алдым.

Өйләдән соң Йокоһамага китдек. Фазылбәк безгә бүлмә табдым дип хат язган иде. Ләкин бүлмәләр бик начар, акчамыз бик аз булса да, анда барып тору бөтенләй базарны төшерәчәк булганга, алмадык. Гомәр әфәнде яңадан бүлмә карарга калды. Бүген Иркутскига газеталар һәм дә хат җибәрдем. Һавалар суык, көнләр ягмурлы. Юешлек күп. Без килгәндән бирле монда бездәге җәй кебек эссе көн бер генә булды. Бер йирдән дә хәбәр юк.

### 16 май

Бүген иң күңелсез вакыйга. Монда жандармский правлениенең бер чиновнигының визиты булды. Япониягә барырга уйлаганымның монда бик кыскалык дигәнне сөйләгәнләр иде. Ләкин без һичбер төрле яшерен эшемез булмаганга, бер нәрсәдән курыкмаган идек. Монда килгәч дә шул юлда дәвам итдек. Бөтен теләкләремезне ачыкдан-ачык сөйләдек, ачыкдан-ачык яздырдык. Ачыкдан-ачык мәгърузәмезне кешеләргә бирдек.

Шуның өчен безнең астан алай тикшереп йөрерлек эш булмаска тиеш иде. Ләкин без килеп бер-ике көн торгач да, безне полиция чиновнигы зиярәт итде. Әллә нинди мәгънәсез-тозсыз сөальләр бирде, һәммәсен язды.

Андан тагы бер-ике-өч көндән килеп, тагы әллә ниләр сорады. Үземезнең бәгъзе кәгазьләремезне күрсәтдек, газеталар укырга кушдык. Андан соң тагы бер проводник алып килде. Анысында сез үзегезгә хөкүмәт төземәкче буласыз икән, фәлән дип сөальләр бирде. Без әүвәл синең эшең түгел, без монда эш берлән килгән кеше, үзеңә кирәген генә сора дип кырт кисдек дә китдек. Андан берәр атнадан тагы килде. Әллә нинди тозсыз-татсыз сөальләр бирә башлады. Мин бик каты кискәч, мине сезгә яхшылык итәр өчен генә йөрим. Менә китәргә телисез икән. Пароход белешергә кушдылар. Сезгә ике урын кирәкме, өчме, фәлән дип сүз башлады. Алай булса, ярый-фәлән дип әйткәч, тагы үз эшенә керешде. Кырыгынчы мәртәбә сез килдегез, ни эш язасыз. Мин тагы ачуландым. Моның берлән көрсенеп чыгып китде. Бүген иртә берлән жандармский правлениенең тылмачы дип берсе килде, русча начар гына сөйли. Элек паспортны сорады. Ахырдан бик күп сөальләр бирде. Кайсысына җавап бирдем, кайсысына бирмәдем. Тагы ник монда килдең мәсьәләсенә җиткәч, озын итдереп ник килгәнне, үземнең махсус йомышым берлән түгел, милләт йомышы берлән килгәнне сөйләдем. Бик ачу килгән булганга, озын итдереп үземнең хәлне аңлатдым. Хәйләкәр генә күзле, әллә нинди ябыша торган сөальләр берлән мине большевик түгелме дип имтихан итүче апдырап калды. Кәгазенә язган бик күп сөальләр булса да, фәләнен-кәгазен тыгып куйды. Шундан бер япон кебек безнең халыкның тормышындан сөальләр бирә башлады. Сезгә безнең берлән бер икътисади бер иттифакъ ясарга кирәк иде диде. Японларның һәммәсенең теләкләре шул. Икътисади бер иттифак ясау. Ләкин андан үзләре генә файдаланырга уйлыйлар, башка халыкның мәнфәгатен аңлавын һич хәтерләренә дә китермиләр. Башка милләтләр берлә эш итәргә өйрәнмәгән, мәнфәгатьләрнең берлеге әсасына эш күрми, әллә аңламыйлар. Үзләренә килгән яурупалы, америкалы һәрвакыт үзләренә хәзер итеп кенә торганга булырга тиеш. Яхшы ният берлән килгән кешегә һич ышанмыйлар.

Гомумән дә, яхшылыкга ышанмыйлар булырга кирәк. Япониядә хәят низагы бик каты булганга, һәр нәрсәгә каршы мәгълүм кадәр акчалата бәһа тәгъйин ителгәнгә, болар зур гаяләр[1]-идеяләр өчен хезмәтне болар аңламый кебек тоелалар.

Һәр нә исә Русиядә Николай заманасыннан да ямьсез итдереп [...] эшен кую, килгән кешенең берсен большевик дип утыртып куеп, Габделхәмид идарәсендәге кебек артыннан кеше йөретүләр шулкадәр мәмләкәт мәйданга китергән, шул кадәр кыска вакытда шул дөсле дә мәдәни якдан үскән японлар өчен гафу итмәслек гаебдер. Һәрбер аңлы кеше, үз-үзенә ихтирамы булган кеше алдында үзләренең мәдәни дәрәҗәләрен бик түбән төшерә торган мәгънәсезлекдә бүген һичбер яңа мәсьәлә булмады. Шул визиткә эч пошды. Ахырдан уйлый-уйлый монда ашын ашап ята торган Русия сәфарәтханәсенең доносы гына түгелме дигән шиккә төшдек. Ни булса да күңелле түгел... Хәерле булсын.

Гомәр Йокоһамадан номер табып кайтды. Иртәгә күчәчәк, мин ялгыз калам.

**17 май**

Бүген иртүк көн төш сөйләү берлән башланды. Без инде күбдән хәбәр алмаганга, Петропаулда ни бар, ни юк, безнең берлән барырга сайланган кешеләр кайда, каян киләләр икәне мәгълүм булмаганга, шул сөальләрнең һәммәсенә җавапны төш берлән генә эзлимез. Мондан берничә көн элек безгә дип җигелеп куелган тройкага Солтанбәк утырырга теләгәнен һәм утыра алмаганын күреп, Солтанбәкнең килә алмавына юраган идек. Бүген Фуадның килүен күрдек, аның да килә алмавына юрадык. Хәзер Себер гаскәре Казанга җитеп килгәнгә, Фуадның ул кадәр тырышып сайланган эшендән кире кайтуы бик ихтимал. Ул бу эшләрне берсен дә ышангандан, иман берлән файда була дип эшләми, фәкать кешедән калмас өчен генә эшли. Әгәр шулай булып чыкса,

[1] Гая – теләк.

безне юкга ике ай көтдерүләр бушлай һавага оча. Һәр нә исә инде күбдән шул эшне ача торган берәр хәбәр булырга тиеш. Икенче эш – Гомәр бүген Йокоһамага күчеп китде. Эч пошкандан бер эш булсын әле, аз булса да үзгәреш булсын дип күчү инде, ни булып чыгар. Файда итәрме?

Номеры мондагыга караганда очсызрак. Бүген мин төркчә белә торган япон берлән японларның милли концертларына бардым. Концерт Америка миссионерларының залында булды. Зал бик зур түгел, алай да халык тулы түгел иде. Тыңлаучыларның йөзгә туксаны хатынлар, кичке концертларда ирләр күбрәк булучан икән. Хатынларның бөкрәеп беткән карчыклардан башлап, имчәк баласына кадәр һәр сыйныфы бүген бар. Халык урта сыйныф булырга кирәк. Байча киенгән хатынлар бик аз. Пәрдә ачыла. Залдан сәке кебек күтәреп эшләткән сәхнәдә халыкга каршы биш кеше утырган. Икесенең кулында озын буйлы өч кыллы гитара кебек бер уен коралы. Өчесе алдына Истанбул мәсҗедләрендә, мәдрәсәләрендә китап куяр өчен алдына куйган, югары башы күтәрелеп тора торган көрсиләр, аларның артына тезләнеп утырган кешеләр рөкугъга киткән кебек астларына бөккәнләр. Берсенең дә башы күренми. Менә акыртын гына, сузып кына астларына сирәк-сирәк чиртеп куя бер музыкант. Үзендән әллә нинди тавышлар чыгара. Менә башын бөгеп моракабәгә[1] киткәнләрнең берсе башын акрын гына күтәрә. Авызын озын гына йомып тора да, акрын гына ачып, тамак эчендән сафларын чыгарып, бер нәрсә көйләргә тотына. Тавышы бик авырлык берлән чыга. Йөзе кызара, тамырлары бүртә, үзе йыртылырлык була. Бер кычкырыбрак җибәрә, бер эчкә таба тавышын ашый. Безгә бер дә тәме булмаса да, бик мәшәкатьләнә. Менә акрын гына күршесе башын моракәбәдән күтәрә, йырлаб китә. Беренчесе туктый.

*Текстны Ләйлә Гарипова әзерләде*

[1] Моракабә – уйга чуму.

## 4 нче дәфтәр
## 1919 ел (май–июнь)

Тавыш берлән бер аз көчәнгәннең соңында, өченчесе башын калкыта. Андан өчәүләп тотыналар, төрле тавышлар чыгаралар. Кычкыралар, эчкә тавышны тарталар, бик маташалар. Надан шәкерд сабак укыган кебек арыйлар. Ләкин минга дыдык кешенең[1] ашыгып сөйләргә теләгене кебек хис калдыра. Бер якдан ачуны китерә, икенче якдан шул зур ук карт кешеләрнең шулай зәхмәт чигүләрен кызганасың. Тәмам. Халык кул чаба, бу бер тарихи әкиятне йыр берлән әйтү икән, күңелле имеш. Пәрдә ябыла, тагы ачыла. Бу юлы өч-дүрт кеше «Юләр яз» дигән музыка парчасын уйнап чыгалар. Беренче башлап уйнаганлары бию көе, күңелле генә, җиңгел генә, безнең «Әтнә көе»нә бик охшаган. Монысында музыйкый як[2] куәтлерәк, урталары да бер җырдан гына гыйбарәт түгел, бер вәзене бар, ахыры тагы күтәренке кылларда шадлыклы, кәефле бию тавышлары берлә бетә. Монысы соңгырак заманның көе икән. Шундан соң тагы пәрдә ябылып, пәрдә ачылган. Бер хатын, ике ир чыгып тезләнәләр. Хатын уртада, кулында өч кыллы гитара. Хатынның бер ягындан бер ир курай тоткан, икенче ягындан бер сукыр берничә кыллы озынча итдереп эшләгән ситра[3] кебек нәрсәне йиргә сузып салган (буе ике аршын кадәре бар). Менә бер якдан уйный башлыйлар, икенчедән үзләре йырлыйлар. Боларның уен коралларындан да, үзләрендән дә өчесендән өч төрле тавыш чыгып, бергә кушылганда бик матур булып китә. Озын бер көй уйныйлар, ерлыйлар, безнең «Агыйдел буйлары» дигән көйне хәтерләтә. Кайбер йирләре тәмам безнең көй төсле булып, кайбер йирләре бөтенләй «чәршәмбегә» борыла. Бусында музыкалык күп, моны мин дә рәхәтләнеп тыңлыйм, бу көй миндә әллә кай йирләремә тәэсир итә. Хосусан курайчының борып йибәрүләре тәмам башкорд дәрдләрен күз алдына китерә (курае камышдан). Халык

[1] Дыдык кешенең – тотлыга торган кешенең.
[2] Музыйкый як – музыка ягы.
[3] Ситра – цитра.

бик каты кул чавып[1] озата.

Андан соң бер мәгънәсез нәрсәне бик озын чыелдаталар, андан соң бию. Ләкин бию гади бию түгел: гакылдан язган бер хатынның биюе. Хикәя шундан гыйбарәт: бер хатынның бердән бер угълын караклар урлап Токиога коллыкга сатканлар. Хатын шуның кайгысындан гакылдан язган, ләкин үзе, йөрәге сизеп, Токиога таба килә. Токиога килеп җиткәч, алдында зур су. Аны чыгарга күпер юк. Көймәчене эзли. Көймәче иптәшләре берлән уйнап-көлеп, биеп утыра. Хатынның көймәчегә түләргә акчасы юк, көймәче: «бер биесәң, бушлай чыгарам һәм дә угылыңны күрсәтәм», ди. Хатын бии, биюе бик зур хис калдыра. Ләкин бер төрле палар бик күб мәртәбә тәкрарланганга караучыны ялыкдыра. Шуның берлән сәгать 1 дә башланган концерт дүрт ярымда бетә. Уйнаган вакытда тыңлаучыларның барысы да диерлек кулларындагы баскан кәгазьгә карап баралар, һәммәсе бик дикъкать берлән тыңлый. Тавышлану-нитү һич юк. Гомумән, музыкалары бик ибтидаи хиссият калдыра. Бер дә тәрәкъкый итмәгән булырга тиеш. Номерлары бик озын – тавышның әйләнүе бик бер төсле. Ерлаучыларның тавышлары бердә матур түгел, концертда Яурупалы бер дә юк иде. Бүген чәйне, кичге ашны ялгыз ашадым, эчдем. Хат-хәбәр юк.

## 18 май

Бүген бераз хасталанып тордым. Баш авырта, кәеф юк. Бер якдан, мигъдә[2] начар, икенче якдан, әхвәл шәп түгел, өченче якдан, киләчәк бик караңгы. Шуларның барысын бергә җыйгач, иргә кешегә[3] түшәккә ятырлык кәефсезлек була. Иртәдән, сәгать алтыдан ук уянып йоклый алмасам да, торып, юынып укырга керешдем. Әле чәйгә чыгарга бик иртә. Андан соң ваннага кереп, андан соң гына чәйгә чыкдым. Өйләгә кадәр көн шулай сүрән генә үтде. Өйләдән соң Гомәр әфәндегә Йокоһамага китдек. Номеры күңелле генә икән. Ашату-эчертү уртача гына ди. Ашның иң күбесе ботка

---

[1] Дөресе: чабып.
[2] Мигъдә – аш казаны.
[3] Дөресе: ир кешегә.

икән. Номерның хуҗасы, рус халкы ботка ашарга ярата дип ишеткән дә, ботка иң очсыз аш булганга, русларга ботка пешерергә тотынган. Гомәр әфәнденең бүлмәсендән чыгып китеп яңгы бер номер табдык. Бик матур урында тау башында, манзарасы диңгезгә, бәһасе дә кыйммәт түгел. Гомәр шунда күчәргә булды, мин дә язылып кайтдым. Мин дә бу Токиодан бик туйдым. Хәзер кич берлән бик арып торам, шуның өчен иртәрәк ятарга уйлыйм.

**19 май**

Бүген Нияз әфәндедән телеграмм килергә кирәк иде, ни өчендер юк. Иртә берлән тагы бер жандарм кереп хәл-әхвалне сорап чыкды. Рус-япон җәмгыятендә һаман әле безнең тәрҗемәне бетермәгәнләр, болай кичектерүләре касдән[1], әллә үзләре шул кадәр вәгъдәсезме? [...] хакында да һәм дә виза хакында да бер эш дә эшләмәгәнләр. Аларга ышаныч шактый кимеде. Бүген озак уйлап торып, японларның башка бер мөәссәсәләренә[2] барып визит ясадым. Зур илтифат берлән каршы алдылар, берәр сәгать сөйләшдек, бөтен әхвал хакында сорашдылар, минем мондалыкны элгәре дә белгәнләр, сүз арасында мәгълүм булды. Тагы берәр мәртәбә чакырырга булдылар.

Хариҗия нәзарәтенә[3] барыр өчен вәгъдә алырга кушдым. Чәршәмбе көн китәрмез төсле тора. Франсадан[4] хәбәр юк. Бик озынга калыр ахырысы. Сәламәтлегем шәп түгел. Мигъдәгә начар, баш авырта.

**20 май**

Бүген берничә мәртәбә барон Микатоны күрер өчен рус-япон җәмгыятенә бардым, тугры китерә алмадым. Аңардан шул виза мәсьәләсендә ярдәм сорар идем. Мәктүп-фәлән булмады. Өйләдән соң акча алышдырырга Йокоһамага китдем. [...] җиде иен илле

[1] Касдән – юри.
[2] Мөәссәсәләренә – оешмаларына.
[3] Хариҗия нәзарәтенә – тышкы эшләр министрлыгына.
[4] Дөресе: Франциядән.




Фуад Туктаров (1880 – 1938)

синт алдым. Гомәр[1] бүлмәсенә күчкән. Нинди буласы мәгълүм түгел, ләкин һавасы һәйбәт. Кич берлән кайтдым, Харбиндан телеграмма бар иде. Фуадлардан[2] һич хәбәр юк диелгән, безнең акчаның бер кыйсменә товар алганлар. Инде аны сата алмаенча йөдәмәсәк ярар иде. Бүген бер журнал китереп бирделәр, исеме «Мәшрике әгъзам» Асия милләтләрен берләштерер өчен тәэссис ителгән[3] икән. Нашире «Асиякай» җәмгыяте. Бу җәмгыятьдә японлар, чинләр, кореялеләр мәшьгульләр. Төрекләр, татарлар иштирак итә икән, ләкин соңгы вакытда җәмгыять һичбер төрле җанлылык галәмәте күрсәтмәгән. Шул җәмгыятькә визит берлән барырга торамыз. Рәшид казый заманасында башланган эш булырга кирәк. Теге мәкаләмезне бүген японча тәрҗемә итеп бетереп бирделәр.

**21 май**

Көтү дәвам итә. Иртүк японларның тагы зур бер сәяси мөәссәсәләрендән телефон берлә чакырдылар. Җомга көнгә вәгъдә бирдем. Рус җәмгыятендән һәм телефон бирделәр. Безнең йомышларны үтәп маташалар икән. Бүген өйләдән соң хариҗия нәзарәтенә барырга уйлап тора идем, тәрҗеман бик соң килде, нәзарәт ябылып калды. Хәзер безнең план бу: виза алу өчен барон Окумадан[4] ярдәм сорарга, ул да бер эш дә эшләмәсә, тагы берничә

[1] Гомәр – Гомәр Хәбибрахман улы Терегулов (1883–1938), юрист, меньшевик, Милли мәҗлес депутаты.

[2] Фуадлардан – Мәхмүт-Фуат улы Туктаров (1880–1938), юрист, журналист, Бөтенроссия Учредительный собрание әгъзасы.

[3] Тәэссис ителгән – оештырылган.

[4] Окумадан – маркиз Окума Сигэнобу (1838–1922), дәүләт һәм сәясәт эшлеклесе, дипломат, икътисадчы, Япониянең 8 нче һәм 17 нче премьер министры, Васадэ университетына нигез салучы.

сәфәрәткә мөрәҗәгать итеп, ярдәм үтенергә. Нияздан кыска гына ачык хат алдым. Чан-чундан яза. Өч көндә кайтып җиткән керешкә, бөтенләй акчалыкдан чыккан ди. Хәерле булсын, безнеке юк иде. Һавалар бик бозылды, ике көндән бирле бездәге көз ягмуры кебек, вак ягмур ява. Һава бик юеш. Ягмур мәүсиме[1] башланды булырга кирәк. Әхвале рухия шәп түгел. Өсткә йөкләтелгән вазыйфаны үтеп буламы-юкмы, бер Алла гына белә. Бүгенге гәзитәдә, 15 нче июньдә Бельгия – Голландия ходуды[2] ачылуы язылган, бәлки шунда китеп булыр. Тел булмауның хәтәре бик зур, тәрҗеман берлә һәр-нәрсәне сөйләп булмый. Телле булсам, әлбәттә, хәзергегә караганда күбрәк эшләп булыр иде. Нияз әфәнде андый бару-килүгә шактый саран булды. Андан соң, безнең эшне бераз кечкенәрәк иттереп тә куймады микән? Шундый шөбһәләр бар. Русиядә эшләр бер төрле бара кебек. Себер гаскәре Казанга якынлашып килә. Безнең авылда инде күптән фронт булып сугыш ачылды, бөтен кардәш-кабиләне эшдән чыгармаган булсалар ярар иде инде.

### 22 май

Бүген көн ягмурлы. Һава бик юеш, шуңарга күрә иртүк баш авыртып уянам. Көн буе китап укып вакыт үткәрдем. Бүген Гомәр әфәнде дә, теге төрекчә белә торган япон да киләчәкләр иде. Алар килгәч тә «Һуҗи шибун» идарәсенә китдек. Маркиз Окуманы тагы бер мәртәбә күрергә сорадык. Ләкин безнең бөтен әхвал берлә бик таныш булды дигән мөхәррир (Танабе Бошишко) безне җибәрмәде, тагы идарәгә алып керде, чәй китерделәр һәм дә бер мөхәррирә хатын кереп күрешде. Сөйләнә башлагач, мөхәррир безнең татар хатынының хәле берлә танышырга теләкне теләде. Без мәгалмәмнүният[3] җавап бирергә булдык. Шундан соң бик урынлы һәм дә хатын-кызча күп кенә сөальләр бирде. Берничә сөале берьякдан кызыклы күренмәсә дә, минемчә, бик урынлы иде. Ул: «Татарларда нинди хатын матур санала?». Мин: «Буе

[1] Мәүсиме – сезоны.
[2] Ходуды – чиге.
[3] Мәгалмәмнүният – шатланып.

уртача, сыны зифа. Биле нечкә, кара саче озын һәм калын. Йөз кара туткыллы. Күз зур, каш кара! Керфек озын. Бит уртасында кечкенә генә чокырлы. Авыз кечкенә, тешләр вак һәм ак», – дидем. «Татар хатыны ничек кияүгә чыга? Кияү сайлауда үзенең хакы бармы, әллә ата-анасы гына эшне тәмамлыймы?». Мин «хатын-кызның хәрәкәте хакында сөйләдем һәм дә шул хокук өчен булган тартышуларны аңлаттым да, хәзерге көндә кыз үзе сайлый инде, җәберләр юк», – дидем. «Татар хатынының тәрбиясе ничек?». Мин: «Хәзерге көндә мәктәп тәрбиясе күрмәгән яшь хатын-кыз юк диярлек. Һәммәсе укый-яза белә, ибтидаи мәктәпне бетергәнләр кул эше беләләр. Йорт идарәсенә өйрәнгәнләр, йортын сөяләр. Өйне ташлап урамда йөрмиләр. Өйне пөхтә, пакь, тәмиз[1] тоталар. Әхлаксызлык бик аз». «Татар хатынында качу һаман да бармы?». Мин: «Хәзер инде карт хатыннарда гына бар». «Татар хатыны баласын үзе тәрбия итәме, татар баласы ана сүзе берлә үсәме?». Мин: «Мотлакан[2], ана сүзе берлән үсә. Баланы татар хатыны бик сөя, кадерләп үстерә». «Татар гаиләсенең баласы күпме була?». Мин: «Уртачалап алты чамасында, бик күп балалы гаиләләр дә күп очрый». «Татар гаиләсендә ир бала күп торамы, кыз баламы?». Мин: «Ир бала». «Хатын-кыз арасында үз хәятын үзе тәэмин итә торганнары бармы, булса, нинди эшләрдә булыналар?». Мин: «Бар һәм дә күп. Хатыннарның иң зур эше хәзердә мөгаллимәлек. Андан соң бик күп хатыннар читек-кәвеш каеп, калфак, кәләпүш эшләп хәятларын тәэмин итәләр. Соңгы елда хатынларымыздан доктор-лар, адвокатлар да бар, зур мәктәпләрдә мөгаллимәләр бик күбәйде, елдан ел күбәя бара». «Татар хатыны хокукда мөсавимы[3]?». Мин: «Хәзер мөсави. Мәскәүдә булган съездда хатыннарның мөсавәте[4] хакында милләт тарафындан карар кабул ителде. Һәм дә шул съездда диния нәзарәтемезгә әгъза итеп бер хатын сайланды. Хәзерге көндә казый хатын бөтен ислам галәмендә фәкать бездә

[1] Тәмиз – чиста.
[2] Мотлакан – шиксез.
[3] Мөсавиме – бертигезме.
[4] Мөсавате – тигезлеге.

генә бардыр». «Татар хатынының иң зур хосусияте нәрсә?». Мин: «Ирендән аерылмавы һәм дә иренең кайгысыны-шадлыгын һәрвакыт бер итүе. Ире Себергә китсә, татар хатыны Себергә китә, ире чит мәмләкәткә чыкса, анда китә. Моның аркасында гаилә мохафаза ителә[1], татар гонсыры[2] әрәм булып әләф-тәләф булмый[3]».

Мөхәррирә рәхмәт укыды һәм дә шулар хакында гәзитәдә мәкалә язарга булды. Үзе «Һуҗи шибун» гәзитәсенең «хатын-кыз» дөньясын алып баручы гали тәрбияле бер ханым икән.

Андан соң без минга чанта (чемодан) алырга чыкдык. Ләкин бик бәһале кебек күренде. Җитмеш, җитмеш биш, сиксән иенләр акча кызганып ала алмадым. Йокоһамада очсызрак кебек иде. Кич берлә безнең «Империал отель»да танса булды. Бик күп кунак. Токио, Йокоһамадагы Яурупа халкының бик күбесе килгән сәбәбдән теге [...] кунакдыр. Танса башлана. Танса Америка тансасы. Гаҗәп бер танса. Һичбер төрле хәрәкәтләрдә, кыланышларда матурлык юк, һичбер күзне көлдерә торган кеше бизәкләре ясау юк. Ир берлә хатын берсенә берсе бик янәшә килеп кыймылдашалар да, бик каты ышкынышалар. Ышкына-ышкына бераз йөриләр дә, картырак хатынларның яшьрәк кешеләр берлә биегәндә кылынган кыяфәтләре аларның фәна фиддансага[4] кадәр җитүләре җирәнгеч хис калдыра, чиркандыра. Якынлык хисен мыскыл итә. Тансалар берсе артындан берсе дәвам итә, ләкин һәммәсенә дә мәркәзе сикъләт[5] музыкальныйлыкта түгел, фәкать тәнне-тәнгә ышкышуда. Гамәлият сөя торган америкалы дансада вакытын бушка әрәм итми, анда да реальный мәнфәгать чыгара. Русларда бу кадәр тупас хайвани тансалар булмый. Американың тимер юлы [...] фабрикасы да бик күп нәрсә чыгара торгандыр, тегермән машинасы да бик күп он тарта торгандыр, һәммәсенә [...]. Ләкин Америкада нәфасәт, нечкәлек кебек хисси нәрсәләр

[1] Мохафаза ителә – сакланып кала.
[2] Гонсыры – элементы.
[3] Әләф-тәләф булмый – юккачыкмый.
[4] Фәна фиддансага – биюдән ләззәткә.
[5] Мәркәзе сикләт – монда: хикмәт.

юк булырга тиеш. Һәрнәрсә торгаший аршины берлән, гирь берлән, доллар берлән үлчәнә. Җирәнгеч. Ни өчендер бүген күңелем «Әремнәр эчендә»ме, башка исемдәме берничә хикәядән мөрәккәб[1] мәҗмуга язарга күңелем төште. Мәҗмугада берничә хикәя улачак, һәммәсендә дә милләтнең балаларының әрәм булганларының хәле тасвир ителәчәк. Мәсәлән, милләт өчен әрәм булган Париждагы җәгърафия галиме анчак милләт өчен исраф булган. Равил Сыртланов: милләт өчен әрәмгә киткән, руска чыккан бер кыз, милләт өчен гаип булган, рус хатынына өйләнеп югалган бер егет.

Хәзер танса бетде. Сәгать унике, ләкин йырлау-бию тавышы ишетелгәч, мин коридорга чыкдым. Коридорда карт кына бер инглиз марҗасы берлә бер япон хатыны биеп маташалар. Мескенләргә танса бүлмәсендә биешергә пар булмаган да, хәзер шуның калдыгындан яланып маташалар. Дөнья тигез түгел шул. Мин үзем нишлим? Хәятның һәр тәмле, татлы манзаралары алдында сәерче[2] булам торам. Хәятның матур дулкынларындан читдә калдым. Япончага тәрҗемә ителгән мәкалә бик начар эшләнгән икән. Бик күп төзәтергә кирәк, ди. Хат-хәбәр, газета-фәлән юк. Шадлыклы бер генә хәбәр бар. Солых мәҗлесендә Истанбулны төрекләргә калдырырга карар биргәнләр. Һиндстан, Әфганстан, Мисырдагы хәрәкәтләр тәэсир иткән имеш.

**23 май**

Бүген сәгать бишдә безне Япониянең зур бер мөәссәсәсенең[3] шактый зур мәсьүл[4] кешеләре кунакга чакырдылар. Мәҗлесе кеченә иде. Танышу-аңлашу мәҗлесе иде. Сәгать бишдән ун ярымга кадәр бергә булдык. Ашадык, эчтек, бөтен әхваль хакында сөйләшдек. Монда килгәндән бирле японлар арасында безнең хәлне бу кадәр яхшы белгән кешеләргә очраганым юк иде. Боларның икесе дә безнең Татарстанда булган. Берсе әле күптән түгел генә

---

[1] Мөрәкккәб – җыелган.
[2] Сәерче – күзәтүче.
[3] Мөәссәсәсенең – оешмасының.
[4] Мәсьүл – җаваплы.

Чиләбедән кайткан. Бик күп өмидле сүзләр сөйләнде. Монда безгә шактый зур эшләр эшләргә мөмкинлеге күренде. Тәфсилле язарга муафикъ[1] күрмим. Көн шуның берлән тәмам булды. Ләкин үз ноктаи нәзарымдан Токиодагы көнләремнең иң тулысы булып үтде.

**24 май**

Бүген һава бик матур. Көн бик күңелле. Уку-йөрүгә башка бер эш дә эшләнелмәде. Фәкать баш назыйр[2] һәм дә хариҗия назыйры[3] берлән күрешү хакында вәгъдә генә алынды. Көне, сәгате әле тәгаен ителмәгән. Мин үзем бу Токиода торудан бик туйдым, быкдым[4]. Тизрәк ичмасам Йокоһамага күчәсе иде. Акчаның курсы һаман шулай. Милли идарәдән хат-хәбәр юк, Франсадан вә һакәза[5].

**25 май**

Бүген көн якшәмбе, монда бәйрәм итәләр. Японлар да үзләрен Яурупалы дип уйласынлар дип, якшәмбене бәйрәм итәләр. Өйләдән соң японларның зур бер зиярәтләренә бардык. Зиярәт бик пөхтә. Тирәсендә ихата юк, фәкать эче урам-урам итеп бүленгән дә, кечкенә-кечкенә зиярәтчекләргә аерылып, тирәсе тотылган. Һәрбер бүлем эчендә бер гаилә, бер фамилиянең зиярәте. Бик күбесендә зур бер таш куелган. Шуңарга кем үлгәне языла барган. Таш янында һәрбер зиярәтдә ике агач савыт. Болары кардәш-кабилә, йә дуст-иш килгәндә чәчәк куяр өчен икән. Бер тарафда кечкенә генә баганада, бездәге гәзитә-хат салыр өчен эшләнгән кебек ясалган кечкенә яшчиклар[6]. Аларның бер карточка салырга тишекләре бар. Бусы килгән кешегә карточкасын салыр өчен икән. Бәгъзе бер зиярәт йортларында ике яклап таш баганалардан фонарьлар ясаганлар. Гаиләдә үлек булса, йә бер махсус гыйбадәт булса, шулар

[1] Муафикъ – тиешле.
[2] Баш назыйр – премьер-министр.
[3] Хариҗия назыйре – тышкы эшләр министры.
[4] Быкдым (төрек.) – туйдым, гарык булдым.
[5] Вә һакәза – һәм башкалар.
[6] Дөресе: ящиклар.

ягыла икән. Зиярәтләрнең бик күбесе янында яңы[1], тазә[2] чәчәкләр куелган. Күбесенең өстенә сулар сибелгән. Бу арада чәчәк күтәреп килә торган бик күп хатынлар, ирләр, балаларга очрыймыз. Кабер ташларының искеләренең шәкеле[3] табигый ташлар. Күбесе таудан ничек чыкса, шул көенчә басдырып куелган. Соңгы еллардагы каберләрдә дүрт кырлы, безнең ташлар кебек. Агач бик күп, һәммәсе бик зур кадерләп үстерелгән. Артык ботаклары киселгән, яфраклары тигезләнгән. Сәрви[4] кебек, нарат-чыршы кебек, каен кебек зур агачлар юк. Юлларында һичбер чүп-чар юк. Зиярәт ямь-яшел, каберләр өсте чәчәккә баткан. Японлар зиярәтне бик сөяләр булырга кирәк һәм дә бик еш зиярәткә килә булырга кирәк. Шул ук зиярәтдә без японча язылган ташлар өстенә салиб[5] куелган каберләргә очрыймыз, болар христиан-японлар. Японийдә диндә хөррият булганга, монда зиярәтләр дә аерылмаган икән. Ләкин бу мәнфи[6], начар тәэсир калдыра, чөнки милләтләрдә иң нык саклана торган гадәт, йола – үлү-күмү гадәте, йоласы. Бонда милләтләр [...] гадәтләрен, йолаларын саклыйлар, үзләренә чит милләтнең гадәтен, йоласын кертмиләр. Японлар читләргә тәкълиддә[7] шул кадәр йомшаклар булырга кирәк ки, болар иң мөкаддәс булган зиярәтләрендә [дә] чит гадәтдән мөхафәзә итә алмаганлар[8]. Тагы шуны онытмаска кирәк, япон халкының игътикадынча[9] үлү – бетү түгел, фәкать башка рәвешкә керү генә. Шулай була торып да, шул кадәр мөсаһәлә[10] боларның бик җиңеллек берлән Яурупа мәдәниятенә, Яурупа диненә, Яурупа гадәтенә батачакларын

[1] Яңы – яңа.
[2] Тазә – монда: әле генә өзелгән.
[3] Шәкеле – тышкы күренеше.
[4] Сәрви – кипарис.
[5] Салиб – хач (тәре).
[6] Мәнфи – күңел кайтаргыч.
[7] Тәкълиддә – иярүдә.
[8] Мөхафәзә итә алмаганлар – саклана алмаганнар.
[9] Игътикадынча – ышаунуы буенча.
[10] Мөсаһәлә – җиңел генә карау.

күрсәтәдер. Ләкин монда христианлык тәдриҗи рәвешдә[1] тәрбия берлән бирелә. Мәктәп, матбугат, музыка аша керә. Бер зур зиярәт янына туктыймыз. Анның зур таш артына озын гына такталарга бик күп сүзләр язылып, уелып куелган. Бу бер рәссамә[2] япон хатынының кабере. Ул язган такталарда дустлары, сөйгәнләренең биргән адреслары. Уң якда визитный карта өчен яшчик. Мин дә карточкамны алдым да, шул яшчиккә салдым. Без бит икемез дә Олуг Асиянең ахмак балалары. Без бит икемез дә Олуг Асиянең үзенең кадерен үзе белми торган балаларына, үзенең кыйммәтле якларын күрсәтергә тырышучы, үзенең хәятының матурлыкларын күз алдына китереп, асияленең үзенә үзенең[3] ышануын уятырга теләгән җүләрләре. Син инде үлгән, мин әле йөрим, ләкин син бер эз калдыргансың, мин дә бер эз калдырачакмын. Бик ихтимал, синең рәссамлыкда ясаган Асиялек эзенең[4] күзен акайтып, Яурупалы хәят артындан чаба торган япон гәнҗе[5] таптап киткәндер. Китмәгән булса, китәчәкдер. Минем милли хәятымызда калдырырга теләгән эземне дә, бәлки, руслык кары, русларга тәкълид[6] басып киткәндер, йә китәчәкдер. Ләкин без үз вазыйфамызда булырга тиеш, син шул вазыйфа кебек, йә син дә инде үлгәнсең, мин шуның артындан монда килдем. Зиярәт янында ике яклап бик күп кабер ташы һәм кыр чәчәге [кисентеләренә] очрыймыз. Көн кич. Күрше казармада быргы чалып, солдатларны өйләренә җыялар. Без дә өйгә китәмез. Хәерле кичләр.

**26 май**

Бүген иртүк автомобиль алып Франса һәм инглиз сәфарәтханәләренә китәмез. Франсадан җавап һаман килмәгән. Англичанлар безнең хакда мәгълүмат алыр өчен Русиядагы

[1] Тәдриҗи рәвешдә – акрынлап-акрынлап.
[2] Рәссамә – хатын-кыз рәссам.
[3] Дөресе: үз-үзенә.
[4] Текстта шулай. «Эзеңне» булырга тиеш.
[5] Гәнеҗ – яшь (егет, кыз).
[6] Тәкълид – иярү.

инглизләрнең фәүкыльгадә[1] комиссарлары Ыслайтонга телеграф берлән мөрәҗәгать иткәнләр, шундан җавап алмаенча бер эш эшли алмыймыз, диләр. Без үземез Русиядә вакытда шул эшне бетереп килмәгәнмез. Омскда вакытда минем керергә зур ниятем булды, фәкать шундагы куркак кешеләр: «эш бозылмасын-фәлән, Колчак[2] белмәсен» дип, тискәрегә димләделәр. Андан соң минга бик күңелсез акча җыю вазыйфасы йөкләтелгәнгә, әллә никадәр гайрәт шуңарга китде. Киңәш итәргә кеше булмады. Фуадка шул хакда телеграмма биргән идем, ләкин ул үзенең көчен иң күбесен [Ижескага] бозарга сарыф итәргә өйрәткәнгә, әлбәттә, эшләмәгән. Харбинда Гомәр, куркып, башны әйләндереп, һаман шул минем планларымны сүтә килде. Андан соң, без монда чыгу ул кадәр авыр булмас дип уйлаган идек. Японларның да бераз ярдәмләренә ышанган идек, боларның берсе дә килеп чыкмады, хәерле булсын инде. Хәзер теләр-теләмәс күтәргә мәҗбүрмез. Өйләдән соң Гомәр берлән киңәшләшеп, Харбинга һәм дә Владивостокга китүче татар егете артындан, анда бәгъзе берәр эш эшләргә кушып, озын мәктүпләр язам. Бәлки бер нәрсә чыгар. Нияз әфәндедән һаман мәктүп юк. Бу арада гәзитә дә килми башлады, Милли Идарәдән дә хат юк. Кич берлән японларның иске театрларына барамыз. Аякдан ботинкаларны чыгарып, оекчан көенчә керәмез. Театрның бинасы бик зур. Үзе агачтан эшләтелгән булса да, сөнбеле матур. Ишекдән керүгә диварга сөяп куйган бик күп сонгый[3] букетлар каршы ала. Болар артистларга бирелгән бүләкләр. Идәндә җефәк арканлар берлән бәйләгән бүләк сандыклары тезелгән. Эчкә керәмез. Театр дүрт почмаклы итдереп эшләтелгән. Каршы якда сәхнә. Ләкин сәхнә эчкә кереп тормый, бәлки яртыга таба чыгып тора. Яртыга камыш намазлык җәйгәнләр дә, аны ике кеше сыярлык дүрт почмаклы шакмакларга тәбәнәк кенә киртә берлән бүлгәнләр. Ул

---

[1] Фәүкыльгадә – гадәттән тыш.

[2] Колчак – Александр Васильевич Колчак (1874–1920), рус хәрби сәясәт эшлеклесе, галим-океанограф, Гражданнар сугышы вакытында Аклар хәрәкәте җитәкчесе.

[3] Сонгый – ясалма.

шакмакларның идәненә кечкенә мендәрләр салганлар. Сәерчеләр шуларга кереп утырган. Зуррак кешеләр икешәр-өчәр, бала-чагалар дүртәр утыралар. Һәрбер шакмак эчендә бер гаилә. Ул үзенең шакмакында мохтар[1] түгел, камыш намазлыклы мохтар. Яртысы, иң тугрысы идән сәхнәдән ерагайган саен, өсткә таба күтәрелә барган сәхнәнең сул-уң як канатлары тәмам күтәртеп үк эшләтелгән. [...] соң тагы бер кат бар. Андан соң тагы бер кат. Без сәгать җиделәрдә барганга, яхшы урын юк. Алай да безне идәндәге бер шакмакка утырталар, астымызга мендәр салалар, алдымызга кечкенә генә мангал бирәләр. Бер чәйнек берлән япон чәе, кечкенә генә савытларда ике төрле япон татлысы, япон хәлвәсе китерәләр. Театр дәвам итә. Фәкыйрь бер гаиләнең ярлылык фаҗигасе. Әллә нинди сүзләр, бер нәрсә түгел. Уйнаулары һаман бер төсле. Артда чылтыр-чылтыр итеп думбыра суккалыйлар. Әллә нидә бер нечкә, җиңел тавыш берлән бер бала сузып-сузып бер нәрсә сөйли, күренмәенчә әллә кем, әллә нәрсә йырлый. Артистка ролен уйный торган зур иләмсез япон яшел тавыш берлән сөйләп, бер туктамаенча еглый. Уенларында осталык-фәләнлек бер дә күренми. Ләкин халык бик ярата булырга кирәк. Хатынлар бер туктамаенча еглап утыралар. Мин күршеләремә карыйм. Бер якда ирле-хатынлы бер гаилә унике-унөчле[2] кызлары, тугыз-унлы угыллары алдына утырган, карап утыралар. Өч-дүрт яшьлек бер балалары атасының итәгенә яткан да, йоклап тора. Хатыны кулына ике чыбык тотып дөгене бер алып каба да, бер сәхнәгә карый. Бер карый да, бер алып каба. Әфәндесе[3] тагы ике чыбык тоткан да, бер дөгедән, бер серкәләгән яшелчәләр капкалап, сәхнәдән күзен алмый. Уң як күршемдә карт кына бер хатын кечкенә генә касә берлән чәй эчә. Ике-өч яшьлек бала үз шакмакларында уйнап йөри. Яшь кенә бер хатын әфлисунлар әрчеп-әрчеп ашап утыра. Театрда бала бик күп булса да, тавыш юк, халык тын, һәммәсе тезләнеп, аягын бөкләп, рәхәтләнеп утырганлар. Бик күбесендәге

[1] Мохтар – ирекле.
[2] Дөресе: унике-унөч яшьләрдәге.
[3] Әфәндесе – ире.

чалбар – анадан туган чалбарлар булганга, ялангач, безнең кебек тезе бөгелүдән һич курыкмыйлар. Ләкин уен вакытында һаман йөреп торалар. Берсе чыга, берсе керә. Бер официант чәй китерә. Бер сатучы мивә[1] китерә. Бер ашчы дөгеләр-яшелчәләр күтәреп үтеп китә. Менә тәмам. Пәрдә төшде, иң тугрысы, безнең авыл өйләрендәге кебек пәрдә тартылды. Халык бераз хәрәкәткә килде, торды, чыкды, без дә чыкдык. Югарыгы катларны гиздек. Бөтен коридор кеше берлән тулган. Җыен чүп-чар, шара-бараны саталар да торалар. Кем ала, ник ала – Алла белсен! Югарыда ике буфет, берсе аяк бөкләп утырырга, берсе урындыкка. Анда ашап-эчеп утыралар. Тар коридорда тыгыла-кысыла хатынлар йөриләр. Менә агач чүкеч берлән агачка сугалар. Бу пәрдә ачылуга галәмәт. (Финляндиянең Сеймында да «Дикъкать» дигән әмерне рәисе агач чүкеч берлән агач сугып белдерә). Урыныбызга утырамыз. Пәрдә күтәрелә. Дикаратсия[2] бик матур: диңгез, көймәләр, җилкәнләр, дулкынлар бик һәйбәт эшләтелгән. Япониянең катыргасы[3]. Ләкин бу юлы да уен бик бер төсле, бер вакыйга бик озын сузыла. Бер мәртәбә еглап бетергәнче, эш өчен ун мәртәбә еглатыла. Яңгы пәрдә ачылды. Монысы иске бер әкият: шайтанлар, пәриләр, самарайлар, гейшалар. Һәммәсе бик күңелле генә, ләкин хатын ролен ирләр уйнаганга, бик чиркен бер хис калдыра. Без китәргә буламыз. Җыенына[4] ике кешегә җиде иен алалар. Шактый бәһале[5]. Һәммә урын бер бәһадән икән, ләкин үзләре өчен бәһале түгел. Бердән, ул иен аларга һаман элгәреге иен. Икенчедән, алар иртәнге сәгать ундан килеп, кичке сәгать унбергә кадәр утыралар икән. Болар бөтен гаиләсе берлән иртәдән үк килеп, шунда ашап, эчеп, шунда көн буе үткәрәләр икән. Иң тугрысы болар айга бер, ике айга бер театр эченә хозурга чыгалар икән. Бәлки бу театрлар тагы тәрәкъкый итә төшәр. Ләкин бу әле балагандан зур аермалы түгел.

---

[1] Мивә – җиләк-җимеш.
[2] Дөресе: декорация.
[3] Катырга – көймә төре (галера).
[4] Җыенына – сеансына.
[5] Бәһале – кыйбат.

**27 нче май**

Бүген һичбер телгә алырлык эш булмады. Иртәдән хәстә булып уяндым, көн буе кәефсез үткәрдем. Йокоһамага барып, ике мең сум акча алыштырдым. Сумына унберәр синт[1] бирделәр.

**28 май**

Бүген иртүк торып, Швеция һәм дә Голландия сәфарәтханәләренә китдем. Максадым – ничек булса да алардан виза алу. Шведлар бик дустча[2] кабул итәләр. Үземезнең хәлне сөйлим. Ләкин: «Нишлик – бер эш эшләп булмый. Эш безнең кулда түгел. Һичбер төрле ярдәм итә алмыймыз, чөнки [...] инглизләр, америкалылар, французлар кулында, алар [...] очрыйлар. Без бер эш эшли алсак, мәгальмәмнүният эшләр идек. Голландия бер-бер ярдәм итә алмасмы», диләр. Бу әфәнде берлән күрешеп чыгып китәмез. Моның дустча мөгамәләсенең сәбәбләрен эзлим. Иң зур сәбәбе – безне яхшы беләләр. Чөнки боларның вәкилләре Салибе Әхмәр[3] җәмгыятьләрендә Германия, Төркия әсирләренә ярдәм иткәндә һәр йирдә татарларның ярдәм җәмгыятьләренә очрадылар, һәр йирдә татарларның инсанияткяранә[4] мөгамәләләрен күрделәр, татарларның мәдәни бер милләт икәнләрен белделәр, шуның өчен бу әфәнде минга вәхши халыкларның бер кешесе дип карамаенча, бер милләтнең вәкиле дип карады. Ул да күңеле боек күңелне шул аз нәрсә дә ачды. Вакыты берлән башка ахмакларга да кем икәнемезне танытырмыз әле. Голландия сәфарәтханәсенә китдек. Анда да мәсьәлә шул: «Рәхәтләнеп виза бирер идек, ләкин эш безнең кулда түгел. Хәзер сугыш вакытына нисбәтән ун мәртәбә кысынкылыклы. Һәммәсенә хөкүмәтдән җавап алырга, җавап өч айсыз килми. Андагы җаваплар һәммәсе дә Англия, Франсиянең катышуы берлән генә эшләнелә». Монда да өмид юк, инде ике генә юл калды. Берсе маркиз Окумадан үтенү, икенчесе көтү. Окума берлән күрешер өчен

[1] Дөресе: цент.
[2] Дустча – дустанә.
[3] Салибе Әхмәр – Кызыл Хач.
[4] Инсанияткяранә – кешелекле, гуман.

шимбә көнгә вәгъдә алдык. Кич берлән бакчада симфонический консерт[1] булды, шунда бардым. Япон халкы бик күп җыелып килгән. Яурупа музыкасына дәрдле кешеләр күбәйгән икән. Шактый гына уйнадылар, безгә бик күптән рәтле музыка ишетмәгән кешегә яхшы тәэсир итде. Көндез минга теге япон мәктәбендә укый торган татар малаен тавып[2] китерделәр. Унсигез яшьлек бер егет булса да бик зәгыйфь, ябык, сабак да укымый икән. Эш күңелсез, фазылы һичбер төрле тәрбия итә алмый булырга кирәк. Шуның тәрбиясе хакында күп нәрсәләр уйладым. Японча бик яхшы сөйли, укый, яза. Укып бетерсә, шактый бер егет булып, берәр милли хезмәткә ярар иде, мөгаллим булыр иде, японлар берлә мөнәсәбәткә ярара иде. Шул хакда Харбинга озын хат яздым, укытырга акча тапсалар бик шәп булыр иде. Милли идарәдә чит мәмләкәтләрдә укытыр өчен ыстипендияләр бар иде, ләкин акчасы йитми. Ни булса да бер эш эшләрмен әле. Бүген берәр хәбәр килер төсле төш күргән идем. Бер нәрсә дә булмады.

**29 май**

Тик кенә үтде. Харбиндан хат-хәбәр, телеграмма юк. Фәкать Париждан кайтып килүче бер рус генералы берлән генә танышып сөйләшдем. Максадым – анда безнең халыкдан берәр кешенең булу-булмавын белү иде, белеп булмады. Фәкать бик күп милләтләрнең вәкиле берлә Париж тулы, ди. Бер үземезнең кешеләрдән берәрсе булса, телеграмма бирәчәк идек, булмады, тагы көтәргә калды. Иртәгә маркиз Окумага барамыз, андан да бер нәрсә чыгар төсле түгел. Әллә Кытайга барынкмы дип дә уйлыйм. Өч-дүрт көн эчендә берәр карарга киләчәкмез, тик көтү бик туйдырды.

**30 май**

Бүген язарлык бер нәрсә дә булмады. Яңлышмасам, бүген рамазан башы булырга кирәк.

---

[1] Дөресе: концерт.
[2] Дөресе: табып.

**31 май**

Иртүк, сәгать сигездә, Гомәр килде һәм дә безгә тәрҗеман булачак төрекчә белә торган япон килде. Сәгать тукызда безгә маркиз Окумада вакыт тәгаен ителгән иде. Шунда китдек. Бераз көтәргә тугры килде, биш-ун минутдан соң маркиз үзенең сәркятибләре берлән чыкды, сөйләшү башланды. Саулык-сәламәтлек сорашкандан соң, татар тарихына сүз китде, андан күчеп Төркиянең хәленә җитде: «Төрекләрнең хәле шәп түгел, яурупалылар җәберлиләр. Истанбулны да төрекләрдән алмакчы булалар, бу ислам галәменә ничек тәэсир итәчәк?», диде. Мин: «Ислам галәме Яурупаның бу хәрәкәтен әһле салиб[1] мөхарәбәләренең[2] икенче төсе дип карыйлар. Яурупаның шул золымына һичбер төрле разый булачаклар түгел. Мисырдагы, Һиндстандагы, Әфганстандагы гыйсъянларның сәбәбе шул. Әгәр Истанбул мәсьәләсе төрекләрнең файдасына хәл ителмәсә, бик зур гыйсъянлар дәвам итәчәк, Яурупа дөньясы берлән ислам галәме арасында тагы үтә алмаслык упкынлар туачак. Инсаният ноктаи нәзарындан[3] бу фәүкальгадә зарарлы булачак», дидем. Шундан тагы башка мәсьәләләр хакында сөйләшкәннең соңында үземезнең максадымызга килдек. «Безгә Яурупага чыгарга рөхсәт алышырга Син-Мангул[4] углы Окума, безгә – татар балаларына – ярдәм ит», дидек. Ләкин Окума әллә нинди хикәяләр сөйләде, кечкенә генә шул ярдәмен итмәде. Без: «Рәхмәт, ләкин бездә сезгә – японларга – зур ышаныч бар иде. Монда кечкенә хезмәтләрне генә түгел, зурларны да итәчәк дип уйлыйлар иде. Сезнең хакда шундый хата фикердә булуымыз өчен гафуңызны үтенәмез», дидек. Һәм дә торып күрешеп чыкдык. Ләкин безнең берлән барган япон бик мөтәэссир[5] булган кебек кылынды[6]. Тугры идеме, юкмы – анысын

[1] Әһле салиб – урта гасырларда барган тәре сугышында катнашучылар.

[2] Мөхарәбәләренең – сугышларының.

[3] Нокта нәзарындан – күзлегеннән.

[4] Син-Мангул – Кытай-Монгол.

[5] Мөтәэссир – тәэсирләнгән.

[6] Кылынды – кыланды.

белеп булмый. Алай да, аш ашагач кәефе[1] бик тиз ачылды. Америка сәфиренә[2] бер мәктүп язган идем, шуны төрекчә белә торган япондан инглизчәгә тәрҗемә итдергән идем, ләкин башка кешедән укытып карагач, бик начар булып чыкды, һичбер нәрсә аңламаган. Шуңгарга күрә аны җибәрмәдем. Яңгыны яздырырга нә русчадан инглизчәгә, нә төрекчәдән французчага, инглизчәгә тәрҗемәче юк.

**1 нче июнь**

Бүген иртә берлән сәгать тугызларда йир селкенде. Монда ул йир селкенүе шактый еш була икән, ләкин мин моның кебек булганын беренче мәртәбә хис итдем. Селкенү ярты минутлар дәвам итде. Диңгез пароходында, дулкында көймә чайкалган кебек булды. Һичбер төрле миндә курку хисе уятмады. Зур бер тәэсир калдырмады. Күп кешенең бүлмәләрендә шкафлар ачылган. Графиндагы су бик хәрәкәткә килгән, асылган лампалар тагын атылганлар. Кичкә таба Асакуса дигән мәхәлләләренә бардык. Монда зур бер гыйбадәтханә бар һәм дә бик зур бер халык өчен хозурлану урынлары бар. Халыкның иң зур кыйсеме прастуй[3] булганга, япон хәятын шактый яхшы күреп була. Иң әүвәл гыйбадәтханә[гә] китдек. Гыйбадәтханәнең алдында зур бер капка. Капка бик биек итдереп, Чин тарзы мигъмарисендә[4] эшләтелгән. Уртада зур капка, ике якда ике кечкенәрәк капкалар. Капка бөтен урамын иңен алып эшләтелгән. Зур капканың югарысында зур Будда сурәте, кечкенә капкаларның өстендә дә кечкенә Будда сурәтләре. Өчесенең алдына алка кебек итдереп зур кәгазь фәнарлар[5] асылган. Шул капка янында гыйбадәт башлыйлар. Капкадан үткәч, күз алдында зур гыйбадәтханә. Аңгарга керер өчен ун-унбиш баскычлы өй алдына менәргә кирәк. Фәкать баскычдан алда зур яслә кебек бер улак куелган. Моның төбендә ярыклары

---

[1] Текстта шулай. «Кәеф» булырга тиеш булса кирәк.
[2] Сәфир – илче.
[3] Дөресе: простой.
[4] Чин тарзы мигъмарисендә — Кытай архитектурасы стилендә.
[5] Фәнар – фонарь.

бик күп, килгән бер кеше шул улакга бакыр акча ыргыта да, кулын без дога кылган кебек тота да башын иебрәк авыз эчендән бер нәрсә укый. Ләкин бу гыйбадәтханә ябык булганда гына шулай икән. Бүген гыйбадәтханә ачык иде, шуның өчен гыйбадәт кылачак кешеләр турук[1] баскычлардан менеп китәләр. Актык баскыч берлән ишек арасында биш аршын чамасы киңлегендә балкон кебек йир бар. Шуның бөтен түшәменә бик зур кәгазь фәнарлар (алтмыш-җитмеш чиләк су сыя торган мичкәләр кадәре) асып чыкканлар. Бер йиренә кыңгырау кебек бер нәрсә тагылган. Аның янындан идәнгә кадәр бер билбау кебек йеп сузылып төшкән. Гыйбадәт итәргә теләүче килә дә, шул йепне кыңгырауга суга. Кыңгыраудан зәгыйфь кенә бер тавыш чыга. Моның берлән Аллага гыйбадәткә килгәнен белгертә. Японлар хисаблы халык булганга, Аллаһы Тәгалә килгәнне белмәенчә калып, биргән ике тиен әрәм булмаудан, әлбәттә, куркалар. Кыңгырау шалтырагач, Аллаһы Тәгалә колагын бу тарафка боргач, ул башын бөгә төшеп, ике кулын безнең догадагы кебек итебрәк күтәрә дә, йә үз эчендән, яисә кычкырып дога укый. Ләкин ачык булганга анда туктамаенча эчкә үк кереп китәләр. Без дә кердек, ур ишеккә каршы йирдә гыйбадәтханәнең түрендәрәк [...] эче бүленгән аның урта бер йирендә бер биек сәке эшләтелгән, шуның өстендә баскычлы-баскычлы өстәл куелган, шул өстәл өстенә, дәрәҗәсенә күрә Буддалар тезелгән, алларында ут яна, шуларга якын гына беренче баскычга имам әфәнде менеп тезләнгән, аның артына түбәндәге идәнгә шәкердләр-мөридләр тезелгән, алар кычкыра-кычкыра мантраны укыйлар. [...]ның бу ягында халык күбесе үзе мыгырдый, сул якда бик күп халык җыелган, анда без дә барамыз. Һәр кеше кечкенә генә акча бирәләр дә, бер кәгазь алалар. Аны укый-укый чыгалар. Бу бер фалханә икән, өч тиенгә синең язмышың язылган кәгазь чыга икән. Без дә барып, кәсеб өстәленең янына барып кизү саклыймыз, кизү җиткәч, өчәр тиенне бирәмез. Бер шәкерд ала да, эчдә, аякын тезләнеп утырган икенчесенә бирә. Ул зур бер агач савытка әллә нәрсә төягән дә, шуны астын өсткә

[1] Турук – туры ук.

әйләндереп бер нәрсә карый да (сыйфыр булырга кирәк) бик күп вак бүлемләргә бүленгән шкафлардан ачып, кеше саен бер кәгазь бирә. Минга биргән кәгазендә «Көтә торган кешең тиз килмәс. Хәзер сәфәргә чыкма, бераз көт. Күңелеңдә тапкан ташның асыл ташмы, әллә ялганмы, дигән нәсия[1] бар. Эшеңнең ахыры хәер булачак», дигән. Фалчылар һәммә йирдә бер кебек: чегән хатыны да шуны сөйли, хәер, әманәтдә. Шундый гам[2] сүзләр берлән юл күрсәтә. Йолдызнамә дә, Будда ышаныңыз ди дә, дөньяның алдаулары һәр йирдә бер төсле. Андан икенче ягына китәмез, монда бөтилекләр, сөйдергечләр, аллалар саталар. Мин унсигез тиенгә японларның өч аллаларын, өч тиенгә бер сөйдергеч алдым. Андан да чыгамыз. Ишек янында берничә кат мендәр өстенә бер агач Будда сурәте куелган, шуның янында бик күп кешеләр бар. Һәммәсе тегенең бер йирен кулы берлән сыйпый да, шул кулы берлән тәнен ышкый. Бу сәламәтлек бирә торган санәм[3] икән. Кулың авыртасы[4], кулын сыйпыйсың да, шуның шәрафәтен кулга сылыйсың. Аягың сызласа, аягын, күзе авыртасы, күзен, колагы авыртасы, колагын вә һакәза[5]. Сылау-сыйпау шул кадәр күп булган булырга кирәк, агачдан яса[л]ган Будданың инде борынлары, күзләре [...] тәмам ышкылып беткән, фәкать шоп-шома бер агач булып калган. Әле кулын сыйпаганга, әле аягын ышкыганга, берничә мендәргә авыл хәлфәсе кебек менеп утырган мескен Будда, бер туктамаенча биеп тора. Андан чыгамыз, халык арасына керәмез. Урам шыгырым тулы. Бүген якшәмбе булганга бәйрәм. Бер почмакда унбиш тиен туплап, бер гастигә керәмез. Ул безнең Петроградның Народный Домы кебек нәрсә икән, үзендә театры, үзендә гасти (?)[6], үзендә тарихи музәханәсе, үзендә хайван музәханәсе, иске япон әсатыйрындан[7] бик күп манзаралар кешеләр төсле итдереп ясатылып куелган.

[1] Нәсия – биредә: йөк.
[2] Гам – гомуми.
[3] Санәм – пот.
[4] Дөресе: авыртса.
[5] Вә һәказә – һәм башкалар.
[6] Ягъни, гостиница.
[7] Әсатыйрындан – легендаларыннан.

Япон хикәяләренең манзаралары, чучеллардан эшләтелгән япон гаиләсендәге төрле манзаралар, мәсәлән, гейша берлән кәеф-сафа сөрү, ир берлән хатынның орышуы, баласыз карт берлән картчыкның армуд[1] эчендән бала тууы, сумарай[2] баласын сарайга китереп, аның сачын сарай хатынлары тарафыннан алынуы (иске гадәт буенча) вә башкалар, башкалар. Болар һәммәсе күңелле, халык өчен бик аңлаешлы. Чит кешегә Япониянең хәятын бик аңлата. Хат-хәбәр юк. Насыйб булса, иртәгә инде Йокоһамага китәм. Бүген Франсадан кайта торган генералдан тагы озынрак кем бар, кем юклыгы хакында сорашдым, без белгән кеше мәгаттәссеф[3] бик аз, безнең кавказлылар да, кырымлылар да юк. Хәбәр, кем белсен, нидер. Бер телеграмма бирмәкче идек.

## 2 нче июнь

Бүген Токиодан Йокоһамага күчдем. Иртәгә үземә аерым бүлмә булачак, бүген Гомәрдә кунам. Монда һава бик шәп, хәят очсызрак




Гаяз Исхакый фикердәшләре белән.
Токио,1919 ел

---

[1] Армуд – груша.
[2] Сумарай – самурай
[3] Мәгаттәссеф – кызганыч.

да. Андан соң, бәлки, ашказаныма да бераз файдалы булыр. Югыйсә мигъдә[1] бик начар. Хат-хәбәр юк. Харбинга телеграмма бирдек. Йокоһамага күчәр алдыннан Токионың дарелфөнүнендә тарих мөгаллиме мөстәшрикъ[2] профессор Торакимичи (?) Сираторига зиярәт берлән бардык. Профессор японлардан беренче мөстәшрикъ. Ул унберенче елны Гамбургда булган мөстәшрикъләр съездына Япониядан вәкил булып барган. Бик күп рус, алман, мажар мөстәшрикъларен белә, бик күп танышлармыз гамм[3] булып чыга. Бераз русча сөйли, бераз төрекчә сөйли, ләкин икесендә дә яхшы аңлыйм, ди. Хәзерге көндә төрек тарихын японча язып ята икән. Миндән безнең мөәррихләрне[4] сорады. Мин Шиһабеддин әл-Мәрҗани[5], Зәки Вәлиди[6], Һади Атласи[7], Бари Батталларны[8] күрсәтдем. Миндән шуларның әсәрләрен җибәрергә үтенде, вәгъдә бирдем. Шундан мәсьәлә Азия мәдәнияте, Азия кавемләренең тарихына, аларның истикъбаленә[9] күчде. Бик озын шул хакларда мозакәрәләрдә булындык[10]. «Мин сәясәт кешесе түгел, ләкин гыйлем, фән ягындан Асия милләтләрен бер юлга кертәсем килә, хосусан, сезнең төрекләр берлән японлар кардәш милләтләр, аларның мәдәниләре кулга кул тотынып барырга кирәк, һәм дә тарихда бер юлга таба борылырга кирәк», ди. Шундан соң японларның безне танымауларына күчәмез: «Һичбер японлар төрек халкын белмиләр, аңламыйлар. Менә монда без (минем танышым Окубуга күрсәтеп) икәү генә», ди. Мин: «Сезнең вазыйфаңыз мәктәб шәкердләренә аңлату, дәресдә тәэсир итү, китаплар язу», дим. Ул: «Кулдан кил-

[1] Мигъдә – аш казаны.

[2] Мөстәшрикъ – көнчыгыш белгече.

[3] Гамм – уртак.

[4] Мөәррих – тарихчы.

[5] Шиһабеддин әл-Мәрҗани – (1818–1889), татар мәгърифәтчесе, тарихчы, дин галиме, этнограф, көнчыгыш белгече.

[6] Зәки Вәлиди – Әхмәтзәки Әхмәтшаһ улы Вәлидов (1890–1979), дәүләт һәм сәясәт эшлеклесе, Башкортстан автономиясенә нигез салучы.

[7] Һади Атласи – Һади (Мөхәммәдһади) Мифтахетдин улы Атласов (1876-–1938), җәмәгать эшлеклесе, тарихчы-тюрколог, педагог.

[8] Бари Батталларны – Габделбари Баттал-Таймас (1883–1969), мәгърифәтче, тарихчы, журналист.

[9] Истикъбаль – киләчәк.

[10] Мозакәрәләрдә булындык – фикер алыштык.

гәнне эшлимез», ди. Сүземез музыкага күчә. Аның хакында шактый күп фикерләшәмез, андан безнең сәяси әхвалемезгә күчәмез. Андан Япониянең хәзерге хәленә керәмез. Мин японлардагы Американың һәрбер эшенә мөкиббән китүен тәнкыйд итәм. Һәм дә: «Япония истикъбале[1] Америкада түгел, Асиядә», дим. Ул да мөсәлләм була[2].

Сәгать ярымлар сөйләшеп утырганның соңында күрешеп китәмез. Профессор кыяфәте берлән әһле гыйлемдәнлеге күренеп тора. Шактый зур бер дәрәҗәдә тора икән. Бай гына булырга тиеш. Үзе хәзерге көндә япон вәлигаһденең[3] тарих мөгаллиме икән.

### 3 нче июнь

Бүген иртә торгач, минга тиз генә бүлмә булмаячагы мәгълүм булды, шуңгарга күрә мине Гомәр бүлмәсендә калырга тугры киләчәк, бу эш, әлбәттә, бик күңелле түгел, мин иркенләбрәк инглизчә укырмын дип уйлаган идем. Өйләдән соң Йокоһаманың тышына чыкдым. Монда хәзер арпа җиткән икән. Бер йирдә урганлар да инде һәм дә сугып торалар иде. Уруларының ничеклеген күрмәдем. Сугуларын күрдем. Элгәре башагын гына өзеп алалар икән дә, аннары шунда бер агач берлән кыйныйлар икән. Арпа аз булганга, әлбәттә[4], мөмкин, ләкин бик мәшәкатьле, ысулы бик иске. Бер болында печән чабалар иде. Кайберләре безнеке кебек чалгы берлән чабалар, кайберләре сач кистерә торган машина системасында ясалган озын саплы машиналар берлән уралар. Машинаны сабындан төртеп баргач, машина, сач машинасы кебек, урып бара икән. Хат-хәбәр юк.

### 4 нче июнь

Бүген инглизчә укырга башладым. Өйләдән соң ягмур ява башлады, һаман ява, туктар төсле күренми. Ягмур мәүсиме[5] башланды бугай.

[1] Истикъбале – киләчәге.
[2] Мөсәлләм була – фикергә кушыла, ризалаша.
[3] Вәлигаһед – тәхет варисы.
[4] «Әлбәттә» сүзенең укылышы шикле.
[5] Мәүсиме – сезоны.

**5 нче июнь**

Бүген төрекчә белә торган японны көтдек, ул «Империал отель»дән хаклар белешәчәк иде. Килде, һичбер хат-хәбәр юк. Көн буе ягмур ява, һава шул кадәр ротубәтле[1], бөтен киемләр юешләнә. Диңгез бөтенләй күренми, каршы якдагы урам да бик начар күренә. Бу юешлек үзен дәвам итә, безгә – өйрәнмәгән кешеләргә – бик начар тәэсир итү ихтималы бар. Бүген үк буыннлар авыр туп, әллә ни баскан кебек тора. Көтә-көтә, хәбәр алмаенча, тәмам эшдән чыкмасак ярый инде.

*Текстны Гөлчирә Ханнанова әзерләде.*

[1] Ротубәтле – дымлы.

## 5 нче дәфтәр
## 1919 ел, июнь

### 1919, 6 нчы июнь

Бүген телгә алырлык бер нәрсә юк. Бер йирдән хәбәр юк. Без һаман көтәмез. Эш эт эчәгесе кебек сузылды. Бүген үземнең хәятем өчен бераз күңел күтәрерлек эш булса, ул да мигъдәм[1] бераз юлга салынган кебек була башлады. Мондагы һава яхшы тәэсир ясады булырга кирәк. Ягмур бүген яумады, көн бик эссе.

### 7 нче июнь

Көн бик эссе, өйдә утырып торганда тир агып тора, хәл бер юк.

### 8 нче июнь

Һич бер хат-хәбәр юк. Бер ни булганы юк.

### 9 нчы июнь

Бүген безгә Харбиндан мәктүб килде. Хат 22 нче майда язылган. Милли идарәдән унынчы майда Фуад[2] шул көндә чыга дип телеграмма барды. Һәм дә Фуадлар Омскида чит мәмләкәт вәкилләре берлә маташып йөрделәр икәнен инде ул телеграммага да бер ай үтде, димәк, һаман килә алмаганлар. Чабата кайтарып торганчы килгән булса, әллә кайчан эш беткән була иде. Хәерле булсын. Бүген олуг дәүләтләрнең сәфирләренә мөрәҗәгать итәргә булдык һәм дә шул хакда бер нәрсә яздым. Бер-ике көндән мөрәҗәгать итәчәкмез. Колчак хөкүмәте хакында газеталар бик нык яза башлаганга, шул хакдагы үз фикеремезне әйтеп каласымыз килә.

### 10 июнь

Бүген безнең рус хозурындан кичүемезгә ике ай тулды. Юл уңган булса, инде без Парижда булачак идек.

Монда [...] өзелгәнне көтеп ятамыз. Хат-хәбәр юк, көн ягмурлы.

---

[1] Мигъдә – ашказаны.
[2] Фуад Туктаров (1880–1938) – сәяси эшлекле, публицист.

**11 июнь**

Бүген кырга чыкдым. Кыр бик матур, арпа өлгергән. Аны урып маташалар. Ләкин монда арпага бер беда бар икән. Чыпчык оча икән. Шуңарга күрә арпа йирләренә бик күп куркынычлар утыртканлар, бер кеше куып да тора. Монда ашлык аз булганга, ач чыпчык бик тиз ачып бетерә күрәсең.

Карабогдай чәчәк аткан, башында умарта кортлары йөри: ләкин бал исе еракдан бер дә килми. Иснәп карадым, бераз бал исе бар икән. Иң күп чәчелгән нәрсә төрле башлыча: торма, бәрәңге, шалкан, суган. Суганның кыягы монда бик эре һәм дә көпшәләнеп үсә. Ике кеше суган түтәлләренең арасындан тупракны күтәреп, суганларның төпләрене өяләр. Аның кыякларының бик күбесен туфрак астында калдыралар, суган зур булсын өчендер инде. Почмакда, берәр савытда, әллә нинди сасы су тора, берәр почмагында тирес череп ята. Шулар берлән түтәлне тиреслиләр булырга кирәк. Ашлыклар бик кечкенә-кечкенә бүлекләрдә. Бик зур кисәге йөз сажин булмас. Ике кеше урырга килгәнләр. Ураклары безнеке төсле түгел. Берәр сөям озынлыгында чалгы сыйфатлы бер пычак. Шуны балта сабы буе бер сапка чалгы рәвешендә утыртканлар. Арпаның саламын кулы берлән тота да, шуның берлән төбендән үк кисә, андан өемгә салып китә. Машина-фәләнгә монда урын да юк. Ашлык да юк. Гомумән, монда бөтен эш бик авырлык берлән, бик иске корал берлән эшләнә. Японларның шул кадәр эшләрне эшләүләренең сәбәбе кешенең күплегендә генә. Монда кешенең исәбе-хисабы юк. Кич берлән безгә Иван дигән әрмән берлән, Вафа дигән татар егете ашка килделәр. Ул әрмән безнең төрек талибәләренә бик күп ярдәм иткәнгә, аны ашка чакырдык, бик кәефе килде. Үзеңнең яхшылыгын тәкъдир итүчене хис итү бик зур шатлык бит. Хат-хәбәр юк. Төшләр юрап кына торамыз. Төшкә караганда, тиздән юл күренә дә бит, белмим, ни булыр. Бүген большевиклар тагы указ алдылар дигән хәбәр чыкды. Мескен безнең халык...

Алла сабырлык бирсен. Акча курсы тагы төшде. Бүген бер сум җиде тиен ярымга хисаплана. Дүрт-биш көн элек тукыз тиен

ярымга менгән иде. Кичкә таба тагы ягмур башланды, бик каты күк күкрәде, яшен яшьнәде. Берсендә бик каты шартлады һәм дә бердән электрик лампалары сүнде. Без электрик стансаны яшен сукды дип уйладык. Ләкин берәр минутдан яңадан утлар кабынды. Кар вә ягмур эчендә боз да бар иде.

**12 июнь**

Бүген иртүк Харбиндан телеграмма алдык. Андан килүче Агишевлар берлән җибәрдем диелгән. Җибәрелгән нәрсәләр мәктүпләр, андан соң, ихтимал, безнең өчен алынган товарлардыр. Һәр нә исә бер-ике көндән ачык мәгълүм булачак. Фәкать телеграмманың Чанчундан[1] җибәрелүе безне тагы уйга төшерде. Әллә Харбинда безнең хакда бер-бер тикшерү башландымы, әллә Фуадлар кулга алынганлар да, безнең хакда да шундан юлларга керделәрме? Бүген көн буе шул мәсьәләләр хакында төрле-төрле фаразлар берлән көнне кичердек. Озак түгел, бер-ике көндән Агишев киләчәк, фәкать кайсы Агишев? Заһидулламы[2], Габидулламы? Икесе булса ярый. Көндез ягмурлы булса, кичкә таба көн ачылып, фәкать һава суыгайды. Көз көне төсе алды.

**13 нче июнь**

Көн тик кенә үтде. Харбиндан бүген килеп җитүне әле көтмимез. Кич суык булганга, бераз суык тигән, баш авырта. Кичкә таба акча курсын белешер өчен Йокоһамага төшәмез (без тау өстендә торамыз). Курс бик төшенке – җиде сум биш тиенләр. Андан кайтуымызга безне Габидулла әфәнде Агишев көтеп тора. Ул бик күп мәктүпләр алып килгән, берсе Фуаддан. Харбинда безнең хаклар алынган, алар буенча гамәл кылып торалар. Ләкин Фуадлардан һаман хат-хәбәр юк. Кайчан киләләр, әллә бер дә килмиләрме, һичбер мәгълүмат юк. Фуадның мәктүбе 13 апрельдә мондан тәмам ике ай элек ул хатда Фуад без хәзер Омскида

[1] Кытайдагы шәһәр.

[2] Заһидулла – Заһидулла Агиш (1881–1970), җәмәгать эшлеклесе, Ерак Шәрык төрек-татар милли хәрәкәтендә актив катнаша, сәүдәгәр.

ятамыз[1]... Бүген Франсә вәкиленә эшләрне рәсмиләшдерү өчен барырга тиеш идек. Ин-Ян әфәнденең әллә нигә кәефе булмады да, бармады. Шуның өчен бүген китә алмыймыз. Шулай да егерменче апрельдән калмамыз. Солтанбәк[2] дә монда без икәү хәзер вәкил булып сайланамыз. Янымызда 15 мең сум акча бар. Солтанбәкнең кирәге юк дигән телеграмманың милли идарәдә бик зур сынау шуңа сәбәб булган һәм дә үзе дә телеграмма да биргән дигән. Теге, без киткәч Агишевларга килгән телеграмма, шундан башка хәбәр юк, ләкин хәзер һаман Фуадлардан хәбәр юк. Әллә инде хөкүмәт бер төрле манигъ булды да, үзләрен ябып куйдылар. Әллә Солтанбәк бара алмагач, Фуадка бирмәделәрме. Һичберсе мәгълүм түгел.

Инде тагы Харбиндан телеграмма берлән сораганлар, җавап кайчан киләчәге мәгълүм түгел. Әмрулла әфәнде[3], Нияз әфәнде, Гыйниятнең[4] мәктүпләрендә зур яңа эш юк. Әмрулла әфәнде безгә дип алган малны җибәрү хакында язган. Габдулла безгә кырык тугыз мең сумлык мал алып килгән. Шулай итеп иенгә алышдыру уңгайрак булмасмы дип уйлыймыз. Ләкин Харбин, Владивостокда чит мәмләкәтләрнең кушылуын күрү хакындагы фикеремез [...] чыгара алмаслар төсле күренә. Аллага тапшырдык. Милли идарә Уфага күчкән, инде Уфаны большевиклар алды, димәк тагы мәсьәлә чуалды.

### 14 нче июнь

Яңа бер хәбәр юк. Теге татар егете Вафа гына килде. Бер мәктәп тапкан һәм дә бүлмә булган, аңарга торыр-укыр өчен утыз иен биреп җибәрдем. Харбингә имамга шуны тәэмин итү хакында язган идем, әле җавап юк. Шуңарга күрә, үземезгә расходны күтәрергә тугры килү ихтималы бар.

---

[1] Бу урында көндәлектә җөмлә төгәлләнмичә калган.

[2] Солтанбәк – Солтанбәк Мәмлиев, Петроград Эшче-солдат депутатлар советы әгъзасы.

[3] Әмрулла Аги – Харбинда мәхәллә житәкчесе

[4] Гыйният – Гыйниятулла Салиәхмәт (1889–1926) – Харбин мәчете имамы һәм мөдәррисе.

**15 нче июнь**

Бүген Токиога бардык. Габдулла әфәнде безнең малны япон сәүдәгәрләренә күрсәтәчәк иде. Ләкин алар килмәгәнләр. Ахрысы сатып булмас. Көн буе анда торып, сишәнбе көн сәфарәтләргә барырга булып вәгъдәләшеп кайтдык. Фуадны сорап һәм дә инглиз вәкиленә керергә кушып, Омскига телеграмма йибәрдек.

**16 нчы июнь**

Көн тик кенә үтде. Акча курсы бик төшенке. Бүген йөз сумга алты иен генә бирәләр. Габдулла әфәнде безнең малларны сата алмаган. Ахрысы Америкага җибәрергә тугры килер. Хәерле булсын.

**16 нчы июнь**

Бүген иртүк Токиога килдек. Анда бару берлән без, Габдулла әфәнде берлән икәүләп, Франсә-Англия сәфарәтханәләренә кердек. Франсә сәфарәтханәсе һаман җавап алмаган.

Без моңарга бик гаҗәбләнүемезне белгертдек. Ике ай мөддәт эчендә сәфарәтханә үзенең мөрәҗәгатенә җавап алмый.

Әллә телеграмма бирдек дип ялганлаганлар. Әллә чынлап да җавап юк... Без – бер милләтнең вәкилләре. Безнең гаскәремез сезнең мөхафәзә өчен аз кан түкмәде. Бүгенге көндә Франсәдә рус гаскәре эчендә меңдән артык татар солдаты бар. Франсә тупрагындагы үлгән татар солдатының саны ике меңгә җитә. Шул кадәр татар солдаты Франсә өчен кан түгәргә барганда безгә – милләтнең вәкилләренә – милләтнең дәрәҗәсен, уен аңлатыр өчен Франсәгә барырга ярамый. Моны безнең халык ни дип атаячак. Без катгый итеп безнең хокукымызны аяк астына таптамауларын үтенәмез. Сәфарәтнең мөстәшары[1] бераз кызарып, бераз оялып: «Мин бүген үк сезнең мәсьәләне сәфиргә сөйлим, берәр катгый хәрәкәт итәрмез. Документлар хәзерме?» – диде. – «Һәр документларымыз хәзер» , - дидек. Тиздән җавап бирергә булып калды. Тизе ни кадәр булыр. Андан Инглитәрә сәфарәтханәсенә китдек. Анда бераз

[1] Мөстәшары – киңәшчесе.

көтдеребрәк кабул итделәр. Бу инглизләрнең сине сөймим дигән сүзләре, ләкин без – халкымыз тарафындан җибәрелгән вәкилләр – инглиз малайларының андый тупаслыгына алай илтифат итмимез. Биш минутдан соң сәфарәтханәнең сәркатибе чыкды. Безгә виза бармы?

Сезгә бит Франсәга барырга кирәк. Мин туп-тугры итдереп: «Җавап бармы?», – дидем. Бар, ул: «Гаяз Исхакыйны белмим», – дигән. Без сезгә безне белә дигән сүземез юк. Сез аңарга үзегез мөрәҗәгать итсәгез, без – милләтемезнең вәкилләре – шуның милләт мәҗлесе тарафындан сайланган кешеләр, кулымызда менә дәлилләремез, без сезнең түрәләрегезнең русчаны белмәвенә без гаепле түгел. Безгә солых мәҗлесенә барырга лязем, шуны ни юл берлә булса да, сезнең манигъ булмавыңыз тиеш. Гаяз Исхакый соң кем дип, минем кемлегеме тагы бер мәртәбә сөйләдек. Кулымыздагы документларны күрсәтдек. Без милләт мәҗлесемез тарафындан сайланылган өч зат идек. Беремезне большевиклар үтерде, беремез гаиб булды. Урта мин калдым. Мин вазыйфаны үтәр өчен шул кадәр мәшәкать берлән килдем. Монда сез юк сүзләр, кирәкмәгән киртәләр саласыз. Матбугат сездә генә түгел, бездә дә бар. Без милләтемезгә ни дип шул мәсьәләне аңлатачакмыз. Сезнең шул кадәр безнең хокукымызны игътибарга алмавыгызны ни дип тәфсир итәчәкмез. Инглиз тагы бер мәртәбә безнең сөйләгән сүзләремезне язды, тагы безгә бер мәртәбә Владивостокны телеграмма биреп сорарга һәм дә Лондонга телеграмма бирергә вәгъдә бирделәр. Вәгъдәсене ни кадәр хак торыр, алла белә. Ләкин без үз вазыйфамызны эшләми хәлемез юк.

Бүген барыбызга Чайковский[1] һәм Уильямс (?) исеменә телеграмма биреп, безгә ярдәм итәргә үтендек. Монда инде японлар әллә никадәр телеграмма тотып, эшдән чыгаралар. Телеграммага йөз кырык иен чыкды, ягъни ике мең сум көмеш дигән сүз. Хәерле булсын. Тагы берничә адымлар атлаячакмыз. Үз вазыйфамызны үтәми калмаячакмыз.

[1] Чайковский – Николай Васильевич Чайковский (1850–1926), рус революцион һәм сәяси эшлеклесе.

**18 июнь**

Берни булмады. Хат-хәбәр юк. Һава матур гына булды. Иртәгә Америка бер газеталарында басдырыр өчен бер мәкалә җибәрәчәк идек. Инглизчәгә тәрҗемәгә өлгермәде. Инде икенче пароход берлән җибәрергә лязем булачак. Малын сатып булмый ахрысы, акча мәсьәләсе мөшкел.

**19 нчы июнь**

Бүген иртүк Англия сәфарәтханәсендән озын бер мәктүп алдык. Мәктүп безнең соңгы мөрәҗәгатемезгә җавап. Мәктүбдә безнең виза соравымызга җавабын бирә. Омскидан алган хәбәремез буенча, безнең Омскидагы вәкилемез Гаяз Исхакыйны белми. Омскида татарларның коммунистларына да Гаяз Исхакый мәгълүм түгел. Сезнең теләкләрне Лондонга телеграмма бирер өчен бик күп расход чыгачак, шуңарга күрә сәфарәтханә ул расходны үз исемендән тота алмый. Әгәр телеграмма бирүне теләсәгез, биш йөз иен (җиде мең сум) акча китереп бирегез дә, телеграмма җибәрермез. Рус сәфарәтханәсендән алган мәгълүматымыз да сезнең файдагызга түгел, диелә. Димәк, безнең эшемезгә каршы, әллә үземезнең начар организованый булумы, башка рус карагруһлары да аяк чалалар. Мондагы сәфарәтханәнең әгъзаларының күбесе Николай заманасында куелып калган карагруһлар.

Болар безнең бөтен хәрәкәтемезгә каршы булганга, нинди юл берлән булса да хәл итәргә тырышачаклар. Безнең моңарга каршы торырлык бер куәтемез дә юк. Милли мәсьәләләремез куелмаган, милли идарә эш башында имансыз әрәмтамак затлар. Боларда мәсъүлият хисе булмаганга, эшнең эш булып чыгуына ярдәм итү кайда, инде менә ике ай торып үтде, милли идарәдән унлап телеграммага бер җавап алганымыз юк. 24 нчы гыйнварда чыгып киткәндән бирле бер мәктүп, бер язу кисәге алганымыз юк. Эш шул дәрәҗәдә булганда ничек итдереп шул кадәр эш эшли алырга кирәк. Ничек итдереп өскә йөкләтелгән милли бурычны үтәргә кирәк. Күп уйлаганның соңында инглиз сәфарәтханәсенә

биш йөз иенне сәдака бирүдән ваз кичдек. Безнең төрек-татар милләтен инглиз мәнфәгате өчен ачылган шул канлы сугышында миллиондан артык углын гаскәр итдереп җибәрде, миллиардлар сонды. Акча сарыф итде. Йөз мең җан корбан итде. Акча кирәкдә бар, ләкин без инде милләт акчасындан шул сумманы инглиз сәфарәтенә һәдия итә алмыймыз. Бездән шул кадәр җитәр. Шул йөзәр мең кардәшләремезнең каны берлән инглизләр алдында милләтнең вәкиленә бирер, дәхи дә кадер казанмаган булсак.

Ул биш йөз иен берлән игътибарын сатып ала алмабыз. Бу мәктүбдин без инглизләрнең катгый җаваблары дип каршы алдык һәм шулай да. Инде калды Франсә сәфарәтендән җавап көтәргә, бәлки алардан бер төрле күңелле хәбәр килер. Без инде Франсәгә телеграмма биргәнгә һәм дә Омскига телеграмма биргәнгә шактый вакыт кичде. Берәр атна эчендә икесендән җавап килер дә, шул мәсьәлә ачылыр дип уйлыймыз. Андан да рәд[1] җавабы килә. Мәсьәлә, фәүкыльгадә, мөшкелләнә. Ләкин әле иман һаман бетми. Ул вакыт мин Пекинга барып, һәм дә Владивостокка барып, яңадан бер хәрәкәт ясап карап чыгамын. Аллага тапшырган инде. Иртәгә японларның иске гыйбадәт йирләренә барып килмәкче буламыз. Окубо[2] килгән иде, японча биргән мәкаләмезне һаман басдыра алмаган. Японларга тәмамән ышаныч бетде.

### 20 нче июнь

Бүген безнең товарны сата алу-алмауны белергә кирәк. Габдулла әфәнде иртәдән шул малын күрсәтеп, сатулашып йөри булырга кирәк, чөнки Никкога[3] барырга дигән вакытда ул килә алмады. Димәк, без Никкога бүген бара алмыймыз. Әгәр товар яхшы сатылса, Никкога баруның әһәмияте ул кадәр зур түгел, кичә шулай итеп вәгъдәләшкәнгә, аның иртә килеп җитмәве дә шуны күрсәтде. Без зур өмид берлә мал сатуны көтәмез, безнең маллар Харбинда төгәл 35 иен биргәнләр. Монда 34 артыграк

---

[1] Рәд – кире кагылган.
[2] Окубо – Окубо Кочи – Комазава университеты профессоры.
[3] Никко – Япониядәге шәһәр.

алмакчы буламыз, әгәр шулай уйлаганча сатылса, безгә иен хәзерге базарга караганда шактый очсыз киләчәк, ягъни базарда уникe сум булганда, безгә җиде сумга киләчәк. Бу безнең эшне бик җиңеләйтәчәк. Сәгать 12ләрдә тагы бер мәктүп. Монысы Франсә сәфарәтханәсендән, кыска гына, ләкин мәгънәсе бик зур. Шул әхвал эчендә шул документлар берлән генә сәфирбик виза бирә алмыймыз дигән. Париждан җавап һаман юк, кайчан киләчәге дә мәгълүм түгел. Омскидан хәбәр юк. Димәк, безгә хәзерге әхвал эчендә рәд килә, димәк, безгә виза бирмәячәкләрен әдәб төсендә аңлатдылар. Инде нишләргә, анысы хакында әле бер карарга килеп җиткәнемез юк. Иң тугры юл шул – мәсьәләне милли идарәгә аңлатып, андан Омскида, Франсә, инглиз вәкилләренә мөрәҗәгать итү иде, ләкин без милли идарәдән ике айдан бирле һичбер төрле хәбәр ала алмыймыз. Алар хәзер Петропавловскдамы, әллә Уфага китеп әвәрә булдылармы, һич мәгълүмат юк. Шуңарга күрә аларга ышанып, бер хәрәкәт дә ясарга хәл юк, алай булса, Харбингә хат язып, идарәгә белдерергә кушкан идек. Мондый зур эшдә бер кешенең иҗтиһады берлән генә бер ни чыкмый. Бөтен мөәссәсә бер кеше кебек хәрәкәт итәргә кирәк. Безнең милли идарә бу эшдә әлегә кадәр хәзергә башка бер эш эшли алмады. Беренче адым итеп Франсә сәфарәтханәсенә яңадан барып, Омскидан граф де Мартельдан телеграмм берлән безнең хакда җавап соратырга, икенчесе Франсә сәфарәтханәсендән яңадан телеграмма бирүне үтенергә, әгәр алар да акча сораса, боларына инде бирергә дә. Шундан соң шуларга җаваб да һәм дә Омскидан киләчәк хәбәрне бераз көтәргә. Шул арада Франсә, Англия сәфарәтләренә яңадан мәктүб берлән виза бирүне сораб мөрәҗәгать итәргә. Боларның берсендән дә без теләгән җаваб чыкмаса, мин яңадан Владивостокга кайтып китәм дә, андагы вәкилләрне тагы бер мәртәбә сөйләшеб карыйм. Андан да берни чыкмаса, үземезнең теләгемезне газеталарда игълан итәмез дә, милләтемезнең хокукы, шул тәгъриз[1] хакында протест игълан итәмез. Кулымызда башка юл

[1] Тәгъриз – ризасызлык.

юк. Өйләдән соң Габдулла әфәнде килде, малны күрсәткән, ләкин бик очсыз бирәләр, ди. Харбинда 35 иен биргән. Сатсаң, бик очсыз сатасың, иен бик кирәк. Ахырдан 32ләргә булса, сатарга карар итдек. Булмаса, Америкага йибәрәмез. Ләкин андан теләгәнчә бик күп вакыт үтәчәк. Мондагы ихтыяҗны канәгать итеп, иен алу берлән үтәргә мәҗбүр булачакмыз. Кәеф бер дә юк.

Эч поша. Бераз күңел ачылмасмы дип, Токиога Габдулла әфәндегә ашка барамыз. Француз офицерлары, француз исемендән йөри торган яһүд марҗалар бииләр, сикерәләр, көлешә-уйнашалар, бәйрәм итәләр. Солых мәҗлесенә бару өчен генә дә виза да ала алмыймыз. Бу эшләр бик зур, дөрес булырга тиеш. Татар-төрк баласына кешеләр өчен өмедгә йөрүнең ни дәрәҗә кадерсез икәнен күрсәтә торган тарихи сабак булырга тиеш һәм булачак да иншааллаһ, халкымызга шул оятсызлык, шул золымны аңлатачакмыз да.

**21 июнь**

Бүген икенче бер сәүдәгәргә малымызны күрсәтергә идек. Габдулла әфәнде көн буе шуның берлән мәшгуль булды, ләкин бер нәрсә дә чыкмады. Берсе дә алмады. Инде мал Америкага җибәреләчәк. Анда ул август башларында барып керәчәк, шактый вакыт үтәчәк. Шуңарга күрә аның акчага әверелүе бик озынга сузылачак. Бәясе күбмегә китәчәк, анысы һәм мәгълүм түгел. Бүген бик эссе булды. Мин кичкә таба диңгез хәмамы[1] эзләп китдем. Йокоһаманың тирәсендә барып табдым һәм дә беренче мәртәбә Тихий океанда коенып кайтдым. 15 нче июньдән алып 21 нчегә кадәр сузылган атнаны зәңгәр сылап, төс биреп [...] атнасы дип атадылар. Һәм дә тимер юллар вагонларын, урамларын зәңгәр тире берлән тотдылар. Кешеләргә зәңгәр тире кисәкләре сатдылар. Бөтен япон зәңгәр тире берлән тулган, бөтен Япониянең хәяте зәңгәр тире химаясенә бирелгән. Бу ахмаклык атнасы, бер якдан караганда, көлке. Икенче якдан караганда, японларның никадәр сабырсыз икәнлекләрен күрсәтә торган күңелсез бер эш.

[1] Хәмам – су керү урыны.

## 22 нче июнь

Бүген иртәдән үк һава бик ягмурлы һәм дә җилле. Җил шул кадәр каты, бөтен өй селкенә. Без тәрәзәне ача алмыймыз. Вак кына ягмур өзелмәенчә яуса да, һава бик бөркү, хәтта эссе дә. Өйләдән соң безнең тәрҗеман керә, аның берлә сөйләшеб утырганда, безгә яңа бер юл күрсәтә, ул – Мексикага китү. Андан Яурупага чыгу җиңел булачак. Анда китәргә мин ярдәм итә алам, ди. Без аңарга ачыграк белешергә кушамыз. Үземез шул фикернең татбигын[1] уйларга тотынамыз. Бу юл шактый озын юл. Иң әүвәл Мексикага чыгарга пароходда егерме ике көн барырга кирәк, андан Яурупага кадәр ике атналап барырга кирәк. Бу – бер. Икенчедән, Франсага керергә, анда да виза алу җиңел булмаячак, ләкин ничек дә ул Яурупага шактый якын булганга, мондагыга караганда юл якынлана төшәчәк, шуңарга күрә бу юл хакында мәгълүмат җыярга булдык һәм дә бик кире кагарга да уйламадык. Ләкин бу хезмәтләр акча бәрабәренә эшләтеләчәк. Нишлисен инде, башкача әмәл булмагач.

Бүген төшдә Садрины[2] күрдем. Күңелсез, картайган. Сачләре агарган. Андан барыб күрешдем. Оренбургда ятдым, беркемгә дә белдермәдем, ди. Ихтимал, аның хакында бер-бер хәбәр килә торгандыр. Кичкә таба көн ачылды.

## 23 нче июнь

Бүген көн иртәдән үк аяз. Ягмур күренми. Һава бик эссе. Без бер тарафдан Мексика хакында мәгълүмат көтәмез. Икенче тарафдан Омскидан бер хәбәр. Өйләгә кадәр Габдулланы көтеп өйдә утырамыз. Өйләдән соң Габдулла килә. Шатлыклы бер хәбәр. Ул безнең малларны саткан. Һәм дә без уйлагандан күп артык саткан. Бу безнең рухны бик күтәрә һәм дә өмидләр тудыра. Ике-өч көндән бирле ул никадәр маташды да һичбер төрле эшне юлга сала алмаган иде. Бу юлы хуҗа Баһаветдиннең ярдәме берлән бик яхшы саткан. Үземезгә илле ике мең сумга төшкән малны җиде

[1] Татбикъ – яраклаштыру, яраштыру.
[2] Садри – Садри Максуди (1878–1957), дәүләт эшлеклесе, сәясәтче.

мең дә сигез йөз иенгә биргән. Илле ике мең сум акчамызга каршы без өч мең дә алты йөз кырык иен алырга тиеш идек. Без бүген шуңарга җиде мең дә сигез йөз иен алдык. Монда әллә ни безнең хезмәтемез булмады. Болар һәммәсе дә Әмрулла әфәнде берлән Габдулла Агиш әфәнденең хезмәтләре.

Шул шатлыклы эш булганга, бүген күңел күтәренке. Башка эшләр шулай матур очланыр кебек булып китде. Әле өмидне өзәргә ярамый. Шул юлга керешкәнемез, шул алган юлымызны эшләп бетерергә тиешмез. Бүген теге тәрҗемә итәргә тиеш иде. Ахрысы бетмәде, китермәде. Мексика хакында мәгълүмат җыяр өчен бер американы күреп сөйләшдек. Мексика берлән [...] арасындан үтү җиңел, ди. Испаниягә бару бөтенләй уңайсыз, шуңарга күрә анда таба китү тарикы тагы куәтләнгәндән-куәтләнә бара. Бүген тагын берничә йирдән мәгълүмат алачакмыз. Иртәгә, я берсе көнгә Франсә сәфарәтханәсенә тагы барамыз һәм дә чехославларның мондагы вәкилләрен күрәчәкмез. Ни булса да бер нәрсә чыкмасмы әле. Инглизчә укырга тотынган идем, тагы бер атнадан мөгаллимсез калдым. Яңаны әле һаман таба алмыйм. Гомумгә төрекчә укыта башладым.

**24 нче июнь**

Бүген бер дә яңа эш юк: мин хисапларны тикшереп чыкдым. Ике ай ярым вакытка ярыйсы ике меңдә биш йөз иенләр чамасы расход чыкган. Расходымыз бик аз, чөнки бик кысып тотамыз. Иртәгә Габдулла китәчәк булганга, хатлар язу берлән мәшгуль булдык. Инглизчә теге мәкаләнең тәрҗемәсе тәмам булды. Бер-ике көндән теге мөрәҗәгатемез дә тәмам булачак. Мексикага китү мәсьәләсе бик соңгарачак. Пароход Кобедан[1] бишенче августтан иртә китә алмаячак. Димәк ки, ул юл берлән булганда, без бик иртә барып җиткәндә, Парижга егерменче сентябрьләрдә барып керәчәкмез. Бик соң түгел. Солых мөзакәрәләре башлануга тәмам унлары тулганда гына. Нишлисе соң?

[1] Кобе – Япониядәге шәһәр.

Иртәгә тагы Франсә сәфарәтханәсенә барамыз. Һәм дә чехославакларны күрәмез. Гомәр Владивостокларга барып килсә бик яхшы булыр иде дә, бик курка.

**26 нчы июнь**

Бүген иртүк торып, Габдулланы озатырга Токиога китдек. Автомобильгә утырдык да Франсә сәфарәтханәсенә китдек. Беренче үтенечем граф Омскига граф де Мартельгә телеграмма биреп, безнең хакда сорарга, икенчесе барыбызга яңадан телеграмма бирергә сорау иде, әгәр үзләрендән бирергә разый булмасалар, үз хисабымыздан бирдерүне үтенергә идек. Барып карточканы биргәч дә, көтү бүлмәсенә безгә бер малай чыкды. Без аны монда лакей урынындагы малай, безне чакырырга килде дип торамыз. Ул шул мистер «Бадак» булды. Монда килгәндән бирле безне берничә мәртәбә болай илтифатсыз кабул итү булды. Ни йомыш, мәсьәлә ни, аңлатдык, үтенечемезне әйтдек. Унсигез-унтугыз яшьле яһүд малае: «Франсәнең вәкиле берлән үземезнең кулымыздан килгән хәл-эшне без кылдык. Мондан соң бер эшне дә эшли алмыймыз», диде. Без белмәмешсезгә салынып, тагы үземезнең үтенечне – Омскига телеграмма бирүне ишарәләдек. Малай, «Мин әйттем» диде дә, бик зур кеше кебек урыныннан торды. Бу яһүд малайның, аудиенция тәмам, димәк иде. Без дә акрын гына торып чыкдык. Габдулла әфәнде яһүд малайның шул кыланышларындан кыпкызыл булган, каны башына-йөзенә йөгергән. Күзенә әллә нинди бер әйтеп бетермәслек ачу чыккан иде. Аларда – үзенең милләтен хокуклы итеп күрергә теләү тойгысы. Автомобильдә ул авыр сулый, әллә ниләр уйлый иде. Мин аның белгән кебек, менә бу мөгамәлә безнең милләтнең кыйммәтен күрсәтә торган эшдер. Без җәмәгать эшендә йөри торган кешеләр һәр көндә кебек шундый муафикъ булмаган мыскыллар күрәмез, аңарга каршы һич бер төрле җавап бирә алмыймыз, чөнки безнең алар берлән тартыша торган коралларымыз юк... Шул авыр хисдән бераз арынганның соңында, Гомәр әфәнде берлән чехославаклар вәкилләрен күрергә китдек. Чехославаклар Русиядә озак торганга, алар безнең халыкның ролен беләләр. Алар безнең вәкиләремез кебек Русиянең идарә демократ

җөмһүрият булганда гына Русиядә мәдәни хәят мөмкин дигән фикердә булганлар. Шуңарга күрә, алар хәзерге безгә дошман итттифакъның әгъзалары булсалар да, мәсләкләре берлә безгә бик якынлар.

**26 нчы июнь**

Бүген иртәнге газеталар Германиянең Учредительное собраниегә солых шартларын кабул итүгә карар биргән. Һәм дә үзенең вәкилләренә могаһәдәгә кул куярга әмер иткән. Солых шартлары Германия өчен бик хәзерле булса да, Германия әхвале, күрәсең, шул хәлгә дә каршы торырлык дәрәҗәдә түгел. Ләкин бу солыхның гомере бик кыска булачак. Сиксән миллионлы нимес халкы үзен тереләтә кимерергә, ашарга рөхсәт бирмиячәк. Могаһәдә канундан чыгарылып, фәкать көчкә таянып кына эшләнүе нимесләрнең күңелләрендә әйтеп бетермәслек ачуны кабартачак. Беренче форсатда ук бөтен канун гайре канун булу белән, тагы сугыш башлаячаклар. Тагы әллә ничә миллионлар каны түгеләчәк.

**27 нче июнь**

Бүгеннең беренче хәбәре Италиядәге зур хәрәкәтләр хакында булды. Андагы сәяси тартышларда җөмһүрият тарафдарлары җиңеп, хәзерге хөкүмәт истигъфа итәргә мәҗбүр булган. Димәк, анда да шул мәсьәлә башлана, анда да революция китә. Безгә – төрк-татар балаларына – бу, әлбәттә, бик сөенечле хәбәр. Италия соңгы ярты гасырда Төркиянең зарарына булган хәрәкәтләрдә иң алгы сафда булыб килде. Төрек хөкүмәтенең тынычлыгы дахили эшкә иң мохтаҗ вакытында Тыраблис өчен сугыш игълан итеп, Төркияне кирәкмәгән сугышка керергә мәҗбүр итде, яңа хөкүмәтнең иң кадерле дахили эшләргә сарыф итә торган вакытын сугыш берлән үзгәртергә мәҗбүр итде. Шуның аркасында Балкан иттифакының мәйданга килүенә юл хәзерләде.

**28 нче июнь**

Бүген сәгать бергә кадәр Германия мөгаһадәгә изһар итәргә тиеш. Бүген кич берлән Габдулла Чанчунга кайтыб җитә. Бер-ике

көндән безгә андагы хәлләр хакында телеграмма бирәчәк. Рус газеталарында безнең Урал сугыш сафы хакында бер хәбәр дә юк. Большевик, аның дошман сугышы инде алты мәртәбә үтде, инде фронт башка йиргә күчсә дә ярар иде. Халык бераз тынар, сулыш алыр иде.

Кырга чыгыб керәм. Арпа-богдай тәмам үсеб йиткән, ямь-яшел булыб йирне каблаган. Һавалар ике көндән бирле томанлы. Сирәк-сирәк кенә вак ягмур яугалый. Рәтләб күренмәс дәрәҗәдә томан каплаган. Акча курсы тагын төшде. Бүген бер сумы җиде тиен.

**29 нчы июнь**

Бүген кич берлән Харбиндан безне икемезне дә чакырыб телеграмма килде. Әмрулла берлән Нияз әфәнделәрнеке. Телеграммада мөһим мәсьәлә өчен күрешергә лязем диелгән. Бик күб нәрсә уйладык. Ни өчен икәнне һич бер төрле китереб аңлый алмадык. Ихтималларның берсе – безнең паспорт мәсьәләмез. Паспорт алганда Әмрулла әфәнделәр алышкан иде, бәлки бер-бер уңайсызлык булыб да, шуның хакында әлләме... Икенче, бәлки милли идарә безнең хакда сәфарәтләргә һәм хөкүмәт түрәләренә бик начар итдереб бер-бер ялган ялганлады. Бусы бик зур кабахәтлек була инде. Әллә башка бер нәрсә чыкдымы. Һичбер аңлап булмый, барырга карар бирдек. Бу тагы эшне бик нык чуалтачак инде.

Кичә Германия вәкилләренең солых имза итдекләре телеграммасы алынды. Димәк, сугыш азгамы, күпкәме бетде. Бәлки юллар да ачылыр иде, ләкин безгә китәргә кирәк. Бүген рамазан гаеде булырга кирәк. Безнең илләрдә бәйрәмне каршы алганлардыр инде. Бөтен ислам галәме зур бер кайгы эчендә. Төркиянең хәле бик авыр...

30 июнь, бүген чехославаклардан мәктүб булырга кирәк иде, ни өчендер килмәде. Бүген бик начар йокладым. Көн буе вак-төяк әйберләр алыб йөрдек. Бүген Япониядән бөтенләй китү булыр диб уйлыймыз. Бәлки безнең солых сәфәремезнең дә ахыры булыр.

*Текстны Ләйлә Гарипова әзерләде*

## 6 нчы дәфтәр
## 1919 ел (июль–октябрь)

### 23 нче июль

Иртүк Харбинга килеп җитдем. Вокзалда Әмрулла әфәнде автомобиль берлә каршы алды. Көн фәүкыльгадә эссе. Бер дә йокламаганга да, эссегә дә мин изелеп торам. Монда Ибраһим Кәмал килеп чыкды. Ул бераз безнең якның хәбәрләрен белә. Безнекеләр сау-сәламәт имеш. Милли идарәмезнең хәлләрен газетадан гына белә. Уфага кайтып, берәр ай юлда йөреп, Уфада өч көн торып, тагы юлда өч атна вакыт үткәреп, Омски килеп берләшкәнләр. Кич берлә Әмрулла берлә бакчага барып утырамыз һәм дә аңарга бөтен планны сөйлим. Аның ярдәменә иң зур мохтаҗлыгымыз – аның акчаны малга алышдыру, аңарга каршы кичне бүген әле асдан-өсдән генә сөйләп үткәрәмез, иртәгә, насыйп булса, тәмамән эшкә керешәм.

Милли идарәгә кеше җибәрү һаман карар карар, фәкать шуңарга күрә тагы бер нәрсә – акча мәсьәләсен кушмакчы булам. Ни килеп чыгар. Гомәргә хат яздым, ул да кайтыр инде, андан соң Ичанйуга(?) барып, теге җавапның кайтуын бераз көтәргә тугры килер төсле тора.

### 24 нче июль

Бүген солых сәфәренә чыгып киткәнемә алты ай тулды. Алты ай ярты гомер булса да, хисап бирерлек бер эш дә күренми. Мин үз кулымдан килгәнне эшләдем кебек күренә...

Бүлмә фәүкыльгадә эссе. Эсселекдән бөтен тәнем чабырынды.

### 25 июль

Бүген иртүк Гыйният әфәнде килде, Гомәрне алырга урынлашырга булып хат яздым. Көн фәүкыльгадә эссе. Паспорт мәсьәләсе шәп түгел. Милли идарәгә тиз көндән курьер җибәрәм дип телеграмма сукдым.

**26 июль**

Бүген-иртәгә Гомәр килгәч, Ичан(?)га барып, андагы мөгаллимен Усига(?) җибәрәчәк идем, ләкин тимер юл хезмәтчеләр эш ташладылар, шуңарга күрә Гайшә ханым да китә алмады, юлда тукталды. Гомәр дә өзелеп калу ихтималы бар. Курьер да җибәрә алмавымыз ихтимал. Ул вакытда мин Харбиндан бер кая китә алмыйча калачакмын. Бу мәгънәсез көтү шулкадәр туйдырды. Шулкадәр вакытны әрәм итде, һич әйтеп бетерерлек түгел. Бүген Нияз Пекиндан кайтды. Артык күп кеше күрә алмаган, җыйган мәгълүматы күп түгел. Кытайның Маньчжурия һәм Пекин әтрафындагы мөселманлар хакында әсәрле бер нәрсә юк. Фәукыльгадә надан, ялкау халыкдыр... Анда бик күп мәртәбә барып йөрегән һөнәрле мөселманның сүзенә караганда Кянсу[1] – аерым мөхтәриятле бер вилаять. Халкы кытайча сөйләсәләр дә, кыяфәт берлә һич кытайга охшамаганлар, үзләре һәммәсе мөселман. Аерым гаскәрләре бар. Батыр, сугышчан халык. Голямәсе бик үк надан түгел. Юлы Пекиндан өч көн тимер юл берлән барганның соңында ике атна кәрван берлән. Юл башы, юл буе мөселман авыллары. Мосафирпәрвар халык. Кянсу Төркестанга кушыла, ике арада зур юл бар. Кәрван берлән ай ярымлык юл. Ләкин Төркестан Чиндан мәгълүмат ала алмаган. Аларның Кытай парламентында берничә депутатлары бар икән. Алар Нияз берлә күрешүдән тартынганлар. Мөселман булганга, берәр нәрсә чыкмасын дип курыкганлар булырга кирәк. Паспорт мәсьәләсе хәл кылынса, мин Владивостокга барырга була идем, ләкин әле һаман ул бер ноктада тора. Гомәргә, кайт, дип телеграмма бирдем. Ләкин кайта алмавы ихтималы бар. Бүген ягмур яуганга, бүген көн яхшырак.

Хәзер минем алдымда дүрт мәсьәлә тора. Берсе Омскига милли идарәгә курьер җибәрү. Икенчесе теге акчаларны товарга алыштырып, иенгә күчерү, өченчесе Владивостокга барып, тагы юл эзләп карау, дүртенчесе, Нике (?) әфәндене күреп, яңа план хакында сөйләшү. Юллар тукталганга, боларның берсен дә хәзер эшләп булмый. Бу сәфәрдә безнең юлга һәрвакыт көтелмәгән «аю» чыгып торды. Хәерле булсын.

---

[1] Кянсу – Ганьсу (Кытай провинциясе).

**27 нче июль**

Бүген тимер юл эшчеләренең забастовкалары бик зур куәт берлә дәвам итә, шуңарга күрә мин Ичанйуга барып, Нике әфәндене җибәрә дә алмыйм, ул да монда килә алмый. Килсә дә, юл юкга, китә алмый. Һәрбер эшдә кѳтелмәгән манигъ[1] чыга да тора. Милли идарәгә әллә тагын телеграмма биримме дигән фикер дә бар. Белмим инде.

Гомәр килә алмады. Товар һаман булганы юк. Эш әле бер төрле дә юлына куелганы юк.

**28 июль**

Бүген иртә берлән тимер юл йѳри башлады дигән хәбәр чыккан иде. Ул да тугры булып чыкмады. Забастовка бетмәгән булырга кирәк, шуңарга күрә минем, безнең эшләргә юл ачыла, дигән сѳенүем иртәрәк булды. Кунак булып тору бик уңгайсыз, шуңарга күрә бүлмә эзләдем. Ләкин паспорт мәсьәләсе бик авыр. Берне тапкан булдым, ләкин бер дә ярарлык түгел. Тагы нелегальный хәяткә күчәм ахрысы, моңарчы торганымда 19 паспорт алышдырган идем, бу инде егерменчесе, ләкин нелегальный торуга җиде ел вакыт үтде. Димәк, тагы шул хәят башлана. Ул вакытда яшьрәк идем. Хәзер чыдау авыррак булыр. Тәнемә кып-кызыл бер нәрсә чабырынды, эсседәнме, суданмы – мәгълүм түгел, ләкин бик эчне поштыра, кечетә.

**29 нчы июль**

Бүгеннең иң зур вакыйгасы – милли идарәдән телеграмма алдым. Теге мәсьәлә хакында кирәкле адымнарны атлыймыз. Тиздән нәтиҗәсендән хәбәр бирәмез диелгән. Ләкин акча мәсьәләсе фәүкыльгадә начар хәлдә. Хәзерге кебек иеннең күтәрелгәне юк иде. Хәзер яшел берлә бер иен егерме ике сум. Товар алырга һаман җай юк, ягъни бүген генә аны алып булмый. Сәүдәгәр халкымыз безгә шул мәсьәләдә ярдәм итмәделәр. Харбинга килгәч дә акча мәсьәләсен Әмрулла Агиев, Вәли Ибраһимов, Латыйф Яушевларга тапшырган идем. Алар

[1] Манигъ – киртә.

ичмасам яртысына товар алуны мәслихәт күргәнләр иде. Ләкин шуны эшләмәделәр, фәкать Әмрулла гына ахырдан кечкенә генә бер партия алдылар. Латыйф бөтенләй бер эш эшләмәде, ул гына түгел, Шәйхулла абзый Шафигуллин безнең алтмыш-җитмеш мең сумымызга товар таба алмады. Шул арада ул Агишевларга бер-ике миллион сумлык товар алган, безгә алтмыш-җитмеш меңлек товар тапмаган имеш... Инде рөхсәт чыгар, акча булмас. Аллага тапшырган.

Шәйхулла абзыйга тагы бер телеграмма сугып сорап карыйм, милли идарәгә дә озын телеграмма сугам.

**30 нчы июнь**

Гомәр һаман килә алмады, өзелеп калды күрәсең. Шәйхулла абзыйга товар алмассыңмы дип телеграмма сукдым. Милли идарәгә дигән телеграмманы Гомәр килгәнче дип көтмәкче идем, ләкин һаман килми дә килми. Булмаса, иртәгә сукмыйча ярамас. Бүген төнлә бик каты ягмур яуды. Урамлар су тулган, бик күп урамдан үтеп булмый. Тимер юл забастовкасы һаман дәвам итә, шуңарга күрә кеше җибәреп булмый.

**31 нче июль**

Бүген мин авырып тордым. Мигъдәм бик бозылган. Рәтләп йоклый да алмадым. Көн буе әлсерәп чыкдым. Тормыш бик мәгънәсез дә, бик ямсез дә. Хуҗаларның тормышлары Мәкәрҗәгә килгән кешенеке кебек. Өй карау, йорт тәрбиясе дигән нәрсә һич юк. Башданаяк дөнья куугa чумганга, аларга, әлбәттә, мондый җитешмәгәнләр күренми торгандыр. Минем кебек тик тора торган кешегә бик бәрелә.

Бүген өйләдән соң Иркутскидан Фуаддан электрист[1] берлә чыкдым дигән телеграмма килде. Мондан дүрт ай элек килергә тиеш булган Фуадымыз хәзер килә. Ни алып килә, нинди йомыш берлә килә, әлбәттә, хәзер әйтеп булмый. Әгәр Маньчжур стансасындан поездан җибәрсәләр, бер-ике көндән килеп җитәргә тиеш. Ничек килсә дә, мәсьәлә бик яхшы ачылачак.

[1] Электрист – электр поезды.

Бәлки рөхсәт дә алып килә торгандыр, ләкин инде ул рөхсәтдән файдалану мөмкин булмаячак. Чөнки акча мәсьәләсе бик чуалды. Безнең килгән чакдагы 20-25 мең акчамыз хәзер ун мең иенлек төшде. Сәүдәгәрләремезнең ярдәме аркасында безнең сибирски акчаларымыз бүгенгә кадәр алышмаенча калды. Ни булса булсын инде. Мин алты ай баш ватдым инде. Җитәр, мондый эшдә организацияң булмагач, бер кешенең тырышуындан гына бер эш дә чыкмый икән.

**1 нче август**

Бүген Фуадны көтдек, ләкин килмәде. Ул якда тимер юлны су юган икән дә, шунда Маньчжур стансасы башында поездлар көтеп ята икән. Саулыгым начар. Мигъдә һаман ташуында дәвам итә. Тәрбияләп булмый. Ашау-эчүне үзгәчәрәк йөртсәк, бәлки бер хәл иде, ләкин мин монда хәзер нахлебник хәлдә булганга, һич бер төрле эш эшли алмыйм. Әллә инде дизентерия була, эч бик бозылган. Корчаңгы да бетми. Бәхетсезлек бит һәммәсе дә бергә килә. Иркутдан җавап көтәм, берәр нәрсә ала алмасلармы.

**2 нче август**

Бүген авыруым дәвам итде. Докторга бардым. Дизентерия түгел диде, ләкин рух бик төшенке. Бик ялыкдым. Кич берлән авырып эшдән чыкдым. Гомәр килеп җитде. Бик зур мәшәкать берлән, мең бәла берлән границаны үткән. Инде Фуадны гына көтәргә калды.

**3 нче август**

Бүген иртә берлән Вәли әфәнде Ибраһимов Маньчжурдан килде. Фуадны Маньчжурда күргән. Фуад мин милли идарә берлән тәмам аерылышып, үзем генә Харбинга киләм дигән. Үзе килгәч сөйләтермен инде. Бик күп хәбәрләр. Хәбәрдән дә күп гайбәтләр бардыр. Шуларны төяп килә инде. Ләкин эш эшдән чыккач, олуг эшемез тәмаман күздән төшерелеп бетеп, аяк астына тапталгач килә. Әгәр шул килүне уңайлы вакытда эшләсә, элгәреге план буенча килгән булса, безнең сәфәрнең бөтенләй

башка якга борылуы ихтималы бар иде... Ниләр сөйләр, ниләр китерер. Тыңлыйк әле. Бүген кич берлән килергә тиеш иде, поезд туктап калган да, иртәгә калганлар имеш.

**9 нчы август**

Бүген минем Мәскәүдән чыкганыма бер ел тулганга гына каләм алдым. Юк исә хәлем алга түгел. Мин бер атнадан бирле постельдә бик каты авырыйм. Эсселек. Өч тәүлек авызыма бер тәгам алмадым. Хәзер күземне ачдым, терелеп киләм, ләкин һич көчем юк. Мигъдәм бик начар эшли. Бөтен авыру буе Агишевларда ятдым. Үзең кеше өстендә, үзең авыру, үзең паспортсыз, үзең бара торган юлыңдан өзелгән. Әлбәттә, болар рухка бик начар тәэсир итеп торды, шуның өчен өйдә хезмәтче марҗа гына, башка кеше булмаганга, караучы бер дә булмады. Былчырак эчендә ятдым. Минем иң җирәнгән нәрсәм – былчырак ятак. Монда килгәндән бирле шул чирне бик күп күрдем. Хосусан авыруым да былчырак баглыдыр... Инде, аллага шөкер, тордым. Мигъдә һаман юлда булмаса да, авызыма тәгам кермәсә дә, хәзер өйдә йөрим. Андан мондый яңа авыру өстәлеп китмәс, акрын гына терелермен инде. Ләкин бу арада монда холера куәтләнгән. Кытайлар арасында авыру, үлү бик күп. Бу Алланың каһәре төшкән Харбинда холерага каршы һичбер нәрсә юк. Монда һәркем спекуляция берлә генә мәшгуль булганга, һич бер төрле андый-мондый эшләр хакында уйлау беркемнең башына да керми. Әле менә буш торып йөдәп беткәнгә булырга кирәк, Харбин больницасының докторлары үз арада комиссия ясап, рус теленең иске имлясе берлән язарга кирәкме, яңасы берләнме дигән мәсьәләне тикшерергә тотындылар. Күбрәге иске имля тарафында имеш, чөнки иске дигән сүздә халык үзенә аерым бер тәм тапкан кебек докторлар да иске имля дигәнгә күбрәк ышаналар булырга кирәк. Холерадан авырганларны яткырырга урын юкга, ташырга арба юкга, урамда үлеп яталар.

Бүген Мәскәүдән качып чыкканыма тәмам бер ел тулды. Мөселман комиссариатының доносы берлән унынчы августда миңа Мәскәүдә революционный трибуналда хөкем булачак иде. Минем контр-революционлыгымның дәрәҗәсенә карап, миңа җәза бирәчәк иде, ләкин төрмәләр бик тулы булганга, ашау-эчү төрмәдә тәмаман юк дәрәҗәдә булганга, мин качып китдем. Шундан Идел аша көймә берлән төшеп, юлда тугыз көн калып, бик куркынычлар үткәреп, сугыш фронтын ерып, унсигезенче августда Казанга килеп кердем. Анда бер туктамаган туп-бомба тавышы астында берәр атна торып, Самарага китдем. Анда безнең халык җыелып бетмәгәнгә, киңәш мәҗлесе дә Уфада булганга, анда китдем. Уфада милли идарә тарафындан дәүләт киңәш мәҗлесенә иштирәк итдем. Милли идарәнең башка эшләренә иштирәк итдем. Уфаның хәле начарлана башлагач, милли идарә берлән Петропаулга күчдем. Максадымыз – анда барып зур гына газета куеп, Себергә хезмәтне күчерү, Себердә милли хәрәкәтне ныгыту иде. Ләкин, матбага начарлыкдан, газетамыз кечкенә булды. Себердә моңынчы искелек бик куәтле булганга, зур хезмәт итеп булмый, ди. Газета берлән, мәкаләләрем берлән һәм дә лекцияләр берлән, Петропаулны шактый кайнатдым. Икенче эш – солых һәйәтен оешдыру иде. Петропаулда аңарга каршы зур хәрәкәт булганга, Петропаул татарлары бик зур киртәләр салдылар. Төрле-төрле саботаж берлән эшне кичекдерделәр. Ахырдан тугрыдан-тугры көпчәккә таяк тыга башладылар. Ике ай алар берлән маташырга вакыт әрәм булганның соңында милли идарәне бераз хәрәкәткә китереп, аны оешдырып, солых һәйәтене яңа әсаска кордырдым. Озын киңәшләрдән соң, минем янга Фуад берлән Гомәрне кушып җибәрергә карар итдек. Гомәр милләт мәҗлесенең төркичеләр фиркасе тәмамында булачак, Фуад Учредительное собраниедән төркчеләр фиркасенең тәмамында булачак иде. Боларның икесендә дә җәмәгать акчасы булганга, алар шундан

үзләренә расход тотачаклар. Һәйәтенең тәмам расходлары милләт акчасындан тотылачак иде. Менә шул ниятне уйлап, Иркутскида берләшергә булып, Гомәр алдан чыгып китде. Мин 24 нче гыйнварда акча җыярга чыгып китдем. Фуад атна-ун көндән чыгачак булып калды. Шундан соң мин шәһәрдән шәһәргә кереп, халыкны җыеп, лекция укып, моназарә кылышып, кычкырышып-бакырышып, ай ярым юлда калып, ике йөз мең сум акча җыйнап, Харбинга килеп җитдем. (Гомәрне Иркутда очратдым, Фуад юк иде). Вәгъдә буенча Фуад Иркутда очрашырга булса да, ул әле Харбинда да юк иде. Иркутдан аңарга тиз кил дип телеграмма бирдек. Без Харбинда паспорт алырга берәр ай вакыт үткәрдек. Ул һаман килеп җитмәде. Без көтә-көтә көтек булып, унынчы апрельдә Япониягa чыгып китдек. Шул вакытда Петропаулдагы конференция минем мәгърузәмне игътибарга алмаенча (милли идарә күрсәтмәгән), тагы дүрт кеше сайлады. Шуларның Фуад берлән Солтанбәге рәсми вәкилләр булып китәмез дип торганлар. Үзләрен генә вәкил дип уйлаганга булырга кирәк, безнең берлән тәмамән мөнәсәбәтне кискәнләр. Без Япониядә өч ай торып, виза ала алмаенча, милли идарәдән, Фуаддан һич бер хәбәр ала алмаенча, Харбинга кайтдык. Менә мондан дүрт ай элек килергә тиеш булган Фуад хәзер килеп чыкды. Безне читдә калдырып, үзләре генә вәкил булып китү эше барып чыкмаганга, инде безнең берләшеп, милли идарәне читдә калдырып барырга булып килгән. Вакыты бераз соңрак, үзе безнең виза алмавымызны белә торып, виза Омскида икәнлекне аңлый торып, авызын күтәреп килгән. Менә шул Фуад монда килгәч, безгә доклад ясады. Конференциядә ике вәкил сайлау мәсьәләсе куелган. Минем мәгърузәм укылмаганга күрә, яңадан сайлау кирәк түгел, фәкать элеккеләрен генә рәтләп җибәрү дигән мәсьәлә мәйданга куелган. Милли идарә минем берлән бергә кабул иткән карарны бозып, яңа әсәска куйган вә шул үзгәртүне миңа һичбер төрле белдермәгән. Конференцияләрдә

кычкырышлардан соң комиссиянең һәм дә милли идарәнең күрсәткән кандидатларын Фуад берлә Солтанбәкне икесене сайлаганлар. Монда имеш (Фуад сүзенә караганда) Фуадны сайлаган өчен милли идарә зур иҗтиһад иткән. Солтанбәкне сайлауны ультиматум кебек куйган, чөнки Солтанбәк булмаса, һәйәтдә мин, Садри, Фуад булачак имеш. Шундан соң берәр атна, ун көн торып Омскига китәләр. Андан элгәре килгәндә Ибниәмин Әхтәмов[1] Франсә вәкиленә барган икән, ул вәкилләрегезгә бөтен җиңеллекне эшлимез дигән икән. Шул вәгъдә буенча Ибниәмин әфәнде солых сәфәренә бару бер кәефле бер прогулка гына була дип уйлаган да, үзен дә сайлатдырган. Ләкин бу килүдә граф де Мартель элгәреге кебек кабул итмәгән...

Шундан соң Милли идарә Солтанбәк берлә Фуадка заграничный паспорт алырга керешкән. Шул эшне чыгарып бетермәенчә үзе Уфага кайтып киткән. Фуад берлә Солтанбәк үзләре тырышып паспорт алырга калганлар... Шул арада Солтанбәк гаскәрлеккә алынган. Безнең ник безгә телеграмма, бер мәктүб, бер хәбәр генә җибәрмисез дигән сөальләргә, андан бит мин милли идарәне көтеп торам дип җавап бирә. Менә шулай итеп көн дә көн үтә, Колчак хөкүмәтенең милли идарәгә мөнәсәбәте үзгәрә. Безнең хакда доносլар ясыйлар. Фуад паспорт алып биргәнне көтеп тора. Шундан милли идарә Уфадан качып килә, Фуад яңадан паспорт һәм виза алып бирергә мөрәҗәгать итә. Шул арада безнең виза ала алмау хакында телеграмма килә. Милли идарә Фуадның мөрәҗәгатен кабул итми, аңарга паспорт алырга тырышмый. Бәлки, билгакес,[2] Фуадның солых һәйәте акчасын алырга карар итә. Шул карарга Фуад разый булмаенча, акчаны бирмәенчә, монда чыгып китә. Хәзер менә монда килгән. Максады - ничек булса да солых сәфәренә чыгып китү.

[1] Ибниәмин Әхтәмов – Ибнеәмин Әбүсогуд улы Әхтәмов (1877–1941), хокук белгече, сәясәт эшлеклесе.

[2] Билгакес – киресенчә.

Янында йөз кырык мең сумлар акчасы бар.

Фуад берлән мин, әлбәттә, орышышып тормадым. Солых сәфәрен җимерүченең берсе икәненә иманым камил булса да, хәзер кычкырышудан мәгънә юк. Бер сүз дә әйтмәдем. Ләкин аны үзем берлән бергә кушмадым. Милли идарәгә Фуад берлән нинди мөгамаләдә булырга дип телеграмма бирдем. Саулыгым төзәлгәч, бер карарга килермен.

**25 нче август**

Харбинга кайткач, хәят шулкадәр чыгырыннан чыкды, хәтта көндәлек хатирә язарга да мөмкин булмады. Башынданрак башламасам аңлашылмас да. Мин терелә башлагач, Харбинда холера китде. Кытай кыйсмендә көненә берничә йөз кеше үлә диделәр. Агишевларда тормыш һаман да кунак төсендә булганга, кунакның мәгълүм һичбер төрле хокукы булмаганга, үзем теләгәнчә бер эш дә эшли алмадым. Шул арада Ичанйудан Гыйният хәзрәт килде. Анда кичә генә шәһәргә хунхузларның һөҗүме булган. Хунхузлар берлә гаскәр арасында ике сәгатьләп атыш барган. Хунхузлар Кытай базарын яндырып киткәнләр, фәкать сугышда унбиш-егерме кешеләрен югалтканга, яңадан үч алырга килү ихтималлары бар имеш. Шуңарга күрә бөтен (...) чыкган кешеләр качалар икән. Агишевлар гаиләсе дә бик курыкганлар, китәргә карар биргәнләр. Гайшә ханымның бердәнбер углы бик каты авырый, шуның настроениесе бөтен өй эченә сираять итә[1]. Һәм дә, бала авырганга, Агишевлар гаиләсе китә алмый, дачада кала. Ул гына булмый, иртәгесен мулла авырырга тотына. Ул бүлмәгә кереп ята. Өйнең икенче хуҗа хатыны Заһидә ханым шәфкать медсестрасы әверелә. Шулай итеп, өй больница кыяфәтен ала. Сүзләр: Ибраһимның хәле ничек, дару бирдеңме, доктор килдеме? Ни диде? Берәр нәрсә ашадымы-эчдеме?.. Монда язарга утырып, бер нәрсә уйлау

[1] Сираять итә – күчә.

кайда. Гакылдан язмасаң, ул да табыш инде. Менә шулай торганда Ибраһимның хәле тагын начарланды. Харбиндан Әмрулла әфәнде килде. Малайның хәле начарланганын күреп, Харбиндан доктор чакырдылар. Заһидулла барып, бер яһүд докторын алып килде. Яһүд шунда килеп, бер мәртәбә карар өчен үзләрендән өч-биш мең сум алган, яшел акча берлән.

Шул больница һавасында бер-ике-өч көн вакыт үтеп китде. Безгә мондагы хәят без теләгән хәят түгеллеге мәгълүм булып җитде. Без аерым-аерым бүлмәләр эзләү юлына керешдек. Ләкин миңа алай иткәндә тагы паспорт мәсьәләсе килеп туа. Шул мәсьәләне хәл итә алмый торганда, яңа вакыйга булды. 19 нчы августда өйләдән соң сәгать алтыларда Агишевларның верандаларында чәй эчеп утыра идек, бердән бер-ике мәртәбә мылтык тавышы ишетелде. Бу нәрсә. Хунхуз килдеме дип карар чыгарырга өлгерә алмадык (хунхузны көтү һаман дәвам итә инде), пулеметдан ату башланды. Бакчада берничә пуля төшеп ярылды. Без, чәйләремезне салган пыялаларымызны ташлап, өйгә кереп бикләндек...

*Текстны Ләйлә Гарипова әзерләде*

# РАССКАЗ Г. ИСХАКИ «СЧАСТЬЕ БАШКИРА» В ПЕРЕВОДЕ Г. АКЧУРИНА

Одним из первых переводчиков Габдуллы Тукая на русский язык был Галим Акчурин. Им были переведены следующие произведения поэта: «Нищий», «Брошенной татарской девушке», «Порвались благословенные четки (На смерть Л. Толстого)». Они были опубликованы в 1914 году в сборнике научных работ Московского Лазаревского института восточных языков под названием «Восточный сборник».(1) Г. Акчурин был выпускником этого института. Он был неравнодушен и к творчеству другого очень большого и популярного татарского писателя Гаяза Исхаки. Г. Акчурина привлекло к себе такое известное произведение названного автора как «Башкорт бэхете» («Счастье башкира»).(2) Как известно, это произведение было написано в 1910 году в Финляндии, которая входила тогда в состав Российской империи. Галим Акчурин перевел и опубликовал это довольно популярное произведение (отрывок) на страницах названного издания. Интерес к творчеству популярных авторов со стороны уроженца отдаленного от Казани г. Петропавловска позволяет утверждать, что татары самых разных регионов Российской империи не только знали Тукая и Исхаки, но и были увлечены их творчеством. Всем этим переводчик был обязан родителям, семье, педагогам учебных заведений. С другой стороны мы должны отчетливо видеть роль книг, газет и журналов ,выходящих на татарском и русском языках в обеспечении информированности переводчика в области литературы и культуры.

Кем же был переводчик Г. Тукая и Г. Исхаки?

Галим (Мухамад-Галим) Хафизович (Мухамад-Хафизович) Акчурин родился 20 апреля 1892 г. в г. Петропавловске. В 1910 г. Г. Акчурин окончил местное реальное училище. В 1913 г. Г. Акчурин окончил полный курс специальных

классов Лазаревского института восточных языков и получил соответствующий аттестат. В лице Г. Акчурина мы видим специалиста, человека, владеющего как иностранными, так и языками народов России. Он свободно владел турецким, узбекским, казахским, азербайджанским, русским и татарским. Одновременно он владел на уровне чтения и перевода со словарем немецким, французским, арабским и персидскими языками.

В 1915 г. способный юноша из далекого г. Петропавловска становится студентом историко-филологического факультета Петроградского университета. К сожалению, из-за событий февраля 1917 г. он прервал учебу на третьем курсе.

Вернувшись на родину, Галим оказался в водовороте общественно-политической жизни края. Мусульмане г. Петропавловска избрали его депутатом Миллэт меджлисе (Национального собрания мусульман тюрко-татар Внутренней России и Сибири). В тюрко-татарском национальном парламенте, работавшем в Уфе с 20 ноября 1917 г. по 11 ноября 1918 г., Галим Акчурин был секретарем.

В советское время он работает в учреждениях и организациях родного города: секретарем местного агентства Центросоюза, секретарем киргизской (казахской) секции уездного ревкома, членом коллегии губернского отдела народного образования и т. д. Г. Акчурин страдал астмой и туберкулезом. В 1925 г. врачи признали его инвалидом III группы.

В 1932 г. Г. Акчурин по рекомендации лечащих врачей переехал с семьей в Казань. В столице Татарской АССР он прожил до конца своих дней. Здесь в основном работал в системе торговли. Последним местом его работы стал Казанский городской пищеторг, где Г. Акчурин занимал должность экономиста. В казанский период жизни он часто болел, его лечащим врачом была З.М. Кутуева, родная сестра писателя Аделя Кутуя. Г.Х Акчурин был необоснованно репрессирован. Галим Хафизович был арестован 1 ноября 1944 г. Ему были

предъявлены традиционные обвинения тех лет. В частности, в его следственном деле, которое хранится в Архиве УФСБ РФ по РТ, утверждается: «В 1917–1919 гг. принимал активное участие в националистических организациях г. Петропавловска, оказывал содействие Колчаку, издавал совместно с бывшими лидерами тат[арской] нац[иональной] к[онт]р[еволюционной организации] Гаяз[ом] Исхаковым и Туктаровым националистические газеты «Маяк» и «Юл». Г. Акчурин был осужден по статье 58–10 ч.11, 58–11. Во время заключения у него из-за неудовлетворительного питания и бытовых условий произошло резкое ухудшение здоровья.

14 июля 1945 г. Г.Х. Акчурин скончался в областной больнице. Через шесть дней ввиду его кончины уголовное дело было прекращено НКГБ ТАССР.

Г.Х. Акчурин реабилитирован 10 августа 1957 года. В «Справке о реабилитации», выданной прокуратурой Республики Татарстан от 29 ноября 2002 г. родственникам Г.Х. Акчурина, указывается: «Заключением прокуратуры Республики Татарстан от 26 ноября 2002 г. постановление прокуратуры ТАССР от 17 августа 1957 г. изменено, уголовное дело в отношении Акчурина Г.Х. прекращено за отсутствием в его действиях состава преступления». (3)

Судя по составу переводчиков данного сборника за 1914 год Г.Х. Акчурин оказался в престижной компании. Так, среди переводчиков были О.Е. Корш, Вл.А. Гордлевский, Н.И. Ашмарин.

Переводы Г. Акчурина, ставшие предметом нашего внимания свидетельствуют о хорошем знании им как русского и родного, татарского языков. Переводы Г. Тукая и Г. Исхаки свидетельствуют об определенных способностях и уровне знаний Г. Акчурина, в частности, знании им татарской литературы. На наш взгляд, всем этим он был обязан родителям, родной семье, своим педагогам. Вся его предыдущая образовательная подготовка (Лазаревский институт, столичный университет) позволяла ему взяться за

творческую, переводческую работу. Публикация переводов позволяет нам в определенной степени считать, что эту задачу он выполнил.

К этому моменту (к 10-м гг. XX в.) среди татар были молодые люди, способные переводит произведения национальных литераторов, в первую очередь, Г. Тукая и Г. Исхаки на русский язык. Юный Г. Акчурин был среди передовой части молодежи, которая понимала необходимость этой работы и стремилась донести до общероссийского читателя авторов национальной литературы.

Известный исследователь Исмагил Рамеев называет Г. Акчурина и в числе авторов журнала «Шура». Трудно сказать какие публикации имелись в виду И. Рамеевым. Знакомство с содержанием журнала «Шура» позволяет нам предположить, что он являлся автором следующих статей, посвященных истории Золотой Орды: «Туктамыш хан ярлыгы» («Ярлык Тохтамыш хана»)(4), «Туктамыш ханнын 2-нче ярлыгы» («2-й ярлык Тохтамыш хана»)(5). Очень возможно,что именно Г. Акчурин автор и публикации о творчестве просветителя К. Насыри «К. Насыйринын тэржемэи хэле хакында кайбер мэгълуматлар» («Некоторые сведения из биографии К. Насыри») (6).

Вниманию исследователей и читателей предлагаем текст перевода произведения Гаяза Исхаки (7).

## Литература

1. Таиров Н.И. Галим Акчурин − переводчик Габдуллы Тукая // Вестник КазГУКИ. 2016. № 1. С. 44−47.
2. Труды по востоковедению, издаваемые Лазаревским институтом восточных языков. Выпуск XLIII. Восточный сборник в честь А. Н. Веселовского. Москва. Типография М.О. Аттая и К°. Маросейка, Косьмодимиановский пер., д.5. 1914. С. 243−255, 277−279
3. Таиров Н.И. Галим Акчурин − секретарь Миллэт Меджлисе //

Гасырлар авазы − Эхо веков. 2003. №3/4. С. 149−153.
4. «Шура», 1912, № 2. С. 49−51.
5. «Шура», 1912, № 10. С. 307−309.
6. «Шура», 1912, № 23.С. 3-я страница обложки.
7. Труды по востоковедению, издаваемые Лазаревским институтом восточных языков. Выпуск XLIII. Восточный сборник в честь А.Н. Веселовского. Москва. Типография М.О. Аттая и Ко. Маросейка, Косьмодимиановский пер., д. № 5. 1914. С. 256−261.

*Н.И. Таиров, Казан дәүләт мәдәният*
*һәм сәнгать университеты*

## Счастье башкира

В рассказе выражен протест против ранних браков, которые у башкиров совершаются, как известно, в очень раннем возрасте. Кратко башкирская свадьба описана в статье П. С. Назарова «К этнографии башкир» //Этнографическое обозрение. 1890. №1. С. 186 – 189.

Когда мы подъехали к подножию Уральских гор, солнце склонилось к закату. Мы остановились на ночлег около бьющего из-под горы ключа. Зачерпнув из шумного источника холодной воды, мы наполнили свой дорожный чайник, разложили огонь и скипятили воду. Несмотря на то, что у нас с башкиром был всего один стакан, мы с наслаждением принялись за чай.

Величавый вид Уральских гор, как-будто хотели они обрушиться на нас, немолчное журчание источников, приятный аромат соснового леса, украшавшего склоны Урала, − все это, конечно, еще больше придавало прелести нашему чаепитию. Когда мы кончили чай, солнце закатилось. Казалось, серебряный диск луны только этого и ждал, и в

полном блеске начал подниматься из-за Урала. Луна принесла с собой не только свет, но и тишину и окутала Урал.

Пока башкир возился с лошадью, я, подложив под голову бешмет, начал при свете луны любоваться Уралом, – горами, принадлежавшими когда-то моим предкам. При лунном освещении он показался еще длиннее. Концы его извилистых разветвлений, охваченные дальней темнотой, приняли еще более величавое очертание. Росшие на горе деревья, окутанные в темноту ночи, казались еще толще, их листья при луне казались еще зеленее и красивее.

Родники все с тем же журчанием продолжали течь и течь; где-то заскрипел дергач. В ответ ему на ближнем озере громко несколько раз простонала выпь: «хуп, хуп!». Где-то замычала корова. Наша лошадь, встрепенувшись, заржала. Урал своим ответным эхом еще более возбудил ее.

Башкир, подойдя ко мне, лег тоже на спину и начал рассматривать небо и красивые Уральские горы.

Должно быть, красивое небо, величественные горы, чистый, как дева, лес, журчание родников, одуряющий запах, – не остались без влияния на него. Он глубоко и многозначительно вздохнул. Предполагая, что вздох не без причины, я сказал ему: «ну-ка, спой что-нибудь! Умеешь петь?». Он ответил мне: «ты сам спой, ты, наверно, знаешь много казанских песен».

Но я знал, что соловьи, услышав мой «прекрасный» голо, умрут от испуга, и , конечно, отказался, не желая оставить Урал без их трелей. Башкир тоже отказался. Мы вполголоса начали разговаривать.

Я спросил у него: «Женат ли ты? Как у вас справляют свадьбу?» Этот вопрос как будто задел его за больное место, и он, глубоко вздохнув, сказал: «женат». Когда же я пристал к нему с просьбой рассказать, как у них проходит свадьба, он согласился и начал: «Вернулся я со службы...»

Его рассказ показался мне не лишенным интереса, и, будучи теперь на другом краю света[1], я вспомнил рассказ и решился написать.

***

Мой отец был человек богатый, и потому перед окончанием службы я купил себе новые сапоги, новую шинель и заказал новую куртку. Грудь свою украсил значком, который получил за меткую стрельбу. И вот, принарядившись, поехал я домой. В пути все смотрели только на меня. Торговки молоком оказывали мне особое внимание и, посматривая на меня, долго любовались. Как только мы подъезжали к станциям, расположенным вблизи башкирских аулов, я, с шапкой набекрень, все чаще и чаще выходил гулять. Башкиры, увидев меня, говорили между собой: «что это за чиновник?» А я, прикидываясь, что не понимаю их, закручивал усы и продолжал все ходить. Вот приехали в Оренбург. Там я нанял пару лошадей, заставил подвязать колокольчики и, развалившись как помещик в тарантасе, поехал домой.

Башкиры, которых мы встречали на пути в аулах, удивленно говорили: «что это за начальник?» Наконец я дома. Весь аул пришел посмотреть на меня. Все удивлялись моей красиво расшитой шинели, блестящему значку и пуговицам, которые, как у чиновника, сверкали на солнце.

Теперь только я узнал, что мой отец умер.

Мать по случаю моего приезда заколола корову и начала меня угощать. Все деревня для меня устроила праздник. Мы ходили из дома в дом, пили кумысы, ели баранину. Потом я поехал гостить в соседний аул. Там тоже всех удивил красотой своей шинели. Так прошла неделя-другая. Я понемногу начал заниматься хозяйством. Старший брат еще до смерти

[1] Рассказ написан в 1910 году в Финляндии.

отца отделился от нас, и мать осталась главной хозяйкой; поэтому я нашел хозяйство очень запущенным. Сено было не собрано, хлеб не сжат и не смолочен. Понемногу я отделался от работ. Но нельзя же было работать в шинели и куртке, и я постепенно забросил их. Хотя сначала ходить в старой башкирской одежде было мне стыдно, но, после я вполне привык. Когда даже мне приходилось видеть свою шинель, я удивлялся, как это могло мне доставлять прежде удовольствие носить такую одежду.

Мать была стара. Так как нужен был человек, который мог бы следить дома за хозяйством, решили меня женить. Я и сам был не прочь от этого. Сначала я думал взять жену из соседней мещерской деревни; мещерские девушки здоровые, полные и красивые.

Но мать, родственники – восстали против этого, говоря: «разве можно жениться на поганой мещерской девушке?» Я уступил им.

Мы порешили взять дочь богатого башкира, который жил в восьми верстах от нас. Сыграли свадьбу.

По-нашему [башкирскому] обычаю не полагается видеть невесту до посещения её родителей. А для того, чтобы увидеться с родителями, нужно поднести матери – камзол, подбитый лисьим мехом, а отцу – суконный «джилян»[1] и полностью заплатить за девушку калым. В результате таких стеснительных правил часто случается, что жених и невеста знакомятся тайком; это возможно, конечно, только при участии разных тетушек; вот почему жениху приходится добиваться их содействия подарками.

Вскоре настало время и моей свадьбы. Чтобы повидаться с невестой, я поехал к ней верхом. Предварительно увиделся с тетушкой и подарил ей большой шерстяной платок. Перед заходом солнца, по нашему обычаю, все деревенские

[1] «Джилян» – род халата, с воротником.

девушки, – в том числе и невеста, отправляются в лес. Жених должен из этой группы девушек выбрать именно свою невесту. Если вместо неё поймаешь другую, это считается позором, значит, жених – негодный; случается, что за это он и плетку пробует. Но как же среди совершенно незнакомых девушек узнать свою невесту? Конечно, и здесь нельзя обойтись без помощи тех же тетушек. Неся в одной руке конфеты и пряники, а другой – придерживая за пазухой шелковый платок, я отправился вслед за девушками. Тетушка за несколько просверленных[1] монет сообщила мне, что моя невеста в желтом платье. Девушки остановились на краю поляны, окруженной со всех сторон мелким сосновым лесок. Увидев меня, они все закрылись платками и начали хихикать. Я подошел к ним и накинул платок на голову девушки, в желтой рубахе, стоявшей позади всех. Не успел я протянуть руки, чтобы схватить ее, как она уже бросилась бежать. Я – за нею. Она пробежала немного, я догнал ее и слегка ударил кнутом. Невеста остановился и закрыла руками лицо и глаза. Я отнял её руки от лица и на руках донес до ближайшей сосны и усадил ее там. При слабом свете закатывающегося солнца, я начал рассматривать свою невесту. Её черные волосы, такие же глаза, круглое лицо – показались мне даже красивыми. Но меня удивило детское выражение её лица и глаз. Хотя я знал, что ей всего только 13 лет, я рисовал её в своём воображании взрослой и здоровой девушкой; а теперь передо мной был ребенок: грудь даже не сформировалась, руки и ноги только что начали развиваться.

Я начал обнимать, целовать свою невесту, − она все мои порывы оставляла без ответа. Мало того, она все еще продолжала закрывать от меня своё лицо. Так как я много слыхал от своих товарищей о первых свиданиях и о том, что

---

[1] Мусульманки вплетают в свои космы ленту, в которой подвязывают просверленные серебряные монеты.

многие из невест при расставании ночью плакали с тоской, мне показалось несколько странной крайняя холодность моей невесты. Не успел я еще объяснить себе это, как настало время нас расстаться. Я еще раз крепко обнял и поцеловал ее. Она и на этот раз ничего не ответила мне. Я сел верхом на своего жеребца, прихлестнуть его кнутом и в один миг поехал домой. На следующий день в обычное время поехал я опять к ней. Теперь я решился поближе познакомиться с ней и поговорить. Тетка встретила меня и повела в клет, где спала моя невеста. Но и на этот раз мои ласки остались без ответа. Это возбудило во мне сомнение. Я стал с ней разговаривать, но в словах её тоже не было ничего серьезного. Она лежала съежившись, подобрав руки и ноги; это мешало мне обнимать и целовать её. Я рассердился и сказал: «зачем ты так упорствуешь?». Она, глядя на меня, ответила: «Ты там, на службе, научился у русских женщин разным непристойностям», и замолчала. В моё сердце вкралось еще большее сомнение. Так, за эту неделю я ничего и не добился. За это время я не видел у нее ни веселого лица, ни признаков любви. Я рассказал об этом одному из своих товарищей. Он посоветовал мне: «Ты не обращай внимания на её протесты и сопротивления, сделай её насильно своей женой». Я поступил по его совету, но моя невеста после этого стала ещё холоднее, чем прежде. Она перестала со мной говорить и наконец, однажды она начала меня просить, умолять и плакать, говоря: «Ради Бога, не делай того непристойного дела, которому научился на службе».

Я потерял всякое удовольствие быть женихом. Иногда я сердился на неё, не обращал внимания на её слезы и протесты, но эти слезы отравляли мне прелесть жизни. В полном отчаянии я рассказал это матери. Она начала лечить её у каких-то мулл, но это не помогло. Прошел день, прошла неделя – месяц. Каждый день с наступлением вечера, я на своем жеребце отправлялся ночевать к ней и на

заре возвращался домой, но в душе не находило никакого удовлетворения.

Я начал помышлять о разводе с ней и о женитьбе на другой. Хотя мать и уговаривала: «потерпи еще, потерпи», я в душе решил все-таки жениться вторично. Однажды ночью, сильно рассердившись на свою невесту, я сказал: «Что ты делаешь? Разве так хорошо? Ведь я женился, чтобы иметь настоящую жену»; этим я дал её понять, что недоволен ею. Когда же и это не помогло, я категорически объявил ей: если так и будет продолжаться и дальше, я женюсь на другой девушке. Эти слова произвели своё действие. Она начала плакать и в слезах умоляла меня не бросать её, она целовала и обнимала меня. Я совершенно растерялся. Вдруг она заговорила: «Я тебя очень люблю; если бы за тобой не было того, чему ты научился в солдатах, я еще больше бы тебя любила». После этого, не знаю почему, от жалости или от чего-либо другого, я перестал думать о разводе. Я не был счастлив в супружеской жизни, но думал, что все это постепенно изменится, заплатил за нее весь калым. Затем повидался я с её родителями, но невеста оставалась такой же, как и прежде… Я перевез её в наш дом. Мать полюбила её.

Оказывается, она давно научилась доить коров, кобыл; умела также готовить кумыс, печь хлеб, стряпать кушанья; но в общем, она была совершенный ребенок. Не желая губить молодость, я обратился за помощью к Нур-джан-хазрету и подарил ему очень хорошую лошадь. Но жена не изменилась. Тогда я вспомнил одного знакомого русского фельдшера, жившего за Троицком; с ним я познакомился ещё на службе. Я отправился за 400 верст к нему. Отыскал его и рассказал ему своё горе. Он прописал её какое-то лекарство. Несмотря на 300-верстное расстояние, я с этим рецептом отправился в Оренбург и там достал лекарство. Но и это не помогло.

Вот уже 4 года, как я женат; а моя жена твердо убеждена,

что я испортился на службе. Теперь не знаю, что и делать. Развестись, − так жаль ее, не жениться, — тоже горе. Он остановился, протяжно и глубоко вздохнул.

Луна исчезла за облаками. Небо, как и лицо рассказчика, потемнело. Горы казались ещё огромнее, деревья еще толще; мрак тихо окутал окрестности Урала. Только тяжелые вздохи башкира и крики дергача нарушали таинственную тишину.

Башкир повернулся на другой бок, и снова послышались тяжелые вздохи. Его лошадь, как бы откликаясь на горе своего хозяина, печально заржала. Из лесу печально отозвалось эхо. Месяц, выплывший из-за облаков, облил своими ярко-белым светом горы, деревья и моего спутника, башкира. Глаза наши встретились. Как бы ожидая от меня совета, он пристально посмотрел на меня. А я не знал, что ему сказать, растерялся и повернулся на другой бок».

# РӘСМИ ЧЫГЫШЛАР

## Милләт Мәҗлесенең мөһим карарлары

*(Милләт Мәҗлесе – 6 гыйнвар утырышы)*

Тарихка тәүге тапкыр татар халкының милли парламенты буларак кереп калган Милләт Мәҗлесенең эшчәнлеге тәмамлануга 2018 еллның гыйнвар аенда 100 ел тулды.

XX гасыр башы тарихи вакыйгалары, татар иҗтимагый хәрәкәтендә башланган уңай үзгәрешләр, татар халкының сәяси һәм мәдәни үсешенә генә тәэсир итеп калмый, милли дәүләтчәнлеге идеясендә беренче адымнар ясаган Милләт Мәҗлесе төзүгә дә ихтыяҗ тудыра. Ул ихтыяҗ 1917 елгы Октябрь инкыйлабыннан соң сәяси вазгыятьтә аеруча мөһим иде. Милләт Мәҗлесе үз вакытында милли тормышта начармы-яхшымы әһәмиятле миссиясен үти алган. Без аны шул яктан искә алырга тиеш тә. Ләкин Милләт Мәҗлесендә катнашкан милли әйдәманнарның эш-гамәлләрен никадәр генә уңай яктан искә алырга тырышмыйк, алар арасындагы каршылыклар, бәхәсләр заман биргән форсаттан файдаланып калырга мөмкинчелек бирмәгән. Кызганыч, большевиклар идарәсе Россиянең барлык дәүләт структураларын кулга алу белән ул мөмкинчелекләрдән файдаланырга тырышу тормышка ашмас хыял гына булып кала. Шунысы ачык: милли идеяләрне аңлау һәм гамәлгә ашыру юлында ике төп фракция – «төрекче»лек вә «тупракчы»лыкка бәйле бәхәсләр, фикер аерымлыклары проблемаларның чишелешендә шактый тоткарлыклар ясый. XX гасыр башында басылган вакытлы матбугатта, аерым алганда, 1917 елның декабре һәм 1918 елның гыйнвар айларында нәшер ителгән саннарында дөнья күргән репортажлар, мәкаләләр, карарларның нигезендә алар ачык чагылыш тапканнар.

Бу урында Г. Исхакыйның Милләт Мәҗлесенең 1918 елның гыйнвар ае утырышында сөйләгән чыгышын тәкъдим итәм. Чыгыш Г. Исхакыйның 15 томлы «Әсәрләр» тупланмасына кертелмәгән. Шуларны да истә тотып җыентыкка урнаштыру кулай булыр дип санадым.

Әдип-публицист үзенең чыгышында «төрекче» фракциясе

әгъзасы буларак киләчәктә дәүләт төзелеше өчен мөһим мәсьәләләр – милли бердәмлек, дәүләтнең икътисадый нигезе проблемаларын күтәрә. Мәгълүм булганча, Милләт Мәҗлесе утырышларында «төрекче» фракциясенә каршы 1917 елның Февраль инкыйлабыннан соң татар иҗтимагый хәрәкәте һәм сәяси көрәше тәэсирендә сәясәт мәйданына килгән, заманы өчен шактый радикаль карашлы татар яшьләреннән гыйбарәт «тупракчы» фракциясе әгъзалары исеменнән Галимҗан Шәрәф тәкъдим иткән мөстәкыйль «Идел-Урал штаты»ның канун проекты, милли сәясәттә инде чыныккан өлкәннәр арасында бәхәс уятудан бигрәк, 1917 елгы Октябрь инкыйлабыннан соң килеп туган катлаулы тарихи вазгыятьтә Россиянең киләчәге караңгылык пәрдәсе артында булуын истә тотып, «төрекче»ләр, шул исәптән, Г. Исхакыйда проектта эшләнеп бетмәгән мәсьәләләр, «Идел-Урал штаты» идеясенең чынбарлыкка туры килеп бетмәгән якларын да искәртергә мәҗбүр булалар. Әдип-публицист чыгышыннан күренгәнчә, ул идеяне якламый, хәтта кайбер фикерләрен тәнкыйтьләп тә уза. Аның дәүләтләр тарафыннан кабул ителгән кануннар яисә килешүләрнең, чынбарлыкта, дәүләтләр, халыкларның хокукый нигезен якламавы, җәмгыятьнең законнары бары көчкә буйсындырыла дигән фикере игътибарны җәлеп итә. Г. Исхакый инде 1918 елда ук: «Дөньяда – көч канун. Көчең булмаса, кануннарыңны тик күтәреп йөр», – дип язган икән, монда уйланырлык нәрсә бар. Әдип-публицистның әлеге фикере бүген дә кәгазьдә идеал вариантта булган БМО карарлары һәм халыкара законнарның дәүләтләр, милләтләрнең милли һәм дәүләти хокукларын яклый алырлык түгеллеген раслый, хәтта ки кисәтә. Хәзерге дөньяда килеп туган катлаулы һәм гаять тә четерекле сәяси вазгыятьтә аерым дәүләтләрнең, шулай ук Россия идарәче даирәләренең күп кенә сәяси, милли проблемаларны корал көче белән куркыту-өркетү юлын эшкә җигеп хәл итүе күз алдында. Заманында тирән аналитик фикергә ия Г. Исхакыйның бу афоризмга тиңләшерлек фикере шул чорның мөһим милли тартыш, көрәшләренә күзәтеп барганнан соң туган. Чыгышта бу ачык күренә.

Хәер, әдип-публицистның чыгышында гәүдәләнгән һәрбер фикеренә ачыклык кертү кирәк тә түгел, чыгыш укучының күз

алдында. Ул аны үзе укып, кирәкле нәтиҗәсен чыгарыр. Шунысы ачык: Г. Исхакый чыгышында яңгыраган фикерләр һәм шул заманда җибәрелгән хаталар бүген дә игътибарга алырлык, ул шуның белән актуаль дә.

## Милләт Мәҗлесенең мөһим карарлары

*(докладның тексты)*

Сәгыйть әфәнде Янгалычев өлкә алуда әсасе миллият[1] икәнен әйтеп бирде. Докладчылар моны ачык әйтмәгәннәр иде. Мин менә шул хакта сөйлим. Милләтләрнең бер-берсен саклашулары өчен менә шушы милли мохтарият вөҗүдкә[2] китерелә. Бу шул мәмләкәттә торучы милләттәш халыкларның иттифакыннан гыйбарәт. Бу иттифакый мәркәз[3], сәкыйләте миллият[4] – безнең бу парламентымыз шул миллият мәсьәләсен хәл кыла.

Русия үзе өлкәләр иттифакыннан мөрәккәб булачак[5]. Бу өлкәләрнең бүлгәләнүендә әсасе икътисад булачак[6]. Менә шул ноктаи нәзардан[7] без тупраклы мохтарият алмакчы булабыз. Монда мәркәзе сәкыйләт икътисад ул иң кирәк әйбер, эш шулай булып чыкса, өлкәмез өчен Идел буеның кирәклегендә шөбһә [юктыр][8].

Әлегә кадәр җир өчен кычкыручыларның бу юлы гына килеп, җирдән качуларына гаҗәпсенә. Иран шаһына: «Руслар Хәзәр диңгезен алырга телиләр, – дигәч, шаһ: «Диңгезнең суы татлы мени?» – дип сораган. – «Тозлы», – дип җавап биргәннәр. – «Алайса ала бирсеннәр», – дигән. Бу шуның кебек була, ди.

Без канун төзибез. Идел барыбер безнеке инде. Ул, Дон казаклары манигъ була[9] башласалар, без аларга канун белән

---

[1] Әсасе миллият – миллилек нигезе.
[2] Вөҗүдкә – барлыкка.
[3] Иттифакый мәркәз – берләштерелгән үзәк.
[4] Сәкыйләте миллият – миллилек авырлыгы, читенлеге.
[5] Мөрәккаб булачак – кушылган, гыйбарәт булачак.
[6] Әсасе икътисад булачак – икътисад нигезендә булачак.
[7] Ноктаи нззардан – караштан.
[8] Бу урында сүз танылмый. Квадрат җәя эчендә автор сүзе.
[9] Манигъ була – киртә була.

каршы торырбыз, диләр. Соң ул канунларга ышана аласызмы? Кырык мәртәбә канун вә могаһәдәләр[1] язылдыгы хәлдә, серб, болгар вә румын халыклары әле булса үзара сугышалар. Мин шул кануннарга ышанмыйм. Дөньяда – көч канун. Көчең булмаса, кануннарыңны тик күтәреп йөр.

Самара губернасы кушылса, 30 гына процент калабыз. Штатның булмавын теләүче руслар күпчелек тәшкил итәчәк, диләр. Без бит шуның өчен референдум кабул иттек.

Референдум ясарбыз. Шул вакыт халыклары кушылырга разый булмаса, Әстерхан белән Самара аерылып калырлар. Әле бит без күпчелек ляихәсе[2] эченә керә торган халыкларның да бу штатка керергә разый булачакларын катгый гына әйтә алмыйбыз...

Г. Исхакыйның бу чыгышы «Тормыш» газетасының 1918 елгы 14 гыйнвар (784 нче) санында басылган. Текст шуннан алынды.

*Кереш мәкалә һәм текстны*
*Зөфәр Мөхәммәтшин әзерләде*

## Речь редактора журнала «Милли юл» Аяза Исхаки

От имени татарской самостоятельной организации «Идел-Урал», входящей в состав организации «Прометей», равно как и от имени самого «Прометея», говорил Аяз Исхаки. От имени всех организаций «Прометея» приветствовал Вольное казачество, как своего соратника по борьбе с общим врагом... «Если раньше наш враг пользовался неорганизованностью угнетенных народов, то ныне объединение и консолидация общих сил против своего врага идет быстрыми шагами. Беспокойство и внимание, которое уделяют нам наши враги, показывают, что именно эти наши шаги наиболее опасны для нашего врага и полезны для дела освобождения всех нас. Вольному казачеству ваши враги,

[1] Могаһәдә – килешү, договор.
[2] Ляихәсе – проекты, тәкъдиме.

начиная от Харламова[1] и кончая Деникиным[2], не перестают уделять пристальное внимание. Раньше о Вольном Казачестве я знал только из вашего журнала, а теперь, встретившись с вами, вижу, что Вольное Казачество представляет собой большую организованную силу. Ныне, когда народы, борющиеся за свою свободу, уразумели причину своих прошлых неудач, стремление наше, безусловно, близко к цели.

Недавно большевики в своей печати констатировали, что в СССР 48% населения составляют «инородцы», и при этом не причисляли к этим «инородцам», к числу угнетенных народов вас, казаков. Если к этим 48% прибавить вас, да еще принять во внимание, что всякие составители статистики преувеличивают то, что им выгодно, и приуменьшают то, что им не выгодно, то приходится убеждаться, что инородцев то в СССР не 48, а 51–52%. Характерным для всех этих инородцев было то, что после революции все они пытались как-то по-новому организовать и наладить свою жизнь, добиться свободы, и только русский народ немедленно принялся за расхищение и разграбление, которое и до сих пор продолжается. Истощив все прочие богатства, большевики принялись за продажу и вывоз... людей! Все вы знаете, что по новому декрету за 1000 рублей можно выписать человека из России навсегда...

В том же, что над нами делают всякие эксперименты русские, виноваты мы сами. Если бы мы были организованы, то враг не мог бы делать с нами то, что делает. Поэтому первейшей нашей задачей является организация и солидаризация сил. С этой целью и организован клуб «Прометей» – Союз угнетенных народов, отделения которого разбросаны почти по всем столицам и вбирают в свой состав и объединяют представителей всех угнетенных Россией народов. Входили туда на персональных началах и некоторые казаки. Теперь, увидев вас и ближе познакомившись, я вижу, что наш путь един и что мы можем и должны работать в

---

[1] Харламов – Василий Акимович Харламов (1875–1957), донской казак, кадет, депутат Государственной Думы четырех созывов.

[2] Деникин – Антон Иванович Деникин (1872–1947), русский военный деятель, генерал-лейтенант; с 1920 года в эмиграции.

одном направлении. Мы, татары, объединенные в организации «Идель-Урал», в союзе с горцами, азербайджанцами, грузинами и украинцами, работаем в одном направлении. Враг одного из нас является врагом общим, как друг одного из нас – друг общий. Между этими народами, как, например, Крымом и Украиной, Грузией и Азербайджаном, Казачеством и горцами могут быть некоторые спорные вопросы. Эти вопросы сейчас нужно отложить. Если мы в этих вопросах будем объективно настроены и подойдем друг к другу не с целью завоевания, не с целью поглощения один другого, а с целью соглашения, то разрешение всех этих вопросов не представляет трудности.

Обращаю ваше внимание на один психологический момент: мы сейчас, сидя небольшой семьей в Праге, говорим ни больше, ни меньше, как о разделении по народностям «великой и единой» России. С точки зрения какого-нибудь русского генерала это безумие. Они так и ведут себя, русская эмиграция так и рассматривает наши стремления. Но осмелюсь обратить ваше внимание на один исторический факт: не были ли таким же «безумием» до войны попытки освободить свои народы двух великих национальных вождей Масарика[1] и Пилсудского[2]?.. Ведь в отношении сил чехов и немцев, поляков и русских, и немцев была такая же пропорция, как в соотношении наших сил с русской. Например, Пилсудский никогда не надеялся, что только польскими силами можно будет победить своих поработителей немцев и русских. Был момент, когда сам Пилсудский, потеряв надежду освободить свой народ при своей жизни, собирался передать свой освободительный завет своим молодым соратникам... Но настал удобный момент, и мы теперь видим и свободную Чехию, и свободную Польшу, и во главе их вождей, смело и с верой взявшихся в свое время за дело.

Если мы внимательно посмотрим на свое положение, то мы должны быть еще более оптимистами: наше положение гораздо

[1] Масарик – Томаш Гаррих Масарик (1850–1937), государственный и политический деятель Чехословакии.

[2] Пилсудский – Юзеф Пилсудский (1867–1935), государственный деятель Польши.

лучше, чем положение чехов и поляков до войны. Я уверен (хотя я уже не молод), что увижу свою свободную Татарскую республику.

От имени организации «Идель-Урал» поздравляю «Вольное казачество» с пятилетним юбилеем и уверяю Вас, что наша цель одна, что наш путь один – к нашей свободе» ...

Затем он, уже как представитель Варшавского клуба «Прометей», оглашает от имени этой организации следующее письменное приветствие:

«Милостивые государыни и милостивые государи! Эмиграция наций, угнетенных Москвой, вышедшая после оккупации их территории на запад и на юг, продолжает свою борьбу за национальное и государственное самоопределение. Сорганизовавшись, создала эмиграция Лигу угнетенных народов. Мы все верим, что идея национального освобождения, закончившаяся победой на западе, так же победоносно доведет народы до полного освобождения на всей территории СССР. И здесь на Востоке первый этап уже пройден. Есть самостоятельная Финляндия, Эстония, Литва, Латвия и Польша. Как представитель Лиги угнетенных народов, прошу вас принять наши добрые пожелания в борьбе, которую вы ведете против порабощения всякой Россией...».

Аяз Исхаки во второй раз берет слово и выражает свое удовольствие по поводу наличия среди вольных казаков их собратьев, представителей калмыцкого национального течения и предлагает тост за возрождение Калмыцкого народа. (Аплодисменты).

Мәкалә 1932 елның 25 декабрендә «Вольное казачество» журналында басылып чыга. «Вольное казачество» (Прага, 1927–1934, Париж, 1934–1939) – ике атнага бер чыккан әдәби һәм сәяси журнал.

## Аяс Исхаки. Идель-Урал[1]

Тюркский народ, как организованный в государственную форму, исторически нам известен за 200 лет до рождения Христа. В это время населенным центром этого народа были окрестности озера Байкала, но его кочевые элементы доходили до Великой Китайской Стены и до Волги. Исторические данные об этом периоде сохранились только в китайских летописях. Из мало разработанного этого материала нам известно, что тюрки в это время имели свое государство, свою культуру и свою письменность, но документов тюркской письменности этого периода до сих пор найдено не было. Самый древний письменный документ, это – так называемые «Орхунские Памятники» VII века по Р.Х. Они написаны национальным тюркским алфавитом. Язык их несмотря на то, что уже прошло несколько веков, очень близок современному наречию казанских татар. После этого времени, т.е. после VII века, уже имеется много документов. Из недавно найденного турецко-арабского словаря[2] видно, что и тогда уже тюркский язык имел два наречия, отличающихся друг от друга главным образом в спряжении глаголов. С тех пор эти различия углубились, и получилось два отдельных наречия. В литературе они называются южным и северным наречием, но общность грамматики, синтаксиса и общность корней мешала обоим наречиям превратиться в самостоятельные языки, как польский и русский или эстонский и финский. Тюрки жили отдельными племенами и управлялись родоначальниками, которые в свою очередь подчинялись верховному вождю всех народов и племен Кахану (повелителю). Отдельные племена часто создавали отдельные ханства и воевали друг с другом. Иногда какой-нибудь полководец собирал их в одно государство. История знает несколько таких тюркских империй. В средние века в начале XII столетия Чингиз-Хан (1154–1227) соединил все тюркские пле-

---

[1] От редакции: настоящую статью помещаем в информационном порядке (ВК).

[2] «Дивану лугат ат-тюрк» – сочинение Махмуда Кашгари, написано в 1147 году от Р.Х.

мена в одно управление и создал могучую тюркскую империю, но и она долго не существовала и разделилась на три группы: а) Кипчак (Поволжье), б) Чагтай (Туркестан) и в) Сельджуки (Малая Азия). Войны Тамерлана (1336–1405) углубили эти розни и образовали три тюркских ханства. На Волге – Золотая Орда, в состав которой входит и болгарское ханство. Золотая Орда впоследствии разбивается еще на несколько ханств (Казанское, Астраханское и т.д.). Чагтайская группа образует Туркестанское Ханство, которое позднее тоже разбивается на мелкие ханства. Сельджуки, а потом османиды, образовали турецкую империю Османов (Малая Азия и Балканы). Как известно, волжская группа в половине XVI века подпала под владычество Москвы и потеряла свою самостоятельность (Казань пала в 1552 г., а Астрахань – 1554 г.), но это не значит, что тюрки или так называемые историей татары покорились судьбе и отказались от своих национальных стремлений. Наоборот, тюрки ни на минуту не отказывались от возможности возрождения своей самостоятельности. С момента падения Казани (1552 г., 15 октяб. нов. ст.) до сегодняшнего дня, т.е. в течение 380 лет, татары борются за восстановление своей самостоятельности. Ряд восстаний в XVII и XVIII веках, в результате которых татарам удалось два раза вернуть самостоятельность Казани хотя бы на короткое время, являются доказательствами того, что татары никогда не отказывались и не откажутся и в будущем от своих национальных идеалов. Первые же дни русской революции 1917 г. ясно показали это. Национальное собрание тюрко-татар, созванное в 1917 г. в Уфе, проектировало создание автономного штата Идель-Урал (Идель – Волга). Быстрый рост большевизма не дал возможности привести в исполнение этот проект. Советская власть из боязни объединения тюрко-татар в проектированной национальным собранием области создала (но, разумеется, только на бумаге) татарскую, башкирскую и чувашскую республики и марийскую автономную область. Такое положение, как по своему внутреннему содержанию, так и по внешнему виду не может отвечать и удовлетворить требование тюрко-татарской нации, стремящейся к самостоятельному государственному существованию. Идель-

Уральская Республика, за самостоятельность которой ведет борьбу Комитет независимости Идель-Урала, занимает пространство между рекой Волгой и Туркестаном. Таким образом, Идель-Уральская республика на северо-востоке, на Востоке и на Юго-Востоке граничит с тюркскими племенами. На западе же имеет естественную границу Волгу. Народонаселение этого богатого края в ханские времена составляли тюрко-татарские племена, как-то: татары, мещеры, ногайцы, киргизы, чуваши, башкиры и группа финских племен, как например: мари, мордва, зыряне и монголы. Русский элемент очутился тут благодаря усиленной переселенческой политике русского правительства и политике конфискации под разными предлогами земель у местного населения. Несмотря на такую политику русского правительства, во всем Идель-Урале до сих пор преобладает тюрко-татарское население; с финскими племенами они составляют громадное большинство. Правда, царское правительство в XIX веке сильно развило свою миссионерскую пропаганду среди финского народа и ему удалось, хотя формально, изрядное количество финского народа превратить в православие и на этом основании, по признакам религии, приписало их к русскому населению. На этом же основании перепись 1897 года по официальной статистике показала громадный рост русского населения, т.е. православного, и очень заметную убыль финского и тюрко-татарского элемента на всем Поволжье. Сам же тюрко-татарский народ, опираясь на данные своего духовного управления, где ведутся тщательные метрические записи во всех мусульманских приходах (7800 приходов) Поволжья, считает себя не менее шести с половиною миллионов, а чувашей и крещеных татар (тоже тюрки), зачисленных в перепись как православные русские, свыше одного миллиона. Эта цифра оправдалась при всеобщей мобилизации во время Мировой войны. Татаро-башкирских солдат оказалось 960 тысяч, причем уклонение от воинской повинности у татар в процентном отношении превышало число таковых среди русских. Сопоставляя результаты переписи 1926 года с цифровыми данными за тот же период духовного управления мусульман Поволжья, легко установить, что в

данный момент в Идель-Урале находятся:

Тюрко-татары..........................7,848 млн.
Русские ...................................4,290
Народы финск. и монг. плем.. 3,213
Всего…………………………15,351 млн.

В процентном отношении: Тюрко-татары 51%, русские 28% и народы финско-монгольск. племени 21%. Иначе говоря, тюрко-татары и финно-монголы вместе составляют 72%. Таким образом, тюрко-татар в Идель-Урале нисколько не меньше процентного отношения великорусов во всем СССР, а с финскими и монгольскими народами, вместе взятыми, не меньше, чем чехов в Чехии и румын в Румынии. Экономическое положение Идель-Урала в настоящее время не представляет ничего отрадного. Там все разрушено и разграблено, но земли большевики не могли уничтожить и вот, принимая во внимание плодородность почвы (раньше она считалась одной из житниц России), следует считать, что при восстановлении там нормальных условий, восстановить хозяйство будет нетрудно. Многоводные реки: Волга, Кама, Белая и др. являются хорошими и дешевыми путями сообщения и играют большую роль в развитии торговли. Уральские горы со своими бесконечными и разнообразными минеральными богатствами (золото, серебро, платина, медь, железо и каменный уголь) обещают богатую промышленность, а нефтяные источники (на склонах Уральск. гор в Уфимск. и Пермск. губ.) дают намного раз больше нефти, чем требуется для края. Так что Идель-Урал, как самостоятельная экономическая единица, имеет все шансы для самостоятельного существования, а экономическое развитие его пойдет гораздо лучше и интенсивнее, чем при старом ханском или российском режиме. Что касается степени духовного развития тюрко-татарского населения, то при настоящих условиях его существования нельзя похвалиться его высокой технической культурой, какую мы видим у европейских народов, но при сравнении с другими народами Востока (персами, арабами и афганцами), тюрко-татары

стоят весьма высоко в культурном отношении, а самое главное то, что они в своем национальном развитии идут по протертой европейской дороге. Несмотря на очень короткий срок (всего 50 лет) национального пробуждения, татары (до большевизма) не только без поддержки правительства России, но даже помимо его желания завели у себя всеобщее начальное обучение. В 1913–14 учебном году все дети обоего пола и школьного возраста были охвачены школой. Народ создал уже и весьма здоровую, бодрую духом литературу и национальный театр. Раскрепощение женщин было совершено уже давно. Что касается технической подготовки управления страной, то до революции 1917 г. она была недостаточна. Русское правительство держало тюрко-татарский народ Поволжья в стороне от государственного управления, и в местные самоуправления допускало только в ограниченном количестве (1/5 русских), поэтому (само собою, разумеется) готового чиновничьего аппарата не было. Этот пробел уже устраняется при большевиках, вопреки их желанию. Как в Татарской республике, так и в Башкирской национализация аппаратов, при поддержке самого народа, в настоящее время идет довольно успешно. По официальным данным советской власти, в советском Татарстане в сельсоветах и волсоветах число чиновников татар 53%, в окружных (т.е. уездных и губернских) 37,8%, и только в центральных учреждениях число их ненормально, так как еще рука Москвы играет там решающую роль. Во всем государственном аппарате татары занимают 30%. Кроме того, многочисленные татарские служащие разбросаны по родственным республикам, как-то: Казахстан, Киргизстан, Узбекистан, Крым и даже в Азербайджане. Подготовка высококвалифицированных работников интеллигенции: докторов, инженеров, педагогов и т.д. тоже идет довольно успешно. В этом году (1933) число учащихся в высших учебных заведениях татар достигает 3397 чел. Специальная военная подготовка идет не хуже. В Казани татаро-башкирское военное училище каждый год выпускает несколько сот красных командиров и количество офицеров татар-башкир, число которое до революции не превышало нескольких сот, в настоящее время

достигает нескольких тысяч. Следовательно, техническая и умственная подготовка татар для управления страной идет вполне нормально. Что касается самого народа, то по своей психологии он вполне государственный и очень далекий от русского фантазерства. Этот народ очень трудолюбив, бережлив, вполне трезв, о его же коммерческих способностях, думается, никто не будет спорить. Народ этот обладает большой подвижностью, инициативой и имеет многовековую жизненную практику, так что он вполне успешно конкурирует с европейцами и очень часто вытесняет их с рынка. Несмотря на долгие годы пребывания под русским владычеством, народ этот никогда не терял надежды на возрождение своего былого величия. Взяв при первой и малейшей возможности управления своим отечеством в свои руки, он способен в самое краткое время восстановить порядок, мир и законность, чтобы вместе с другими народами не только освободиться из-под московского ига, но и самостоятельно жить далее свободным и независимым.

Мәкалә «Вольное казачество» журналының 1933 ел 10 май (№119) санында басылып чыккан.

*Текстларны Ләйсән Галиева әзерләде*

## Мөхәрриргә

*И мөхәррир! Кайсына биргән яшен күз кибриа!*

*И мосаувир! Кемгә биргән пакь вә чын сүз кибриа!*

*Кайт әле монда ватанга, кайт әле, саргайтмале!*

*Күз карашыңнан керер җир тапмасынчы кер, рия!*

*Алты елда үзгәреп китте лөгать һәм истилях,*

*Сәүдәгәрлектер зыялылык вә сәүдәдер зыя.*

*Җанлылык тормыш та бетте, шанлырак бер эш тә юк,*

*Бер-берен чәйни Бишенче елдагы күп әүлия.*

*Алты ел торды чулпансыз, айрылышты яшь көтү;*

*Карт бүре күк, бары корган айрым-айрым бер оя.*

*«ул Гомәрдән курка шәйтаннар» дигән төсле рәсүл,*

*Бер карашың иң шома яоганчыны сүздән тыя...*

*Г. Тукай*

## ГАЯЗ ИСХАКЫЙНЫҢ ТОРМЫШЫ ҺӘМ ИҖАТЫ ТУРЫНДА ЯЗМАЛАР

## ИСТӘЛЕКЛӘР

### Әдип юбилеен Төркиядә...

*Узган гасырның 80 нче елларында классик әдипләребезнең олы юбилейлары – тууларына йөз ел тулу даталары билгеләп үтелде. Бу вакытларга туры китереп, Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галим-текстологлары аларның күптомлы фәнни басмаларын әзерләп чыгарды, иҗади эшчәнлекләренә багышланган халыкара фәнни-гамәли конференцияләр уздырылды, монографик хезмәтләр, фәнни, фәнни-популяр мәкаләләр язылды. Әйе, XX гасыр башында татар әдәбияты үсешен моңа кадәр күрелмәгән югарылыкка күтәргән Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Камал, Г. Ибраһимов, М. Гафурилар иҗаты мондый хөрмәткә бик тә лаек иде. Совет режимы да бу милли рухлы әдипләребезне зурлауга каршы тора алмады. Әмма аларның өлкән замандашы, шулай ук классик әдип, публицист-журналист, күренекле җәмәгать эшлеклесе, сәясәтче Гаяз Исхакый андый игътибардан читтә торып калды. Сәбәбе: аның большевиклар хакимиятен кабул итмичә, эмиграциягә китеп, гомере буе татар халкының милли азатлыгы өчен көрәш алып баруы. Әдипнең 1978 елның 23 февралендә тууына (вафаты 1954 елда) нәкъ менә 100 ел тулуы турында туган җирендә – Татарстаныбызда бер генә дә юбилей чарасы үткәрелмәде дип әйтергә кирәк.*

*Шулай да бу юбилей бөтенләй искә алынмаган диган сүз хаклыкка туры килмәс. Шөкер, ул үткәрелгән, әмма газиз туган җирендә түгел, чит илдә – Төркиядә (татарлар, төрки халыклар күңеленә иң якын мәмләкәт ул). Хәер, бу гаҗәп тә түгел: Гаяз Исхакый гомеренең соңгы 15 елын Истанбулда яшәп уздырган (җәсәде дә шунда – Әдернәкапы зиратында). Ул елларда Төркиянең башкаласы Әнкарада әдипнең нәсел дәвамчылары – кызы Сәгадәт Чагатай, кияүләре Таһир Чагатайлар әле исән булалар. Һәм, алар тырышлыгы белән, «Ayaz Ishaki. Hayati ve faaliyeti» (100 dogum yili dolaisiyla») («Тууына 100 ел уңае белән») исемле китап әзерләнә. Ул Әнкараның «Ayyildiz Matbaasi» ширкәтендә 1979 елда басылган, төзүчеләре (тәртип итүчеләре): Сәгадәт һәм Таһир Чагатайлар, Али Акыш, Хәсән Агай.*

*Шактый күләмле (351 битле) бу китапта Г. Исхакыйның язучы буларак та, журналист-публицист һәм иҗтимагый эшлекле сыйфатында йөзе ачык гәүдәләнә. Моның беренче төп сәбәпләреннән берсе – төзүчеләрнең барысы да Гаяз Исхакыйны якыннан белүчеләр булуда.*

*Китапнең беренче битләрендә С. Чагатайның кереш сүзе һәм язучының җыйнак кына биографиясе (ул төрек, инглиз, француз һәм немец телләрендә; имзасыз), кыскача библиографиясе (әсәрләре - 46 исемдә; 11 газета һәм журнал) китерелә. Китапның бер урынында, «Аяз Исхакыйның әсәрләреннән» исемле гомуми баш астындагы язмаларда С. Чагатай укучыны «Зөләйха» пьесасының кыскача эчтәлеге белән, «Остазбикә» повесте турындагы фикерләре белән таныштыра. Китапта Исхакыйның «Зиндан» повестеннан, көндәлек дәфтәрләреннән 1920 елгы тормышын чагылдырган өзекләр, «Яңа милли юл» журналыннан алынып, «Газетачылык эшендә 25 ел» исемле мәкаләсе дә бирелгән.*

*Гомумән алганда, бу юбилей җыентыгының төп өлешен мәкаләләр алып тора. Аларның кайсылары истәлек*

*рәвешендә язылган, кайсыларында, башлыча, әдипнең тормышы һәм иҗади эшчәнлегенә бәя бирү рухында сүз бара. Аеруча Сәгадәт Чагатайның әнисе, әтисе, әби һәм бабалары хакындагы «Мөхәммәд Гаяз Исхакый» исемле күләмле язмасы зур әһәмияткә ия. Киләчәктә әдипнең фәнни биографиясен өйрәнергә алынган кеше өчен ул аеруча да кыйммәтле язма, ышанычлы чыганак.*

*Мәкаләләрнең авторлар даирәсе шактый киң. Г. Исхакый турында үз сүзен әйтергә омтылганнар арасында Төркиягә килеп төпләнгән татар зыялылары, галимнәре (мәсәлән, Али Акыш, Әмрулла Аги, Фатыйма Бугра, Әхмәт Таһир, Абдулла Баттал-Таймас, С. Чагатайлар) генә түгел, язмышларын башка илләр белән дә бәйләгән шәхесләр, башка милләт вәкилләре дә күренә (Т. Дәүләтшин, Б. Мусабай, Густав Бурбиель, Мәдинә Салиәхмәт, М.Ә. Рәсүлзадә, Сәед Шамил һ.б.). Мәкалә һәм язмаларның һәрберсе диярлек укучыны бөек әдипнең тормышына һәм иҗади, сәяси-иҗтимагый эшчәнлегенә кагылышлы кызыклы фикер һәм фактик мәгълүмат белән таныштыра. Китапта Г. Исхакыйның төрле еллардагы, төрле яшәү урыннарындагы тормыш мизгелләрен чагылдырган фотосурәтләрнең, кайбер мөһим документларның күчермәләре дә урын алган.*

*Исхакый исеме, язма мирасы кайтарыла башлагач, әлеге китаптагы байтак мәкаләләр, татарчага тәрҗемә ителеп, газета һәм журналларда басылып чыкты, унбиш томлы «Әсәрләре» басмага әзерләнгәндә файдаланылды. Әдипнең туусына 140 ел тулу уңае белән, әлеге китаптагы берничә мәкалә татар теленә күчермәдә укучы игътибарына тәкъдим ителә. Моннан тыш Б. Урманченың шәхси архивында сакланган Н. Гасрыйның (1886–1937) әдип хакындагы кечкенә күләмле истәлеге дә урнаштырылды.*

*Зөфәр Рәмиев*

*Алиуглы Фадли*[1]

## Мин Гаяз агай белән ничек таныштым?..

Мин яшь чагымда Гаяз агай белән бәйле бер әйберне дә белми идем. Мәктәптә укыганда да аның хакында бернәрсә ишетмәдем. Мөгаллимнәребез дә аның исемен беркайчан телгә алмадылар. Аны яраткан кешеләр күп булса да, аның турында сөйләшергә куркалар иде. Көннәрдән бер көнне Тәтеш китапханәсендә «Правда» газетасын укып утырган вакытта Гаяз Исхакый һәм Мулла Корбан Галигә багышланган озын гына бер мәкаләгә тап булдым. Мәкаләне кызыксынып укый башладым. Анда Гаяз Исхакый һәм аның дуслары кискен рәвештә тәнкыйть ителеп, түбәндәге сүзләр язылган иде: «Буржуаз милләтчеләр әле һаман да үзләренең керле эшләреннән кире кайтмаганнар. Һаман да Ватаныбызга пычрак атып яталар. Һаман да туган илебездә паразит бер җәмгыять булган, халык канын эчүгә корылган капитализм җәмгыятен терелтеп, Казанга тагын бер тапкыр Крестовниковларны китертеп, халык канын эчәргә планлаштыралар».

Әлеге мәкаләне укыганнан соң, Гаяз агайның кем булуы, башкарган эшләре, нәрсә белән шөгыльләнгәнлеге турында кызыксына башладым. Ул мине электр магниты кебек һәрвакыт үзенә тартып торды. Мин еш кына аның турында уйлый башладым. Вакыт шул рәвешле үтә торды һәм һич көтмәгәндә үзе белән 60-70 миллион кешенең гомерен алып киткән Икенче Бөтендөнья сугышы башланды. Җир йөзендә кыямәт купты.

Мине армия сафларына алып фронтка җибәрделәр. Сугышта куркыныч бәрелешләрдә катнаштым.

Көннәрдән бер көнне без чолганышта калдык. Шул рәвешле мин немецларга әсирлеккә эләктем. Моңарчы һич күрмәгән, тел белән сөйләп бетерә алмаслык авырлыклар аша уздым.

---

[1] Алиуглы Фадли. Мин Гаяз Исхакый белән ничек таныштым / Muhammed Ayaz Ishaki. Hayati ve faaliyeti. – Ankara, 1979. – Б.306-309.

Әсирләр тупланган концлагерьларда бездән күпкә олырак булган һәм Гаяз агайны яхшы белгән берничә кеше белән таныштым. Лагерьларда шулай ук юлбашчыбыз Гаяз Исхакый, мөхтәрәм профессор Садрый Максудый, Габдулла Баттал, Закир Кадири, Зәки Вәлиди һ.б күренекле затлар турында мөһим сүзләр ишеттем. Гаяз агайның язган әйберләрен үз күзләрем белән күрмәсәм дә, аның әсәрләре белән якыннан кызыксынган кешеләрдән күп кенә нәрсәләр өйрәндем. Төркиядә яшәгәнен ишеткәч, аны күрәсе килү теләгем тагын да артты.

Ниһаять, үзенең мәрхәмәтсез утында миллионнарча гөнаһсыз җаннарны яндырган, күп кенә ата-аналарны балаларыннан аерган, сабыйларны ятим калдырган Икенче Бөтендөнья сугышы тәмамланды. Сугыш беткәч, күп кенә кеше туган илләренә кире кайтудан куркып, Германиядә калдылар. Аларга мин дә кушылдым. Германиядә калдым. Берләшкән Милләтләр Оешмасы карары белән Германиянең төрле почмакларында Унра (?) лагерьлары ачылды.

Ватаннарына кайтмыйча калган башка халыклар кебек без, ягъни Россия төркиләре дә Германиянең Югары Бавария өлкәсендә урнашкан Миттенвальд шәһәрендә төркиләр лагерен кордык. Ул Вавилон манарасын хәтерләтә иде дисәк тә, ялгыш булмас. Чөнки биредә һәртөрле антропологик төркемнәрнең вәкилләре җыелган иде. Менә шундый зур лагерьда 3500–4000 гә якын җан иясе яшәде. Алар арасында төрле социаль катлам вәкилләре дә очрый иде. Миттенвальд лагере минем өчен зур тормыш мәктәбе булды. Биредә мин Беренче Бөтендөнья сугышында әсирлеккә эләгеп, туган илләренә кире кайтмыйча калган кешеләрне дә күп очраттым. Алардан Гаяз агай турында шактый мәгълүмат тупладым. Алар миңа Гаяз агайның тирән эчтәлекле «Милли Юл» журналын күрсәттеләр, Ерак Көнчыгышта чыга торган «Милли Байрак» газетасы белән таныштырдылар. Шул рәвешле минем Гаяз агайга карата булган мәхәббәтем тагын да арта төште. Ничек тә булса аның белән күрешергә тели идем. Аның белән кара-каршы утырып сөйләшү, күп кенә нәрсәләрне өйрәнү теләге тагын да көчәйде.

Бөек грек философы Гераклит әйткәнчә, «Көннәр бер-берсен кудылар, үтеп киттеләр, тормышта да күп кенә үзгәрешләр булып узды». Бер көнне һич тә көтмәгәндә, Бавариянең башкаласы Мюнхен шәһәреннән бер хат килеп төште.

Хатны ачуга мин аның күптәннән күрешеп сөйләшергә теләгән бөек юлбашчыбыз Гаяз агайдан килгәнлеген аңладым. Хатны алуга зур изге эшләре белән дан казанган әлеге бөек зат ничек кенә булса да минем кебек кечкенә кеше белән күрешергә, сөйләшергә тели икән дип, тирән уйга баттым. Бу турыда озак уйладым, шатлыгым эчемә сыймый иде. Хатны ачып укый башладым: «Кадерле Фадли илдәшем, без Америка Комитеты чакыруы буенча Мюнхенга килдек. Бераз вакыт табып, юл уңае килсә, сез торган Ной-Ульм шәһәрендә яшәүче Идел-Ураллылар белән күрешеп сөйләшергә телим. Көтегез, сәлам белән агагыз Гаяз Исхакый Иделле». Әлеге юлларны укыгач, эчем сурәтләп бирә алмаслык зур бер шатлык белән тулды. Моннан соң кичә-көндез бары тик аның турында гына уйлый башладым. Күз алдымда ул гына булды. Ишек ачылган саен, аннан Гаяз агай кергән кебек тоела иде. Менә күрешү көне һәм минутлары да килеп җитте. Ишекнең кыңгыравына бастылар. Чабып барып ишекне ачуга бусагада Гаяз агай белән аның дустын күрдем. Аның ишектән атлап керүен күргәч, тиле кеше кебек сөйләшү сәләтен югалттым. Бер нәрсә дә әйтмичә, Гаяз агайны кочаклап алдым. Күзләремнән мөлдерәп кайнар шатлык яшьләре ага башлады. Гаяз агай да мине бу хәлдә күреп, мине күкрәгенә кысты.

Гаяз агай Ной-Ульмда яшәгән бөтен Идел-Ураллылар белән җыелыш уздыруны сорады. Без бер кунакханәнең ресторанында тупландык. Беренче сүзне Гаяз агайга бирдек. Ул Идел-Урал халкының бүгенге хәле турында сөйләде. Аңа гына хас булган ысулда акрын гына матур, тирән эчтәлекле фикерләрен халык гыйбарәләре белән бизәп, кайбер очракларда көлкеле сүзләр катнаштыра-катнаштыра сөйләп, тыңлаучыларны үзенә җәлеп итте. Мин гомеремдә күп кенә бөек затларның чыгышларын тыңлаган булсам да, аларның берсе дә миңа бу кадәр тәэсир

итмәгән иде. Аның бу гүзәл чыгышы тыңлаучыларга бөтен чынбарлыкны күзгә кебек ачып бирде. Миндә Гаяз агайга карата булган мәхәббәт хисе артканнан арта барды. Җыелышта булган бөтен илдәшләребез сулышлары киселгән кебек шул кадәр тын утырдылар ки, хәтта чебен очкан тавышны да ишетергә мөмкин иде.

Чыгышлар тәмамланганнан соң пластинкалардан татар халык җырларын һәм музыкасын тыңладык. Гаяз агай арабызда булган шагыйрь Минһаҗ әфәндедән үзенең берничә шигырен укуын сорады. «Әйдә, син гүзәл шигырьләреңне укы. Мин аларны яратам», – диюгә, Минһаҗ әфәнде үзенең берничә шигырен укыды. Гаяз агай шигырьләрне игътибар белән тыңлады. «Әйбәт, Аллаһы Тәгалә сиңа тагын күп шигырь язарга насыйп итсен», – диде.

Гаяз агай Ной-Ульмда яшәгән Идел-Уралларның берсен дә онытмады. Хатлар язып, хәлебезне һәрвакыт сорап торды.

Гаяз агайның әсәрләренә килгәндә, аларның барысында да чынбарлык ничек бар, шулай сурәтләнгән. Ул илебезнең гасырлар дәвамында чит халыкның изүе астында яшәвен, канлы күз яшьләре түгеп чиккән газапларын, бөтен хокуклардан мәхрүм булуын бөтен барлыгы белән анализлаган.

Аның әсәрләре бер тапкыр укып чыккан кешене электр магниты кебек гел үзенә тартып тора. Алар тирән психологизмга корылган. Әдәбият теориясенең мөһим элементларыннан саналган , архаизм һәм сүз уены (метафора) алымы белән сарказм гаять оста файдаланылган. Көлкегә алынган һәм зур игътибар биреп төзәтелергә тиеш тискәре күренешләрнең зәгыйфь якларын табып, аларны тәнкыйть итүе, аның әсәрләренә үлмәс әдәби көч һәм яктылык биреп тора.

Мин Гаяз агайны «Ромео һәм Джульетта», «Гамлет», «Отелло» кебек әсәрләр язган бөек инглиз язучысы Шекспир кебек мәңге сүнмәс яктылык сирпеп торучы йолдыз буларак күрәм. Ул чыннан да безнең Шекспирыбыздыр. Гаяз Исхакый безнең өчен итальяннарның Дантесы, испаннарның Сервантесы, алманнарның Гетесы, Шиллеры һәм Лессингы кебек беркайчан

да сүнмәячәк йолдыз булып калачак.

Ул үзе үлсә дә, аның калдырган әсәрләре җир йөзендә тереклек беткәнче яшәячәк. Гаяз Исхакый – гомерен һәм көчен кызганмыйча, ару-талуны белмичә эшләгән бөек шәхесебез. Ул чит изү астында кысылып кимсетелгән халкыбызның хөррияте, бәйсезлеге һәм аның шат яшәве, дөньяның башка халыклары кебек ирекле, бөтен хокукларга да ия булуы өчен көрәште. Кайбер кешеләр кебек беркайчан да үз мәнфәгатьләрен кайгыртмады. Беркайчан да мәзлум халкын онытмады. Халкы белән бергә елады. Аның белән бергә көлде. Һәр адымын «Милләтем, милләтем», – дип атлады. Аның кайгысын да, шатлыгын да бүлеште. Милләте өчен тәнен дә, җанын да кызганмады. Милләте өчен патша төрмәләреннән дә, үлемнән дә курыкмады. Патшаның жандармнары аны җиңә алмады. Ул яраткан туган җиреннән, Ватаныннан аерылгач та, чит җирләрдә авыр шартларда яшәгәндә дә мөкатдәс милли азатлык өчен көрәшүен туктатмады. Зур авырлыклар белән оештыра алган «Милли Юл» журналы белән халкыбызның авыр хәлен дөньяның башка милләтләренә танытып, үзенә күрә бер барометр вазыйфасын башкарды. Халкыбызның иҗтимагый тормыштагы омтылышларын саклады.

Ул үзе үлсә дә, калдырып киткән бөек мирасы, аның шаһәсәрләре һәрвакыт йолдыз кебек нур чәчеп, караңгы кичләрдә безгә юл күрсәтеп торалар. Шунысын да әйтергә кирәк, ул күп кенә Идел-Уралны милли азатлык рухында тәрбияләп китте.

Илебезнең Ватан өчен көрәшкән күп санлы азатлык фидаиләре, һичшиксез, Гаяз агайның эшен дәвам иттерәчәкләр.

*Хафиз Шахмай*[1]

## Әдибебез Гаяз Исхакый

Бөек әдибебез Гаяз Исхакый турындагы истәлекләремне язып, аның нинди шәхес булганлыгын ачып бирүне милли бурычым дип саныйм.

Гаяз Исхакый язучылык чорында илебезнең шәһәрләрендә һәм авылларында рәхәт яши алмады. Ул илебезнең төрле почмакларында качып йөреп, милләте өчен әллә никадәр авырлыклар аша үтсә дә, 50 ел эчендә күп кенә кыйммәтле әсәрләр язып калдырды. Аның әсәрләре белән халкыбыз шатланырга, горурланырга тиеш.

Мин Гаяз Исхакый белән Япония һәм Кытайда күрешеп сөйләшкән кебек, кайбер мәҗлесләрдә дә еш кына аның белән була идем. Гаяз Исхакый Япония һәм Кытайдагы безнең җәмгыятьләребезне тәртипкә салып, ике корылтай җыйды, милли матбугатыбызны корып, халкыбызны күз алдына китерә алмаслык зур шатлыкка күмде. Тагын да шундый күп кенә файдалы эшләр башкарып, Ерак Көнчыгыштагы бөтен оешмаларыбызны тәртипкә салып Европага китте.

Әлеге газиз кешене яңадан 1953 елның январь аенда Истанбулга килгәч күрергә насыйп булды. Төркиягә килгәч, аның чирләгәнлеген ишеттем. Шунда ук хәлен белергә киттем. Ул мине ишекне ачып, үзе каршы алды. Бик ябык һәм хәлсез иде. Каршымда элеккеге Гаяз ага урынына ап-ак чәчле әдибебезне күрүгә, йөрәгем чәнчеп куйды. Күзләремнән аккан яшьләремне тыя алмадым. Ул мине ябык куллары белән кочаклады да: «Менә минем яныма милли көйләрне уйнаган Хафизым да килде, Төркиягә хуш килдең. Аллага шөкер, йөрәгемне тынычландырып, тагын скрипкада милли көйләребезне уйнарсың», – диде һәм кулымнан тотып, мине китаплар белән тулган китапханәсенә

[1] Хафиз Шахмай. Әдибебез Гаяз Исхакый таныштым / Muhammed Ayaz Ishaki. Hayati ve faaliyeti. – Ankara, 1979. – Б.310-316.

алып керде. Утыргач: «Менә минем бөтен барлыгым, байлыгым, шатлыгым», – дип, китапларын күрсәтте.

Гаяз Исхакый бөек кеше булган хәлдә киң күңел белән һәркемне якын күреп, кайгыларын, шатлыкларын уртаклаша иде, һәркемгә ярдәм кулын суза иде. «Син әле яңа килдең, борчылма, сәламәт булсаң, бар нәрсә дә булыр», – диде. «Яшәргә урын тапканчы, миндә калырсың. Үз вакыты белән бар нәрсә дә булыр, әле минем язылып бетмәгән әсәрләрем дә бар, аларны бергә тәмамларбыз», – дип шаяртып, күңелемне юатты. Авыруы турында сөйләшкәндә күзләремдәге зарны күрде. Кинәт таш төшкән кебек: «Әйдә Хафиз, Кытайдагы хәлләр турында сөйлә, анда безнекеләр күпме калды әле?» – дип, сөйләшүне тиз генә башка якка борды.

Бу күрешүдән соң озак та үтмәде, мин Сарыйәрдә (?) бер сәгать сатучының кибетенә эшкә урнаштым. Кибет хуҗасы улы Германиядән кайткач яшәр өчен Сарыйәрнең тау битендә ике катлы өй салдырды. Салынып беткәннән соң ярты ел беркем дә яшәмәячәге билгеле булгач, кибет хуҗасы мине әлеге йортка урнаштырды. Бакчасында төрле агачлар, чәчәкләр һәм матур үләннәр утыртылган юллар бар иде. Көннәрдән бер көнне без Гаяз аганы кунакка чакырырга булдык, матур чәчәкләр белән хозурланыр, саф һава сулар дидек. Мин Истанбулга барган саен доктор Исмәгыйль Терегулга кереп, Гаяз аганың сәламәтлеге турында сораша идем. Бер тапкыр баруымда Исмәгыйль бәй белән бергә Сарыйәргә безгә килүләрен үтендем һәм шунда ук көнен дә билгеләдек. Билгеләнгән көнне Гаяз ага, Исмәгыйль бәй һәм хезмәтче ханым өчесе бергә Бугазичи пароходы белән килделәр. Алар киләчәк көн һәм сәгать алдан билгеле булгач, без дә аларны каршыларга төштек. Пароходтан төшкәч, безгә кадәр җәяү хәйран озак барырга кирәк иде, шуңа күрә ат арбасы ялладык. Безнең матур бакчага килеп җиткәндәрәк: «Атны туктагыз әле, мондый матур җирдән бераз җәяү барасым килә», – диде. Яшел чирәмдән атлаган вакытта бер утыргычны күрсәтеп, утырырга тәкъдим иттек. «Юк, минем чирәмдә ятып торасым килә», – диде. Без дә шунда ук бер юка юрган алып килеп җәйдек. Аны шунда яткырдык. Яткач, куллары белән үләннәрне

һәм чәчәкләрне сыйпады. «Мондый шатлык бөтен җирдә дә һәм һәрвакыт булмас», – дип, зәңгәр күк йөзен күзәтеп ятты һәм бераз йокымсырап алган кебек булды.

Мәрхүмнең яраткан вак Казан пилмәнен әзерләдек. Бакчада табын кордык. Табынга утырып ашый башлауга кашыгы белән табактагы пилмәнне алды да: «Нинди хуш исле, үзе дә тәмле булырга тиеш», – дип, пилмәнне мактап алды. Ләкин күпме генә мактаса да, бер пилмәннән артык ашый алмады. Шуңа да карамастан бик бәхетле иде. Аштан соң чәй әзерләнгәнче миңа мөрәҗәгать итеп: «Хафиз, скрипкаң белән милли көйләребезне әйттер әле», – диюгә, башта «Әллүки», «Ашказар» һәм «Сакмар суы» көйләрен уйнадым. Аларны тәмамлагач: «Сәгыйть Рәминең «Сызла күңелем»ен уйна», – диде. Уйнаган вакытта акрын бер тавыш белән җырлый башладым. Карасам, мәрхүм дә акрын тавыш белән җырга кушылган иде. Фәкать күзләрендә яшьләр ялтырый иде. Мин дә аны бу хәлдә күреп, тиз генә «Ямьле Агыйдел буйлары» көен уйный башладым. «Әй алмагачлары, сайрый сандугачлары» белән тәмамладым.

Кояш батканчы көне буе ачык һавада булды. Ашыкмый гына пароход пристаненә төштек. Пароходтан озак кына ак кульяулыгын болгап, безнең белән саубуллашты. Шул рәвешле күздән югалдылар.

Илдәшләр, без Мөхәммәт Гаяз Исхакый белән беркайчан аерылмадык. Алла насыйп итсен, җәннәттә тагын бер тапкыр кочаклашып күрешергә өметләнәм. Милли шагыйремез Габдулла Тукай әйткәнчә, аның кебек бөек әдипне мәхшәргә кадәр «Сөйләр телләр, язар каләм», – дип, сүземне тәмамлыйм.

*Текстларны Рифат Мирхаев әзерләде*

*«Әмәл»*[1]

## Ерак Көнчыгышта Идел-Урал оешмалары[2]

Мөхтәрәм Гаяз Исхакый Бәй Ерак Көнчыгышка киткәннән соң, Япония һәм Манчжуриядә яшәгән төрки милли-азатлык хәрәкәте вәкилләре арасында гаять шатлыклы һәм тарихи әһәмияткә ия булган эшчәнлек башланып китте.

Японияalthough зур шәһәрләрендә яшәгән кардәшләребез арасында Гаяз Бәй тарафыннан оештырылган конференцияләрнең тәэсире астында Идел-Урал мәдәни оешмалары булдырылды, спектакльләр куела башлады. Меңләгән кыенлыкларга каршы торып, иң явыз дошманнарны җиңеп, Япониядә халкыбызның үсешен тәэмин иткән Гаяз Бәй, берничә ай эчендә Маньчжуриянең барлык шәһәрләрендә диярлек була.

Һәр җирдә халкыбызның Гаяз Бәйне станцияләрдә каршылап, олы хөрмәт күрсәтеп кунак итүләре һәм аның чыгышларын яратып тыңлаулары, һичшиксез, куандыра торган хәл. Бу – халкыбыз бердәм түгел, оешмаган, милләт һәм ватан мәсьәләләреннән ерак тора диючеләргә нинди матур һәм тарихи җавап! Бездә булган мәгълүматларга караганда, Маньчжуриянең һәр шәһәрендә Идел-Урал мәдәни оешмалары булдырылган һәм халкыбызның 95 проценты бер байрак астында җыелган.

1552 елның 15 октябре Казанның руслар тарафыннан алыну көне булганга күрә, бу көн барлык Ерак Көнчыгышта булдырылган оешмалар тарафыннан милли матәм көне буларак игълан ителгән, руслар белән бәрелештә шәһит булганнарның рухларына дога кылынган, җыелышларда нотыклар әйтелгән, шигырьләр укылган.

Барлык бу очрашуларда халкыбызның бае, фәкыйре, укымышлысы, наданы, хатын-кызы, ир-аты, бала-чагасы катнашкан һәм барысы да күз яшьләрен түгеп, Казанның һәм

---

[1] Әмәл. Ерак Көнчыгышта Идел-Урал оешмалары / Muhammed Ayaz Ishaki. Hayati ve faaliyeti. – Ankara, 1979. – Б.310–316.

[2] Әлеге язма 1930–1941 елларда Румыниядә, хәзерге көндә исә соңгы 18 ел дәвамында Истанбулда чыгып килә торган «Әмәл» журналында 1935 елның гыйнварында басылды.

бөтен Төрки дөньяның һәлакәтләрдән котылуын сорап дога кылганнар, моның өчен барлык булган көчләрен куеп хезмәт итәргә ант итешкәннәр.

Гаяз Бәйнең Ерак Көнчыгышка китүе Идел-Урал мәсьәләләрен халыкка һәм халыкның иманына тагы да ныграк бәйли. Аның әлеге тарихи мәсьәләне шактый уңышлы башлап җибәрүен, бу мәсьәләнең киләчәгенә дә ныклы нигез салу дип кабул итәргә кирәк.

Бу зур уңыш барыбызны да, барлык төркиләрне, аеруча без кырымлыларны шатландырды.

Гаяз Бәйне хөрмәт һәм мәхәббәт белән сәламләгәндә Ерак Көнчыгыштагы кардәшләребез тарафыннан күрсәтелгән ватан һәм халыкка карата мәхаббәт, иман, фидакарьлек һәм егетлекне иң зур сөенү һәм иң зур өмет белән алкышлыйбыз.

Тәңре сезне ярдәменнән ташламасын. Кылган гамәлләрегезне тарихның үлмәс, онытылмас сәхифәләренә күчерсен...

*Кадыйрҗан Кафлы*[1]

**Әсир төркиләр...**

*(«Йәни Сабах», 06.09.1954)*

Рус патшалыгы чиктән тыш милләтче һәм Православие дине йогынтысы астында була. Әйләнә-тирәдәге халыкларны яулап алу максаты белән янып яши. Бертуктаусыз үз җирләренең чикләрен киңәйтергә тырыша, киңәйгән саен тагы да киңәю теләге арта бара. Рус дәүләте төрки халыкларны руслаштыру сәясәтен күптән башлап җибәргән була инде. Ләкин, ничек кенә булмасын, рус идарәсе астында калган төркиләр, ким дигәндә, чит илләр белән мәдәни мөнәсәбәтләр коралар, китап һәм газеталар бастыралар, туган телләрендә башлангыч, урта һәм югары белем бирү мәктәпләрен ачалар, милли үзбилгеләмәсен саклап калу максаты белән төрле хәрәкәтләргә кушылалар, «Дума» дип

[1] Кадыйрҗан Кафлы. Әсир төрекләр / Muhammed Ayaz Ishaki. Hayati ve faaliyeti. - Ankara, 1979. – Б.350-351.

аталган Милләт мәҗлесенә вәкил җибәрү хокукына ия булалар.

Кызганычка каршы бүген төрки халыклар барлык югарыда саналып киткән мөмкинлекләреннән мәхрүм калдылар. Чечен, Карачай, Татар кебек төрки халыклар яшәгән җирләреннән куылып җибәрелә, билгесез җирләрдә үлемгә дучар була.

Русия төркиләренең мәдәниятен һәм милли үзбилгеләмәсен саклап калу һәм үстерү өчен мөмкинлекләр бары тик Төркиядә һәм кайбер Аурупа илләрендә бар. Алманиянең Мюнхен шәһәрендә оештырылган Идел-Урал төркиләренең азатлык һәм Бәйсезлек каһарманы Гаяз Исхакыйны искә алу кичәсе әлеге милли чараларның берсе булып тора.

Булган мәгълүматка караганда, әлеге чараны әзерләүдә Идел-Уралллы майор Мостафа Вәлинең дә зур өлеше бар. Украинаның элеккеге президенты Витвицкий җыелышның мактаулы рәисе итеп сайланган һәм түбәндәге сүзләрне җиткергән:

«Гаяз Исхакый Бәйнең вафаты бары тик Идел-Урал төркиләре өчен генә түгел, ә бәлки без – украиналылар өчен дә зур югалту. Чөнки аның азатлык һәм бәйсезлек өчен көрәштә куйган хезмәте безнең өчен бер үрнәк булып тора».

Соңрак Шопенның матәм маршы яңгырый, Идел-Урал оешмасының вәкиле Ибраһим Бадай дога кыла.

Гаяз Исхакыйны вафатына берничә көн кала күргән Төркестаннан килгән Аман Бердимурат болай ди:

«Гаяз Исхакый гомеренең соңгы минутларына кадәр акылын һәм ихтыяр көчен югалтмады, аның соңгы теләге Идел-Уралның Бәйсезлеге өчен көрәшне дәвам итү булды. Рус идарәсе астында калган милләтләргә берләшергә киңәш биреп, мөкаддәс максатны яшь буынга әманәт итеп, якты дөньяга күзләрен йомды.»

Сүзне Азәрбайҗан комитетыннан майор Фәтхали Бәйгә бирделәр: «Гаяз Исхакый Бәйнең вафаты рус кул астында калган 40 миллион төрки өчен зур югалту. Без бәйсезлек өчен көрәшәбез. Моннан күп гасыр элек без бу көрәшне башлап җибәрдек, кан түктек, инде максатыбызга ирешкәнчегә кадәр көрәшебезне дәвам итәчәкбез».

Кавказ, Кырым, Белоруссия һәм Әрмәнстан вәкилләренең әйткән сүзләрендә дә әлеге рухтагы мәгънә ята иде. Зур югалту

китергән борчылу белән башланып киткән чара, мөкаддәс максатның бер көн, һичшиксез, чынга ашасына тагын да көчлерәк ышану белән тәмамланды.

Төн кыяматкә кадәр дәвам итмәс. Кызыл Мәскәүлеләрнең җәберләүләре астында сыкраган әсир төркиләр өчен дә, һичшиксез, кояш күтәрелер, көн булыр.

*Кадырҗан Кафлы*[1]

## Бәйсезлек каһарманы

*(«Азәрбайҗан», 1954, № 4–5)*

Идел-Урал татарларының бөек лидеры Гаяз Исхакыйның вафаты уңаеннан, танылган мөхәрриребез Кадырҗан Кафлы «Йәни сабах» газетасының 1954 елның 27 июлендә чыккан санында түбәндәге мәкаләсен бастыра.

XIII гасыр урталарында Волга, ягъни Идел елгасы белән Урал елгасы арасында төзелгән Алтын Урда дәүләте Русия дәүләтен дә үз кул астына ала, рус князьләре Алтын Урда ханнарының әмерләреннән башка халык тарафыннан танылмый.

Соңрак руслар берләшә, ә төркиләр арасында, киресенчә, аерымлану сизелә башлый. XV гасыр ахырларында Аксак Тимер белән Алтын Урда ханы Туктамыш хан арасында каршылыклар килеп чыга. Аксак Тимер өстен кала, ә Туктамыш хан чит җирдә вафат була. Шушы вакыттан башлап татарларның бөлгенлек дәвере башланып китә, ә руслар, киресенчә, күтәрелеш чорын кичерәләр. 1552 елда Казан ханлыгы яулап алынганнан соң, Русия дәүләте дүрт тарафка да киңәя башлый.

Идел-Урал төркиләре арасында милли тойгылар һәм бәйсезлек турындагы фикерләр XIX гасыр ахырларында яңадан формалаша башлый. Милли уянышка зур өлеш кертүче шәхесләр арасында берничә көн элек шәһәребездә бакый дөньяга күчкән

---

[1] Кадыйржан Кафлы. Әсир төрекләр / Muhammed Ayaz Ishaki. Hayati ve faaliyeti. – Ankara, 1979. – Б.79–81.

Гаяз Исхакый да мөһим урын алып тора.

Гаяз Исхакый 1877 елда Казаннан ерак булмаган бер авылда дөньяга килә. Аның әтисе авылның имамы була. Ул вакытта имамнар авыл халкының хокукларын яклаганнар һәм, гомумән, югары дәрәҗәдә укымышлы кешеләр булып саналганнар.

Мәрхүм Гаяз Исхакый башлангыч белемен мәдрәсәдә ала, соңрак Казандагы укытучылар мәктәбендә укый. Әлеге мәктәпнең максаты төрки халыкларны руслаштыру булуга карамастан, Гаяз Исхакый биредә чын милләтчегә әйләнә, 18 яшендә үк милли романнар һәм хикәяләр яза башлый. Аерым бер вакыт аралыгында укытучы булып эшләп, үзен милли мәсьәләләргә багышлый, роман һәм хикәяләре ярдәмендә укучыларында мөмкин булганча каһарманлык тойгыларын үстерергә, иҗтимагый мәсьәләләрне яктыртырга тырыша. Патша хөкүмәтенә каршы көрәшүчеләр кебек үк, Гаяз Исхакый да социалист була, ләкин аның социализмы тулысынча милли төсмер ала. Исхакый, шулай ук, шактый уңышлы гына драма әсәрләре иҗат итә, татар газетасын булдыра.

1905 елда, Русия дәүләте Япон дәүләтенә җиңелергә мәҗбүр булганнан соң, бәйсезлек өчен милли хәрәкәт көч ала. Татарларда милли мәктәпләр оеша, татар театрына нигез салына, милли җәмгыятьләр корыла, байлар исә әлеге милли күтәрелешне матди яктан тәэмин итеп тора. Ләкин берникадәр вакыт узганнан соң, хөкүмәт илдәге милли вазгыятьне үз кул астына алу өстендә эш башлап җибәрә. Гаяз Исхакый кулга алына һәм сөргенгә җибәрелә. Соңрак ул сөргеннән качуга ирешә һәм яшерен рәвештә татар халкының милли үзаңын күтәрүгә юнәлдерелгән эшчәнлеген дәвам итә. Һәрвакыт эзләнүчеләр исемлегендә булуына карамасатан, ул хәтта театрларда сәхнәләштерелгән спектакльләрендә дә еш кына тамашачы буларак катнаша.

1917 елгы революциядән файдаланып, Гаяз Исхакый фикердәшләре белән берлектә мөстәкыйль дәүләт кора һәм милли корылтай җыя[1]. Ләкин 1920 елда әлеге дәүләтнең хөкүмәте Русия дәүләте тарафыннан куып таратыла[2], ә Гаяз Исхакый исә

---

[1] Г. Исхакый Милли Шураның актив әгъзасы булган

[2] Бу вакыйга 1918 елның маенда була.

милли бәйсезлек өчен читтән торып көрәшергә мәҗбүр була – Маньчжуриядә, Финляндиядә, Япониядә һәм Польшада яшәп иҗат итә.

Гаяз Исхакый Идел-Урал милли мәсьәләләрнең символы буларак кабул ителә. Аның илледән артык әдәби әсәре бар һәм әлеге әсәрләрдәге персонажлар соңгы сулышларына кадәр милләт өчен кахарманнарча көрәшәләр. Исхакый үзе дә әсәрләрендәге персонажлар кебек иде һәм бакый дөньяга да ватан һәм бәйсезлек фикере белән күчте.

Кешеләр үлә, ләкин изге фикерләр мәңге яши һәм көннәрдән бер көнне хакыйкатькә әйләнә.

Гаяз Исхакый – бөек Төрки бердәмлек фикеренең төп кахарманы.

## Мәрхүм Гаяз Исхакыйның җеназасы[1]

*(«Азәрбайҗан», 1954, № 4–5)*

22 июльдә бакый дөньяга күчкән Гаяз Исхакый, үзенең васыяте буенча, Истанбулдагы Әдернәкапы зиратында якын дусты һәм танылган ватандашы яткан туфракта җирләнә.

Бераз алдарак, Әнкара станциясендә якын дуслары һәм фикердәшләре тарафыннан оештырылган искә алудан соң, җеназа поезд белән Истанбулга күчерелә. Идел-Уралдан, Төркестаннан, Төньяк Кавказ һәм Азербайҗаннан килеп хушлашырга җыелган халык агымында Гаяз Исхакыйны соңгы юлга озату процессиясе Баезид мәчетенә таба юл ала. Биредә җеназа намазы укыла. Соңрак якын дуслары һәм мәдәни җәмгыятьләр алып килгән чәчәкләргә күмелгән Гаяз Исхакыйның гәүдәсе куелган машина Әдернәкапы зиратына таба кузгала. Күпсанлы чәчәк букетлары һәм веноклар арасында Әнкара һәм Истанбул Төрек Үзәкләре тарафыннан җибәрелгән

[1] Мәрхүм Гаяз Исхакыйның җеназасы / Muhammed Ayaz Ishaki. Hayati ve faaliyeti. - Ankara, 1979. – Б.344-345.

веноклар күзгә ташланып тора иде. Мәрхүмнең кабере янында сүзне беренчеләрдән булып, аның алтмыш еллык дусты профессор Садри Максуди Арсал алды. Вакыт-вакыт үксүләр белән бүленгән чыгышында ул мәрхүм белән беренче тапкыр очрашып танышуын, аның гаиләсенә карата булган чиста һәм идеаль мөнәсәбәтен, Идел-Урал төркиләренең милли уянышы һәм үсеше юнәлешендә бергәләшеп эшләгән вакытларын, Гаяз Исхакыйның югары әдәби зәвыгын, кайбер әсәрләрен һәм аның сәяси хезмәтен искә алды.

Аннан соң Көнбатыш Төркестаннан килгән Б. Наим һәм Көнчыгыш Төркестаннан килгән Б. Иса мәрхүмнең сәясәтче буларак куйган хезмәтләре турында сөйләделәр.

Соңрак чыгыш ясаган А. Ваһап Йортсәвәр түбәндәге моментларга тукталып үтте: «Мәрхүм Гаяз Исхакый үзеннән соң бары тик югары сыйфатка ия булган күпсанлы әдәби әсәрләр калдырган әдип кенә түгел, шул ук вакытта ул төрки-татар дөньясының көрәш алып баруын үз кулларына алган, аның сакланып калу юлларын булдыру өстендә эшләгән идеолог һәм сәяси лидер буларак та тарихта кала.

Идел-Урал милли азатлык көрәше дигәндә хәтергә иң элек Гаяз Исхакыйның тирән фикерле, тынгысыз һәм максатчан шәхесе килә. Дус һәм дошманнары аны нәкъ менә әлеге сыйфатта беләләр һәм ул шушы образда тарихка да кереп калачак.

Гаяз Исхакый, мәңгелек дөньяга күчкәндә, үзенең максатына ирешә алмаган хыялын Идел-Урал яшьләренә изге әманәт буларак тапшыра. Яшьләр мәрхүмнең кабере янында бу изге әманәтне һичшиксез кабул итеп алырга тиеш».

Җеназа тирән кайгы һәм күз яшьләре эчендә тәмамлана.

*Текстларны Бәхтияр Миңнуллин әзерләде.*

*Фәйзи Акйөзем*[1]
*Әнкара*

## Тууына 100 елга багышланган Мәрхүм Гаяз Исхакый-Иделле

«Мәрхүм Гаяз Исхакый күренекле әдип, бөек әсәрләр калдырган әдәби зат кына түгел, шул ук вакытта бөек төрки-татар катламының көрәш һәм азатлык юлын үткән һәм азатлык идарәсен үз өстенә алган идеолог һәм сәяси лидер да булган.

Идел-Урал милли көрәш сугышы диюгә, иң беренче чиратта, Гаяз Исхакый шәхесе алга чыга. Дус һәм дошман аны бу үзенчәлекләре белән таный һәм бу сыйфат белән тарихка кереп кала» дип әйтте Гаяз Исхакый бәйнең үлгән көнендә Азәрбайҗанның кадерле мәрхүм А. Ваһап Йортсәвәр.

Әйе, 22 июль 1954 елда үлгән Идел-Уралның милләтче лидеры Гаяз Исхакый бәй бөек төрки галәм тарафыннан тәрбияләгән фикер иясе буларак кадерле хезмәтләре белән, төркичелек лидерлары арасында аерым бер урын тота иде.

Төрле авырлыклар һәм мәшәкатьләр белән 77 ел дәвамында бөтен гомерен бары тик милләтенә һәм ватанына хезмәт иткән Гаяз Исхакый бәй, 50 гә якын төрле әдәби гыйльми һәм милли әсәрләре белән бөек исемгә лаек булган. Идел-Уралның азатлыгы һәм хөрлеге өчен патша хөкүмәтенә, соңыннан большевик рус империализмына каршы ясаган куркыныч көрәш вакытында, төрле сәбәпләр аркасында тотылып, озак еллар сөргенлектә яшәгән.

Золым һәм авырлыкларны үткән Гаяз Исхакый бәй, патша дәверендә нәшер ителгән «Таң» газетасы белән эшчәнлеген башлап, «Ил», «Сүз» кебек сәяси газеталардан соң, большевизм дәверендә чыккан «Милли юл», «Милли байрак», «Яңа милли юл» исемле журнал һәм газеталар белән Идел-Уралның милли көрәшендә, азатлык хәрәкәтендә лидер булган, аны тизләтергә тырышкан һәм юл күрсәткән.

[1] Фәйзи Акйөзем. Мәрхүм Гаяз Исхакый-Иделле / Muhammed Ayaz Ishaki. Hayati ve faaliyeti. – Ankara, 1979. – Б.108-111.

Бүген тууына 100 ел булган мәрхүм 23 февраль 1878 елда Идел-Урал Казан тирәсендә туа. Чыгышы белән рухани гаиләдән, дини тәрбия алуына карамастан, ул һәрвакыт милли мәдәниятне алгы планга куйган һәм халкының социаль проблемаларына йөз тотып, бөек һәм нечкә осталык белән әсәрләр иҗат иткән.

Ул Идел-Урал белән бергә башка әсир төрки илләрне дә бәйсезлеккә ирешүенә һәм милли бәйсезлекләренә ия булуларын гел кабатлап торган һәм болай дигән: «Без Кавказ, Кырым, Төркистан, Идел-Урал төрле җирләрдә яшәсәк тә, бер нәтиҗәгә килдек. Ул безнең милли берлегебез, төрки милли берлегебезнең чынлыкка ашуы».

Канлы сугыш нәтиҗәсендә, большевик режимының бетүе белән тәңгә килгән бушлык, Төркестанда да, Кавказда да, Кырымда да, Идел-Уралда да яшәгән төрки халыкларны үз илләрен корырга һәм үз дәүләтләрен төзү мәсьәләсен уртага куячаклар[1]

Гаяз Исхакый бәй – туган илен, ватанын яратучы яхшы комитетчы һәм оста оештыручы да. Ул большевикларның Идел-Уралны алу вакытында Ерак Көнчыгышка күченгән һәм анда төрле авырлыкларга дучар ителеп, тормышларын алып барган якташларының бергә җыелуларына, бердәмлек һәм бергәлек эчендә яшәүләренә көч сарыф иткән. Шуңа күрә 1934 һәм 1935 елларда корылган «Идел-Урал төрки-татар милли мәдәният җәмгыяте» аркасында милли, мәдәни һәм дини эшләрнең үзәге булдырылуына ирешкән һәм нәшер иткән атналык «Милли байрак» газетасы белән дә Россиянең әсирлектә булган бөтен төрки республикаларының хакларын яклаган.

Аурупада «Россия милләтләренең гомуми фронты»на катнашып, көрәшен алып барган Гаяз Исхакый бәй, география чикләре бер-берсеннән никадәр ерак булса да, бөтен төркиләрнең бер мәдәни берлек тирәсендә берләшүләрен шарт итеп алга алып бара.

«Төрки халык географик чиктә никадәр күп таралган булса да, уяну дәвере башлангач, төрки мәдәни берлекне кыйбла итеп

[1] «Яңа милли юл» журналы, август 1935 (Бүгенге вазгыять һәм безнең вазгыятебез)

кабул иткән. Патша дәверендә бөтен милли хәрәкәтләребез бу юлдан киткән. Революция чорында азатлык хәрәкәтләребез, географик шартларыбызның аерым булу сәбәпле, эчке берлек үз рухында эшен дәвам итә иде. Мәмләкәт эчендәге эшләребез дә, дәүләттән тыш эшләрне алып бару өчен дә Төркистан, Азәрбайҗан, Кырым, Идел-Урал революцион комитетлары тирәсендә туплану белән бергә, аларның алып барган юлы һәм куйган максатлары – төрки мәдәни берлекне саклау рухында һәм мөстәкыйль яшәтү» дип әйтә иде[1].

Россия милләт вәкилләре белән якын бер диалог корган Гаяз Исхакый бәйнең Азәрбайҗанның милли лидеры М. Әмин Рәсулзадә белән якын дуслыгы бар иде.

Рәсулзадә аның турында: «Ул һәрвакыт төрки берлеккә, төрекчелектә барлыкка килгән, бөтен төрки илләрдә алга барган фикерләр һәм эшләр өчен җан атып яши иде»[2] дип әйтә иде.

Гаяз Исхакый бәй – бөтен гомерен Идел-Урал һәм башка әсир төрки илләрнең азатлыгы һәм хөрлеге көрәшендә катнашкан бөек мөҗәһидче. 100 ел элек тугач та, кайдан белә ала иде, ватаны Идел-Урал XX йөз елда әсир булып калачагын, кешелеклектән мәрхүм калачагына, ватандашлары төньяк ярымутравының һәм Себернең бозлы җәһәннәмендә үлем белән очрашачагына?!

Газиз Гаяз Исхакый бәй,

Син әдәби урыныңда рәхәтләнеп йокла! Синең алып барган азатлык һәм хөрлек мәхәббәтең, хыялланган төркичелек идеалларың, синең хисләрең кебек хисчән, көрәш һәм азатлык рухлы меңнәрчә миллиятче төрки яшьләр тарафыннан хәзергәчә булган кебек энтузиазм һәм дулкынлану белән алып барыла.

Рәсулзадә М. Әмин бәй әйткәнчә:

«Газиз дус, бөек мөҗәһид, рухың шат булсын! Яткан җирләреңдә рәхәтләнеп йокла! Артында рәхмәт әйтүче милләтне, яшьлекне калдырдың, болар барысы синең юлыңнан китәчәк, Идел-Уралны коткарачак»[3].

Рухың шат, урының җәннәттә булсын!

---

[1] «Яңа милли юл» журналы, февраль 1937.
[2] «Азәрбайҗан», № 28-29, 1954
[3] «Азәрбайҗан», № 28-29, 1954

*Мәдинә Сали Әхмәт*[1]
*Шанхай*

## Г.Исхакый әсәрләрендә хатын-кыз образы[2]

Төрек милләтенең барлыкка килүеннән алып хәзерге көнгә кадәр сакланып калган үзенә генә хас сыйфатлары бар. Төрки культурага, төрки мәдәнияткә таянган тормышыбыз, аның караңгы һәм якты тарафлары белән халкыбызның уңай һәм тискәре образлары, сыйфатлары, иҗат көчен үткен каләме белән җанландырган, алдыбызга җәеп салган бөек язучыбыз Гаяз Исхакыйның әсәрләрендә көчле һәм уңай образлары, һичшиксез, хатын-кызларыбыздыр. Исламны хак диндән чыгарган кайбер оятсыз дин әһелләре фикерле дин әһелләренең төрки халыкларның хатын-кызларының башын яптырып, аны хокуксыз, фикерсез, телсез-сүзсез, җанлы курчак хәленә китерергә тырышулары аркасында, соңгы йөз елда хатын-кызларыбыз төпсез караңгылык эчендә калганнар иде. Хатын-кызга карата тагы да түбән дәрәҗәдә булган дәверләрдә хатыннарыбыз фанатизм сазлыгында калган. Шуңа күрә, төрек хатынының бөек шәхесен кечерәйткән һәм түбәнсеткән фикерләр киң таралган. Тик бөек шәхесләрдә күренгән тарихи үткенлекнең киңлеге аркасында, кискен фикергә ия бөек язучыбыз караңгылык астында калган төрек хатынының чын йөзен күрә ала һәм төрек хатынының үзәк урынын аңлап, аларның арасыннан эре энҗеләрне сайлый һәм менә төрек хатынының чын үзенчәлекләре шушылар диеп, үз әсәрләрендә аларны бәян итә. Шулай итеп, берничә караңгы гасыр үткәннән соң, хатын-кызларыбыз яңадан якты дөньяга чыга башлыйлар.

Бөек язучыбызның әсәрләреннән кулыма төшкән ике әсәре бар: «Зөләйха», «Остазбикә» әсәрләренә бер күз салыйк.

---

[1] Мәдинә Сали Әхмәт. Г.Исхакый әсәрләрендә хатын-кыз образы / Muhammed Aүaz Ishaki. Haүati ve faaliүeti. – Ankara, 1979. – Б.162-166.

[2] «Милли байрак» газетасы, 64 -14 сан, 1937 ел, 26 февраль
Мәдинә Сали Әхмәт, 1897 Уфада туган, 28.05.1964 тә Истанбулда үлде. Төрек культурасы, июль 1964.

«Зөләйха» һәм «Остазбикә» әсәрләрендәге (остазбикә ханым – укытучы) Сәгыйдә ханым белән Зөләйха образларын ничек энҗе-мәрҗәннәр дип атамыйк? Төп хатын-кыз образын чагылдырган кешеләр болар түгелме? Зөләйханы әдәбиятыбызның иң драматик образы дип атасак та була. Зөләйха – ислам өчен көрәшкән хатын-кыз образы. Йөз еллар дәвамында арабызга үтеп кергән дин өйрәтмәсе халкыбыз арасына шулкадәр нык кереп урнашкан милли максатларыбызга ныклы рәвештә бәйләнгән. Аларны бер-берсеннән аеру авыр. Аеруча деспотизм дәверендә, үз-үзебезне саклау көрәшендә, ул безгә көчле корал иде. Шуңа күрә Зөләйха бары тик ислам өчен көрәшүче образ гына түгел, милли максатларда көрәшкән хатын-кыз образы да иде. Егерме ел дәвам иткән сугыш, аны төрмәләрдән сөргенгә, сөргеннән Себергә, Себердән дә башка җиргә тибәрде. Егерме ел дәвамында сузылган газаплар аны арытса да, көчсез итмәгәндер, киресенчә, ул рухи яктан тагы да батырая һәм байый. Зөләйха Әюп пәйгамбәр сабырын каян алган икән дигән сорау туа? Тарихыбыз битләрен актарып карыйк. Үткәнебезгә бер күз салыйк. Анда да төрек хатынының урынын табыйк. Янып торган, давыл кебек дөньяны гизгән, халкыбызның хатын-кыз образын пассив бер көч булып күрү акылга сыяр микән? Каһарман уллар үстергән ана көч-куәтсез җан иясе була аламы? Татар хатыны үз халкының тарихи юлын, ирләр белән бергә каһарманлыкта үткәргән. Бәлки кайвакыт ирләрдән рухлары тагы да көчле һәм сынмас булган. Шуңа күрә сугыш артында гына калмаган татар хатыны бер мизгелдә сугышның алгы сафында шәһит булган улының мәңгелеккә йомылачак күзләрен үз куллары белән каплап, бер үк җирдә яткан нарасыена яңадан каһарманлык сөтен имездергән.

Зөләйханың кан тамырларында шушы каһарман хатын-кызларның каны ага. Бу кан көрәшендә көч-куәт бирелә. Шуңа күрә аны күрергә килгәннәргә «Мине рус тоткынлыгында калдырачаксызмы?» дип каршылык күрсәтер, аналык хисе белән рустан тапкан баласының бишегеннән аерыла алмыйча, качу өчен кирәкле, кадерле вакытын югалта. Тик әтисе һәм халкының диненнән чыгып, башка чит агымга таба киткән баласына

каршы, аның каһәре дә зур. «Юк, ул минем улым түгел, аңлыйсызмы? Мин Зөләйха, Имадетдин кызы Зөләйха, мин мөселман, минем Захар исемле улым юк, юк...» ди.

Шулай итеп, элеккеге чорлардагы кебек, тарихыбызның сатлыкҗаны Шаһгали кебек, сатлык улларын әби-бабаларыбыз яннарына алмаган.

Таныш булмаган гаскәр солдатның букчасында Коръән белән бергә мең километр йөреп, «Остазбикә» Шанхайга кадәр җитеп, безнең дә кулларыбызга да килеп керде. Саргайган битләрен укырга дип күзләр йөгерешә. Күңел күздән дә тиз тоемлап, битләрне бер-бер артлы актара. Яшьлегемдә бу китапны күз ачып йомганчы укыган идем. Күз ачып йомганчы укуымның сәбәбе яшьлегем белән бәйле идеме яки рус фикерле булуыма бәйле булды микән, белмим. Инде хәтерләмим. Китапның ул вакыттагы тәэсире белән бүген укуымның хис-тойгылары җир белән күк арасы кебек аерыла.

Сәгыйдә ханым образы тормышыбыздан шулкадәр дөрес итеп алынган, кайчандыр дөньядан киткән анабызны, яраткан апабызны, безгә сабак биргән укытучыларыбызны, тагы әллә ничә таныш хатын-кызларны хәтерләтә. Аның йогынтысы җан тамырларыбызны сыйпый. Башкаларда нинди тәэсирләр уятадыр, мин әйтә алмыйм. Оста язучыларыбызның берсе Фатих Әмирханның «Тигезсезләр»дәге Рокыясе дә бераз тәэсир итми калмагандыр. «Рус кызына хас кыяфәтләрне ташла, үзебезчә калып булмыйммы?» дигән теләген уята. Сәнгати һәм психологик яктан караганда, Сәгыйдә ханым – нечкәлекләре белән уйланылып тудырылган образларның берсе. Язучы китапның беренче юлларында ук «Сәгыйдә остазбикәдә бер дә артыклык-кимлек юк иде. Ул гади генә авыл остабикәсе иде» дип башласа да, тора-бара аны рухи яктан шулкадәр күтәрә, китабының ахырында – ялгыш уйламыймдыр дип саныйм, - башка милләтләрнең әдәбиятында да сирәк очрый торган көчкуәтле, нык хатын-кыз образына әйләндерә. Сәгыйдә ханымның рухи үсеше үзебезнең табигый, дини, милли акылыбызның юлы белән бара. Анда бернинди дә ялгыш, гайре табигыйлык сизелми. Сәгыйдә ханым кебек, Зөләйха да көрәшче. Зөләйха

ир-ат белән хатын-кыз өчен уртак булган тышкы дөньябызның сугышында җиңүче булып чыкса, Сәгыйдә ханым – хатын-кыз булуы белән эчке хис-тоемлау сугышында үз-үзендә көч таба ала алган, җиңүче хатын-кыз образы.

Көз аеның куркыныч, әкрен, тирән, караңгы бер кичендә Сәгыйдә ханымның бәхетле иткән йөрәгенә агулы ук атыла. Аның алдына төшкән куркыныч фаҗига күренеше – «Әй, бер улым булса» теләге барлыкка китерә. Әлеге теләкне тормышка ашыруда төрле чараларга мөрәҗәгать итсә дә, Аллаһы Тәгалә аңа бала бирми... Караңгы бер кичтә Сәгыйдә ханым кунакка барган бер йортта башка ханымнар белән үткәрә. Бу ханымнарның пышылдаулары, хырылдау тавышлары, шкафтагы табак-савытларның төнге караңгылыкта ялтырап китүләре, гүя күзләрен чагылдырып, нур сибәләр иде, янында яткан Үлмәс карчыкның начар уйлары аша «Ирнең үгие юк» дигән сүзләре ишетелә кебек иде. Сәгыйдә ханым бу пычрак уйларның саф күңеленә урнашуына рөхсәт бирмәс иде беркайчан да. Ләкин бу сүзләр хатынның үгие бармы дигән фикерне башына китертә. Бу фикер аны ничек кенә яраласа да, агуласа да, әлеге фикерләр аның башыннан китми. «Балага мәхәббәт, хәзрәтне бәхетле итү теләге» аның күңеленә кабат-кабат килә, ныклы итеп урнаша. Аның рухи көче, ниһаять, ул үзендә бу корбанга барыр көч табуын сизә. Сәгыйдә ханым карар бирә. – Язмыш аның күзен кара белән буяса да, маңгаена яңа бер җыерчык чыгарса да, эшләгән эшләре сәбәпле йөзенә авырлык бирми. Сәгыйдә иң агулы дип саналган еланны җиңгән иде.

Кызганычка каршы, егерме елдан бирле, җан азыгыбыз булган бу китаплар дошманның пычрак кулы астында иде. Егерме ел дәвамында халкыбыз үзенең тәмле чишмә суы урынына сасыган баткаклыктан су эчәргә мәҗбүр булды. Дошман һөҗүм итү белән бергә, Зөләйхаларны Марфага әйләндерергә тырышкан.

Ләкин бу булдырырлык түгел. Төрки-татар хатын-кызы үзенең тарихи юлын табып, үзенең бара торган юлыннан чыга торганнардан түгел. Чөнки бу хатын-кызларның Остазбикә белән Сәгыйдә ханымның сурәтләнүе кебек, «Маңгаена бөеклек языл-

ган, Карашларында падишаһлар карашы, хәрәкәтләрендә баһадирлар чалымы,» җөмләсе белән хатыннарның бөек кыйммәтләрен биргән, халкының шанлы үткәне белән якын киләчәген билгели.

«Зөләйха», 48 б., Зөләйханың Габдулла белән сөйләшүендә:

«Өч дүрт көн бер буйдан аттан атка күчереп чаптылар. Чаптылар да монастырьга илтеп тыктылар. Анда тугыз ай тоттылар, Кылмаганнарын кылмадылар. Ач та тоттылар, кыйнадылар, үгетләделәр дә. Иртә чиркәү, кич чиркәү, анда ничек гакылдан язмадың, диең.. Тел белмим, сөйли алмыйм, кая киттем, ни булдым, берсен дә белмим.. Шуннан соң менә шуңарга бирделәр. Тора торган җирем кай җир, безнең аыл кай якта – һичберен белмим. Былтыр бер кырыктартмачы килгән иде. Шунда гына әнинең исәнлеген белдем».

*Басмага Гүзәлия Хаҗиева-Демирбаш әзерләде*

## Бакый Урманче хатирәсендә Г. Исхакый шәхесе

Мәгълүм ки, XX гасыр башы вакытлы татар матбугатында мәгълүм шәхес – әдәбият тәнкыйтьчесе, публицист, Гаяз Исхакый мөхәррирлегендә Петербургта басылган «Ил» газетасында сәркатип вазыйфасын башкарган Нәҗип Гасрый (Мөхәммәтнәҗип Аллабирде улы Мәүләбирдиев) (1886–1937) газета битләрендә бер-бер артлы әдәби тәнкыйть мәкаләләре, публицистик язмалары белән чыгыш ясый. Шул ук вакытта Г. Исхакыйны төрле яктан яхшы белгән дусты да ул. Б. Урманче да Н. Гарсый белән таныш, якыннан аралашкан. Рәссам 1920–1926 елларда Мәскәүдә сәнгать институтында укыган елларында Н. Гасрый белән шактый аралашкан күрәсең, аның шәхси архивын күзәткәндә әдәбият тәнкыйтьчесенең шәхесенә һәрвакыт җылы мөнәсәбәт белдергән истәлекләре еш очрый. Алар арасында аның Сәмәркандта җирләнүе вә Б. Урманченың Н. Гасрый каберенә зиярәт кылуы хакында да мәгълүматлар күзгә чалына. Монда ачыкланып бетмәгән бер сорау да туа

кебек. Татар энциклопедиясендә Н. Гасрыйның вафат булган елы 1937 ел күрсәтелә. Ләкин истәлекләрдә чагылып киткән фикерләр аның әле XX гасырның 50 елларында исән булуына ишарә дә бирә. Кызганыч, безнең кулыбызда бу шәхеснең 1917 елгы Октябрь инкыйлабыннан соңгы тормышы һәм иҗаты хакында төпле чыганаклар юк дәрәҗәсендә, табылуы да шикле. Шул сәбәпле, фикер фәкать фараз буларак кына кала. Бәлкем, киләчәктә Н. Гасрыйның шәхесе, иҗаты белән кызыксынучылар табылыр, күп мәсьәләләргә ачыклык кертелер дигән өметтә калам. Гомумән, рәссамның шәхси архивы XX гасырның күренекле шәхесләре хакында язылган хатирәләргә бик бай һәм аларның иҗатлары яисә шәхесләренә багышланган истәлек-мәкаләләрендә шактый уңай фикерләр белән дә очрашабыз.

Н. Гасрый истәлегендә Г. Исхакый турында фикерләр урын алган. Форсаттан файдаланып, Б. Урманченың да бөек әдип-публицист белән очрашып сөйләшүен дә искә алырга кирәктер, мөгаен. Рәссам, Г. Исхакый белән беренче һәм соңгы тапкыр 1913 елда Мәкәрҗә ярминкәсе вакытында таныша. Дөрес, бу танышу хәл-әхвәл алышудан узмый. Шуңа карамастан, ул истәлек-хатирәләрендә һәрвакыт Г. Исхакыйның шәхесенә, иҗатына ихтирамын белдереп бара, аны XX гасырның иң күренекле әдибе итеп күрсәтә. Хәтта, соңрак, әдипнең иҗатына таш атучыларга үзенең тискәре мөнәсәбәтен дә сиздерә.

Н. Гасрыйның Г. Исхакый эш стилен тасвирлаган хатирәсе укучы өчен кызыклы булыр дип уйлыйбыз.

Язма татар халкының күренекле рәссамы, скульпторы, шагыйрь, галим Габделбакый Идрис улы Урманче шәхси архивында табылган Нәҗип Гасрый хакындагы истәлегеннән алынды.

## Нәҗип Гасрый

Гаяз Исхакыйны бик ярата иде. Мәфтүн иде[1]. Аның тиз һәм бик шаукымланып язуын сөйли иде. Алдында һәрвакыт бер тартма корыч каләм тора икән. Дәртләнеп язган вакытында

[1] Мәфтүн иде – соклана иде

каләмләре сына, ул аларны каләм сабыннан алып ыргыта да, икенче каләмне кигезә. Шулай сәгатьләр буенча утыра. Язган вакытында ул бөтен дөньясын оныта.

*Кереш мәкалә һәм текстны басмага*
*Зөфәр Мөхәммәтшин әзерләде*

## Гаяз Исхакый турында Мөстәҗип Үлкүсал

**Мөстәҗип Үлкүсал** (1899-1996) - кырым татар халкының милли мәнфәгатьләре өчен көрәш юлына гомерен багышлаган милли каһарман. Ул (Румыниядә туган) озын еллар кырым татарлары һәм башка төрки халыклар арасында киң таралган вакытлы матбугат органы –«Әмәл» («Гамәл») журналын бастырып килә. Гомеренең соңгы елларын Төркиядә үткәрә. Мөстәҗип Үлкүсалның кырым татар халкының тарихы, әдәбияты, этнографиясе белән бәйле язмалары да бар.

М. Үлкүсалның «Кырым өчен багышланган бер гомер» китабы исә истәлекләр рәвешендә язылган. Ул авторның үлеменнән соң гына, 1999 елда Анкарада басылып чыга. Аның аерым сәхифәләрендә Гаяз Исхакыйның тормышы һәм эшчәнлегенә кагылышлы шактый кызыклы мәгълүматлар да китерелә. Билгеле булганча, Гаяз Исхакый тууының 100 елы мөнәсәбәте белән 1979 елда Анкарада бастырылып чыгарылган җыентыкта да Мөстәҗип Үлкүсалның Гаяз Исхакый турында язылган бер мәкаләсе урын ала. Ләкин бу соңгы китаптагы текстларда исә әдип белән бәйле тагы да тулырак мәгълүматлар булуын билгеләп үтәсе килә. Моны, мәсәлән, «Әмәл» журналының латин хәрефләр белән чыгара башлавына Гаяз Исхакыйның мөнәсәбәте белән бәйле материалларда күрергә мөмкин. Шулай ук «Кырым өчен багышланган бер гомер» исемле истәлекләр китабында Гаяз Исхакыйның башта төрки халыкларның милли лидерлары белән мөнәсәбәтләренә, Икенче дөнья сугышы башы еллары белән бәйле фикер һәм позициясенә кагылышлы уй һәм фикерләре тәфсиллерәк бирелә.

Мөстәҗип Үлкүсалның бу истәлек китабында Гаяз Исхакыйга,

аның кешелек сыйфатларына, милли көрәш юлында күрсәткән лидерлык позициясенә югары бәя бирелә. Гаяз Исхакыйның Казан татарлары өчен генә түгел, бөтен төрки дөнья өчен үрнәк алырлык кеше, бик күпләрне үзенең артыннан әйдәп барырлык көчкә ия булган шәхес итеп күрсәтелә. Истәлектә шулай ук кайбер башка татар зыялылары эшчәнлеге турында да сүз бара. Мөстәҗип Үлкүсал Гаяз Исхакыйның Ерак Көнчыгыштa татарлар белән булган мөнәсәбәтләре, килеп чыккан каршылыклары турында да әйтеп уза. Бу вакытларда булып торган вакыйгаларны чагылдырган мәкаләләрнең «Әмәл» журналы битләрендә дә урын алганлыгы белдерелә. Бу исә киләчәктә татарлар һәм Гаяз Исхакыйга кагылышлы тагы да яңа материалларның табылачагы турында сөйли.

*Мүстәҗип Үлкүсал*

## Кырым өчен багышланган бер гомер[1]

### *Гаяз Исхакый белән танышу*

1929 елында беркөн Мәхмәт Ниязи бәйдән бер телеграмма алдым. Бу телеграммада Германиядән Гаяз Исхакый бәйнең килүе һәм минем белән күрешергә теләге булуы турында белдереп, мине Констанцага (Румыниядә бер шәһәр) чакыра иде. Шунда ук юлга чыктым һәм Констанца шәһәрендә икесе белән дә очраштым. Төньяк төркиләренең бу каһарман миллиятчесен, ару-талу белмәгән көрәшчесен көчле һәм киләчәккә өметле күрүемә бик шатландым. Алар белән коммунистик Россия һәм аның әсирлеге астында яшәгән төрки халыкларның бүгенге тормышы һәм киләчәкләре турында озак итеп сөйләшеп утырдык. Гаяз Исхакый Берлиндагы эшчәнлеге һәм бөтен дөньядагы төрки халыклар турында мәгълүмат бирде. Берлинда басылып чыга торган «Яңа милли юл» журналының берничә санын бирде һәм әбүнәлек өчен

---

[1] Ülküsal Müstecip. Kırım Yolunda Bir Ömür. Ankara, 1999. S. 424. Бу җыентык өчен китапның Гаяз Исхакый белән бәйле язылган өлешләре сайлап алынды.

минем адреска 50 данә җибәрәчәген белдерде. Берлинга кире кайтканнан соң, ул җибәргән нөсхәләрне әбүнәләргә тараттык. Соңыннан бу эшләр белән туганым Нәҗип шөгыльләнә башлады. 1931 нче елда Гаяз Исхакый кызы Сәгадәт ханым белән Добруджада безнең гаиләбезгә килгән вакытта Нәҗип белән таныштылар һәм журналны тарату эше аңа тапшырылды.

Гаяз һәм Ниязи бәйләр белән Констанцада фотографиягә төштек һәм бер көн буенча анда калдык. Бу күрешүдән соң да Гаяз Исхакый белән гомеренең соңына кадәр бик күп тапкырлар очраштык, күрештек.

## *Ерак Көнчыгыштагы Идел-Ураллылар белән мөнәсәбәтләребез*

Беренче Дөнья сугышы елларында Россиядә чыккан революция вакытында башка төрки җөмһүриятләр кебек Казан төркиләре дә тулы азатлык һәм бәйсезлекләренә кавышу өчен милли мәҗлесләрене коралар һәм хөкүмәтләрен оештыралар. Бервакыттан соң бөтен Россия большевиклар кулына күчүе нәтиҗәсендә Идел-Урал төркиләренең хөкүмәте таркатыла. Шуңа күрә дә бик күп Идел-Урал татары Маньчжурия, Кытай, Японияга китәргә мәҗбүр була һәм бу илләрдә күп санлы татарлар яшәгән колонияләр барлыкка килә. 1934 нче елда бу илләрдә яшәгән татарлар янына килгән бөек мөҗаһид (тырышучы, көрәшче) һәм олы әдип Гаяз Исхакый татарларны берләштерә, үзе идарә иткән Милли Үзәк белән бәйләнешләрен оештыра һәм ныгыта. Манчжуриянең Хайлар шәһәрендә «Милли Байрак» исемле атналык газета бастырып чыгара башлый. Бу газета Румыниянең Пазарджик1 шәһәрендә чыгарылган «Әмәл» (Гамәл – И.Р.) журналына да даими рәвештә җибәрелә иде. Без дә үз журналыбызны аларга җибәреп тора идек. Оешма әгъзалары белән аралашып, хатлар алышып тордык. Шулай итеп, Манчжуриядә яшәгән Идел-Урал туганнарыбыз белән Добруджадан бирле мөнәсәбәтләребез бар иде.

[1] Хәзер Болгариядә.

Япониянең үзэге Токио шәһәрендә Идел-Ураллы Габделхәй Корбангали исемендә бер кеше бастырып чыгарган «Япон мөхбире» журналын да ала башлаган идек. Аларга да үзебезнең «Әмәл» журналыбызны җибәрә торган идек. Бервакыттан соң Габделхәй Корбанали, «Аләме Ислам» әсәренең язучысы һәм сәяхәтче Габдерәшид Ибраһимов белән берләшеп, Гаяз Исхакыйга каршы чыгып, милли хәрәкәт таркала башлагач, «Япон мөхбире» журналы белән мөнәсәбәтләребезне туктаттык. Безнең өчен иң әһәмиятлесе – төрки берлек, азатлык һәм төркиләрнең үсеше өчен тырышкан һәм хезмәт иткән кешеләргә ярдәм итү иде. Бу фикердә тормаганнар белән дә мөнәсәбәтләребез киселә иде. Хәтта мондый кешеләрнең төркичелек фикеренең яшәеше өчен зарарлы һәм ул затларның хаин булулары турында курыкмыйча язу иде. Шуңа күрә дә «Әмәл» журналында ул тарихларда бу темага кагылышлы күп кенә мәкалә бар.

### *Идел-Урал Корылтаеның 20 нче елы*

Идел-Урал кардәшләребез, лидерлары бөек мөҗаһид һәм әдип Гаяз Исхакый булуына карамастан, Идел-Урал татарлары Корылтаеның 20 нче ел котлауларын 6 февраль 1938 нче елда Варшавада билгеләп үтәргә карар биргәннәр иде. Бу җыелышка катнашу өчен Истанбулдан Варшавага баручы бер Казан татары ханым, энисе белән Констанцадан узып барышлый, безгә керде һәм ике көн бездә калды. 6 февральдә Варшавада оештырылган котлауга «Әмәл» журналының мөдире һәм Добруджа Төрки мәдәният берлеге җитәкчесе сыйфатында тәбрикләү телеграммалары җибәрдем.

### *«Әмәл» журналының латин хәрефләре белән чыгарыла башлавы*

Төркиядә гарәп әлифбасыннан латин әлифбасына күчү тормышка ашты. Без дә инде күптәннән «Әмәл» журналын

латин хәрефләре белән чыгарырга тели идек. Ләкин латин хәрефләренә күчү өчен кирәкле матди мөмкинлекләребез юк иде. Күптәннән дә журналдагы мәкаләләрнең исемнәрен латин хәрефләре нигезендә булган румын әлифбасы хәрефләре белән яза идек. Ниһаять, 1939 нчы елның июнь аенда Бухарестта төрле зурлыктагы 200 килограмм хәреф сатып алдым. Шулай итеп, 1939 нчы июль ае санын «яңа төрек хәрефләре» дип атап йөртелгән латин хәрефләре белән чыгардык. Июль аеннан башлап журналның латин хәрефләре белән чыга башлаячагын июнь санында да укучыларыбызга белдергән идек. Бу хәбәрне укыган Гаяз Исхакый безгә нык кызган, ачуланган. Миңа дүрт бит тутырып бер хат язган. Бу гамәлебезне нык тәнкыйтьли, хәтта авыр сүзләр дә куллана иде. Гаяз Исхакый бу хәрәкәтне «милли көрәш юлыннан аерылу», «большевикларга ияру», «акылсызлык», хәтта «милли көрәшкә хыянәт» дип атый иде. Гаяз Исхакыйның бу кадәр ачулануы мине аптыраш та калдырды һәм лидер булган шәхескә бер дә килештермәдем. Үзенә саллы гына бер хат яздым. Төркиядә кабул ителгән латин әлифбасын куллана башлавыбыз төрки берлек өчен файдалы һәм мөһим булачагын белдердем. Бу хатымны исә Гаяз Исхакый җавапсыз калдырды.

## *Кадерле кунакларыбыз*

1939 нчы елның 17 июлендә Гаяз Исхакый бәй, 6 августта Мәхмәт Әмин Рәсүлзадә бәй хатыны белән бергә Польшадан Констанца шәһәренә килделәр. Алар белән еш кына очрашып, Европа һәм дөньяда булып беткәннәр, аеруча Төркиянең киләчәге турында озак итеп сөйләшеп утыра идек. 13 нче августта алар өчен Констанца шәһәрендәге «Зече» ресторанында Добруджа Төрки мәдәният берлеге исеменнән 50 кешелек прием оештырдык. Ул вакытларда Carmen Silva шифалы суларында ял иткән поляк профессор Томкевич белән хатынын да кунакка чакырдык. Килделәр. Эчкерсез һәм самими сөйләшеп утыруның соңында озын итеп төрекчә һәм кыска гына французча сөйләдем. Гаяз Исхакый һәм Мәхмәт Әмин Рәсүлзадә бәйләр төрекчә,

профессор Томкевич дә французча җаваплар бирделәр. Бу прием һәм күрешмәләр турында «Әмәл» журналының 1939 елгы август ае санында билгеләр бар.

Август аенда булып узган әһәмиятле вакыйгалар Европа өчен никадәр катлаулы көннәр һәм иминлеге өчен куркыныч янаган вакытларның килүе хәбәрен бирә иде. Гитлер Германиясе сугыш хәзерлекләрен тәмамлады. Сугышка хәзерлекләрен яшерү максаты белән Советлар хөкүмәте белән дуслык аңлашмалары имзаланды. Киләчәктә безне көткән бу зур үзгәрешләр һәм вакыйгаларның нәтиҗәсен кызыксыну белән көтә бышладык. Фаразлар кылып, барган юлыбыз,ягъни милли көрәшнең киләчәге белән бәйле уйлар эчендә идек.

Гаяз Исхакый бу очрашу вакытында түбәндәгеләрне сөйләде: «Кардәшләрем! Катлаулы һәм буталчык бер вакытта яшибез. Бөтен бу зур вакыйгаларның нәтиҗәсендә Советларның таркалуы һәм яңа дәүләтләрнең барлыкка килүенә шаһит булачакбыз. Барлыкка киләчәк бу яңа дәүләтләр «Прометей» эченә кергән һәм безнең төрки халыкларның дәүләтләре булачак. 1917 нче елдагы Россиянең беренче таркалуы вакыты белән чагыштырганда, хәзер без тагы да көчлерәк һәм хәзерлегебез дә бар. Бүген бөтен дәүләтләр һәрбер төрки илнең бәйсезлеккә ирешүенең ни кадәр әһәмиятле булуы турында беләләр һәи аңлыйлар. Ләкин, кардәшләрем, бу мөкаддәс хакларыбызның танылуы һәм бәйсезлегебез өчен көрәшнең җиңүе өчен бердәнбер шарт бар. Ул да булса, без бердәм булырга тиеш, бер-беребез белән аңлашып эш итәргә тиешбез. Иң башта сез, кырымлылар, үз арагызда, Идел-Уралылар, азәрбайҗанлылар, төркестанлылар, төньяк кавказлылар үз араларында, соңыннан инде без бөтенебез үз арабызда аңлашып берләшергә тиешбез».

Мәхмәт Әмин Рәсүлзадә бәй түбәндәгеләрне сөйләде: «Без, Добруджага кояшның җылысыннан файдаланып, бераз ял итәр өчен килгән идек. Ләкин кояш безгә җылылыгын бик күрсәтә алмады. Шулай да без монда яшәгән кырымлы кардәшләребезнең самими мөнәсәбәте белән каршылаштык. Кардәш төрки халыклар арасындагы бу җылы мөнәсәбәт безне сөендерә һәм шатландыра. Соңгы көннәрдә бөтен дөньяда зур үзгәрешләр

башланды. Халыклар һәм дәүләтләрнең киләчәк язмышы һәм хаклары турында яңадан сөйләшүләр алып барыла башлады. Бу вакыйгаларга бәйле рәвештә Россия составында булган һәм бигрәк тә төрки халыкларның язмышы аерым урын алып тора. Киләчәктә Россиянең таркалуы һәм төрки дәүләтләрнең үз бәйсезлекләренә ирешүе бәхәссездер. Бу бәхетле һәм куанычлы көн өчен безнең берләшүебез һәм хәзерлекле булуыбыз кирәк».

Икенче дөнья сугышы алдыннан сөйләнелгән бу сүзләр, Россия составында булган төрки дәүләтләрнең бәйсезлекләренә ирешүләре белән бәйле өметләребезнең никадәр көчле булуының бер дәлиле иде. Кызганычка каршы, безнең киләчәк белән бәйле өметләребез тормышка аша алмады. Алда безне тагы да аяныч һәм өметсез көннәр көтә иде.

Поляк профессоры Томкевич, башта рәхмәтләрен белдергәннән соң, түбәндәгеләрне сөйләде: «Әмәл» журналы мөдире белән бергә монда яшәгән кырым татарлары авылларында булдык, халык белән аралаштык. Халыкның үз ватаны Кырымны никадәр яратканын аңладым һәм аның бәйсезлеге өчен көрәшергә әзер. Сезнең дә ватаныгызның бәйсезлеккә ирешүенә ышанам һәм халкыгыз да азатлыгына кавышыр дип өмет итәм. Без поляклар сезгә бу юлда ярдәм итәргә әзербез.

## ***Гаяз Исхакый белән язышулар***

Гаяз Исхакый Истанбулга кайтканнан соң 17 февраль, 1940 елда язылган хатында Идел-Урал мөҗаһидләренең Варшава һәм Берлиннан ташынып чыгып китүләре өчен борчыла һәм аларның Румыниягә килеп җитүләре турында сораша иде. Финляндиядә яшәгән татарлар, фин гаскәренә катнашып, русларга каршы сугышканнарын, ике татар офицерының шәһит булуын сөйләгән иде. Хатта шәһит булган ике офицерның исемнәре дә язылган иде: Хәсән улы Фәйзи һәм Билал улы Сөләйман. Кызыл Армия сафларында хезмәт иткән берничә Идел-Ураллы төрки гаскәринең фин гаскәре кулына әсир төшкәнен дә белдерә иде. Гаяз Исхакый да Финляндиягә чакырылган, ләкин үзе Варшава һәм Берлиннан килүче милләттәшләрен көтүен белдерә иде. Фин

гаскәре кулына әсир төшкән татарларның милли көрәш максатларын аңлаулары өчен миндә булган «Яңа милли юл» журналларын, «Милли байрак» газеталарын һәм башка милли газета һәм журналларны Финляндиягә җибәрүемне, кайбер китапларны да аңа Истанбулга җибәрүемне сорап яза, адреслар биргән иде. Финляндиягә шулай ук «Әмәл» журналын җибәрүемне дә үтенә иде. Бик әһәмиятле булганга күрә, бу хат Истанбулдан Констанцага баручы азәрбайҗанлы Али Азертекин белән җибәрелгән иде.

Али Азертекин 1940 елның 22 февралендә миңа Бухаресттан хат җибәрде. Аның хаты янында Гаяз Исхакый хаты да бар иде. Хатында шулай ук Истанбулдан поляк дустыбыз Башковский (Baczkowski) белән бергә килүе һәм шунда ук тиз арада Бухаресттан китәргә мәҗбүр калуы турында һәм минем яныма керә алмаячагын белдереп гафу үтенә иде.

Гаяз Исхакый Париждан 1940 елның 19 март тарихында бер хат җибәрде. Бу хатта Истанбулга кире кайткан Али Азертекин белән җибәрәчәгемне көткән китапларны алмаганын белдерә, ул китапларны Парижга җибәрүемне үтенә иде. Якын көннәрдә Финляндиягә китәргә җыенганын, Финляндиянең Советлар Союзы белән аңлашма имзаларга мәҗбүр калуын, Парижда доктор Мир Ягъкуб һәм Сәед Шамил бәйләр белән күрешүе турында аңлата иде. Янында булган икенче хатны Бухаресттагы Мәхмәт Әмин Рәсүлзадә әфәндегә тапшыруымны үтенә иде.

Мәхмәт Әмин Рәсүлзадә 1940 елның 19 июлендә Бухарестта миңа килгән хатында боларны яза иде: «Сезнең хатыгызны алганга күп вакыт узды. Вакытында җавап бирә алмавым өчен гафу үтенәм. Вакыйгалар да без көткәннән тискәре рәвештә үсеш алды. Бик күп кеше гаҗәпләнде, аптыраашта калды. Франциянең кыска вакыт эчендә басып алынуын күрүчеләр, сентябрь аенда полякларны тәнкыйть иткәннәр дә гыйбрәт алганнардыр. Англия көрәшне дәвам итәчәген сөйли. Ләкин Германияне юк итә алырлык көч кайда? Россияме? Лондон Мәскәү белән уеннар уйный башлады. Ләкин Россия ярдәм итә алырлык хәлдәме? Озын бер сугыш нәтиҗәсендә көнбатыш дәүләтләре кебек үк, Германиянең дә көчсезләнәчәген уйлаган Сталин да алдандымы

юкса? Күрербез, вакыйгалар ни рәвештә үзгәрәчәк. Ләкин шулай да, без көтмәгән юллар аша булса да, милли азатлыгыбызга, максатыбызга ирешә алырбыз дип ышанасым килә».

### *Габдерахман Шәфи әфәнде белән күрешү*

Шул ук көнне (22 декабрь 1941) сәгать 18.00 дә Идел-Урал татарларының вәкиле һәм Гаяз Исхакый әфәнденең ышанычлы кешесе Габдерахман Шәфи әфәнденең өендә үзем генә очраштым. Ул инженер Фуат Казакның апасына өйләнгән һәм үзләренең өйләре бар иде. Балалары немец мәктәбендә белем ала иде. Милләт җанлы (миллиятче) һәм хәлдән аңлый торган кеше иде. Аның өендә сәгать 21.30 га кадәр калдым. Әсирләр тотылган лагерьлар һәм Польша турында күп итеп сөйләде. Әсирләрне күрү өчен гаскәри министрлыктан рөхсәт алырга кирәк икән. Юл билетларын Гаскәри министрлык бирә, көнлек чыгымнарны Көнчыгыш министрлыгы бирә икән. Габдерахман әфәндегә Гаяз һәм Җәгъфәр бәйләрнең тәкъдим хатларын тапшырдым. Габдерахман әфәнде Җәгъфәр әфәнденең «Әмәл» журналының соңгы саннарында Германиягә каршы язган мәкаләләренең начар фикер калдырганын, фон Менденең бу мәкаләләрне алман теленә тәрҗемә иттереп үзендә тотуы турында сөйләде. Мин бу мәкаләләрнең ни өчен һәм нинди максат белән язылганын, бу мәкаләләрне Германия турында хаксыз бер әйбер дә язылмаганын белдердем. Моңа каршы бары тик шуны гына әйтте: «Төрекчә мәкаләләрнең тәрҗемәләрендә ялгышлар булса, төзәтергә кирәк». Ләкин без бу тәрҗемәләрне фон Мендедән ала алмадык.

24 декабрьда әтисе кырым татары, әнисе төрек булган Һарун Токсавул исемле бер студент белән күрештек. 45 яшьләрендә иде. Самими, ләкин бераз оялчан иде. Әсирләр белән шөгыльләнәчәген сөйләде.

Өч көн буе Рождество бәйрәме иде. 26 декабрьда Мостафа Чокай әфәнденең тиф авыруыннан үлеп китүе хәбәре килде. Бик борчылдык. Төрки берлек хәрәкәте өчен бөек югалту иде. Җирләүгә барырга уйлыйбыз.

***

1942 нче ел 4 май дүшәмбе көнне иртән үк Әhмәт Вәли Мәнгәр әфәнде Истанбулдан килүен hәм безнең белән «Adlon» кунакханәсендә күрешергә теләгәнен белдерде. Телефоннан хәзер үк киләчәгебезне сөйләдем. Бераздан «Adlon» кунакханәсенә килдем. Вәли әфәнде миңа Истанбулдан китергән хатларны тапшырды hәм аннан яңа хәбәрләрне алдым. Әhмәт Вәли Мәнгәр әфәнде hәм Гаяз Исхакыйның, шулай ук Гаяз Исхакыйның Җәгъфәр әфәнде hәм генерал Хөсни Фикрәт белән булган мөнәсәбәтләренең начарланганын өйрәндем hәм бик борчылдым. Мондый вакытта милли лидерларыбызның үз араларында аңлаша алмаулары бик кызганыч иде.

*Басмага Илсөяр Равил кызы Рәмиева әзерләде.*
*(Окан Университеты, Төркия)*

## Новый документ о реакции людей на преследование властями Г. Исхаки

Вниманию читателей и исследователей предлагается исторический документ, имеющий отношение к жизни и деятельности известного татарского писателя, драматурга Гаяза Исхаки. История его возникновения (создания) такова.

8 августа 1907 года жандармами (органами жандармерии) был произведен обыск в редакции газеты «Танг йолдызы» (Тауш) в Казани. В результате этих действий,было отобрано 8 пакетов (1 пакет с 17 документами и 7 пакетов с 140 документами). Среди них был и данный документ, предлагаемый вниманию читателей. Документ нужно датировать временем ранее 8 августа 1907 года (до 8 августа 1907 года). Позднее эти пакеты с документами были получены Хусаином Абузяровым. В этом он и сам расписался .

На листе писчей бумаги помещен по-русски и по-татарски «Отчет по сбору пожертвований в пользу Гияза Исхакова», политического преступника, высланного из Казани. В начале

говорится: «Мы были сильно огорчены высылкою его. 5–10 человек собрались и из них 3 составили комитет!» Обращаясь к редактору и издателю газеты «Танг», комитет восклицает: «Следуйте за издателем «Танг» – и не подвергайтесь презрению». Станемте под красный флаг их, любящих родину, ибо, блогадаря лишь борьбе, можно добиться своего права. Не забывая это будемте бороться! Да здравствует свобода! Да сгинет мрак! Да здравствует умная наша молодежь! Да здравствует социализм!».

Затем перечисляются 38 человек, которые пожертвовали 22 рубля, именно:

1. Мухамед –Шакир Симиниев, он же казначей – 1 р.
2. Мухамед-Хафиз Енгулатов,член комитета – 1 р.
3. Абдулла Бурнашев, член комитета – 50 к.
4. Абдул-Валей Заманов – 1р.
5. Иван Гришин Тузов – 20к.
6. Хасан Сакаев – 50к.
7. Г. Так(х)мазов – 1р.
8. Галей Мухамедханов – 50к.
9. М.В. – 45 к.
10. К.Г. – 1 р.
11. Рахим Мамедов( Мухаммедов) – 1 р.
12. Афзалетдин Канцеров –20 к.
13. Мухамедша Алиев – 15 к.
14. Ибрагим Негманов – 50 к.
15. Насырбай Уразаев – 1 р.
16. Шакир Мухамедиев – 50к.
17. Неизвестный – 50 к.
18. Галий Негманов – 30к.
19. Закир Бурнашев – 1 р.
20. Сулейман Галиев – 15 к.
21. Хабибулла Сераджетдинов – 15 к.
22. Садык Ерзин – 30 к.
23. Кадыр Ерзин – 1р.
24. Неизвестный – 45 к.
25. Абдулла Бурнашев – 45 к.
26. Мухамед- Шакир Ахмеров – 45к.

27. Хусейн-бай Фазильбаев – 75 к.
28. Шариф Девликамов (не читается-НТ.)
29. Неизвестный – 75 к.
30. Абдулла Чембарисов –50 к.
31. Магинетдин Урманов – 30 к.
32. Абдул-Халик Лаишев – 1 р.
33. Алим Енгалычев – 60 к.
34. Сагид Абаев – 75 к.
35. Хасан Ибрагимов – 60 к.
36. Исмаил Енгалычев 40или 45 ?.
37. Абдул-Кадыр Бисеров – 45 к.
38. Рахим Бурнашев –30 к.

Итого 22 р.

**Путевые издержки до Новой Бухары … 1 р. 05 к.**

**Пересылка почтою ...........................29 к.**

Которые и переданы в администрацию газеты «Танг Юлдузы» для пересылки Гиязу Исхакову. Отчет подписан первыми тремя лицами».

Сложнее определить место проведения этой акции по сбору денежных средств для оказания финансовой помощи писателю. Попытаемся определить или установить место проведения данного мероприятия (При определении, фиксации места сбора средств необходимо указать об упоминании географической точки под названием: «Новая Бухара». Что же кроется под этим названием? Где она находилась? Нет ли связи с Средней Азией ?.

Один из вариантов ответа-это Средняя Азия, т.к. упоминается район Новой Бухары. Местом сбора денег могло быть географическая точка, довольно отдаленная от Казани и губернии в Средней Азии. С другой стороны, нельзя исключить и другое место проведения этой благородной акции солидарности с писателем.

Хотелось обратить внимание читателей на следующие моменты. Внимательный анализ исторического документа в виде списка показывает следующее. Состав жертвователей, поддержавщих писателя и зафиксированных в списке был интернациональным. Абсолютное большинство жертвователей составляют татары и представители тюркских народов. В нем

мы видим не только тюрко-татар, но и представителей других народов. Мы имеем ввиду людей с русскими (славянскими) фамилиями и именами. На наш взгляд, они были представителями русского или других народов.

Некоторые из состава списка не назвали себя и сочли нужным скрыть свои имена и фамилии. (ФИО). Они «скрылись»(«спрятались») за таким словосочетанием как: «Неизвестный». Скорее всего это были сделано ими по соображениям безопасности как своей, так и родных и близких. В качестве таковых составителями списка были зафиксированы три человека. (В эту группу «Неизвестных» вошли три человека). Общая сумма их сбора взноса составила 1 руб. и 70 коп. Скорее всего, мы никогда не узнаем личности этих людей. Перед нами стоит очень проблематичная задача.

Наконец, остальные из этой группы, поддерживающей Г.Исхаки, решили написать только свои инициалы (М.В. и К.Г.).Эти два человека внесли 1 руб 45 коп.

Итак, эти люди симпатизировали Г.Исхаки. Очень возможно,что импонировали политические взгляды литератора.

Анализируемый документ-свидетельство тому,что в те дни до августа 1907 года были люди, которые поддерживали популярного автора не только идейно, но и материально-финансово.

В настоящем документе отчетливо можно увидеть реакцию группы людей, пока неизвестных нам, на преследование Г.Исхаки со стороны властей. Говоря о состоянии (качестве) документа необходимо сказать следующее.Отдельные части списка деформированы. Например, это цифры, которые указывают сумму вклада двух жертвователей.Они не читаются .

По нашему мнению, данный документ несомненно может помочь в дальнейшем исследовании богатой на разного рода события и на частые перемещения биографии и многогранного творчества Г. Исхаки. Определение этих людей важен при решении обозначенной исследовательской задачи: изучение жизни и творчества писателя.

*Басмага Таиров Наил әзерләде*

# ТӘНКЫЙДИ МӘКАЛӘЛӘР

*Гаяз Исхакыйның күптән түгел Г.Ибраһимов исемендәге Тел,әдәбият һәм сәнгать институты әдәбиятчы-текстологлары тарафыннан әзерләнеп, Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан унбиш томлы «Әсәрләр»ендә (соңгы 15 нче томы – 2014 елда чыкты) әдипнең тәнкыйди һәм публицистик мирасын эченә алган мәкалә һәм рецензияләре дә зур урын, төгәлрәк әйтсәк, бу басманың 6,7, 9-13 нче томнарын били. Аның язучы, публицист-журналист, тәнкыйтьче, җәмәгать эшлеклесе сыйфатында ярты гасыр дәвамындагы эшчәнлегенә үз вакытында замандашларының мөнәсәбәтен чагылдырган язмаларга да игътибар ителде, бер кадәресе әлеге басманың 8 һәм 15 томнарында (төзүчеләр Фатыйма Ибраһимова, Рәшит Кадыйров, Гөлчирә Ханнанова) урын алды. Аларны басмага әзерләү барышында мондый язмаларның күплеге һәм төрлелеге мәгълүм булды. Г. Исхакый иҗатын, Тукай әйткәнчә, инәсеннән җебенә кадәр тикшереп чыгу, шәрехләү өчен бик тә әһәмиятле бу басма чыганакларны да өйрәнү зарур. Әмма язучы каләменнән чыккан барлык төр текстларның (роман, хикәя, мәкалә һ.б.ларның) тулы, фәнни библиографиясе төзелмәгән әле. Шул ук сүзне аның иҗаты турындагы әдәбият библиографиясе турында да әйтергә була...*

*Әдипнең быелгы юбилее – 140 еллыгы уңаеннан Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының берничә фәнни хезмәткәре, XX гасыр башы татар вакытлы матбугаты сәхифәләрендә әдип иҗаты турында хуплаулы да, тәнкыйди дә сүз әйтү очраклары белән кызыксынды. Казан китапханәләрендә, музейларында саклана торган татар газета һәм журналларының берничәсен карап чыгу нәтиҗәсендә исхакыйчылык фәненә әле аз билгеле булган язмалар белән танышу мөмкинлеге туды. Бүгенге киң катлау укучылар өчен дә кызыклы булачагын фараз итеп, аларның текстларын берниндидә үзгәрешләр кертмичә бастырып чыгару уе туды. Бу язмалар төрле характерда. Әдип әсәрләре басмаларына аннотация һәм бәяләмәләр рәвешендә язылганнарында бу*

*иҗатка уңай бәя бирелә (мәс., «Теләнчы кызы», «Кыямәт», «Кияү»гә). Ә менә «Ике йөз елдан соң инкыйраз» турысындагы рецензиясендә Насретдин әл-Хуҗаши әсәрдәге кайбер моментларның чагылышы, образлар бирелеше белән килешмәвен әйтә. 1916 елда «Йолдыз» газетасы юбилее уңае белән татар вакытлы матбугатында булып алган бәхәсле чыгышлар (аларның кайберләре генә бу басмага кертелде) кызыксынып укылырдыр. 1914 ел ахырында Гаяз Исхакый Исмәгыйль һәм Зөһрә Гаспринскийларның шәхси тормышына нисбәтле күләмле мәкаләсе (15 томлыкның 6 нчы томында басылды) аларның туганы Ибраһим Акчуринда, М. Акчуринада ризасызлык тудыра һәм матбугатта мәкаләләр басыла. Бу басмада алар да урнаштырылды. Түбәндә укучылар игътибарына тәкъдим ителә торган Г. Исхакый турындагы мәкалә һәм язмалар бүгенге татар язуында беренче мәртәбә әзерләнде.*

## «Теләнче кызы»

Мөхәммәдгаяз Исхакый тарафындан каләмә алынмыш[1] бу әсәрдә рәзаләт вә сәфаләт[2] дөньясы вә бу бәхетсезлекләрнең сәбәпләре беркадәр тасвир иделмешдер. Шөйлә ки, боны укымыш кемсәләр, фәрештәләр дәрәҗәсендә хөрмәтле улан инсанлар бу дәрәҗәдә кабахәт хәлләрдә йөреп дөньяны тәлвис итдекләре[3] ичүн тәхәссыр идәчәклердер[4]. Бәгъзе кемсәләрнең әхлакларыны төзәтер ичүн яхшы әхлак китапларының вә фәсыйх һәм гыйлем илә гамәл улан вәгазьләрнең әсәрләре[5] күп улачагында шөбһә юк. Ләкин күп кемсәләр вардыр ки, анларның холыкларыны игътидалга[6] кайтарыр вә кәндиләрене инсан кылыр ичүн[7] «Теләнче кызы» кеби китапларны моталагә

[1] Каләмә алынмыш – язылган.
[2] Рәзаләт вә сәфаләт – хурлык һәм түбәнлек.
[3] Тәлвис итдекләре – пычратулары.
[4] Тәхәссыр идәчәклердер – кайгырачаклар.
[5] Фәсыйх һәм гыйлем илә гамәл улан вәгазьләрнең әсәрләре – матур эчтәлекле һәм белемле вәгазьләрең йогынтысы.
[6] Игътидалга - уртача фикергә.
[7] Кәндиләрене инсан кылыр ичүн – үзләрен кеше ясар өчен.

кылырга[1] мәҗбүрият вардыр. Мәзкүр[2] рисаләдә улан тасвирлар, ихтимал ки, хыялыйдыр, шөйлә исә дә золым илә җәфага гадәт итмеш, башкаларны тәхкыйрь вә истиһза итмәкене[3], мәгъсум вә мәгъсумәләрнең[4] гыйффәт вә әманәтләре илә сәүдә кылмакыны кәндиләренә бер мәсләк идеп тотмыш инсанлар ичүн, һәрберенең хакыйкать улмакында да истибгад[5] юкдыр. Аллаһы рәхмәт итсен, Мәгарри диюр: «Әра эн-нәслә зәнбән лил-фәтә лә йукалүһ / Фәлә тәнкихәннә әд-дәһра гайра гәкыйм»[6]. Дөньяны вә инсанларны дөрест вә тугъры күрер ичүн Мәгарри күзе кирәк вә «Ә тәҗгәлү фиһә мән йүфсидү фиһә»[7] һәм дә «Вә лә тәкрабү әл-фәвахишә мә заһәра минһә вә мә бәтанә»[8] Кол Шәрифне гүзәл аңлар ичүн «Теләнче кызы» кеби рисаләләрне укырга кирәк, диюр улсак, шаяд, хата улмаз.

«Шура» журналының 1909 елгы 17 нче санында «Тәкъриз» рубрикасында имзасыз басылган. Текст журналдан алынды.

*Текстны Гөлчирә Ханнанова әзерләде*

## Яңа әсәрләр

Бу көнләрдә идарәмезә килмеш әсәрләрдән иң кызыклы вә гыйбрәтлесе «Кыямәт» исемендә ике пәрдәле комедия китабыдыр. Бу китапта, бу көндән 13–14 еллар мөкаддәм[9] Казанда булган бер вакыйганы тасвир кыла. Вакыйганың башы мәшһүр бер байның дворнигы илә күчеры, мөселманча язулы

---

[1] Моталагә кылырга – укырга.

[2] Мәзкүр – югарыда әйтелгән.

[3] Тәхкыйрь вә истиһза итмәкене – хур һәм мыскыл итүне.

[4] Мәгъсум вә мәгъсумәләрнең – гөнаһсызларның.

[5] Истибгад – чит күрү.

[6] «Мин нәселле булуны егет өчен кимчелек итеп күрәм, Һич өйләнмә, фәкать үрчемсез булсаң гына» (гарәп теленнән. А.М. Сәлахов тәрҗемәсе)

[7] «Җир өстендә азгынлык кылачак бәндәңнеме хәлифә итеп куячаксың?» ( «Сыер» сүрәсе, 30 аять, гарәп теленнән А.М. Сәлахов тәрҗемәсе).

[8] «Кеше каршысында да, яшерен рәвештә дә яманлык кылмагыз» («Терлек» сүрәсе, 151 аять, гарәп теленнән А.М. Сәлахов тәрҗемәсе).

[9] Мөкаддәм – элек.

алтын йомырка табып, байга кертүләрендән башлана. Бай бик тиз шәһәр муллаларыннан вә башка кавем-кабиләләрдән дусларын чакырып: «Бу нигә галәмәт булыр?» - диеп фәтва сорый, шул арада шәһәр хатын-кызы да бай өенә тула. Муллалар, сәгатьләрчә моназарә[1] кылышкандан соң: «Кыямәт булырга галәмәт» - дип фәтва виреләр. Ләкин кыямәтнең кай көн булачагы хакында янә зур бәхәс вә моназарә башлана, ниһаять, буны да тәгъйин кылалар[2].

Муллалар байдан, берәр яңа чапан киеп, шәһәр башлыгына барып кыямәт булачагын белдерергә, русларны иманга дәгъват кылырга торганда, байның (Германиядән укып кайткан) матбага мөдире: «Ул тавык йомыркасы да, әтәч (кураз) йомыркасы да түгел, бәлки мин кимия[3] куәте илә ясап язып ташлаган идем» – диеп кереп әйтә дә, муллаларның кәефе таралып таралалар, кыямәт дә булмый кала.

Мөхәррире Мөхәммәдгаяз Исхакый, нашире Хөсәен Әбүзәрев.

Бәһасе почта илә 34 тиен язылган.

«Идел» газетасының 1910 елгы 16 март (№238) санында, «Яңа әсәрләр» рубрикасында имзасыз басылган. Текст басмага газетадан алынды.

*Текстны Гөлчирә Ханнанова әзерләде*

## Ике йөз елдан соң инкыйраз хакында

1904 нче елда басылган бу китабны базарга чыкгач да, бер нөсхәсен алып укыган вә тәнкыйд юллы бер бәнд[4] язган идем. Ул заманда мөнтәшир[5] «Шәркы рус»га, соңра «Нур»га күндерсәм дә, төрле сәбәпләр табылып, бәндемне кире кайтардылар.

---

[1] Моназарә – бәхәсләшү.

[2] Тәгъйин кылалар – билгелиләр.

[3] Кимия – химия.

[4] Бәнд – кушымта.

[5] Мөнтәшир – басылган.

Билахир[1], «Әлгасрелҗәдид» зоһур итде[2]. Аңа йибәрдем. Бәндемнең яртысы мәкъбүл булып[3] дәреҗ ителде[4] исә дә, ошбу яртысы кире кайтарылды.

Үткән гомерләрне, яшьлек заманларны сагынып, бүген иске кәгазьләрне актарганда бу бәнд килеп чыкды. Бу язылганга инде ничә еллар үтде, күп сулар акды, байтак тәҗрибәләр күреп үткәрергә насыйп булды. Шунлыкдан бу бәнддәге[5] бәгъзе нәзарларымның[6] хаталыгы үз гандендә дә сабит булды инде. Шулай булса да, яшьлек һавасы илә язылган бу бәндне шул хаталары илә бергә дәреҗ иделүен үтенәмен.

Мөхәммәдгаяз әфәнденең «Ике йөз елдан соң инкыйраз»ы гүзәл бер әсәр улдыгы илә бәрабәр, занымча[7], косурсыз дәгелдер[8]. Бондый косурлар беренче әсәрләрдә мәгъфу исә дә[9], Гаяз әфәнденең унберенче әсәредер. Косурларның бәгъзесе бонлардыр:

1) Киләчәк, мәфруз[10] нәрсәләрнең «улмыш, үтмеш» кеби язылуларыдыр. Әдәбиятда бондый киләчәк, мәфруз булачак нәрсәләрне рөэя[11], яхуд бер хикәя сурәтендә мәйданга куялар. Гаяз әфәнденең бу әсәренә карагач, татар милләте мөнкариз булган[12], Җәгъфәр, Петербургларга сәяхәт идеп, иң соңгы татар сыйфаты илә вафат булган, Гаяз әфәнде татар булдыгы хәлдә, үзе генә калганда, милләтнең башына килгән бу хәлләрне язып мәйданга чыгарган кеби күренә вә бу латыйфә сүрәтене ала. Әгәр Билләминең[13] «Йөз елдан соң» нам әсәре кеби рөэя, Золяның

---

[1] Билахир – ахырда.
[2] Зоһур итде – мәйданга чыкты.
[3] Мәкъбүл булып – яраклы булып.
[4] Дәреҗ ителде – кертелде.
[5] Дөресе: бәнддәге.
[6] Нәзарларымның – уйларымның.
[7] Занымча – минем уемча.
[8] Косурсыз дәгелдер – кимчелексез түгел.
[9] Мәгъфу исә дә – гафу ителсә дә.
[10] Мәфруз – уйланылган.
[11] Рөэя – төш.
[12] Мөнкариз булган – юкка чыккан.

[13] Билләминең – Эдвард Беллами (1850–1898), америкалы сәясәт эшлеклесе, фантастик романнар авторы.

«Хезмәт» нам әсәре[1] кеби булачак бер хикәя тарызында[2] язылган булса иде, вакыйгъга муафикърак[3] булыр иде.

2) Биш йөз еллар элек оныдылган «Болгар» намыны яңадан галәмгә чыгарырга тырышуыдыр. Башкордларны, мишәрләрне, хәтта Кырым татарларыны «болгар» диеп атыйдыр. «Болгар» шәһәре тәхте пай[4] булып торган бер заманда, берничә меңләрдән гыйбарәт табигысына[5] «болгар» исеме бирелгән булса да, филхакыйкать[6], анларның да татар улдыкларыны (?) хәтеренә дә китермидер. Китап читләрендәге «әл-болгари» сүзе Гаяз әфәнденең зиһендә бик нык урнашкан булырга кирәк.

Башкордларны, мишәрләрне, казанлыларны һәм кырымлыларны шамил булган[7] «татар» сүзе (?) булып торганда, «болгар» сүзен истигъмальгә[8] ихтыяҗ булмаса кирәк, янә башкорд вә мишәрләр һәм кырымлылар һичбер вакыт «болгар» улмадыклары кеби киләчәкдә дә «болгар» исемен тәхәммел итмәзләр[9].

3) Инкыйразга сәбәп вә мөкаддимә[10] ичүн милләтнең иң кечек ноксанларыны[11] вә иң әһәмиятсез косурларыны[12] һич калдырмаенча язуыдыр ки, китап озын булудан сакланыр ичүн җөмләләрне бик кыска итәргә мәҗбүр булган, шунлыкдан җөмләләр бер берсенә рабитасыз[13] калганлар. Бер вакыйганы тәмамән[14] тасвир идеп бетермичә, икенче нәрсәне тасвирга керешкәнгә күрә, язылган хәлләрнең инкыйразга мөкаддимә, яхуд сәбәп булулары ачык сурәтдә аңлашмыйдыр. Гомуменә карамаганда,

---

[1] Золяның «Хезмәт» нам әсәре – француз язучысы, публицист, җәмәгать эшлеклесе Эмиль Золяның (1840–1902) тәмамланмаган әсәре.
[2] Тарызында – рәвешендә.
[3] Вакыйгъга муафикърак – чынга туры килгәнрәк.
[4] Тәхте пай – башкала.
[5] Табигысына – буйсынганнарга.
[6] Филхакыйкать – чынлыкта.
[7] Шамил булган – эченә алган.
[8] Истигъмальга – кулланырга.
[9] Тәхәммел итмәзләр – күтәрә алмаслар.
[10] Мөкаддимә – кереш.
[11] Ноксанларыны – җитешсезлекләрене.
[12] Косурларыны – кимчелекләрен.
[13] Рабитасыз – бәйләнешсез.
[14] Тәмаман – тулысы белән.

инкыйразны мөнтиҗ[1] бер мөкаддимә бөйлә юкдыр. Бинаән галәйһи[2], күп кеше агызындан «мантыйксыз вә рабитасыз язылган» диеп ишедергә тугъры киләдер.

4) Гаяз әфәнде милләтне хәзерге кеби надан, әхвале галәмендән бихәбәр[3] идеп алып бармыйдыр: бәлки бер вакыт милләтемездә моктәдир[4] әдәбиятларның булуыны, бик маһиранә сурәтдә[5] язылмыш романлар, хикәяләр, һәртөрле фәнни, әдәби, тарихи китапларның мәйданга чыгуыны, драма, трагедия, комедия вә опера китапларының бик күп булуларыны, милли театр вә ширкәтләренең вөҗүдене[6], фәкать Казанда гына «Кабан», «Игенче», «Һөнәр», «Болгар», «Дин вә мулла» исемле газеталарның нәшер иделүене, Иделдә татар пароход ширкәтләренең күп вә файдалы булуыны, мәктәп вә мәдрәсәләрнең лаекы илә[7] ислях кылынуыны[8], хакыйкате мәгълүм булмаган вә һичбер идея тәэсир итмәгән сираятле[9] авыруның хакыйкате татар докторлары тарафындан кәшеф иделеп[10], мөгаләҗә[11] тарикы да табылуыны фараз итәдер.

Әгәр Гаяз әфәнде фараз иткән дәрәҗәләргә ирешер исәк, белмим, нинди сәбәбдән мөнкариз булачакымыз? Әүвәл мәртәбәләргә[12] ирешкәндән соң мөнкариз булып бетсәк дә, наданлыкдан түгел, бәлки бу көнге франсуз[13] инкыйразының гайне[14] булачакдыр.

5) Милләтне Фәрәнкнең[15] мәразларына[16] вә башка әмразы

---

[1] Мөнтиҗ – нәтиҗәле.
[2] Бинаән галәйһи – шуңа күрә.
[3] Бихәбәр – хәбәрсез.
[4] Моктәдир – көчле.
[5] Маһиранә сурәтдә – осталык белән.
[6] Вөҗүдене – барлыкка килүен.
[7] Лаекы илә – лаеклыча.
[8] Ислях кылынуны – үзгәртүне.
[9] Сираятле – йогышлы.
[10] Кәшеф иделеп – мәйданга чыгарып.
[11] Мөгаләҗә – дәвалау.
[12] Мәртәбәләргә – югары дәрәҗәләргә.
[13] Дөресе: француз.
[14] Гайне – үзе.
[15] Фәрәнкнең – Аурупаның.
[16] Мәразларына – авыруларына.

сарияләргә[1] мөбтәля идеп[2] инкыйраз итдерүедер. Тарих аларның ифадәсенә бакылыр исә[3], бу көнгә кадәр дөньядан бик күп милләтләр мөнкариз булганлар. Ләкин инкыйразның сәбәбләре һичбер вакыт Фәрәнк вә башка әмразы сарияләр булмаган финикәлеләр[4], асурилар[5], кәлданилар, Американың йирле халкы мәзкүр[6] мәразлар[7] сәбәбендәнме мөнкариз булдылар?

Занымча[8], бер милләт француз авыруларына мөбтәля булмазса да, надан, мәдәниятсез уларак, мәдәниятле әкъвам[9] арасында яшәве мөмкин түгелдер. Мәдәниятле кавемләр, никадәр тәгали итсәләр[10], мәдәниятсез милләтләр шул дәрәҗә изелеп, әмразы сариядән башка ук, үз алдына мөнкариз булулары табигыйдыр. Затән[11] тарихның ифадәсе[12] вә инкыйраз ичүн күрсәткән сәбәпләре һаман бер: мәдәниятсез милләтнең башка мәдәниятле милләтнең нөфүзе[13] астында калып тапталуыдыр; Фәрәнк мәразы фәлән түгелдер. Бик яхшы, безем милләтнең инкыйразы башкаларның инкыйразына охшамасын, Фәрәнк мәразларына мөбтәля булуыда тасвир улынсын! Ләкин Фәрәнк мәразларының идеяләре вә тарикы мәгаләҗәләре[14] мәйданда улдыгы кеби, мәгълүм түгел мәразның хакыйкате дә татар докторлары тарафындан кәшеф иделүе[15] фараз кылыныр. Ул тәкъдирдә тыйбби комиссияләрнең, хосусый мәэмүрләрнең[16] тәдависе[17] нидән татарларга тәэсир итмиячәк? Юкса, башкаларга

[1] Әмразы сарияләргә – йогышлы авыруларга.
[2] Мөбтәля идеп – дучар итеп.
[3] Ифадәсенә бакылыр исә – аңлатуына күз салсаң.
[4] Финикәлеләр – финикиялеләр.
[5] Асурилар – ассирияләр.
[6] Мәзкүр – алда атап кителгән.
[7] Мәразлар – авырулар.
[8] Занымча – минем уемча.
[9] Әкъвам – кавемләр.
[10] Тәгали итсәләр – бөекләсәләр.
[11] Затән – нигездә.
[12] Ифадәсе – аңлатмасы.
[13] Нөфүзе – авторитеты.
[14] Тарикы мәгаләҗәләре – дәвалау юллары.
[15] Кәшеф иделүе – ачыкланып мәйданга чыгарылуы.
[16] Хосусый мәэмүрләрнең – махсус кешеләрнең.
[17] Тәдависе – авыруны дәвалаулары.

нисбәтән татарларның хилкатьләрендә[1] бер нәүгъ[2] башкалыкмы бар!? Дөрест, милләтемез бу көнге хәлендә калыр исә, бер көн мөнкариз булып бетәчәк, ләкин Фәрәнк мәразларына мөбтәля булып түгел. Бинаән галәйһи[3] Фәрәнк мәразларыны милләтемезнең инкыйразына сәбәб идеп күрсәтү урынсыз вә тарихларда һичбер мисалы күрелмәгән бер хыялдыр.

6) Хәддендән зиядә[4] мусыйкага әһәмият бирелүедер. Мусыйканың тәэсире бар, аны инкарь кылып булмый; фәкать аның вөҗүде[5] – милләтнең бәкасына[6], юклыгы – милләтнең инкыйразына сәбәп булу кадәр әһәмиятне хаиз түгелдер[7]. Минемчә, ярты китапны мусыйка илә тулдырмак, бөтен нотыкларны аңа хаср итмәк[8] урынсыздыр. Хыялый бер иддигаэ булуы[9] өстенә, нәтиҗәсез бер мөкаддимәдер.

7) Китаб каһарманларының әфгаль[10] вә хәрәкәтенә вә ул хәрәкәтләрне заман мөсагыйд булып[11], булмавына һичбер дикъкать вә игътибар ителмәведер. Мәсәлән, Җәгъфәр Казандан Оренбургга вә Петербургга бер көндә барып йитә, Җәгъфәр йөз яшендә икән, һаман кара сакаллы улдыгы кеби, Сөембикә ханым да 80-90 да вәзыйге хәмәл итә[12]!

Шөйлә ки, 21 нче гасырның 50 нче елларында Җәгъфәр бик маһир бер мөхәррир була, 2100 сәнәсе Петербургга барып, бөтен галәмне хәйран калдырырлык нотыклар сөйли. Җәгъфәр тәхриргә башлаганда[13], иң азында, 20-25 дә булырга кирәк була. Шул хәлдә Җәгъфәр 75ләрдән үтеп, беренче хатыны Сөембикә вәзыйге хәмәл заманы якынлашканга, Петербургга бары-

[1] Хилкатьләрендә – табигатьләрендә, буй сынларында.
[2] Нәүгъ – төр.
[3] Бинаән галәйһи – шуңа күрә.
[4] Хәдендән зиядә – чиктән тыш.
[5] Вөҗүде – барлыгы.
[6] Бәкасына – мәңгелегенә.
[7] Хаиз түгелдер – эченә алмый.
[8] Хаср итмәк - монда: чикләр билгеләү.
[9] Иддигаэ булуы – дәгъва итү.
[10] Шфгаль – эшләре, фигыльләре.
[11] Мөсагыйд булып – ярдәм итеп.
[12] Вәзыйге хәмәл итә – бала таба.
[13] Тәхриргә башлаганда – яза башлаганда.

рга муаффәкъ булмый[1] кала. Фараз итик, хатын ирендән ун яшь кечек булсын, ул тәкъдирдә дә Сөембикә 65 яшендә бала тугъдырадыр.

Җәгъфәрнең Петербургда булуын язган вакытда «хатынларга Җәгъфәрнең кара күзләре, кара чәчләре, түгәрәк сакалы гаҗәип сәбгы галәмдән[2] күренә иде. Аның төсе бик бик матур, бөтен кешене гаҗәбгә калдырырлык Йосыф (г.м.) кебек беленә иде» сүзендән, ул вакытда Җәгъфәр гүзәл бер егет булуы аңлашыладыр, 65 яшьле кара чәчле, гүзәл егет!

Дөрест, хикәядән максад анларның йөз яшәве, яхуд йөз яшендә угълан тугыруы түгел, фәкать бондый китап каһарманларының үзләре, хәрәкәтләре, вакыйгъга, гадәткә мотабикъ булулары[3] әдәбиятның беренче шартларындан саналадыр.

Гаяз әфәнденең әнзаре гаммәгә[4] куйган бу «инкыйраз» мәсьәләсе – әһәмиятле вә бик олугъ бер мәсьәләдер. Бөтен галәме исламиятьне әндишәгә[5] төшергән бу мәсьәлә хакында башка галәмләрдә җилдләр илә китаблар язмышлардыр. Гаяз әфәнде дә бу инкыйраз хакында тарихларга, фәнләргә мөрәҗәгать итмәенчә, фәкать үз башыннан, үз гакылыннан бик күп әфкяр сөйли вә бик күп нәрсәләрне тәхкыйк итмәк[6] була. Ләкин шунысы шаян тәәссефдер[7] ки, «әфкяре» итәчәк тәхкыйкате[8] һаман «зол[9]» булып бер золмәтдә[10] кала.

Тәкрар итәм[11], «Ике йөз елдан соң инкыйраз», мале гомумиясе[12] вә милләтнең бөтен косурларыны[13] күрсәтүе җәһәтендән гүзәл бер әсәрдер. Милләткә мәхәббәт идеп аһ вә фәган[14] иткән

[1] Барырга муаффәкъ булмый – бара алмый.
[2] Сәбгы галәмдән – җиде галәмдән.
[3] Мотабикъ булулары – туры килүләре.
[4] Әнзаре гаммәгә – җәмәгатчелек игътибарына.
[5] Әндишәгә – борчуга.
[6] Тәхкыйк итмәк – хакыйкатькә чыгармакчы.
[7] Тәәссефдер - үкенү
[8] Тәхкыйкате – хакыйкатьләрне эзләве.
[9] Зол – шәүлә.
[10] Золмәтдә – караңгылыкта.
[11] Тәкара итәм – кабатлыйм.
[12] Мале гомумиясе – гомуми байлыгы.
[13] Косурларыны – кимчелекләрен.
[14] Аһ вә фәган – аһ һәм елау.

җөмлә әрбабы хәмият[1] бирер нөсхәсене алдырып, әфкяре илә танышулары ляземдер.

Бу гүзәл әсәр, табигый, бер басылып калмый, бәлки әллә ничә мәртәбәләр басылачак булганга, икенче мәртәбәдә тәкмил идебрәк[2], җөмләләрнең рабитсызлыгын[3] бетеребрәк басылуын үтенер идем.

Иштә мин мәзкүр китабда бу кадәр аңладым, ихтимал ки, минем нәзар[4] вә тәнкыйдләремнең үзләре дә хата булырлар, дөрестлекне дәгъва итмим. Фәкать аңлавым бу кадәр.

*Ноябрь 15, 1904 сәнә.*
*Насреддин Әл-Хуҗаши*

Мәкалә «Шура» журналының 1911 елгы 18 нче санында «Тәкъриз вә интикад» рубрикасында басыла. Текст басмага журналдан алынды.

*Текстны Гөлчирә Ханнанова әзерләде*

## Кияү (хикәя)
## Г. Исхаков әсәре. «Гасыр» нәшере

«Кияү» хикәясе бер авыл баеның бер өйләнгән углы һәм дә йиткән кызы улдыкыны вә шушы кызыны күрше авылда яңа гына имтихан кылыныб мөэзин булган бер шәкердкә бирүене вә шушы шәкердне ашата-ашата, аны йортлы-йирле ясый-ясый, бер-ике йыл эчендә тәмам ярлылануыны, ниһаять, бу хәлгә түзә алмыйча, углы Галәүнең хатыны илә җыеныб, йортны ташлаб чыгыб китүе, вә ул чыгыб киткәндә генә соңгы елларда мөэзин кияүгә бал-май акмый башлагач, «инде син кирәкмисен» дийә аерылыб йибәрелгән кызы балалары илә төялеб кайтыб кердекне тасвир илә тәмам уладыр.

Хикәядә күрсәтелгән шәхесләр, һәр каюсы татар тормышында адым саен очрала торган чын типлар булыб, бик матур тасвир ителмәгәнләр. Хакыйкатән, мәзлум[5], каенана-

[1] Әрбабе хәмият – яклаучылар.
[2] Тәкмил идебрәк – тулыландырыбрак.
[3] Рабитсызлыгын – бәйләнешсезлеген.
[4] Нәзар – фикер.
[5] Мәзлум – рәнҗетелгән.

ның эче пошкан саен аны орышыб, талаб, үзенә бер тынычлык хасил итә торган хайван итдереб кенә карый торган килен тибы бу «Кияү» хикәясендә аерымачык күрсәтелгән. Бичара килен иртәдән кичкә кадәр чаба, һаман эшли, туйганчы йокламый, вазыйфасындан тыш хезмәтләрне үти, шулай да иртәге чәйне өйләдән соң гына эчә, ашны бөтенләй дә ашамый кала, боның өстенә каенанасы «син мужик – затсыз» диеп сүгә, мөэзин кияүгә, ата-анасына ачу итеб, ире тотыб кыйныйдыр. Менә бу чын татар килене инде.

Әсәрдә өч, бетмәс-төкәнмәс, көчнең (бай, углы, килене) көне-төне эшләгәнне бер сорыкорт – мулла кияүнең бетерә баруы, ничә еллар, әллә никадәр көч сарыф ителеб җыелган йортны туздыруы тасвир ителеб, гаилә эчендә бер эшсезнең генә дә күбме зарар итдеке бик ачык күрсәтелгән. Ә җәмгыять-общество эчендә ул эшсезләрнең зарары күбме дә шушы эшсезләр бездә күбме? Менә болар бит - безнең чын больное место[1] - авыру урынымыз.

«Кияү», хакыйкатән, тормышдан алыныб, поэтический итеб язылган, геройларның психологияләре һәр кайусы ачык итдереб күрсәтелгән. Хасыйл, «Кияү»не укыганда татар тормышын көзгедән караган яки оста бер рәссам тарафындан тәрсим ителгән[2] картинага караган кебек күрәсең, рәхәтләнеб укыйсың. Шагыйрьнең янә татар тормышының шушындый авыру йирләрне тасвир итүен көтеб, икенче тизрәк күрергә ашкыныб каласың. Насыйб булсын да, Гаяз әфәнденең тагын шундый матур әсәрләрен күрү мөяссәр улсын[3].

Мәкалә «Сибирия» газетасының 1912 елның 22 июлендә (№22) басылып чыккан. Текст басмага газетадан алынды. Гамәлдәге татар язуында беренче мәртәбә дөнья күрә.

*Текстны Гөлнара Зәйниева әзерләде*

[1] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[2] Тәрсим ителгән – ясалган.
[3] Мөяссәр улсын – насыйп булсын.

## Мәҗбүри изах

Петербургда чыга торган «Ил» газетасының 8 нче номерында «Гаяз» имзасы илә «Мөселман фракциясе» гонванында[1] бер мәкалә чыкды.

Мәкаләнең башы – минем хакымдадыр. Бонда минем мөселман фракциясенең фатиры хакында бәгъзе газеталарда басылган игъланым хакында матур буяулар илә һәҗүвирәк итеп[2] язылган.

Мин беллетристика, көлке вә нөктәданлыкыны тәкъдир итү[3] илә бәрабәр, җәмәгать эшенә, яки берәр кешенең җәмәгать эшенә мөтәгалликъ[4] эше хакында язган мәкаләдә, иң әүвәл хаклык булырга кирәк дип, уйлыйм.

Ләкин тәәссефемә каршы[5], мин өйлә[6] хаклыкны «Мөселман фракциясе» мәкаләсендә күрмәдем. Шуның өчен үз хатымда булган бу хаклыкны изах кылырга[7] мәҗбүр булдым.

1) Минем фракциянең фатиры хакындагы игъланым – Гаяз әфәнде әйткәнчә, мөселман фракциясе тарафыннан түгел, бәлки үзлегемдән генә эшләгән эш. Шуның өчен мин, мөселман фракциясе әгъзасы дип, имза кылмыйча, «Дәүләт думасы әгъзасы» дип имза кылдым.

2) Гаяз әфәнденең көлеп язуына сәбәп булган ул игълан һичбер гарыз[8] илә булмыйча, бәлки бер файда өмид итеп язылганлыкдан, Гаяз әфәнденең аны юллап кына алуы килешә торган эш түгел.

3) Гаяз әфәнде уйлаганча, мин дә, фракция әгъзалары да, сайлаучыларга хисап бирәмез дип уйлаганымыз юк. Шуны да ихтар итеп[9] китәргә кирәк ки, мин бу ел Уфада 9 нчы октябрьдә үземнең сайлаучыларыма гомуми бер хисап бирдем вә ул хисап

---

[1] Гованында – исемендә.
[2] Һәҗүвирәк итеп – мыскыллап.
[3] Нөктәданлыкны тәкъдир итү.
[4] Мөтәгалликъ – караган.
[5] Тәәссефемә каршы – үкенечкә каршы.
[6] Өйлә – монда: ул.
[7] Изах кылырга – аңлатырга.
[8] Гарыз – тәкъдим итү.
[9] Ихтар итеб – искәртеп.

вакытында мөселман гәзитәләренең күбесендә чыкды да.

4) «Мәҗбүри изах»ымның ахырында «Ил» газетасының мөхтәрәм мөхәррир вә нашире Гаяз әфәнде Исхаков җәнабләренә гаҗәбсенгәнлегемне әйтми китә алмыйм.

Гаяз әфәнде Исхаков, мәгълүм бер беллетрист булу илә бәрабәр, бервакытлар сәяси эшче дә иде бит. Бер халык, йә бер милләт тормышында шундый вакытлар була ки, андан көлү килешеб бетмидер. Һәм шундый вакыйгалар була ки, аның хакында нөктәданлык кылу гөнаһ буладыр.

Элекдә сәяси эшче булган Гаяз әфәнде Исхаковка болар бик яхшы мәгълүм булса кирәк. Ул, әлбәттә, боларның һәммәсен бик яхшы белә.

Шулай улгач, ул ни өчен «Мөселман фракциясе» мәкаләсен язган Гаяз әфәндегә шуны аңлатмаган икән? ...

*Дәүләт Думасы әгъзаларындан:*
*Ибнеәмин Әхтәмов Петербург.*

Мәкалә «Йолдыз» газетасының 1913 елгы 24 декабрь (№ 1088) санында басылган. Текст басмага газетадан алынды.

*Текстны Гөлчирә Ханнанова әзерләде*

## Гаяз Исхакыйның «Җавапларына» каршы... (Идарәгә мәктүб, гайнән[1])

Үткән елның 1660 нчы санлы «Вакыт» та Гаяз Исхакыйның Гаспринскийлар тугрысында «Ил»дә язган мәкаләләрендә бәгъзе яңлышлыклар барлыкыны күрсәтеп язган идем. Ул берничә юлны язарга ирексезләгән нәрсәне әйтү белән Гаяз Исхакый белә торып ялган язды дип һич әйтмәгән идем, минем язганыма ике айга якын эндәшми торып, «Ил»нең 74 нче номерында, «Минем җавабларым» дигән мәкаләсендә мине тугрыдан-тугры ялган сөйли дип әйтүдән ул галиҗәнаб тыгызланмаган, тартынмаган...

Ул сүзләренә җавабка керешүдән элгәре, мөхтәрәмә

[1] Гайнән – үзгәртмичә.

Мәхбүбҗамал ханым Акчурина җәнабләрене үзләренә ашнә булган матбугат мәйданына бу юлы да, борынгылары кеби, күркәм төстә чыгулары берлә тәбрик кылып, мәрхүмә карендәш Зөһрә һәм барча катын-кызымызның гыйффәтенең самими булуларына тәшәккер кылуны[1] үтәве күңелле бурычымнан саныйм. Гаяз Исхакыйның язуларыны күтәрә алмаган вөҗдан минем ялгызымда гына түгел икәнлеккә гаять куандым һәм аның язуларыны укучылар тәкъдир кылырлар, тиешле бәһасене бирерләр, диюемдә исабәт иткән икәнмен[2].

Дәхи[3] үткән язуымдагы кеби, бу юлы да минем атым берлә баглы булмаган вакыйгалар тугрысында агыз ачмавымнан Гаяз Исхакыйның язулары бары да раст дигән мәгънә чыкмавыдыр. Үзем шаһид, танык булмаган вакыйгаларның, нә бәянына, нә мөхакәмәсенә[4] керешергә хакым юк дип беләм. Шуның өстенә, «Ил»нең 5 фельетонындан укучылар ни гыйбрәт алалар? Исмәгыйль бәкнең олуглыгыны, Зөһрә ханымның татар катын-кыз галәменә бер уртак булырлыгыны, Гаяз Исхакыйның бәяны өслүбе[5] сәбәпле, Ибраһим Акчурин берлә Әсфәндияр Акчуринның ямьсез мөгамәләләре, котсызлыклары бөтенләй капламыймы? «Исмәгыйль бәк вә Зөһрә ханым Гаспринскийлар» гонваны урынына, бу ике җаныйның кабахәтләре диеп атау йирлерәк булмас идеме?

Бу сораганнарымны агырлы укучыларга тәкъдим кылып, битараф җавапларына бу көннән ук разыймын.

Ул бөек, бинәзыйр[6] тиңсез мөхәррир Гаяз Ихакый әйтүенә күрә, тәнкыйтьләргә җавап язу гадәт галиләре булмадыкыннан, минем язуымы җавапсыз калдырмакчы икән. Минем бәхетемә каршы, «Сөембикә»дә Мәхбүбҗамал ханымның мәкаләсе чыккан. Табигый, андагы олуг адәмнәргә календарьлардан алып, русчадан тәрҗемә кылган иске мәкаләләргә җавап язып

[1] Тәшәккер кылуны— рәхмәт белдерүне.
[2] Исабәт иткән икәнмен – дөреслеккә ирешкәнмен.
[3] Дәхи — тагын да.
[4] Мөхакәмәсенә — хөкеменә.
[5] Өслүбе — ысулы, рәвеше.
[6] Бинәзыйр – ишсез.

ваксыну кыйммәтле вакытларыны зыяг кылу[1] буладыр. Бу бер монафикъ галәйһи нәрсәдер. Мәгәр нишләмәк кирәк? Үзеңдә Гаяз Исхакыйдагы кеби илһами гыйлем вә мәгълүмат булмагач, әл-хикмәтел-заләтел-мөэмин диеп[2], иске календарь артларымы, «Фәзаилеш шөһүр»ме, яхуд Гаяз Исхакыйның әсәрләре эчендә сачылган тирән фикерләр, энҗеләреме... Кыскасы, кайдан булса да, үзеңә яраклы нәрсәне ирексез аласың. Минем кайдан алып язуны белү дә үткәнлеке, нә фирасәтенә тәхсин кылмай[3] чарам юк. Бер адәмне мөлзәм кылаем[4] дисә, әдәбият галәменнән ерак торгучы таифәләрнең теле берлә сөйләмәсә дә көчендән килә икән...

Бу олуг әфәнденең минем Гаспринскийның өйләнүенә кире булганлыгым дәлилләре мантыйки дию исәк, бераз аксакрак мантыйк икәнене әйтеп узмай хәл юк. Ул каршылыгым Гаяз Исхакыйга (илһами сурәттә булса кирәк) элгәредән мәгълүм икән; бәс, мин әйтсәм дә, дөрест булмай. Бу көндә инде мәшһүр «Коромысловкага барма да, йөрмә дә, тапмассың да, булмас да» дигән сүзләр мин әйткән булмай чара юк. Гаяз Исхакый хәтта ант итәргә хәзер. Шуның өстенә, Гаспринскийларның никахы язылган метрика дәфтәрендә минем атым, кулым юк... Бумы дәлил түгел?

Бер нәрсәне бер үк игътибарга алырга кирәк дию саныйм: 81 нче елда, мин 21–22 яшьлек «вак-төяк, чүп-чар фабрикант малайларының» җөмләсеннән булып, Исмәгыйль бәкнең олуг адәм булачакыны аңламасам да, ихтимал, һәм дә һәр адәм Гаяз Исхакый кеби тугмышдан ук олуг булмай. 81 нче елда шул канун табигый Исмәгыйль бәк хакында ярый булган булу ихтимал түгелме? Фәкать бу сүзләремнән Гаяз Исхакый баштан әйткәннәремнән кайттым диеп куанмасын. Бу юлы да шуны ук әйтәм: Исмәгыйль бәкнең чын тәрҗемәи хәлене язгучылар, аның хәятендәге бу ноктага әһәмият биреп, мәйданны биләгәнемне сорай булсалар, бәян кылудан баш тартмыйм, ләкин бундай вак нәрсәләргә әһәмият бирүне шөбһәдә тотам.

[1] Зыяг кылу – әрәм итү.
[2] Әл-хикмәтел-заләтел-мөэмин – туры юлдан чыккан мөэмин хикмәте.
[3] Фирасәтенә тәхсин кылмай – сизгерлеген мактамый.
[4] Мөлзәм кылаем – бәхәсләшеп җиңәм.

Гаяз Исхакый үзенең хөрмәте берлә, безнең кеби гөнаһлы, олуг адәмнәрне рәнҗеткән кешеләрне үзе аяган булса да, киләчәктә безне чын төсемездә күрсәтергә һәвәсле кешеләргә, кайда мөрәҗәгать кылырга юл күрсәтә. Әмма олуг адәмнәр аларны кыйнар өчен фабрика собственниклары бирдерү берләме, Архангельләргә сөргенгә йибәрелү берләме олуг булалар? Юкса эшләгән эшләре берләме олуглык атыны кәсеп кылган булалар? Бозлы диңгез янында моржлар берлә күршелектә тору берлә, яхуд ат кыены күрү берлә дә олуг булдым дию тәфахир кылмасын[1].

Гаяз Исхакый җәнабләре миңа сабак бирү берлә бушка вакытыны заегъ итәдер[2]. Кадеремне белү, белмәү мәсьәләсене хөкем кылу үз ихтыярымда калып торса да яраячак. Бу мәсьәләдә хаким булу аның вазыйфасы түгел диеп саныйм. Гафу итә күрсен. Дәхи дә күңелендә шик, шөбһә калмасын. Мәкәрҗәдә Исмәгыйль бәкнең Зөһрәне сорау фикерене миңа сөйләмәкене Нижний ягында түгел, Ярминкә ягында, флаг төшмәсеннән борын вакыйг булды. Хата иттем диеп пошынмасын. Минем «Мәкәрҗәдән борынмы, соңмы» сүземне тәфсирләү тиеш булса, күңеленә авыр алмасын, кайвакытта ул эш вакыйгъ булуны Гаяз Исхакыйга әйтергә хаҗәт күрмим дигән мәгънәдә иде. Аның «тавып» дигән сүзенә сөаль галәмәте куюның сәбәбе үзенә аерым ачык булмаса әйтәем: яхшы гына тел булырга кабилиятьле[3] телемезгә шундый «тавып» ка, яхуд соңгы мәкаләсендәге «мингә» ләргә охшашлы сүзләр кертә башлагач, сөаль галәмәте кую гына түгел, булса «Каравыл!» кычкыру галәмәте куяр идем. Әйткәнечә, «тавып» сүзенә зур сөаль галәмәте куелган булса, матбагада хәреф төзүче чыдый алмаенча инде зурракны үзеннән куйган булырга кирәк. Һәм хакы да бар. Мөхәррирләремез никадәр олуг булсалар да, телемезне бозарга хаклары юк. Алардан көткәнемез бозу түгел, төзәтү. «Тавып»лар, «минга»лар берлә тулдырып, ике янәшә авылда аңланмасдай телгә әйләндерүләренең хәвефе бик зур.

[1] Тәфахир кылмасын – мактанмасын.
[2] Заегъ итәдер – әрәм итәдер.
[3] Кабилиятьле – сәләтле.

Гаяз Исхакый җәнабләренең миңа һөҗүм кылулары, мине бу бәлагә грифтар итүгә[1] бәрабәр диеп уйлаулары, бераз мөбаләга[2] булса да, ул бәладән йолыту өчен зур нәрсә хаҗәт түгел икәнене үзләре үк күрсәтteләр. Календарь артындагы иске рус мәкаләләре[3*]... Бер үк бу серләрене әйтелүе берлә үзләренең мохалифләренә[4] дә бу зур коралны бирүләренең гакыйбәтене[5] уйладылармы икән? Ашыгычлык кылынмадымы икән? Рус календарьларыннан башка татар календарьлары да күп: «Кәримовлар», «Мәгариф»ләр һәм башка башкалар бар. Моннан магада[6] Гаяз Исхакый җәнабләренә бәлки мәгълүмдер, минем башка ят телләр берлә дә азмы-күпме ашналыкым[7] бар (моны мактаныр өчен түгел, ул мөхтәрәм затны кызганып әйтәм), үзенә агырлык килмәсен. Соңгы көндә үкенү файда бирмеш. Бөтен Яурупа, Азия календарьлары уен эш түгел... Үткән фельетоннарында «якыннан күргән» кешедән мәгълүмат алдым диеп әйткән иде, бу «Җавапларында» ике мөхтәрәмә ханымнарның исемнәрене зикер кылды[8] һәм анларның морадлары нидән гыйбарәт икәнене белү миңа бер куаныч хасыйл кылдырды. Бу ике мөхтәрәмә карендәшләремнең изге теләүләре, бөек арзулары[9] карендәшләре мәрхүмә Зөһрә ханымның да хезмәтләрене күрсәтү тиешлек тойгылары һәркем кашында заһир булды. Әмма ул мактауга мөстәхикъ[10] теләкләре, яңлыш адрес берлә юллану сәбәпле, нә рәвештә йиренә килтерелүне күрәмез. Әһли түгел кулларга ушлану берлә барча катын-кызымызның гыйззәтенә, гыйффәтенә напак[11] әлләр[12]

---

[1] Грифтар итүгә – дучар итүгә.

[2] Мөбаләга- арттыру.

[3] Мәхбүбҗамал ханымга җавабындагы аршин мәсьәләсенәдә шуннан җавап алынадыр... (И.Акчурин искәрмәсе)

[4] Мохалифләренә – каршы килүләренә.

[5] Гакыйбәтене – нәтиҗәсен.

[6] Магада – гайре.

[7] Ашналыкым – танышлыгым.

[8] Зикер кылды – искә алды.

[9] Арзулары – омтылышлары.

[10] Мөстәхикъ – лаеклы.

[11] Напак – шакшы.

[12] Әлләр – куллар.

сузылды... Мәхбүбҗамал ханымның пакь вөҗданы күтәрә алмаган кеби, барчамызның йөрәкләре яраланды.

Мөхтәрәмә Фатыйма һәм Зөһрә ханымнар үзләренең исабәт итүләрене[1] сүи истигъмаль кылынганлыкны[2] ашкярә[3] күреп безнең өслүбемезгә[4] кушылуларында шөбһәм юк. «Сүз сүзне чыгара, сүз күзне чыгара» (бу мәкаль русчадан моктәбәс[5] диеп булмай) раст икән, (хәзерге сүз тугърысында булса да, күзләремезгә эш йитешмәс диеп ышанам). Шуның буенча сүзне инде бетерү өчен Гаяз Исхаков җәнабләренең аның сүзләренә хәтерем калган диеп, хата икәненене генә әйтәм. Әстәгъфируллаһ! Мин монда читтә торам. Кемнең хәтере калырга хакы бар исә, ул да хакыйкать вә хакъканиятьдыр[6]. Бәһаләрене белгән кешеләр кашында шунлар мәзлум[7] һәр золым кылучы Гаяз Исхакый галиҗәнабләредер.

Мөхтәрәмә Мәхбүбҗамал ханым Акчурина үз ягыннан җавап бирергә тәнәззел кылса[8], алыннан ук җаваплары берлә тәбрик кылам.

Миңа тагы да язарга кирәк булса, әле иске календарь артлары аксылмаган, бетмәгән, төгәнмәгән...

*Ибраһим Акчурин*

*Петроград. 23 февраль, 1915.*

«Вакыт» газетасының 1915 елгы 3 март (1716) санында «Ибраһим Акчурин» имзасы белән басылган. Гарәп графикасында. Гамәлдәге татар язуында беренче мәртәбә дөнья күрә.

*Текстны Эльмера Галимҗанова әзерләде*

---

1 Исабәт итүләрене- дөреслеккә ирешүләрен.
2 Сүи истигъмаль кылынганлыкны – урынсыз куллану.
3 Ашкярә – ачык.
4 Өслүбемезгә – рәвешебезгә, ысулыбызга.
5 Моктәбәс – алынган.
6 Хакъканиятьдыр – турылыктыр.
7 Мәзлум – рәнҗетелгән.
8 Тәнәззел кылса – түбәнчелек итсә.

## Мөхәммәдгаяз әфәнденең җавабларына җаваб

Мөхтәрәм Мөхәммәдгаяз әфәнде «Ил»нең 42 санында Зөһрә ханым җәнабләрене мактавында кызыб, мәдехе киресенчә чыккан төсле. 74 сандагы җавабларында да кызганлыгы, хәтта тәһәүверләнүе[1] күренә.

Могътәбәр «Вакыт» гәзитәсендә Ибраһим әфәнде Акчурин җәнабләре тарафындан язылган «Ачык хат» аның әйтмәгән сүзләрене әйтде диб язылганга каршы язылган иде. «Сөембикә» журналының 7 нче санында басылган минем мәкаләм кырык икенче санга иде. Ибраһим әфәнде Акчурин ул сүзләрне әйткәнме, әйтмәгәнме? Аның минем өчен асыл кирәге юк. Ибраһим әфәнде Акчурин җәнабләрене ишеткәнем булса да, танышлыгым юк. Вәхаләнки[2], Гаяз әфәнде бу фельетонында фикерләре һәм сүзләре тәмам башка булган ике кешегә бердән һөҗүм итә. Тәфсыйлән, язарга теләүчеләр булса, «тешсез Гайнүш абызтайны онытмауларын тәүсыя итәм[3]», ди.

Мин бит мәкаләмдә «тәрҗемәи хәл язмакчы булам, кемләрдән сорашыйм икән?» диб үтенмәдем. Гаяз әфәнденең кемләрдән сорашыб язган идекендә эшем булмаган кеби, аның «фактлар»ы, «справка»лары илә дә эшем юк. Язган тәкъдирдә «тешсез Гайнүш абызтай»га хаҗәтем төшмәз. Гаяз әфәнде мәдрәсә почмагында зарабә, йәзрибү, фәрра, йәфиррү[4] диб, иләкдән чиләккә бушатыб утырган вакытда йийган мәгълүматым да йидәчәк.

Минем мәкаләм пароходда барганда бер көн эчендә анасы-апасы алдында биш-алты русларның чүгүе хакында иде. «Мөхәррир әфәнде иң элек үзенең тәрбияле гаиләдән улган гакыллы ханымлар-туташлар илә таныш түгел идекене әйтүб бирә» дигән сүзләремә каршы, Петроград, Мәскәү, Казандагы йөзгә якын курсистка, берничә йөз мөгаллимә, берничә мең татар ханымлары илә таныш улдыгыны санаб чыга. Минем кай сүземдәндер мөхтәрәмә ханым вә туташларга «сез гыйффәтсез»

[1] Тәһәүверләнүе – кызуы, дуамаллануы.
[2] Вәхаләнки – чынлыкта.
[3] Тәүсыя итәм – киңәш итәм.
[4] Зарабә, йәзрибү, фәрра, йәфиррү – сукты, суга; качты, кача.

дигән мәгънәне чыгаруб һөҗүм итә. Түгел, тәрбияле туташ вә ханымларгә, бер дә укымаган надан калган мөселман хатын кызларына да «гыйффәтсез» дияргә һичкемнең көче йитмәз. Мөселман хатын-кызларында гыйффәт башка милләтләргә караганда күб дәрәҗә югарыдур. Гаяз әфәнденең Зөһрә ханым җәнабләре хакында язган сүзләренә караб, тәрбияле гаиләләр илә таныш түгел диб уйлаган идем, инде хәзер юл ачылды. Гаяз әфәнде шулкадәр күб курсистка, мөгаллимә ханым вә туташлардан сорашыб карасын иде. Бонларның кайусы гына булса, кирәк рус, кирәк башка ир булсын, аналары, туталары алдында тез чүгеб мәхәббәт изһар итәргә батырчылык кыйлганлары бармы икән? Билгеле, юк. Әгәр, «бар» диб җаваб бирүчеләр булса, бу эш әдәбсезлек саналмаса, ул вакыт мин үз хатамны игътираф кыйлыб, сүземне кире кайтаруб алуга хәзермен.

Әгәр бу ханым вә туташларның кайусына булса танышыб йитмәгән руслар анасы-апасы алдында тез чүгеб мәхәббәт изһар кыйлган тәкъдирдә ничек хәрәкәт итәр иделәр? Әлбәттә, әдәбсезлек кыйлган өчен йөзенә чабар иделәр. Гәрчә Гаяз әфәнде бу чабуны орыш-сугыш диб тәгъбир кыйлса да, минемчә алай түгел, бәлки әдәбсезлек һөҗүменә мөдафага[1] буладыр. Гаяз әфәнде: «Зөһрә ханымның куәте кулының ныклыгында түгел иде, аны зур иткән, аны көнләткән хасиятләрдә, аның оста кычкырышуы-талашуында түгел иде. Ул зур мәгънәви куәткә хуҗа, ул искиткеч бер җазибәлеккә[2], хәйран калырлык бер матурлыкка малик иде. Менә шул куәтләре-көчләре аның алдында вак-төяк чүп-чарларны гына түгел, әллә нинди фабрикант малайларын гына түгел, татарның иң олуг кешесе Исмәгыйльне дә тез чүктерде», ди. Искиткеч җазибәлек, хәйран калырлык матурлык булгач, ирләрнең гашыйк булуына һичкемнең исе китми. Мин дә бит русларның мәхәббәт итүләрене инкярь итмәдем, анасы-апасы алдында тез чүгеб изһар мәхәббәт итүләрене инкяр итдем, хәзердә дә инкяр итәм. Чөнки бу эш әдәбсезлек саналганга күрә, Зөһрә ханымның пакь исеменә кер

[1] Мөдафага – каршылык күрсәтү.
[2] Җазибәлеккә – сөйкемлелеккә.

кундыра. Бу эш яхшы саналган булса, анасы илә апасының нигә куәтләре оча? Нигә рус обществосына аралашуына чик сызыла? Исмәгыйль бәк хәзрәтләре танышыб йитмәз борын тез чүгеб изһаре мәхәббәт кыйлмаган. Аулакда үз хатынына ирләрнең тез чүгүе бик табигый эш. Анарга да ис китәрлек түгел. Ләкин зур мәгънәви куәткә хуҗа булган туташны анасы-апасы алдында мөхәррир әфәнденең үз тәгъбиренчә «вак-төяк чүп-чарлар фабрикант малайлары»ның тез чүгәргә батырчылык кыйлулары исне китәрә.

«Зөһрә ханымның кием-салымына артык әһәмият бирелә дигән сүзләремә каршы Гаяз әфәнде: киез-каталар, алача күлмәкләр, сәленгән балаклар тезеб китә. Фабрикант кызларының кыйммәтле нәфис киемләр кидекләре «Фәзаилешшөһүрче абызтайларга» да мәгълүм, тик ул киемләрне киеб, башка кәмаләтләре улмаган кызлар тарих сәхифәләрендә язылмыйлар. Ул киемләрне кигезеб куйган кием калебләре магазин тәрәзәләрендән күренеб торса да, аның ни икәнене һәркем аңлый да, битенә-башыга түгел, киемнең формасына гына карыйлар. Зөһрә ханым җәнабләренең олуг дәрәҗәләргә ирешүе «әфәләм» төсле киемләре аркасында түгел, сабырысәбаты, җәсарәте[1], мәгънәви куәте аркасындадыр. Киемесалымы аркасында булганда, Багчасарайда милләт файдасына тырышкан вакытларында анасы өендәге байлыкның бер кисәге дә булмагач, дәрәҗәсе киму тиеш булыр иде. Вәхаләнки ул мөкәрәмә ханымның дәрәҗәсе көндән-көн арта барды. Фельетонның ахырында Гаяз әфәнде сүзене мәкаләмә түгел, үземә борыб байтак кына нәсыйхәтләр бирә.

«Исмәгыйль бәкләр кебек олуглар янына барганда, аларны үлчәргә тотынганда үзеңнең авылыңдагы аршиның берлән үлчәб, шуңарга сыймаса, Вильһельм тонында хөкемләр чыгару килешеб бетә микән. Сезнең авылда чәй суына барганда сөйләнмәсә, бәлки башка йирдә сөйләнгәндер. Сездә булмаса, күрше авылыңызда, бәлки, бардыр. Дөнья бит шактый гына зур. Дөньяның морале, дөньяның әхлакы да иске «Фәзаилешшөһүр»ләрдә генә күреб бетмәгән кебек, матурлык, нәфасәт

[1] Җәсарәте – кыюлыгы.

хакындагы уйлар да иске әбиләрнең мәкальләре берлән генә чикләнеб бетмәгәндер», ди.

«Үлчәү», «үз аршиның» дигән сүзләре миңа түгел, Гаяз әфәнденең үзенә кайта. Исмәгыйль бәкләрне мин түгел, Гаяз әфәнде үлчәде; үз аршинына үлчәгәнгә күрә, дөрест чыкмады. Шулай ук киләчәк көндә дә минем үлчәү-үлчәмәвем Гаяз әфәндегә мәгълүм түгел. Гаяз әфәнде Исмәгыйль бәк вә Зөһрә ханым җәнабләрене үлчәгән фельетонларының 42 нче сандагы «бер көн эчендә анасы, тутасы хозурында биш-алты русларның тез чүгүе бүгенгә кадәр күрелгәне һәм ишетелгәне юк иде» дигән сүзләремне «Вильһельм тонында хөкемләр чыгару» диб тәгъбир кыйла. Гаяз әфәнде тарафындан язылыб чыкган һәрбер сүзләргә (гакылга сыйса-сыймаса да) иман китерергә мәҗбүрият күрелде. Һәркем үзенең фикерендәдер. Һәрбер язылган нәрсәләргә каршы төшү ярамый дигән заманлар үтде инде. Чәй суына барганда мәгънәле сүз сөйләнү мөмкин улдыгы кеби, чәй янында мәгънәсез сүз сөйләнү дә мөмкин. Дөньяның «шактый гына зур»лыгын инкяр итеб, безнең авылымыз илә күрше авылымыздан ары дөньяның чиге дигән сүз дә минем мәкаләмдә юк иде кебек? Ике урында «Фәзаилеш-шөһүр»не кысдырыб, авыл хатын-кызларының наданлыгын, әхлакын тәнкыйд итә. Наданлык бәласе, тупаслык, дорфалык, авыл кызларына гына хас булганда, шәһәрләрдә торучы хатын-кызларның барлыгы галимә, нәфисә булыр иделәр. Мөхтәрәмә Зөһрә ханым җәнабләре дә авылда үскән әмсалсыз чәчәк иде бит.

Хәзерге язучы әфәнделәремезнең бик яшьләре генә ысуле җәдидә илә башлаганлардыр. Олуграк яшьләре иске мәдрәсәләрдән чыкган әфәнделәр түгелме? Анлар да бит йиде-сигез яшьләрендән «Шәрхе Габдулла»га төшмәгәнләрдер. Һәр кайуларымызның бар кебек гыйлем нигезләре, «Кисекбаш», «Бәдәвам», «Ярты алма», «Фәзаилеш-шөһүр»ләрнең кирпечләрендән салынган. «Фәзаилеш-шөһүр», «Сөбател-гаҗизин» китабларыны аңлаб укыган хатын-кызларга хәзерге заманда язылган китабларны да уку кыен түгел. Кяшки, шул китабларны аңлаб укыган хатын-кызларымыз күбрәк булса иде.

Шулай ук әбиләремезнең мәкальләрене күбрәк ядымызга алган булсакчы.

Фельетонның ахырында: «Сезнең безгә зур бурычларыңыз бар. Аның иң зурысы: сездән башка да матбугат галәмендә хөкем сөрә торган гайбәт базарына сезнең яңы гайбәтләр чыгармавыңыз сезнең кебек хатын-кыз арасындан чыкган язучыларның кечимәгән йирне казуларына нә халкымызның нә матбугатымызның ихтыяҗы бардур», ди. Минем хакда булган сүзләр дә тупас каләм илә язылса да, авыл хатынының нәзакәтене аңламавына хәмел ителеб гафу кылыныр иде. Ләкин матбугатымыз хакындагы сүзләрендә әдиблек даирәсендән чыгу тиеш түгел иде.

Ул гайбәт базарында товар күб булганга, безнең яңы гайбәтләремезне чыгармазка тәүсия кыла. Ләкин гайбәт хакындагы сүзләре үзенә кайта. Чөнки минем мәкаләмдә гайбәт юк. Гаяз әфәнденең үлчәве генә тикшерелгән иде. Гаяз әфәнде исә авылның абыстайларын, әбиләрен, алача күлмәкләрен, киез каталарын, авыл хатын-кызларының сәленгән балакларын, чәй суына йөрүләрен – берсен дә калдырмады. Гайбәт сыйфаты кайумызның сүзләрендә икәнене хөрмәтле укучылар үзләре тикшереб хөкем итәрләр.

Гаяз әфәнденең соңгы сүзләрендән берсен генә түгел, барлык ханым вә туташларның «кечимәгән йирне кашу»дан башка нәрсә яза алмый икәнлекләре аңлашыла. Хатын-кызлардан булган мөхтәрәмә язучы тиңдәшләрем «нә халкымызның, нә матбугатмызның ихтыяҗы бардыр» дигән сүзләренә карaб, каләмләрене ташламасалар кирәк.

*Мәхбүбҗамал Акчурина.*

Мәкалә «Вакыт» газетасының 1915 елгы 5 март санында басылган. Мәхбүбҗамал Акчурина (1869–1948) – язучы, мәкаләләр, очерклар авторы. Текст басмага газетадан алынды.

*Текстны Ләйлә Гарипова әзерләде*

**Мәхмүд Фуадка тәнбиһ**

Менә шул принципны алда тотып, мин «Йолдыз»ның ун еллык юбилее мөнәсәбәте белән «Сүз» гәзитәсендәге Гаяз әфәнде тарафыннан язылган, гаклы сәлим һәм зыялы татар укый алмаслык урам сугышуыннан гына гыйбарәт фельетонга каршы «Шәкерт абый» исеме белән бер мәкалә язган идем. Табигый инде, беркатлы кешеләр яисә ни әйткәнен, нәрсә ташлаганын белмәүчеләр «нигә син килеп чыктың, нигә мәсьәләне «Йолдыз» өстенә калдырмадың диерләр. Бу фикернең хаталыгында һичбер шик-шөбһә юктыр. Әгәр кеше «Йолдыз»ның кәгазе, хәрефе начар дип сүгенсә, яисә Һади әфәнде Максудиның дәреслек китапларына кагылса, әлбәттә, мин тын гына калыр идем. Ләкин, мәсьәлә бөтенләй башка. Гаяз әфәнде кәгазенә, хәрефкә кагылмады. Ул ун ел эчендә «Йолдыз»га каләм белән хезмәт иткән ике йөз егерме ике кешенең тәкъдире белән уйнады, Марс йолдызыннан торып, аларга яшь хулиганнар дип кычкырды. Шушы ике йөз егерме милләт кешеләре тарафыннан яшәп килгән, татар мәркәзендәге, дөресен әйткәндә, Волга, Агидел, Кама татарларының бердәнбер милли органнары булган «Йолдыз» газетасын доносчы дип атады. Бу тугрыда инде озаеп торасы юк. Аның сүзләре генә күчерелгән иде.

Әлбәттә, мин, шул газетада язучылардан берәү, элек үземнең доноска хезмәт итә килгәнемне һәм татар эчендә хулиганлык артдырырга тырышмаганлыгымны, андан соң үземдән башка 219 кешенең хезмәтләрен тәкъдир кыйлганлыгымны белдереп мәкалә язарга мәҗбүр булдым. Әлбәттә, мин милләтемә хезмәтемне беренче вазыйфам дип белгәнгә; үзем катнашкан органны да милләткә файдалы ак юл дип таныганга, «донос», «хулиган» дигән сүзләрне йөкли алмадым; шулай ук татар дөньясындагы әдипләр, мөхәррирләр, сәясиләр, халык хадимнәре, журналистлар һәм галимнәр (Г. Ибраһимов, Г. Камал, Һади, Садри Максудилар, Г. Баттал, Һади Атласов, Хәсәнгата Габәши, Зәки Вәлиди, Нәҗиб Гасрый, Фатих Сәйфи, Г. Кәрам; Хәлим Искәндәр; Хәлил Әбүлхан; Муса Бигиев; Зыя әл-Кәмалиләр) не хулиган дидертәсем килмәде һәм алар кара данус органы «Йолдыз»га иштирәк

итеп милли хулиганнар йитешдерергә иҗтиһад иткәннәрдер дип сүз зан кыйла алмадым. Менә шул кешеләрнең ун ел буена милли орган «Йолдыз»га татар милләте өчен эшләгән эшләренә каршы, нәрсәнең, нинди шомлыкның тәэсире беләндер, Гаяз әфәнденең «Йолдыз» һәм аның мөхәррирләре астына чеп-чи итдереп, чирканмыйча «хулиган», «донос» пычракларын ташлавы миңа искиткеч күңелсез тәэсир итде.

Шул тәэсир белән, бердәм, Гаяз әфәнде өчен тәэссеф итеп, икенчедән, 220 мөхәррирнең намусын саклап, бик инсафлы һәм киңәш тарзында гына: «Шәкерд абый, нигә син болай күкрәк тибүеңә бирелеп, шул дәрәҗәдә шашып китдең? Урынсыз шул кадәр былчырак ташлау кирәкмәс иде. Үзең дә дөнья күргән кеше бит инде», дип куйдым. Шулай ихтирамән генә һәм киңәш белән генә әйткән сүземә каршы, син күр дә мин күр, Мәхмүдфуад әфәнде, «Сүз»нең 20 нче нумирына калкып: «Шәһид Әхмәдиев, кечкенә генә «Сөембикә» журналына Гаязны күккә күтәреп язуын онытып, бүген ...» дип тезеп китә, минем адреска күчкән сүзендән үк күзгә карап ялганларга тотына.

Минем «Сөембикә»дә Гаязны күккә күтәреп язганым юк. Тик ун еллык матбугат мәсьәләсендә аның исеме генә зикер кыйлынды. Һәм аның каһарманлары хакында берничә сүз әйтелде (әдәбият дөньясында Гаяз әфәндегә «үз» урынын бирергә тырышмау минем сүзләрдән чыкмаска тиеш). Бу – бер. Монда иң гаҗәб, иң көлке нәрсә шул: Фуад әфәнде, нәрсәгәдер, Гаяз әфәнденең «әдәби» хезмәтен бу мәсьәләгә китереп чыгарырга тырыша, вә халь аңа ул хакда минем тарафтан бер сүз әйткәнем юк, господин Фуад Гаяз әфәнде хакында «татар әдәбиятының мөәссисе, мөҗәддиде, атасы, бабасы, анасы, хода белсен, тагын ниләре», ди. Әлбәттә, моның өчен Фуад әфәндегә Американың кәшфиятенә ничә йөз еллар үткән иде, ул яктан икән, менә сез кәшеф кыйлдыңыз, маладис, маладис, дарелфөнүн бетерүеңез бушка китмәгән диясе генә килә. Андан соң ул, сүз белән Гаязны бик зур итеп күрсәтүгә күңеле канәгатьләнеп йитмәгәнгә Һади Максудовы белән Шаһид Әхмәдиевне бизмәннең бер ягына, Гаязны бер ягына салып үлчәргә тотына. Карагыз әле, укучылар, Гаяз авыр бит, Гаяз ... шулай булгач, уйлагыз инде. Кемнең сүзе

дөрест булырга кирәк, ди. Әлбәттә, инде уйлый торган укучы: «Мелла Фуад, чишмәсе бер йирдән чыкмагач, икенче йирдән казый башлады: үлчә, үлчә, весовщик булырга кабилиятең юк түгел...» генә диячәк инде.

Менә моны матбугат галәмендә «Фуад бизмәне» дип атарга ярый. Әгәр ул хокук шөгъбәсен бетереп чыкмаган булса, әлбәттә, бизмәнне татар дөньясы күрә алмас иде; юкса үлчәнергә кем тарафыннан ишарә булган соң?.. Ләкин мәсьәлә бөтенләй башка, Гаязның әдиплеге хакында торырга тиеш; Гаяз мөхәррир, әдип икән, аны ихтирам кыйлынган һәм кыйлынадыр. Ләкин Гаяз әфәнде татар-туганларының бу ихтирамларын аяк астына таптады. Ул шуны аңларга кирәк иде. Буңар кадәр татар дөньясы үз кешесе, үз хадиме итеп, барлы-юклы эшкә зур һәдия бирергә, һәм үзенең хадимләренең кимчелекләрендән күз йомарга тырышты. Шуның өчен дә үзенең барлы-юклы шагыйрь вә мөхәррирләрен мактады, күтәрде, ихтирам кыйлды. «Сукыр, аяксыз, ямьсез булса да, үз туганыбыз, бит, яратырга, сөяргә бурычлымыз» дигән әсаска бар эшемез корылды. Менә шуның өчен Гаязның да әлегә бер генә кимчелекләрен дә күрмичә, «олуг әдибемез, әдәбиятның мөҗәддире[1]» дидек, шуның белән бергә татар дөньясы Гаяз әфәндегә үзенең башка хадимләре, әдипләре, галимләре өстенә төкерү хокукын бирмәде һәм бирмәячәк, мондан соң да «эш эшләүчеләрне тәкъдир» принцибы дәвам итәчәктер, үзеңнең көчең, авторитетың белән башкаларны изәргә, эштән чыгарырга тырышуның инсаният, вөҗдан алдында нинди урын алганын, бар кемдән дә бигрәк, космополитлар белергә кирәк иде... Менә шуның өчен дә без бу мәсьәләдә Гаяз әфәнденең: «Очды, очды, арбалар очды» дигәненә бармак күтәрергә мөмкин түгел бит.

Сез Фуад әфәнде, мәсьәләдән бөтенләй читкә чыгып, Гаяз әфәнденең әдәби эшен китереп бутыйсыз да татар каршында үзеңезне акларга, кызгандырырга тырышасыз. Без бит һөҗүм кыйлмыймыз һәм кыйлмадык. Моңар бөтен дөнья шаһид. Андан соң минем Гаязга «ләкаблар» кушканым юк. Бу, әлбәттә, ифтирадыр.

[1] Мөҗәддире – яңалык кертүчесе..

Кешенең үткән гомерендәге профессияләрен санап китү «ләкаб» булмый, тик аның тәрҗемәи хәлен генә искә төшереп китү була. Әгәр сез, господин Фуад, «Гаяз шәкерд, хәлфә, учитель, мулла, кәрчәүникче булмады, менә шул сакаллы һәм мыеклы көенчә «татарның милләтчесе» булып анадан туды» дисез икән, бер сүзем дә юк. «Яңа бизмән» үзеңездә бит, үлчәңез!

Хәзер инде ялганлау, ифтира, сүгенү, буяу белән генә милләтне үз чанаңа утыртып булмый. Шуны аңларга вакыт. Шуның ахыры итеп мин шуны әйтәм: Гаяз әфәнде һәм аның «Очды, очды, арбалар очды!»сына бармак күтәрүче сез, татар дөньясындагы 220 әдип, мөхәррир, галимләрнең астына былчырак ыргыттыңыз, агу ташладыңыз, менә шул кара буяуыңыздан акланыңыз; даирә бик кечкенә; аны киңәйтергә урын юк. Мин үз хакымдагы ялганлар, ифтиралар өчен сезне әдәби мәсъүл саныйм һәм Гаяз әфәнде тарафыннан хулиган исеме алган 219 иптәшемнең һәм шулар белән бергә үземнең дә аклануымны телим.

Вөҗданы саф, хөббе нәфсе бар кешеләр башкаларга да саклык белән мөгамәлә кыйлалар.

*Ш. Әхмәдиев*

Г. Исхакыйның «Мәхмүдфуадка тәнбиһ» мәкаләсе «Йолдыз» газетасының 1916 нчы елгы 19 нчы февраль санында басылып чыккан.

*Текстны Зөфәр Рәмиев әзерләде*

## Вөҗданым көчләде

«Мәхмүдфуадка тәнбиһ» дигән мәкаләсендә Шәһид Әхмәдиев[1] кызык кына сүзләр сөйли:

Гүя Гаяз әфәнде «Йолдыз» турында язган мәкаләләрендә «Йолдыз» илә бергә «Йолдыз»да язгалаган 220 имзага хулиган дип кычкырган була да, Шәһид әфәнде, шул 220 кеше өчен сыкрап, аларны акларга, пакьләргә керешә...

220 имза эчендә минем дә исемем булганлыкдан, башдук

[1] Ш. Әхмәдиев (1888-1930) – язучы, дәүләт эшлеклесе.

шуны әйтеп куярга кирәк: «Гаяз» «Йолдыз»га каршы чыкган мәкаләләрендә 220 имзага бәйләнмәде, Гаязның алар белән эше булмады дип беләм. «Йолдыз» үзенең язышучыларын куркаклыкга өйрәтде...» кебек сүзләр булса, бу сүзләр турыдан-туры «Йолдыз»га вә анын алып баручысына тиядер. 220 кешедән килгән язуларны кыркып, ямап, үз иләгендән үткәрүче идарә (220) кешедән гыйбарәт булмыйча, тик бер-ике генә кешедер ки, алар да – мөдир яки мәсъүл[1] секретарь.

Инде низагның-мәсьәләнең эченә керергә теләсәк, бер яклы булмыйча гына мөхакәмә итсәк, түбәндәгечә сөйләмичә чарамыз юк. «Йолдыз» үзенең ун ел буенча тукталмыйча дәвам итә алу шадлыгы өчен үзенә бәйрәм, «юбәләй» ясый. Һәрбер мөәссәсә, хәтта сәүдә фирмалары кебек частный урынларда үз-үзләренә юбәләй ясарга хакы булганлыгы кебек, «Йолдыз» газетасы да, әлбәттә, бу хакдан мәхрүм түгел иде. «Йолдыз» үзенә юбәләй ясады, юбәләйгә барганлар аны мактадылар. Мөхәррирен, язышучыларын тәбрик итделәр. Батыйнән[2] бу тәбрикләргә кушылмасалар да, бәгъзе кешеләр юбәләй хөрмәте өчен шунда «Йолдыз»га каршы бер кәлимә булсын сүз әйтмәделәр. Юбәләйнең әдәбен сакладылар (моны исбат өчен Фуад Туктаров[3] йитә). Гадәтдә, юбәләй дигән нәрсә, мотлакан, макташу, шадланышу өчен генә корыладыр, сүгәр өчен, кычкырышу өчен һичбер мөәссәсә үзенә юбәләй ясамый.

«Йолдыз»ның шушы гөнаһсыз юбилеен бөтен милләт исемендән булу төсен алганлыкны күребме, әллә матбугатның ун еллык эшенә хисап бирү хасияте ташып торган чак булуданмы, Гаяз, юбәләй әдәбен сакламыйча, «Йолдыз» турындагы һәммә кара фикерләрен язып чыгара: «Йолдыз»да үзе тапкан килешсез сыйфатларны санап ташлый. Менә шушы чыгыш, Гаяз булмаган башка берәүләр тарафындан булса, яхшы ук гаеп ителерлек бер эш булыр иде. Ләкин чыгыш, Гаяз чыгышы булганга, анын шәхесен әз генә пычратмый.

---

[1] Мәсъүл – җаваплы.
[2] Батыйнән – эчтән.
[3] Фуад Туктаров (1880–1938) – сәяси эшлекле, публицист.

Гаяз, әдиплекдә ачы юмористлек, сатира белән танылган булса, журналистлыкда, һич шөбһәсез, кызу, утлы язучыдыр. Гаяз сатирик әдип, радикаль журналист, соңгысын исбат өчен «Таң», «Тавыш», «Ил», «Сүз» номерлары йитә. Монда журналистлардан бердәнбер кеше булса, ул да – Гаяз, Гаяз – бердәнбер тип. Шулай булгач, бу кешенең юбәләй вакытында «Йолдыз»га каршы чыгуын әдәпсезлекдән санарга хак бетәдер. Могтәдил журналист Фатих Кәрими чыкса, әдәпсезлек булыр иде. Шул ике кешедән башка безнең бит әле танылган журналистларымыз юк да. Шәһид белән «Йолдызчы» журналист сүзен нинди мәгънәдә йөртә торганлардыр, мин аңлый алмыйм. Журналистлыкны Гаяздан алып ташларга теләгәнләрен аңлый алмыйм...

Менә сезгә радикал журналист бер тип! Шул «тип» бәреләсугыла да, «Йолдыз» турындагы фикерләрен әйтеп ташлый. Аның карашында «Йолдыз» – доносчы, ялганчы, фәләнтөгән... икән. «Йолдыз»ның өстенә йөкләнгән вазыйфа хәзер, һичшиксез, шул өстенә ыргытылган сыйфатларны Гаяздан исбат итдерү, яки шуларның юклыгын үзе исбат итү иде. «Йолдыз» баш мөхәррире мөхтәрәм Һади әфәнде Максудов һәм шул юлда эшләргә дә башлаган иде. Аның, «Таңчыга җавап» дип, үз имзасы белән басылган мәкаләсе һәм гакыллы, һәм әдәпле булып башланган иде. «Йолдыз»га хөрмәтем булганлыкдан, мең мәртәбә тәәссефкә[1] Һади әфәнде җаваплашудан туктап, эшне Шәһид белән «йолдызчы» алып китде. Милләт тарафындан әле бер төрле дә танылмаган бу кешеләр, милләт эчендә үз сүзләренә күпме бәһа барлыгын үлчәр-үлчәмәс тотдылар да Гаязны бетерергә, аның шәхесенә кадыйр итәргә, элеп алып, селкеп салырга ябышдылар...

Әйтегезче, Алла риза булсын, «Таң», «Тавыш», Гыйлаҗ мулла малае Мөхәммәдгаяз һәм Низам мулла малае Һадилар при чем[2] монда! Мәйданда бит «Йолдыз» белән аңа әйтелгән сүзләр генә бар. Шул ноктадан карап кына сөйләнергә тиеш бит. Әдәп, гакыл шуны тели бит! Гаяз әйткән начар сыйфатларны юып ташларлык «Йолдыз»да матур сыйфатлар юкмыни! Бар, бик

[1] Тәәссеф – кайгыру.
[2] При чем – кирилл хәрефләрендә.

күп бар, казынсаң, «Йолдыз»дан әллә никадәр яхшы сыйфатлар табып була; «Йолдыз» могтәдил[1] милли бер газета. Менә шундый могтәдил газеталардан нәрсә көтәргә мөмкин булса, шуларның һәммәсе дә «Йолдыз»да бар.

Шул ноктадан карап сөйләгәндә, «Йолдыз»ны аклар, пакьләр өчен артыгы белән йитәрлек яхшы сыйфатлар табып булачак, бәгъзе бер милли теләкләрнең ялкынлы итеп мәйданга куелмавы, «Йолдыз»ның мәсләксезлегендән булмыйча, игътидаллык тактикасы теләвендән. Шуның илә бергә, «Йолдыз»ның провинциальный бер газета булуындандыр. Могтәдил провинция газеталары, ни булса да була дип, хакыйкны ялганлы итеп әйтеп калыр өчен генә чыкмыйлар, алар озак дәвам итү нияте белән, яшәү арзусы белән чыгалар ки, бу теләк үзе генә дә хәзерге вакытда сак сөйләнүне, мөдара[2] белән эш кылуны лязем итә. Могтәдил тәрәккыйпәрвәр провинция газеталары өчен бу һичибер косур[3] түгелдер. Димәк, «Йолдыз»ның тәрәккыйпәрвәрлек вә миллилекдә могтәдиланә бер тактиканы тәгъкыйб итеп баруы «Йолдыз» өчен кимчелек булмый. Кимчелек дип дәгъва итүчеләр булса, бөтен татар матбугаты өчен уртак булган бу мәсьәләне кузгаган булалар ки, татар матбугаты нинди тактика илә эш күрергә кирәк? Бусы – бөтенләй башка һәм гомуми бер мәсьәлә. «Йолдыз»да билкасд эшләнмәгән бәгъзе бер хәбәрләр бәгъзе берәүләргә зарар китергән икән, хата булган дип гафу үтенергә кирәк. Болар доносчылыкдан ерак булсалар да, һәрничек килешле эшләр түгелдер, шуның илә бәрабәр хаталар кешедә була торган эшләр бит.

Шәһид Әхмәдиев белән «йолдызчы»ның мәкаләләрен укыгач, дөресен генә әйтсәм, «Йолдыз»ны үзенә тиешле урындан да түбән төшерергә сәбәп булалармы дип курка башладым. Чөнки аларның кыланышы «Йолдыз»ның әлегә кадәр тоту килгән мәсләкенә хилаф булу өстенә, буш батырланулар гынадыр ки, мәкаләләренең эчендә ни «Йолдыз»ны аклау вә нә дә чынлап Гаязны тикшерү бар. Милләтнең аңлы бер табәкасенә[4] Гаяз

---

[1] Могтәдил – уртача.
[2] Мөдарә – күркәм мөгамәлә
[3] Косур – кимчелек
[4] Табәкасенә – катлавына.

турында әйтәчәк сүзләре булган кеше псевдоним белән чыкмас да иде... Гаязның түгел, «Йолдыз»ның битенә кара якдылар дим мин бу кешеләр...

Мин бу чыгыш, бу батырлыклардан шаһиди булып тордыгымыз берничә ел эчендә булып, узган «шәйгә пәрвәслек»нең сүи нәтиҗәләре тәкрарланган төсле бер хәл сизәм. Бервакытлар татарның яшь әдипләре Тукай тирәсендә әйләнә иде. Дөресен генә әйткәндә, андан көнләшкән бер гөруһ аны көч белән изәргә теләде. Тукай үлде. Тукай тирәсендәге халык Фатих Әмирхан янына җыелды. Баягы гөруһ Тукайны да изә алмый, Фатих тирәсенә дә керә алмый аерым бер гөруһ булып китде дә татарлык дөньясында үзләренә тиң тапмагандай кәпәрә башладылар... Бу гөруһның Гаязга булган ошбу һөҗүмләре беренче һөҗүм генә түгелдер...

Бу – бер тарафдан. Икенче тарафдан, мин таңчыларның хәтта узган дәверләренә дә үзләре милли төс бирергә теләгәнләрен, һичбер сәбәп юк икән, һаман ялган буяу илә буяп, аны йотып калдыруга азапланганларын аңлыйм ки: бусы инде - юкга гына маташудыр. Ул вакытдагы идеяләр, ни кадәр генә хак вә тугры булсалар да, татарлык эчендә харчауник малайларын эш ташлатудан башкага узмады. Татарның үзендә әле Яурупадагы кебек ачыкдан-ачык күренеп торган буржуй капиталистлар да, мәзлум пролетариат да юк ки, менә шушы үзенә генә дә андый идеаллар артындан йөрүнең татар өчен вакытсыз икәнен белдерәдер.... Балкан сугышлары, әлбәттә, сабак бирде. Тугрысын сөйләргә кирәк, «шулай идек, болай булдык» – моның өчен беркем дә сукмый да, кыйнамый да, оят да түгел. Шуның илә бергә гомуми теләкләр өчен күңеленең иң төбендә гомуми идеаллар сакларга Ходай һәркемне ирекле иткән, зоһуры монакыйз[1] булса да, нәтиҗәсе файдалы булган хосусый иманның эшләрен дә гомуми иман эченә аладыр...

*Н. Думави*

Мәкалә «Кояш» газетасының 1916 елгы 1 март санында басылып чыга, басмага газетадан алынды.

*Текстны Ләйлә Гарипова әзерләде*

[1] Монакыйз – капма-каршы

## Кечкенә фельетон

«Кизүдәге мәсьәләләр» дигәч тә, мин Гаяз әфәнденең мәкаләләрен башта гади обывательләргә[1] хас бер кызулык белән укырга керешкән идем.

Ләкин бераз соңрак мин аларны почтенный гражданнарга гына хас бер салкын канлылык вә җиддиять[2] белән укый башладым. Чөнки бу мәкаләләрдә һәммә нәрсә табылырга мөмкин, тик обыватель өчен кирәк булган кизүдәге мәсьәләләр юк. Мәсәлән: кыйммәтчелек, эспекуляция[3], утын кахтлыгы[4], азык кахтлыгы вә гайреләр...

Бәс, шулай булгач, табигый, салкын канлылык настроениесенә бирелеп укый башларга туры килде.

Ләкин бу настроение дә озакга бармады, чөнки Гаяз әфәнденең башдагы берничә мәкаләсен укыган чакда, аның җидди тонда язуына бер дә шөбһә итмәдегем хәлдә, алтынчы мәкаләгә йиткәч, күңел базарына шөбһә төшде. Монда ул «юмор»га бирелгән төсле күренә башлады.

Бу мәкалә, бервакытлар Русия мөселманларының милли-сәяси бер партиясе сыйфаты белән оешып, тамыр җәяргә теләгән «Мөселман иттифакы» белән интернациональ «Яшьләр» фиркасының сыйфаты «сәлбия[5] вә сөбүтия[6]»ләрен яд итүгә багышланган.

Ләкин боны укыганда, әлеге ир уртасы гражданларга хас җидди настроение югала да китә, ихтыярсыз рәвешдә елмаерга мәҗбүр буласың.

Мәсәлән, фараз итеп караңыз, Тупчыбашев, мәрхүм Исмәгыйль бәк Гаспринский Мәдинәи Мөнәвәрәдән голүме исламия тәхсил кылып[7] кайтканлар. Башларында кечкенә генә гарәп чалмалары, өстләрендә буйлы ефәк «җәлләбия»ләр

[1] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[2] Җиддиять – җиддилек.
[3] Дөресе: спекуляция.
[4] Кахтлыгы – кытлыгы.
[5] Сәлбия – тискәрелек.
[6] Сөбүтия – ышанычлылык.
[7] Тәхсил кылып – гыйлем алып.

өстендән киң җиңле гарәп җөббәләре[1], аякларында кызыл сахтияндан эшләнгән үткен борынлы чарыклар[2]. Шушы мөбарәк Мәдинәи Мөнәвәрә шәкердләре «Русия мөселманлары иттифакы» оештыру эше белән әвәрә булалар. Шәрыкның мәдрәсә күшәләрендә[3] ни хәтле хыялпәрәстлек[4] мәүҗүд булса[5] булыр – һәммәсен диярлек үзләре белән алып кайтканлар.

Алар, әлбәттә, үзләре генә түгел. Байтак кына ибдәшләре бар.

Мәсәлән, Бохараның Күкелташ мәдрәсәсендә тәхсил кылып кайткан Сыртланов, Акчурин, Тәфкилев кеби зур чалмалы кәттә муллалар да әлеге эш артыннан йөриләр. Ләкин Гаяз әфәнде әйтмешли: «Бу Шәрык шәкердләренең төшенчәләре бик киң булса да, мәсьәләләрнең һич берсендә мәгълүм әсаслар[6] куелмаган, аларның уйлары Шәрыкнең матур күге, зөмред[7] кебек диңгезе арасында уйланганга, бик күбесе хыял дәрәҗәсендән индерелмәгән вә тормышка татбикъның[8] ысулы уйланылмаган».

Менә инде шушы «Шәрыкның мәдәнияте черегән вакытындагы моральне сеңдереп кайткан» кешеләр, «Мөселман иттифакы» партиясе оешдырып йөргәндә, икенче бер фирка – «Яшь халык хөррияте» фиркасы – флагы астында йөрделәр.

Менә болар инде, тегеләргә караганда бөтенләй башка халык! Болар Гаяз әфәнде әйтмешли: «Русиядәге үзгәреш алдындагы сәяси тәрбияне күргәнгә (ә тегеләр әле ул чагында кайсы Мәдинәдә, кайсы Бохарада дини мәсьәләләр хакында ду күчереп моназарә[9] кылышып яталар икән), рус әдәбияты аша шул вакытдагы икътисади уйлауны, тарихи вакыйгаларны маддиноктаи нәзардан[10] карауны кабул иткәнләр иде».

---

[1] Җөббә – җиләннең бер төре.
[2] Чарыклар – күн олтанлы аяк киемнәре.
[3] Күшәләрендә – почмакларында.
[4] Хыялпәрәстлек – хыялга бирелүчәнлек.
[5] Мәүҗүд булса – тормышта булса.
[6] Әсаслар – нигезләр.
[7] Зөмред – зөбәрҗәт.
[8] Татбикъның – яраклашуның.
[9] Монәзарә – бәхәсләшү.
[10] Ноктаи назардан – караштан.

Болар һәммәсе диярлек зур тәҗрибәле, киң белемле, аек нәзарлы[1] булып, теге Шәрык шәкердләре шикелле хыялга бирелмиләр, ни эшләсә дә белеп эшлиләр, һәм дә тоткан юлларында сәбат[2] күрсәтәләр.

Менә шунлыкдан да, үткән ун ел эчендә теге хыялпәрәст[3] иттифакчылар кайсы социалист, кайсы анархист булып беткән хәлдә, хөрриятче «Яшьләр» үзләренең мәсләкләрендән зәррә[4] кадәр читкә авышканлары юк. Алар һаман да: «Берләшеңез бөтендөнья эшчеләре!» шигаренә[5] самими сәдакать[6] саклыйлар! Һалән[7] шушы яшьләр фиркасенә мәнсуб[8] Икенче Г. Думага сайланган депутат хәзрәтләре һаман да Маркс, Каутский, Бебель вә Лассальлардан башка һичбер авторитет игътираф кылмыйлар[9].

Анысы шулай. Ләкин эшнең тагын икенче ягы да бар.

Гаяз әфәнденең бәянына күрә, мәзкүр ике фирканың берләшеп эш күрүләре дә мөмкин булган. Ләкин моңар һәм әлеге Шәрык шәкердләре – «Иттифакчылар»ның хыялпәрәстлеге юл бирмәгән.

Мәсәлән, алар гомуми программга 1) Мисырда дини исляхат[10] ясау; 2) Габделхәмиднең золымларына каршы тору; 3) Японияне мөселман ясау маддәләрен кертергә тырышканлар.

Яшьләр аны кабул итәргә тиеш тапмаганлар, әлбәттә.

Аерылышу шундан соң булган дисезме? Юк шул. Яшьләр соңындан шушы маддәләргә күнмәкче булганлар.

Ләкин теге Шәрык шәкердләре во что бы не стало[11] яшьләрдән аерылырга карар биргәнләр: иртә сәгать 10 да китәргә тәгъйин

---

[1] Нәзарлы- карашлы, уйлы.
[2] Сәбат – ныклык.
[3] Хыялпәрәст – хыялга бирелүче.
[4] Зәррә – бөртек.
[5] Шигаренә – лозунгына.
[6] Самими сәдакать – эчкерсез турылык.
[7] Һалән – хәзер.
[8] Мәнсуб – караган.
[9] Игътираф кылмыйлар – танымыйлар.
[10] Исляхат – реформалар.
[11] Кирилл хәрефләре белән язылган.

кылынган[1] «Съезд» пароходына сәгать 9 да килгәнләр дә, әйдә бакалым!

Ләкин яшьләр «яр якасында» авыз ачып калмаганлар, бәләкәй генә бер пароход алганлар да, әйдә тегеләрне куарга...

Пароходда тегеләр яшьләргә хуш кабул күрсәтсәләр, эшләренең тагын да җайланып китүе бик мөмкин икән.

Ләкин Шәрык шәкерләрендән азмы-күпме нәзакатьле мөгамәлә көтәргә мөмкин соң?

Монда яшьләргә күрсәтелгән әллә ни хәтле золымлар, әллә ничә төрле куркытуларны Ходай үзенең дошманларына да күрсәтмәсен, вәссәлам.

«Тыныңыз чыкды исә, шәһәрдән утыз-кырык чакрым йиргә илтеп далага ташлыймыз», диләр икән.

Гаяз әфәнде әле монда барын да әйтеп бетерми. Чөнки ул вакыйга хакында миңа байтак нәрсәләр ишетергә тугры килде.

Җөмләдән бере: нәкъ шушы сәгать 9 белән 10 арасында бу буксир пароходы болар янындан үткән. Менә шушы буксирның капитаны әйтә: «Карыйм-карыйм ди ул кенәзләр тулган пароходда эшләр яхшы күренми, шау-шу, кычкырыш бара, – ди. – Шулай дигәнчә булмады, – ди, – ике кеше, бер яшь егетне берсе аякларындан, берсе башындан тотдылар да, селтәп торып суга ыргытып да йибәрделәр дә! Мескенне чак-чак гына коткарып алдык», ди.

Капитанның тәгърифенә күрә[2] мәзкүр «тәрбия»нең икесе, ягъни ыргытучылары Тупчыбашев белән мәрхүм Гаспринскийга тугры килә. Өченчесен исеме, фамилиясе белән ук атап әйтсә дә, мин бу урында белдерүне уңгайсыз табам. Чөнки Гаяз әфәнде бу вакыйга хакында бөтенләй сөкүт кылырга [3] тиеш тапкан...

Эшләр бу дәрәҗәгә йиткәч, табигый, аерылмаска хәл калмаган була, ләкин монда бик кызык бер хәл бар ки, ул да «Иттифакчы»лар белән «Хөрриятче»ләрнең аерылуы түгел, бәлки «Берләшеңез бөтендөнья эшчеләре!» лозунгына ябышкан яшьләрнең милләтчелек шигарен тоткан «Иттифакчы»лар

---

[1] Тәгъйин кылынган – билгеләнгән.
[2] Тәгърифенә күрә – аңлатуына караганда.
[3] Сөкүт кылырга – дәшми калырга.

арасында чуалып йөрүләре!

Гаяз әфәнде «Таңчылык» «Уралчылык»ның мәйданга чыгуына фәкать «Иттифакчы»ларның «сүи мөгамалә[1]»ләрен сәбәп итеп күрсәтә икән, анысы, әлбәттә, үз файдасына булып чыкмый.

Һәрхәлдә, добродушный «Иттифакчы»: «Мин үзем сине элеккеге гөнаһларың өчен азрак кыздырып аласы иде, ә син үзең ук өлгердең, хәерле булсын!» дип әйтсә, урыны бар.

*Ш.К.*

Мәкалә «Вакыт» газетасының 1916 елгы №1973 санында басылган. Текст басмага газетадан алынды.

*Текстны Гөлчирә Ханнанова әзерләде*

## Бөтенрусия мөселманнары җыелышы[2]. Мәркәз шурага сайлау. Г. Исхакый мәсьәләсе Зур җәнҗал

Май, 11, кичке мәҗлес. Мәсьәлә: Мәркәз Шура һәм аңа әгъзалар сайлау. Бу хакта Вакытлы Мәркәз бюро тарафыннан көтелгән доклад электә һәммә маддәсе[3] берьюлы укылып, тоташ кабул ителсә дә, бер гөруһның[4] нык теләве белән, яңадан маддә-маддә мөзакәрәгә[5] куела. Оренбург вәкиле Мәхмүд Мәрҗанинең тәнкыйте сәбәпле, «Милли» дигән сүз ташланып, «Бөтенрусия мөселманнарының Мәркәз Шурасы» дип исем бирү кабул ителә. Мәркәз Шурага утыз вәкил сайланачак.

Боларның 12 се үзләре тарафыннан эш комитетына сайланып, һәрвакыт Петроградта торачаклар.

Боларга һәр елга сигез мең сум биреләчәк. Мәркәз Шураның

[1] Сүи мөгамалә – начар мөгамалә.

[2] Бөтенрусия мөселманнары җыелышы – Биредә Бөтенроссия мөселманнарының Беренче съезды турында сүз бара. Ул 1917 елның 1-11 маенда Мәскәүдә уздырыла. Г. Ибраһимов анда делегат һәм «Ирек» газетасы хәбәрчесе буларак катнаша.

[3] Маддәсе – бүлеге.

[4] Гөруһның – төркемнең.

[5] Мөзакәрәгә – фикер алышуга.

Петроградта булуы байтак игътиразга[1] очрады. Оренбурглылар Петроградта хөкүмәт белән мөнәсәбәт өчен өченче кеше торсын, асыл Мәркәз Шура мөселман мәркәз берендә, мәсәлән, Казанда булсын, диделәр. Ләкин теге як үтте. Вәкилләрнең ачыккан, арыган, ничек тә булса да, тизрәк бетереп, таралу ягындалар. Шунлыктан, бу хактагы бик мөһим маддәләр карар булып керә алмады. Зәки Вәлиди[2] Мәркәз Шура үзенең һәммә эшендә федерализм нигезе белән барсын, рус һәм башка милләт партияләре белән бу хакта аңлашсын дигән кебек тә берничә маддә арттыруны сораган, оренбурглылар исеменнән Мәхмүд Мәрҗани: «Моңарчы яшәп килгән Вакытлы Мәркәз бюро үзенең эшләреннән, алган вә тоткан акчаларыннан хәзер җыелышка хисап бирсен; 2) хәзер сайланып калачак Мәркәз Шураның акча тотуын тикшереп торырга берничә кешедән гыйбарәт комиссия сайлансын», – дигән иде. Элгәреге бюро әгъзалары хәзерге шурага сайлау өмиде белән йөргән.

Президиумның кайбер әгъзалары, юк-бар халыкны арытып, ачыктырып шундый хәлгә җиткерделәр ки, ачлыктан хәле беткән вәкилләр, ничек җитте алай, карарга кул күтәрделәр дә арттырылачак маддәләр хакында мөзакәрә итү мөмкин булмады. Мәрҗани һәм башкалар тарафыннан гарыз ителгән[3] мөһим нәрсәләр шулай калды. Вәкилләрнең байтагы бөтенләй кайтып та киткән иде. Калганнары да юлга билет алганнар. Мәҗлеснең тәртипсезлегеннән ачлыктан кямил[4] җөдәп, ничек кенә булса да, бетерү ягын алга тотар хәлгә җиткәннәр. Мәркәз Шураның Петроградта булуы, аңа утыз имза сайлану, мәгашнең сигез меңге бераз артык тавыш белән кабул ителә. Бу утыз вәкил ошбу рәвешчә булына:

Кырымнан – 2, Төркестан, Бохара вә Хивадан – 7, Казакътан – 5, Кавказдан – 5, Литвадан – 1, эчке Русия һәм Себер татарларыннан – 10.

Кырым, Кавказ, Казакъ, Төркестаннан Бохара вә

---

[1] Игътиразга– каршы фикергә.

[2] Зәки Вәлиди – Зәки Вәлиди (1890-1970), күренекле тарих белгече.

[3] Гарыз ителгән – тәкъдим ителгән.

[4] Кямил– бөтенләй.

хивалыларның һәркаюсы үз вәкилләрен үзләре сайлаячак ала. Бераз мөзакәрәдән соң, хәзергә вакытлы уларак, берничә кеше калдырачакларын, әмма даими әгъзаларны илләренә кайтып, халык тарафыннан сайлатачакларын, чөнки монда сайлау тугрыдан-тугры түгел, бәлки ике катлы сайлау булачагын игълан иттеләр.

Татарлар да бу фикерне кузгатып, ике катлы сайлау ярамавын, хәзергә эш тукталмасын өчен, берничә кеше калдырыйк та, башкаларын ил вә халкының үзе тарафыннан сайлатырмыз дисәләр дә, бу фикер үтмәде.

Башкалар мәҗлестән чыгып, эчке Русия һәм Себер татарлары Мәркәз Шурага үзләреннән ун вәкил сайларга тотындылар. Бирелгән кәгазьләр буенча кырык кешенең кандидатурасы куелган. Исемнәрен укыганда болардан беразы үзләренең сайлана алмауларын игълан итәләр. Кала утыз бишләп. Кандидат сайлау яшерен ысулда шар белән булачак.

Г. Исхаков бер фикер гарыз итә:

– Җәмәгать, ди, боларның барын куйсак, шар да, тартма да җитмәс. Без вәкилнең исемен әйтик тә кул күтәрик, бу вәкилне шарга куярга кирәк булса, куелыр, куймыйк, аны сайламыйк дигән як күп булса, аның кандидаты бөтенләй ташланыр, – ди.

Бундый ачыктан-ачык тавыш бирү гаделлек һәм демократия теләгенә каршы булса да, эшне тизрәк бетерергә ярдәме тияр өмиде белән җәмәгать буңа риза була.

Кандидатуралары куелган кешеләрнең исемнәре кычкырыла. Иң элек бу кешене шарга куйыйк диючеләр кызыл билетлы кулларын күтәрәләр.

Салихов[1], Бигиев[2], Ибраһим Әхтәмев[3], Нәҗип Хәлфин[4],

---

[1] Салихов – Әхмәдбәк Салихов, 1917 елның 1 маенда узган беренче мәҗлестә Россия мөселманнарының Вакытлы Мәркәз бюросы рәисе.

[2] Бигиев – Бигиев Муса Ярулла улы (1875–1949), дин галиме, публицист, җәмәгать эшлеклесе.

[3] Ибраһим Әхтәмев – Әхтәмев Ибраһим Әбүсогуд улы (1880–1931), хокук белгече, татар меньшевиклары җитәкчеләреннән берсе.

[4] Нәҗип Хәлфин – Хәлфин Мөхәммәтнәҗип Латыйп улы (1886–1937), әдип, юрист, педагог.

Ильяс Алкин[1], студент Мостафа Туминов[2], тагы бик күпләр күпчелек тарафыннан шарга куелырга кирәк табыла. Болар ягына күпчелек ачык мәгълүм булганга, күтәрелгән кызыл билетларны санап та тормыйлар. Нәүбәт килә Гаяз Исхакыйга, мин буңа аеруча дикъкать иттем. Гаяз әфәнденең Мәркәз Шурага сайлануын теләп, аны шарга куярга риза булучылар кул күтәреңез дигәнгә каршы, анда бер, монда бер, бик сирәк кенә кызыл билетлар күтәрелде. Карыйм, зыялылар, аңлы яшьләр, аңлы эшчеләр берсе дә кул күтәрмәгән. Гаяз әфәндене шарга куймыйк, Шурага сайламыйк дигәннәр кул күтәреңез дигәч, бөтен зал югары сузылган кызыл билетлар белән капланды.

Санамыйча ук мәгълүм булса да, рәис санатты: шарга куярга теләүчеләр 63 кеше, башкалар һәммәсе каршы.

Буны күргәч, бер кечкенә гөруһ, аңламадык, яңадан күтәртеңез, дип тавыш кузгатты. Яңадан кул күтәрергә куштылар, тагы аз чыкты. Бер гөруһның талашы, гаугасы белән Гаяз хакында дүрт мәртәбә кул күтәрделәр. Нәтиҗә шул рәвештә булды.

Беренче мәртәбәдә шарга куярга теләүче – 63, икенчедә – 95.

Өченчедә һәм дүртенчедә – 138.

Һәммәсендә дә шарга куймыйк, сайламыйк дигән як бик артык күп булганга, карар буенча Гаяз шарга да куелмый калырга тиеш булды.

Дүртенче күтәрү дә Гаяз файдасына артмагач, яңадан күтәртүне файдасыз таптылар. Исхаков үзе:

Җәмәгать, болай санап тормыйк, күз карашына яртылашы күтәрелгән булса, шуның белән канәгатьләник, – диде.

Берничә егет президиум ягыннан халык эченә, залның ишеккә таба ягына китте. Гаязга каршы халык шулай башлады:

Аз кул күтәрелгән кешеләрнең кандидатуралары куелмас, дип, үзеңез гарыз итдеңез, җәмәгать шуны кабул итте. Үзеңез сайланмаска тугры килгәч, карарын бозасыз... Бу нинди анар-

[1] Ильяс Алкин – Алкин Ильяс Сәетгәрәй улы (1895–1937), милли азатлык хәрәкәте эшлеклесе, педагог.

[2] Мостафа Туминов – Туминов (Төмәнев) Мостафа (Мөхәммәтмостафа) Хәсән улы (1892–?), милли азатлык хәрәкәтендә катнашучы.

хия... Бу нинди уен..., дип, протест итәргә, кычкырырга тотындылар. Элекке таңчы һәм Исхаковның якын иптәше Шакир Мөхәммәдъяров мөнбәргә менде дә:

– Исхаков безгә яхшы хикәяләр, пьесалар язды. Әдәбиятымызга хидмәт[1]... Аны сайламасаңыз, мин дә кандидатурамны алам, дип сөйләнә башлады. Халык аңа каршы кычкырып көлде, Гаязның әдәбиятка хидмәтен беләмез, ләкин әдәбият башка, сәясәт башка. Крыловның «Балык һәм Мәче» мәсәлен укыңыз... Сайланмасаң, сиңа ялынган кеше юк, дип кычкырдылар. Аның артыннан Салихов: «Мин дә кандидатурамны алам», – диде. Федералист яшьләр буңа да: «Рәхим ит!» – дип кычкырдылар. Ул арада халыкның артыннан биш-ун солдат зур тавыш чыгарды, аяныч кирәк, Аязны сайламасаңыз, башыңызны ватармыз, береңезне дә кайтармамыз, дип дулап, җенләп, бөтен залны тавыш, гауга, җәнҗал белән тутырдылар. Тыныч мөзакәрәдә утырган бер мәҗлескә биш-ун полицейский кереп, куа, кыйный, бәйләп алып чыга башлаганда нинди хәл булса, җыелыш та шул рәвешкә керде. Солдатларның күпчелеге боларны тынычландырырга тырышып, сайлау вакытында болай көчләшү, куркып сайлату ярамаганлыгын, бу хәл хөррият рухына сыймаганлыгын, иске заманның залим хөкүмәтләре генә болай эшләгәнен әйтеп карасалар да, теге гөруһ туктамады.

Тавыш, кычкырыш, куркыту да, аз гына тынычландырырга теләүчеләр өстенә җикереп бару да дәвам итте. Залдан чыгармавы, кайтырга чыккач, вагон вату, сугыш чыгару бу гөруһның бөтен залга кычкырып сөйләгән сүзләреннәндер. Хөррият көннәрендә, хөррият бер бәйрәмендә җыелуның иркен бер мәҗлестә Икенче Николай заманындагы җәбер ысулы белән эш кылу һәммә зыялыны һәм вәкилне бик борчыса да, Исхаковның үзенә буны әйтсәләр дә, файда чыкмады. Ахырдан Исхаковны шарга куярга ирек бирелде. Сайлау яшерен һәм шар белән булса да, тарихка калырлык бер көлке һәм аяныч күренеш белән үтте. Тартмалар тезелгән. Шарлар янында баягы солдатлар тора. Салган бер кешегә үзләренең куркыту, җәберләрен игълан кылалар. Нәзыялыларның беразы һичкемгә

[1] Хидмәт – хезмәт.

шар салмады. Чөнки бу ысул хөрриятне, халыкны чиктән тыш тәхкыйрь[1] иде.

Сәгать төнге берләрдә шарларны сайлый башладылар. Нәтиҗә ошбу рәвештә булды:

Кандидатлар – ак шар – кара шар.

Салихов – 372 – 40.

Кәримов[2] – 353 – 68.

Заһид Шамил[3] – 317 – 112.

Муса Бигиев – 296 – 121.

Ильяс Алкин – 266 – 143.

Студент Мостафа Туминов – 260 – 143.

Ш. Мөхәммәдъяров[4] – 258 – 149.

Максудов[5] – 258 – 152.

Г. Исхаков – 249 – 168.

Башкаларныкы болардан ким булганга, шул ун кеше татарлар исеменнән Мәркәз Шурага сайланган булып чыкты.

Г. Исхакый тавыш күпчелеге ягыннан иң азаккы булып үтте.

Боларга якынраклар түбәндәгечә:

Студент Мамлиев[6] – 231 – 179.

Туктаров Фуад[7] – 218 – 173.

Саратов мулласы Янгаличев – 217 – 193.

Гомәр Терегулов[8] – 202 – 200.

Башкаларныкы тагын кимрәк.

Сайлау бетте. Ләкин бу хөррият рухы белән сугарылган аңлы

---

[1] Тәхкыйрь – мыскыл итү.

[2] Кәримов – Фатих Гыйльман улы Кәрими (1870-1937), язучы, журналист.

[3] Заһид Шамил – Шамил Заһид (Мөхәммәтзаһид) Мөхәммәтшәфи улы (1868–1920) – нашир, журналист, җәмәгать эшлеклесе.

[4] Ш. Мөхәммәдъяров – Мөхәммәдъяров Шакир Зариф улы (1883–1967), сәясәт эшлеклесе, хокук белгече, педагог.

[5] Максудов – Максуди Садретдин Низаметдин улы (1887–1957), дәүләт эшлеклесе, сәясәтче, хокук белгече.

[6] Мамлиев – Солтанбәк Мамлиев.

[7] Туктаров Фуад – Туктаров Фуад Фәссах улы (1880–1938), сәяси эшлекле, публицист.

[8] Гомәр Терегулов – Терегулов Гомәр Хәбибрахман улы (1883–1938), сәяси эшлекле, педагог.

кешеләрнең эш башында йөрүчеләремезгә иманын да бетерде.

Чөнки, ирекле Русиянең ирекле мөселманнарының беренче ирекле җыелышында кайчандыр үзен социалист дип игълан кылган «әфәнделәр»нең үзләрен Мәркәз Шурага үткәрү хакында бундый җәбер, бундый җәнҗал чыгаруга, шул җәбер вә җәнҗал белән үтүгә риза булуы, чыннан да, бер тарихи кара вакыйгадыр.

Без ирекле димез, халык теләге канун димез, халык теләгенә каршы җәбер ысулын гамәлгә кую фәкать залим иске хөкүмәтләр эше генә димез. Шулай дип сөйлимез, язамыз да, халык теләгенә каршы биш-ун солдатны мәйданга чыгарамыз. Бу хәлгә көлсәң, көлке түгел, җыласаң, күз яше әрәм!

*Г. Ибраһимов*

Мәкалә татар әдәбияты классигы, җәмәгать эшлеклесе, сәясәтче Галимҗан Ибраһимов (1887–1938) тарафыннан язылып, «Ирек» газетасының 1917 елгы 21 май (15) санында Г.И. имзасы белән басылган. Гарәп графикасында. Текст «Ирек» газетасыннан алынды. Гамәлдәге татар язуында беренче тапкыр дөнья күрә.

«Ирек» – 1917 елның 30 мартыннан Уфада чыга башлаган газета. Газета барлыгы биш ай ярым чамасы дәвам итеп, 35 нче саны чykканнан соң, шул ук елның сентябрендә «Авыл халкы» һәм «Солдат теләге» дигән газеталар белән берләшеп, «Безнең юл» исеме астында чыга башлый. Нашире – Ф. Сәйфи-Казанлы, мөхәррире – Г. Ибраһимов.

*Текстны, искәрмә һәм аңлатмаларны*
*Фәния Фәйзуллина әзерләде*

## Аңларга тырыштык, аңлый алмадык

*(Галимҗан иптәш Ибраһимовка җавап)*

Галимҗан иптәшнең 56 нчы [№] «Татарстан»да[1] миңа җавап уларак язган «Аңларга тырышыгыз» дигән мәкаләсе чыкты. Укып мәмнүн булдым. Мәсьәлә торган саен киңәя, миңа да бу мөһим мәсьәлә турысында әйтелеп бетмәгән фикерләрне әйтергә юл ачыла.

[1] Г. Ибраһимов. Татар әдәбиятында өченче дәвер. Аңларга тырышыгыз! – 1922. – 7 март (№56).

Иң элек Галимҗан иптәшнең мәкаләсендә дикъкатьне җәлеп иткән нәрсә – әдәбиятны дәверләргә аеру турысында булган шаблончылыктыр. Ысулы җәдидә дәверендә чыккан әдәбиятның һәммәсен бергә өеп, аларны, бер яктан, иске «Бәдәвам», «Тәкый гаҗәб»ләргә, икенче яктан, соңгы революция дәвере әдәбиятына каршы кую – мәсьәләне аз гына җентекләп караганда да әсассызлыгы күренеп тора торган бер нәрсәдер.

Галимҗан иптәшнең җәдид дәвере әдәбиятына мисал итеп китергән әсәрләре арасында, әдәби кыйммәтләре җәһәтеннән генә түгел, шәкел вә стильләре һәм рух вә мәгънәләре ягыннан да бер-берсеннән шулкадәр ерак нәрсәләр бардыр ки, аларны «җәдид әдәбияты» дип кенә бер почмакка ыргытуга аз гына әдәби зәүкы булган кеше дә разый булмас. Мәсәлән, Фатыйх Әмирханның әсәрләре, Риза казый хикәяләренә караганда, революция дәвере әдәбиятында булган Галимҗан Ибраһимов әсәрләренә күп якын торадыр.

Бу җәһәттән Гаяз үзе дә икегә бүленәдер ки, аның башта төче әхлакчылык рухында язылган «Тәгаллемдә сәгадәт», «Кәләпүшче кыз» һәм «Бай угылы» кеби әсәрләре белән, соңгы вакытта чыгарган «Тормышмы бу?», «Мулла бабай», «Сөннәтче бабай»лары кеби реальный тормышны тасвир иткән әсәрләре арасында җир белән күк аермасы кадәр аерма күрендәер. Бу соңгыларында нинди булса да мәгълүм бер фикер, фәлсәфә сатылмый, тормыш шул булган көйгә тасвир ителә. Аларның әдәби кыйммәтләре дә шунда һәм аларның бер дәвердә мәгънәле булып та, икенче дәвердә мәгънәсез булулары мөмкин түгел. Риязияттагы[1] хакыйкатьләр, фикер үзгәрүгә карап үзгәрмәгән, ике җирдә ике – революционер кашында да, революционер булмаган кеше кашында да һаман дүрт булган кебек, әдәбиятның мондый ялангач хакыйкатьләрдән гыйбарәт булганнары фикерләр, дөньяга карашлар үзгәрүгә карап, үзенең иске кыйммәте, мәгънәсен югалтмыйдыр. Әгәр дә бу мисал да ифратка кителгән дисәгез, тагын да якынрак бер мисал китерик.

Мәсәлән, бер шагыйрь иртәнге таң ату манзарасын тасвир итеп бер шигырь язды, яки бер рәссам шуның рәсемен төшерде,

---

[1] Риязияттагы – математикадагы.

менә боларга бер бәһа куйганда һичбер кеше бу әсәрләрнең революционныймы, түгелме икәнлеген тикшермичә, фәкать сәнгать таләпләрен үтәгәнме, юкмы икәнчелеген генә күздә тотачагы бик билгеле бер хакыйкатьтер.

Әдәбиятта сәнгать сәнгать өченме, түгелме дигән бик иске бер бәхәс бар. Монда без хәзер шул мәсьәләгә килеп төртеләбез.

Мин бу кечкенә мәкаләдә бу турыда үземнән бернәрсә дә әйтмичә, Галимҗан иптәшнең бу турыда үзен тыңлауны муафыйк күрәм. Ул үзенең «Аң альбомы»нда нәшер ителгән бик мөһим мәкаләсендә бу турыда шушы мәфһүмдә[1] бер нәрсә яза: «Сәнгать сәнгать өченме, түгелме бәхәсе үзе мәгънәсез бер бәхәс булып, мәсьәләгә һичбер болай килергә ярамый, әдәби әсәрләрнең кыйммәте монда түгел, бәлки хакыйкатьне дөрес иттереп, матур иттереп күрсәтүдәдер» ди.

Шулай итеп, Галимҗан иптәш реализмны үзенең соң чигенә җиткерә торган бер фикер әйтә.

Аннан соң, шул ук Галимҗан иптәш бервакыт, кайдадыр хәтеремдә калмаган, Гаяз хакында язган бер мәкаләсендә, «Ике йөз елдан соң инкыйраз»га зур әдәби кыйммәт биргәннән соң, Гаязның соңгы вакытта «Солдат», «Алдым-бирдем» кеби революция тәэсирендә язган нәрсәләрен яратмаган, «Гаяз үзенең чын сәнгатькәрлеген югалтты, вакытлы фикерләргә бирелеп, агитация эшенә кереште» мәзмунендә[2] язган иде.

Хәзер шул Галимҗан иптәш шуңа капма-каршы булган фикерләр белән мәйданга чыга. Дөрес, Галимҗан иптәш монда үзен юллауга тырышачак, мин «Мулла бабай»ларны бөтенләй кыйммәте беткән нәрсәләр дип әйтмәем, алар үзләренең тарихи кыйммәтләрен югалтмыйлар, алар хрестоматияләргә керәләр диячәк. Ләкин мәсьәлә шунда: иң элек боларда нинди мәгънә югалсын? Тукайның «Таң» шигыре мәңге искерми, мәңге мәгънәсен югалтмый торган бер әсәр булган кебек, Гаязның мәзкүр[3] әсәрләре дә андый югала торган бер нәрсәгә малик[4] түгелләр.

---

[1] Мәфһүм – эчтәлек.
[2] Мәзмунендә – мәгънәсендә.
[3] Мәзкүр – югарыда искә алынган.
[4] Малик – ия, хуҗа.

Болар публицистика түгел, гыйльми әсәрләр түгел, шуның өчен Рәшит казыйның[1] вакыйган[2] да артта калган, вакыты үткән фикерләрен сөйләгәндә, татар әдәбиятының мәңгелек хәзинәсе булырлык әдәби, шигъри әсәрләрне китереп кыстыруның мәгънәсе нәрсә?

Бу чагыштыруның аз гына әсасы3 бармы? Аннан соң бу әсәрләрне «Фәзаилеш-шөһүр»ләргә[4] чагыштыру мәсьәләне бөтенләй чыгырыннан чыгара. Галимҗан иптәш «Бәдәвам»[5], «Фәзаилеш-шөһүр»ләрне без җәүһәр дип таныйбыз ди. (Аннан соң китерә дә, боларны хәзер карчыклар гына укый, ди).

Ә мин әйтәм: болар берсе дә җәүһәр түгел һәм боларның җәүһәр булмаулары бик борынгы заманда язылуларыннан яки иске фикерләр тәлкыйн[6] кылуларыннан түгел, бәлки әдәби кыйммәтләре булмаудандыр. Юса юнаннарның[7] миладидан күп элек язылган «Илиада»лары әллә кайчан эштән чыкан игътикадлар[8], хорафатлар[9] белән тулы булган хәлдә, бу замандагы бөтен мәдәни телләргә тәрҗемә ителеп, бөтендөнья халкы тарафыннан укыла. Безнең «Фәзаилеш-шөһүр», «Бәдәвам»нарның исә әдәби дәрәҗәләре ноль, алар чүп. Аларны «Тормышмы бу?»лар белән бергә кую, хакыйкатән дә[10] чүп белән энҗене бергә өеп куюдыр.

Әгәр «Мулла бабай» искергән, мәгънәсез бер нәрсә булса, Галимҗан Ибраһимовның әсәрләре арасында, һич шөбһәсез, иң беренче урынны тоткан «Табигать балалары» да искергән, мәгънәсез бер нәрсә булырга тиеш. «Мулла бабай»ның бер урын-

---

[1] Рәшит казый – Ибраһимов Габдерәшит Гомәр улы (1857–1944) дин һәм җәмәгать эшлеклесе, публицист.

[2] Вакыйган – чыннан да, дөрестән дә.

[3] Әсасы – нигезе.

[4] «Фәзаилеш-шөһүр» (Изге айлар) – Җамалетдин Бикташи дигән мулла язган дини эчтәлекле әсәр. Беренче тапкыр 1854 елда Казанда басылган.

[5] «Бәдәвам» – гарәпчәдән: кабатлана торган, дини әдәбият ядкәре. Авторы мәгълүм түгел.

[6] Тәлкыйн – төшендерәеп сөйләү, аңлату.

[7] Юнан – грек.

[8] Игътикадлар – ышанулар.

[9] Хорафатлар – искелек калдыклары, легендалар.

[10] Хакыйкатән дә – чыннан да.

дагы «Шәкертләрнең хозурга чыгуы» дигән бабы[1] «Табигать балалары» белән янәшә куелырга тиеш бер нәрсәдер. Хәлбуки[2], профессор Гордлевский[3] тарафыннан русчага тәрҗемә ителеп, «Загородное гулянье шакирдов» исеме белән аерым бер китап хәлендә нәшер ителгән «Хозурга чыгу», «Мулла бабай»дагы шундый хисапсыз күп матур сәхнәләр арасында бер сәхнә вә бу бай картиналар залында бер картина гынадыр.

В. Либкнехт үзенең дусты Карл Маркс хакында язган хатирәсендә: «Маркcның һәр көнне укый торган әсәрләрнең берсе – Данте әсәрләре иде» ди. Соң бу Данте кем? Данте коруне вөстадан[4] килгән бер Италия шагыйре булып, аның язган әсәрләреннән иң мәшһүре «Илаһи комедия» дә дөньяда явызлык кылган кешеләрнең ахирәт көнендә ничек газап кылганлыкларын тасвир итәдер. Данте үзе дингә ышанучы, хәтта католиклар ноктасында торучы бер кеше, әмма Маркс булса, яңа материализмны нигезләүче бер кеше булганлыктан, боларны арасында фикердә аз гына да якынлык булуы мөмкин түгел.

Шулай булгач, Маркcның Дантега кызыккан җире кайда иде? Әлбәттә, Дантеның әдәби куәтендә иде. Шул ук Либкнехтнең бәянына күрә, Маркс хакыйкый тасвирның, тугры вә матур стильнең гашыйкы иде. Инде Маркс кебек бер даһи үзеннән җиде йөз ел элек килгән бер шагыйрьнең әсәрен һәр көнне укыгач, без ничек итеп аның бүгенге шәкертләренә әле соңгы җөзьэләре[5] чыгып та җитмәгән әсәрләрне иске, мәгънәсез нәрсәләр дип тәкъдим, вә аларны укыган кешеләрне карт хәлфә дип атау дәрәҗәсенә ирештек? Революция дәверендә бер-ике ел эчендә берничә гасыр алга китү шулай буламы?

«Бәдәвам»ны хәзер карчыклар гына укый, яки тарих язучылар гына укый. Бу турыда Галимҗан иптәш белән безнең арада низаг[6] юк. Ләкин «Тормышмы бу?», «Мулла бабай»ларны фәлән-

---

[1] Бабы – бүлеге.

[2] Хәлбуки – шулай булуга карамастан.

[3] Гордлевский Владимир Александрович (1876–1956), шәркыятьче-тюрколог.

[4] Коруне вөста – урта гасырлар.

[5] Җөзьэ – кисәк, бүлек.

[6] Низаг – ызгыш, талаш.

нәр генә укырга тиеш, фәләннәр укымаска тиеш дияргә булмый. Боларны һәркем укырга тиеш һәм аларны һәркем укый. Монда картлык-яшьлек, хәлфәлек-шәкертлек юк. Руслар Толстойны, Гогольне укыган мөддәттә[1], татарлар да Гаязны укыячак. Монда мәгънә эзләп уку, мәгънә эзләмичә уку дигән ике нәрсә булырга мөмкин түгел.

Сүз ахырында шуны да әйтеп китәргә кирәк ки, минемчә, Галимҗан иптәш белән безнең арада булган низаг милләтчелек, коммунистлык яки консерваторлык, революционерлык вә, гомумән, сәяси караштa булган бер аермадан килеп чыккан бер нәрсә түгел. Галимҗан иптәш моны юкка шул почвага тартырга азаплана. Бу чеп-чи әдәби бер бәхәстер.

Шуның өчен Галимҗан иптәш салкынканлылыкны саклый төшеп, «Лат, Манатларны»[2], «Әбүҗаһилләрне[3]» худка куймый торса, тагын да күңеллерәк булыр иде.

Галимҗан иптәшнең үзенең хосусый, бик артык хосусый булган фикерен бөтен яшь буын укучыларның карашы итеп тәкъдим итүе дә кирәгеннән артык бер җөрьәттер.

*Җ.Вәлиди*

Мәкалә «Татарстан хәбәрләре» газетасының 1922 елгы 10 март санында басылган.

*Текстны Рәисә Шәрәфиева әзерләде*

## Финляндиядә милли бер утырыш

Большевик явы нәтиҗәсендә ана йортымызны ташлап ил тышына мөһаҗирлеккә чыгарга мәҗбүр булган Идел-Урал төрек-татарларының бер бүлеге Финляндиягә чыккан иде. Бу төрек-татар мөһаҗирләре, дөнья сугышыннан элек үк финнар белән алыш-бирештә булып, мәмләкәтенең теле вә икътисади хәле белән шактый ук таныш булганга, хәзерге көндә качаклыкның

[1] Мөддәттә – вакытта.

[2] Лат, Манат – борынгы мәҗүси гарәпләрнең табыга торган потлары.

[3] Әбүҗаһил – көнчыгыш мифологиясендә «караңгылык атасы», кешеләрне аздыручы зат.

юксыллык вә ачлык кебек иярченнәренә бик үк бирелмичә, һәркем көченә вә тырышуына күрә, матди яктан кысынкылык күрмичә тормыш итә. Ләкин вакыт узып горбәттә яшәү[1] озая барган саен, мөһаҗирләрнең мөһаҗир булмаган яшь буыны мәйданга чыга башлады. Шуңа күрә бу җәмәгатьнең алдына, һәр яктан безгә бөтенләй башка булган бер мохит эчендә туып-үсәргә мәҗбүр булган бу яшь буынга дини вә милли тәрбия бирү мәсьәләсе килеп басты: Финляндия төрек-татарларының киләчәктә ана йортыбыз булган Идел-Уралдагы халкыбыз берлә бер милләт вә өммәт булып яшәргә мөстәхикъмы[2], түгелме икәнлеге тамак туклыгы вә өст-баш бөтенлеге белән үлчәнмичә, әйтелеп узганча, дини вә милли вазифаларының тәртипкә салынып, уңышлы бер сурәттә алынып барылуы белән генә үлчәнәчәктер. Шуңа күрә бу яшь буынга дини вә милли тәрбия бирү мәсьәләсе, башта Финляндия мөселман оешмасының башкарма җыйнавының (һәйәтенең) вә акылы башында булган һәрбер гаилә башының уртак кайгыларыннан берсе вә иң кирәклесе рәтенә керә башлады; ләкин, кызганычка каршы, халкыбызның җәмәгать тормышына ул кадәр өйрәнмәгәнлеге сәбәпле һәркем үз юлында эш күрүчән булганга, күп вакытта бер фикергә килә алмыйча, болай да чикле булган матди вә мәгънәви көчләребезнең зәгыйфьләнүе, халкыбызга вә яшь буынга дини вә милли тәрбия бирү эшләренең өмет ителгәнчә тәртипкә салынуына бик зур киртә булып килгәли иде. Шулай да булса бу мәсьәлә әгъзалары күбрәк булган Һельсингфорс[3],Таммерфорс[4] (бераз да Абу[5]) шәһәрләрендә торучы төрек-татар колонияләре өчен уку чорында (кыш) уку яшендә булган балаларга дин вә ана теле дәресләре бирү белән, моңар кадәр бертөрлеләнеп киленгәләсә дә, Финляндиянең башка шәһәр вә авылларына

---

[1] Горбәттә яшәү – мөһаҗирлектә, чит илдә яшәү.

[2] Мөстәхикъмы – хаклымы, лаекмы.

[3] Һельсингфорс – Финляндия башкаласы Хельсинки шәһәренең шведча атамасы.

[4] Таммерфорс – Финляндиядәге Тампере шәһәренең шведча атамасы.

[5] Финляндиянең көньяк-көнбатышында урнашкан порт-шәһәр. Фин телендә Турку дип аталса, шведча Або (Абу) дип йөртелә.

чәчелгән саны аз төрек-татар колонияләренең балаларына кыш вакытында милли тәрбия бирү мөмкинлеге юк иде. Шуңа күрә баштарак милләтебезнең киләчәк өмете булган бу балаларның ят мәктәп вә чит мохит эреме белән финләшеп китүләре куркынычы да күзгә бәреләә башлаган иде. Әле дә, тәңрегә шөкер, баштарак ачык күзле гаилә башларының вә соңгы өч ел эчендә татар милли оешмасы җыйнауның һиммәт вә гайрәте белән җәйге ял итү вакытларында Териоки[1] вә Һювинкә[2] шикелле Финляндиянең җәйләү урыннарында ике айлык курслар ачылгалап, кыш көне милли мәктәпкә йөри алмаган балаларга дини вә милли тәрбия бирү чарасына керешелеп килгәләнде. Бу елда башка еллардагы кебек, Ярвенпяа[3] вә Териокидә җәйге курслар ачылып, беренчесендә имам Вәли Әхмәд Хәким тарафыннан 25 балага, соңгысында укытучы Гыйбадулла Мортаза тарафыннан 18 балага дин вә ана теле дәресләре бирелде.

Териокидә ачылган курс 15 августка кадәр дәвам итеп, 16 августта башкарма җыйнавы әгъзаларыннан Исмәгыйль әфәнде Гарифулла вә шул вакытларда туры килеп Териокидә булган «Яңа милли юл» баш язучысы Гаяз әфәнде Исхакый җәнабларыннан торган җыйнау (һәйәт) тарафыннан балалар имтихан кылындылар. Имтиханның икенче көнендә курс ябылу уңгае белән һәр яктагы кебек Териокинең вакытлы вә һәр замангы төрек-татар колониясе әгъзаларына програмлы бер чәйле утырыш ясалды. Бу утырыш курска дәвам иткән шәкертләргә имтихан шәһадәтнамәләре бирү белән башланды. Аннан соң бу ел Мәүлед көне август аена туры килгәнгә, шул мөбарәк көн хөрмәтенә балалар тарафыннан хор белән «Мәүлед таңы» исемле шигырь җырланып, соңра утырышта хазир булган җәмәгать тарафыннан аягүрә торылып, нәби[4] мөхтәрәмебез рухына өч мәртәбә салават укылгач, Корьән укылып багышланды. Шуның

[1] 1939 елга кадәр Финляндиягә кергән, хәзерге вакытта Россиянең Зеленогорск шәһәре.

[2] Финляндиянең көньягындагы Хювинкяа шәһәре.

[3] Финляндиянең көньягындагы шәһәре.

[4] Нәби – пәйгамбәр.

белән утырышның дини бүлеге бетеп, кунакларга сумса белән чәй таратылды. Чәйдән соң балалар тарафыннан «Халкым өчен», «Милли моңнар», «Әй, татар», «Кошларга» , «Әй, авыл» шигырьләре хор белән җырланды вә балалар алкышланды. Җыр араларында, эчке мәгънәләре белән яшьләрнең күңелләрендә ил вә халык сөйгесе, ата-анага хөрмәт вә тырышлык тойгыларын уятырлык вә куәтләндерерлек шигырьләр укылып, утырышның рәсми бүлеге тәмамланды. Соңра утырыштагыларның үтенүләре буенча програмнан тыш чыгышлар башланып, Г. Кәриминең «Былбылга» исемле шигыре, «Уел» көенә Разия туташ Хәйретдин тарафыннан – ялгыз; «Таһир белән Зөһрә»дән «Хан кызлары» ариясе белән Ф. Туйкинның «Идел буйларында» дигән шигыре Фатыйма туташ Вафаның кушылуы белән – икәүләп – җырланып, утырышны ямьләндергән Разия вә Фатыйма туташлар да хазир булганнар тарафыннан бик алкышландылар.

Утырышның бөтен бүлекләре тәмам булгач, Гаяз әфәнде Исхакый җәнабләре: «Киләчәктә урыс буендырыгыннан котылачак мөстәкыйль илебезнең иркле әгъзалары булачак яшь буынга ничек кенә вә нинди генә юл белән булса да, дини вә милли тәрбия бирү мәсьәләсе һәр гаилә башының вә бөтен Финляндия төрек-татар оешмасының иң кирәкле вә иң җаваплы вазифаларыннан берсе икәнлеген ачып биргәннең соңында, бу җәйге курсның балаларга биргән файдаларыннан бик куанып сөйләде. Бу хәерле эшнең киләчәк елларда да дәвам итә баруын теләп, гаилә башларының вә милли оешма әгъзаларының һәртөрле фидакарьлекләрдә булачакларына чын күңелдән ышанганлыгын белдерде. Шулай булса да, киң Могылстан вә Төркестан сахраларын тарсынып, ярты Яурупаны кул астларына алып, заманасының иң куәтле император вә чарларын үзләренә баш идергән каһарман бер милләт балаларының Финляндиянең бер почмагында, дини вә милли дошманыбыз булган урысларның берьеллык баскыч мәктәбенең бер бүлмәсе белән генә канәгатьләнеп, шунда балаларыбызга дини вә милли тәрбия бирелүе вә бүгенге шикелле милли утырышлар ясалуы белән генә калу, татар милли минлегенә бигүк килешеп бетмәгәнлеген

аңлатканның соңында, киләчәктә мондый милли утырышларның татар маңгай тире белән табылган акчага алынган яки салынган бер бүлмәдә, кечкенә булса да, татар милли оешмасының үз йортында ясалуын теләп вә өмет итеп утырышта булганнарның күңелләрендә бик тирән эз калдырган эремле бер нотык сөйләде.

Соңра башкарма җыйнау әгъзаларыннан Исмәгыйль әфәнде Гарифулла сүз алып, әүвәлән балаларга: киләсе курска кадәр бу ел укылган вә өйрәнелгән нәрсәләрнең онытылмавы өчен кыш көннәрендә дә дин вә ана теленнән бирелгән дәресләрне кабатлап, үз телебездә язылган китапларны укыштыргалап торырга кирәклеген хәтерләткәннең соңында, бу мәсьәләдә бөтен кыш көне фин мәктәпләренә йөреп, фин дәресләре белән мавыгачак балаларга баш-күз булып тору гаилә башларының, бигрәк тә аналарның һичбер онытмаска тиешле булган бер изге вә җаваплы бурычлары икәнлеген, бик җанлы рәвештә аналарның исләренә төшереп сүзен бетерде. Шуның белән өйләдән соң сәгать өчтә башланган утырыш кичке сәгать җидегә кадәр сузылып, кунаклар киләсе елларда да шундый күңелле милли утырышларның булгалап торуын теләкләшеп, шат күңел вә ачык йөз белән таралыштылар.

*Кыпчаклы*

Мәкалә «Яңа милли юл» журналының 1930 елгы 10 нчы (октябрь) санында «Кыпчаклы» имзасы белән «Башкармага хатлар» бүлегендә басылган. Гарәп графикасында. Гамәлдәге татар язуында беренче тапкыр дөнья күрә. Текст журналдан алынды.

Г. Кәрими – Мөхәммәдгариф Гыйльман улы Кәримов (1892–1934), җәмәгать эшлеклесе, әдип, журналист. 1930 елдан «Яңа милли юл» журналында эшли.

... Ф. Туйкинның «Идел буйларында» ... – Сүз язучы, фольклорчы Фазыл Кәрим (Әхмәткәрим) улы Туйкинның (1887–1938) 1912 елда язылган «Ямьле җәй» («Зөләйлүк» көенә) шигыре хакында бара. Аның беренче строфасы «Идел буйларында киң болында ...» дип башлана.

*Текстны, искәрмә һәм аңлатмаларны*
*Гөлназ Хөснетдинова әзерләде*

## Гаяз Исхакыйның 20 еллык гэзитчелек бәйрәме

Мөһаҗирлекдә яшәүчеләрнең күңелләре һәрвакыт төшкен булганга, алар арасында булган һәрбер бәйрәм үткәнне сагындыра торган, илендән аерылганын хәтерләтә торган кайгы бер көн хәлен ала. Бик күб вакытларда бәйрәмгә җыелган ибдәшләр арасында, җыелышның ахыры илне сагыныб, туганын, кардәш-кабиләсен үзләб күз яше түгүләр берлә,

*Чәчәк идек илләрдә,*
*Чәчелдек чит җирләргә,*
*Тагы да чәчәк булыр идек,*
*Кайтсак туган илләргә.*

җырында өмид-өмидсезлек бергә кушылган дәрд берлә, моңлану берлә бетә. Бу илдән, җирдән аерылу бәйрәмләрдә тагы да ныграк сизелгәнгә, Аурупаның гөрләб торган калаларында бу көнләрдә үзеңне өзек, ят итеб хис итү тагы да тирәнрәк булганга, мондый бәйрәмләрне мөһаҗирләр бер курку берлә каршы алалар вә бөтен котлашуларны, киләчәк бәйрәмләрне ирекле илдә каршы алырга язган булуын теләб башлыйлар һәм шуның берлүк бетерәләр. Бу teләкне алар чын күңелдән дустларына һәм дошманларына бердәй телиләр. Бу вакыт бөтен көнләр бер өмид уты берлә яна.

Төрле илләрдә, төрле халыкларның бәйрәменә очраганда алар бер кайдан – шул халыкның оныттылыб бәйрәм итүенә кызыгыб, икенче якдан – аның бае-ярлысы бергә, шундый тынычлыкда бәйрәм итә алуын көнләб, аны катлаулы бер хис берлә каршылыйлар. Ирексез, бездә кайчан шулай булыр икән, без кайчан шул көнне күрербез икән дигән уйга чумалар. Шуңар күрә мөһаҗирлекдә мондый бәйрәмләрне ясаргә берәү дә ашыгыб тормый вә алар ясаганда да илдәге күк җанлы булыб чыкмый. Шуңар күрә Гаяз бәкнең өч ел элек булыб үткән әдәби хезмәтенә 30 ел тулу көне дә һичбер башка көнләрдән аерылмады. Бәйрәмсез генә, аңа һичбер төрле аерма ясамыйча гына үтеб китде. Менә бу елда шул ук әдибнең мөхәррирлегенә, гэзитчелек эшенә 20 ел тулу көндә, шулай тын гына үтәчәк булды. Ләкин Гаяз бәкнең хәзер яши торган Варшау шәһәренең аңлылары моңа күнмәделәр. Алар бу көнне, бик өстдән генә булса

да, башка көнләргә караганда бераз башкачарак итеб үткәрергә кирәк табдылар вә шул көн өчен Варшауда кечкенә генә булса да бер мәҗлес ясарга карар итделәр: төрле илләргә таралган милләтдәшләребез безгә чакырулар җибәрделәр. Боларның күбесе еракда, бик еракда яшәгәнгә, алар үзләре килә алмаячаклар иде. Ләкин аларның рухлары, омтылулары шул мәҗлесдә яшәргә, шундагылар берлә бергә булырга тиеш иде.

18 нче майда билгеләнгән бәйрәм кичәсе башланыб өлгермәде, дөньяның төрле почмагына таралган илдәшләрдән тәбрик телеграммалары, котлау мәктүбләре килә башлады. Мәҗлес вакыты җитде. Украина хөкүмәте назире – генерал Сальский[1], Гөрҗи хөкүмәте министры – мусье Салакай вә Төркиядәге сәфире – мусье Мдивани[2], Азәрбайҗан милләт мәҗлесе рәисе – Рәсүлзадә Мөхәммәд Әмин бәк, шимали Кавказ истикъляли комитеты рәисе – Сәгыйд бәк Шамил, Кырым хөкүмәтенең хариҗия назире – Җәгъфәр бәк Сәид Әхмәд, Кубан хөкүмәтенең назире – мусье Сулятицкийләр бер-бер артлы башладылар. Прометей комитетына кергән төрле милләт вәкилләре һәм бик күб җәмәгать эшчеләре, мәбгусләре[3] вә мөхәррирләре килделәр.

Юбилей иясе һәм кунаклар урынларга утыртылдылар. Мәҗлесне ясаучылар исемендән Госман мирза Кувич (?) кунакларга бу көннең Идел-Урал хәрәкәтендәге урынын аңлатыр өчен кыска бер нотык сөйләде: Гаяз бәкнең нинди гәзитләр чыгаруын, нинди мәсләккә хезмәт итүен, аның бу юлда очраткан киртәләрен, «Таң йолдызы»ндан башлаб «Милли юл»га кадәр дәвам иткән шул 20 еллык гәзитчелек тарихын берәм-берәм күздән үткәреб узды. Шул көнләрне искә алу мәҗлесенә килгән кунакларга рәхмәт укыды.

Аның артындан «Прометей» исемендән рәис могавине[4] Мдивани сүз алды: Прометей байрагы астында үзләренең истикъляльләре өчен тартыша торган милләтләр исемендән Идел-Уралның бу көнен котлады. Гаяз бәкне шул 20 еллык

---

1 Сальский – Владимир Петрович Са́льский (1885–1940) – Украина хәрби эшлеклесе.

[2] Мдивани – Симон Мдивани (1876–1937).

[3] Мәбгусләре – депутатлары.

[4] Могавине – ярдәмче.

гәзитчелеге берлә тәбрик итде. Андан соң ул Гаяз бәкнең шәхесенә килеб: «Без Прометей эчендә берләшкән милләтләр, Гаяз бәкдә сынмый торган бер иман, армый торган бер көч күрәбез. Без өмидсезлеккә батканда аның сүзләре безне җанландыра. Мин Гаяз бәкнең алдагы бәйрәменең мөстәкыйль Идел-Уралда булганын күзем берлә күргән кебек булам. Гаяз бәкне күргән саен шул киләчәккә иманым ныгый. Яшьдән Идел-Уралның армый-талмый тырышкан хезмәтчесе, мөхәррире Гаяз «бәк», – дип сүзен бетерде.

Украина исеменә сүз сөйләгән генерал Сальский башда Украина җөмһүрияте рәисе, андары Левицкий җәнабләренең читдә булганга мәҗлескә килә алмавындан мөтәәссир булганын сөйләде вә аның исемендән мөхәррирне котлаб, рәис җөмһүрнең тәбрик мәктүбен бирде. Соңындан Украина мөһаҗирләренең тәбрикләрен табшырды.

Андан соң Азәрбайҗан милләт мәҗлесе рәисе Мөхәммәдәмин бәк борынгы Русиядә яшәгән төрек-татар матбугатының тарихы, матбугатның төрк дөньясында уйнаган роле һәм Гаяз бәкнең шул эшдә тоткан җире турында тәфсилле вә гыйльми кыйммәтле бер нотык сөйләб, аны азәриләр исемендән тәбрик итде.

Гөрҗестан хөкүмәте исемендән министр мусье Салакай сүз алды. Ул күбрәк Гаяз бәкне шәхсинән котлады: «Прометей» комитеты корылганда без – гөрҗиләр, мин үзем дә мондан Идел-Уралга ни чыгар икән, дип шөбһә берлә карый идем. Ике еллык бергә эшләү Идел-Уралның истикъляль өчен нигезе ни кадәр нык булганлыгына безне тәмам ышандырды. Гаяз бәкнең самимилеге, уртак йөкне тартышуга һәрвакыт хәзер булыб торуы безнең барыбызда да аңа каршы хөрмәт уятды, аны сөйдерде. Мин бүген сезнең арагызда Гаяз бәкнең бер буйдан ничек 20 ел эшләб килүен күргән кебек булдым. Аның тагын да шулай ук эшләвен, ләкин бәйрәмләрен иректе илдә булуын телим», диде.

Кырым вәкиле Сәид Әхмәд Җәгъфәрнең, Кырым берлә Казанның кайгыларының, аларның мәдәни тарихы берлеге, Кырымлы Исмәгыйль бәк берлә Казанлы Зөһрә ханым Гаспринскийларның

берләшеб чыгарган «Тәрҗеман», «Галәми нисван»лары турында сөйләде. Соңгы елларда бу берлекнең кирәк мөһаҗәрәтдә, кирәк илебездә булсын, бик ныгыганын әйтеб, Гаяз чыгарган гәзитләрнең төрк берлеге нигезендә барганын һәм Кырымның бөтен кайгыларын «Идел» һәм «Сүз»нең үз кайгысы итеб каравын хәтерләтде. Бүгенге бәйрәмнең Идел-Урал бәйрәме генә булмыйча, бөтен төрк илләренең, бигрәк дә Кырымның үз бәйрәме булуын сөйләде. Сәгыйд бәк Шамил үзенең сүзен мөселманлыкдан башлады: «Безне Идел-Урал мөселманлары берлә уртак мәдәниятдән башка дин-мәзһәб дә берләшдерә. Бу берлек борынгы заманларда мөдәррисләр алышу төсендә булса, соңгы елларда мөнәүвәрләр безне уртаклашу юлы берлә дәвам итде. Безнең мәрхүм кардәшебез Заһид Шамил Идел буе төркләренең Мәскәүдәге илчесе иде. Безнең мәрхүм Әхмәд Саликать[1] Учр. Собраниедә Идел буеның вәкиле иде. Бездә бүген дә бик күб Идел буйлы ир-хатын эшләб тора. Болар безне беребезгә нык баулар берлә бәйләб киләләр. Прометейда Гаяз бәк Идел-Уралның милли вәкиле булыб эшләсә, ислам дөньясында ул СССРдагы мөселманларның хокукы өчен тартышучы бер мөхәррир. Ул һәр якдан безнең үз кешебез», диде.

Сүз юлы Төркестанлы кардәшләребезгә килде. Төркестан истикъляль комитеты рәисе Мостафа бәк Чокайның[2] мәҗлескә килә алмавын белдергән мәктүбе берлә котлау телеграммы укыды.

Мондан соң бер ләһ җәмәгать эшчесе аякка калыкды. Мөхәррир үзе дә монда 13 ел гына элек илсез, йортсыз мөһаҗәрәтдә яшәгәнгә, горбәтдә ясалган бу бәйрәмнең нинди авыр хис эчендә уздырылганын белә иде: «Мондан берничә еллар элек, без поляклар, сезнең кебек читдә, горбәтдә яши идек. 10 нчы елларда мин – Русия университетларының берсенең студенты – Австриягә чыкдым. Кракауда[3] безнең милләтчеләребездән берәү

[1] Әхмәд Саликать – Әхмәдбәк Цаликов (1882–1928), мөселман-төрки халыкларның милли азатлык хәрәкәте җитәкчеләреннән, «Сүз» газетасы нашире.

[2] Мостафа Чокай ( 1890–1941) – сәяси эшлекле, галим, икътисадчы, публицист.

[3] Кракауда – Краков, Польша шәһәре.

поляк яшьләрендән гаскәр көче хәзерләү берлә шөгыльләнә вә шуның өчен гаскәр курслары ясый иде. Ул чакда бик күб кеше аңа булмый торган хыял артындан йөрүче дип карый иде. Ләкин без – яшьләр – аның һәр сүзенә ышана идек. Ул курсларга төрле җирләрдән җыела идек. Курсларыбыз тәмам булды. Төрлебез төрле якга таралачак булганга, бер аерылу мәҗлесе ясалды. Безнең остазыбызны шул көнге әхвалгә караб, бер өмидсезлек баскан иде. Ул безгә: «Инде мин картайдым. Миңа инде мөстәкыйль Ләһстанны күрү насыйп булмас. Сез яшь. Мин бу идеяне сезгә табшырам. Сез бу фикерне үтермәгез, мөстәкыйль Ләһстанны күрергә тырышыгыз, диде. Менә шул көндән күб үтмәде – дөнья сугышы башланды. Безнең остазыбыз поляк милли гаскәрләренең башлыгы булыб, мөстәкыйль Ләһстан байрагын күтәрде. Берничә ел канлы тартышдан соң Ләһстан терелде. Бу кеше бу илне терелтүче, бөтен ләһләрнең иң сөя торган каһарманы булды. Ул безнең маршал Пилсудский[1] иде. Милләте өчен үзен фида иткән кешеләрдә андый өмидсезләнү вакытлары була. Гаяз бәк бу сездә дә илендән читдә яшәргә мәҗбүр булган, иленә керүе кызыл урыслар тарафындан тыелган, сездә дә мондый кара уйлар булу ихтималы мөмкин. Ләкин һичбер вакыт өмидсезләнмәгез. Хаклык сезнең тарафда. Ләһстан мөстәкыйль булыб чыккан кебек, Идел-Уралда мөстәкыйль булыб торачак», диб котлады.

Тагы бик күбләр котладылар. Төрле әдәби, гыйльми оешмалар исемендән тәбрик сүзләре сөйләнде. Сүз арасында вакытның узганы сизелми дә калды. Сәгать 12 не узыб китде.

Гаяз бәк аякка калыкды. Ул кунакларга шул кичкенә мәҗлесне зур итеп килүләре өчен рәхмәт укыды. Ул бу юбилейны үзенең шәхси бәйрәме итеп түгел, үзе берлә бергә эшләп килгән ибдәшләренең уртак бәйрәме итеп каравын һәм үзенең шулар арасында бер эшче генә икәнлеген сөйләде дә: «Әфәнделәр, бу бәйрәм берлә бәйләнгән берничә онытылмаслык нокталар бар, мин шуларга туктап үтмәкче булам. Минем 20 еллыгымдан берничә ай гына элек Идел буенда татар матбугатының 20 еллыгы

[1] Пилсудский – Юзев Пилсудский (1867–1935), дәүләт һәм сәяси эшлекле.

тулып үтде. Идел буенда беренче гәзит «Казан мөхбире» 1905 елның октябрендә чыккан иде. Мондан бер-ике ел элек шул көнгә (1930 ел 29 октябрь искечә) хәзерләнү өчен Кызыл Татарстанда бер аерым комитет төзелгән булса да, Татарстан һәм Башкортстанда ул бәйрәм ителмәде. Идел буеның мәдәни тарихында зур урын тоткан бу көн төрк-татар илендә Роза Люксембургның үлгән көне дәрәҗәсен дә ала алмады. Ул көн һичбер бер аермасыз гына үтде. Менә бу Идел буе матбугатының 20 еллык бәйрәме минем гәзитәчелегемнең бәйрәме төсендә булса да, беренче мәртәбә читдә, чит илдә эшләнде. Бу бәйрәм, кызганыч, безнең кан, дин кардәшләребезнең илендә ясала алмады. Бу бәйрәм борынгы тарихы берлә безнең Идел буе берлә багланган, соңгы елларда милләтләрне изүче, милли мәдәниятләрне җимерүче урысларга каршы сафда булган ләһләрнең яңа туган ирекле илендә ясалды. Моңа катышучылар арасында минем берлә бергә каләм тартышы алып барган Идел буйлы ибдәшләремнең бик күбесе хәзер була алмаса да, милли истикъляльләрен бәйнәлмиләл мәйданга чыгарган бөтен милләтләр хәзер булды.

Мин бер Идел буе гәзитәчесе сыйфаты берлә, матбугатның бу олуг көнендә янымда ибдәшләремнең булмавына, бу матбугатның туган илендә бу бәйрәмне ясарга заманының мөсагыйд булмавына[1] бик кайгырсам да, Идел буе матбугатының бәйнәлмиләл сахәдә[2] шундый хөрмәтле бер урын тотуына вә сез мөхтәрәм ибдәшләрнең безнең бәйрәмебездә бергә булуына бик сөенәм һәм шуның шадлыгы берлә кайгыларымны каблыйм. Яшәсен матбугат берлеге, яшәсен Прометей», дип сүзен бетерде. Зур бер эчке берлек берлә дәвам иткән мәҗлес бик соң гына таралды.

Бер мәҗлескә генә бөтен кунакларны чакырып бетерергә мөмкин булмаганга, 19 майда мәҗлес тагы дәвам итдерелде. Мәҗлесдә азәри, Кырым, шимали Кавказ, Идел һәм Ләһстан мөселманлары гына булганга, ул тагы да җылырак, тагы да җанлырак чыкды. Бик күп котлау, теләкләрне эченә алган сүзләр сөйләнде.

---

[1] Мөсагыйд булмавына – мөмкинлек бирмәвенә.

[2] Бәйнәлмиләл сахәдә – халыкара мәйданда.

Ике мәҗлесдә дә үзләре килә алмаганга, бәйрәм иясен котлап җибәргән 30 дан артык мәктүб һәм телеграмма укылды.

Шулай итеп, Яурупаның урта бер җирендә Идел буе матбугатының зур бер мөхәрриренең 20 еллык гәзитчелек бәйрәме уздырылды. Мондан соң милләт эшчеләребезнең һәм милли оешмаларыбызның алдагы бәйрәмләренең үз илебездә, үз йортыбызда булуын телибез.

*Ибраһим*

Мәкалә «Милли юл» журналының 1931 елгы июль санында басылган, текст шуннан алынды.

*Текстны Ләйлә Гарипова әзерләде*

## Русия мөселманлары турында ислам дөньясы

Шәйхел Әзһәрнең Русия мөселманларының хәлләрен тикшерер өчен билгеләгән утырышы рамазан аенда берничә мәртәбә җыелды һәм Шәйхел Әзһәргә бирелгән мәгърузәне[1] җентекләп тикшереп чыкды. Андагы большевик хөкүмәтен гаепләгән 12 маддәнең һәрберсенә аеры-аеры документлар сорады. Гаяз Исхакый һәм Сәгыйд Шамил бәйләр җыелышка чакырылып сораулар алынды. Гаяз Исхакый боларны ачык күрсәтә торган большевик нәшриятын (динсезләр оешмасы нәшрияты, «Алласызлар» мәҗмугасы, дин-фән мәҗмугасын һәм комсомоллар өчен язылган динне мыскыл итә торган китапларны) бергә алып килгән иде. Ул аларны җыелышка тәкъдим итде. Аларның бик күп җирләре тәрҗемә ителде. Мәсҗедләрнең ябылуы һәм Коръәннең җыелып алынуы турында большевик матбугатындан алынган бик күп дәлилләр гарәпчәгә тәрҗемә ителеп бирелде.

Бу дәлилләр Шәйхел Әзһәрнең үзенә һәм шулай ук җыелышдагы голямаларга бик авыр тәэсир итде. Җыелышның рәсми утырышында – совет Русиядә исламияткә каршы тарихда охшашы булмаган бер золым, хөкүмәт тарафыннан эшләнә икән һәм ислам дөньясының дини оешмаларына Русия мөселманла-

[1] Мәгърүзәне – проектны.

рын химая итү[1] фарыз икән[2] – дигән фәтва кабул ителде. Шул карар буенча, Мисырның иң зур дини оешмасының башлыгы булып, Шәйхел Әзһәр бер протест ясады. Ул бөтен ислам дөньясына мөрәҗәгать итеп, аларның совет золымындан котылулары турында дога кылырга өндәде. Шәйхел Әзһәрнең бу протесты рамазан гаеде көнне басылып чыкды.

Вәкилләребез Кодесдагы ислам корылтаенынң рәисенә, Фәләстыйн, җамигъларында Русия мөселманларының большевик золымындан котылуы өчен дога кылдыруны үтенеп мөрәҗәгать итделәр. Мөфти хәзрәтләре гаед намазында мәсҗедел Аксада ун мең халык алдында, Русия мөселманларының бу золымдан котылулары өчен дога кылды һәм халыкка Русиядәге хәлне аңлатды.

Вәкилләребез шулай ук һәрбер ислам патшасына аерым мәктүбләр берлә, Шәйхел Әзһәргә бирелгән мәгърузәнең күчергечен кушып күндерергә карар иткәнләр иде. Алар гаед көнендә шул мәктүбләрне алып, Мисырдагы мөселман хөкемдарларының илчеләрен (Хиҗаз, Әфган, Иран, Гыйрак) зиярәт итеп, Русия мөселманларының бу көнге хәлен сүз берлә дә аңлап, шул мәктүбләрне падишаһларына җибәрүләрен үтенделәр. Русия исламлары турында матбугатда бик күп язылган булганга, илчеләр эшне аңлаган бер хәлдә иделәр. Аларның барысы да мәктүбләрне үзләренең падишаһларына күндерәчәкләрен һәм аларның да бу авыр золым каршында ялгыз сәерче[3] генә булып тора алмаячакларын сөйләделәр.

Шәйхел Әзһәргә бирелгән мәгърузә гаед көннәрендә гарәп дөньясының бөтен матбугатына җибәрелгән иде. Мисырдагы бөтен гәзит һәм мәҗмугаларда алар тулы көенчә басылдылар. Әле хәзерге көндә дә, анда кузгатылган мәсьәләләр турында, һаман языла тора. Алар Мисыр хөкүмәтен һәм Мисыр әфкяре гомумиясен Русия мөселманларының хәлләрен яхшыртыр өчен, совет хөкүмәте алдында тәшәббесдә булырга[4] өндиләр. Андагы

[1] Химая итү – яклау.
[2] Фарыз икән – тиеш икән.
[3] Сәерче – күзәтүче.
[4] Тәшәббестә булырга – эшкә керешергә.

төрле җәмгыятьләрдә хәзер бу турыда протест кампанияләре ачу һәм зур җыелышлар уздыру турында сөйләшүләр дәвам итә. Бу мөнәсәбәт берлә гарәп матбугатында язылган мәкаләләр бик күп булганга, аларның санын бу урында санап үтү мөмкин түгел.

Бөтен ислам дөньясы бу бәйрәмдә Русиядәге мөселманларның хәле берлә мәшгуль булды. Тиз көндән ислам дөньясының әфкяре гомумиясе үзләренең хөкүмәтләрен Русиядәге мөселманларны химая итү турында рәсми адым ясатырга мәҗбүр итәр дип өмит итәбез.

Шәйхел Әзһәр янында корылган мәҗлес, Гаяз Исхакыйның биргән документларында бик күп мәгълүмат барлыгын искә алып, большевик золымын тикшерү эшен дәвам итдерергә булды. Бу һәйяткә Русия мөселманларындан берничә әгъза чакырылачак. Бу һәйят, Румада папа янында, совет Русиядәге христиан динен саклау һәйяте кебек, даими рәвештә Русия мөселманларының дини эшләре берлә мәшгуль булачагын һәм аларны химая итү юлларын эзлиячәк.

Мәкалә «Яңа мили юл» журналының 1932 елгы 3 нче санында басылган. Текст басмага журналдан алынды.

*Текстны, искәрмә һәм аңлатмаларны*
*Гөлчирә Ханнанова әзерләде*

## ХАТЛАР

*Мәгълүм ки, Гаяз Исхакый исемен һәм язма мирасын халкыбызга кайтару мөмкинлеге ачылгач та, аның эпистоляр иҗатын барлауга да игътибар бирелә башлады. Моның ачык бер чагылышы – әдип «Әсәрләр»енең 15 томлы басмасына аның хатлары (һәм автобиографик язмалары) урнаштырылу (14 т.; Казан, 2013). Томны төзүче, текстларны, искәрмә һәм аңлатмаларны әзерләүче Фәния Фәйзуллина «Кереш сүз»ендә, хат текстларының башлыча ТР Милли архивыннан, М. Горький музеендагы И. Нуруллинның шәхси фондыннан һәм ТӘһТИдән алынуын әйтеп, әдип хатларының әле киләчәктә табылачагына ышаныч белдерә. Әйтергә кирәк, якындагы елларда да Г. Исхакый каләменнән чыккан әдәби һәм публицистик текстларны эзләү һәм матбугатка тәкъдим итү юнәлешендә эш дәвам иттерелде. Шул исәптән, хатларын да. Г. Исхакыйның быелгы юбилее вакытларында аларның берничәсен бастырып чыгару мөмкинлеге дә туды. Шул ук вакытта Г. Исхакыйның үзенә язылганнары да табылды.*

*Түбәндә укучыларга тәкъдим ителә торган хатлар арасында аеруча да әһәмиятлеләре – Гаяз Исхакый белән Камил Мотыйгый хатлары. Алар Уральск шәһәрендә «Әлгасрелҗәдид» журналын нәшер итүгә әзерләнү вакытларында – 1905 ел башында язылганнар. Әдипнең әүвәлге хаты кулъязма «Әлгасрелҗәдид»кә аның 4 нче санында К. Мотыйгыйның татар язучы һәм журналистларына мөрәҗәгатенә җавап рәвешендә җибәрелгән була. Әйтергә кирәк, Г. Исхакый аның журнал чыгаруга омтылышын хуплый һәм журнал битләрендә әдәби әсәрләре белән генә түгел, бәлки мәкаләләре белән дә чыгыш ясарга теләк белдерә. Ул журналны Казанда чыгару җиңелрәк итеп күрә. К. Мотыйгый бу фикергә каршы төшми, тик татарлар яшәгән*

*башка шәһәрләр дә халыкны «мөмкин кадәр мәдәнияткә ияләштерү өчен көрәш»ергә тиешләр итеп саный, татар журналистикасы, басмачылык, нәшрият өлкәләрендә «туктаусыз фикер алышу»ны хуплавын яза.*

*Хатларның кайберләре Г. Исхакыйга адресланган, кайберләре исә аңа язылмаган да, әмма аларда сүз бу әдипнең эшчәнлегенә мөнәсәбәттә бара. Мәсәлән, Ибраһим Акчурин «Вакыт» газетасында чыккан «Идарәгә мәктүб»ендә «атаклы язучы» Г. Исхакыйның «Ил» газетасы (берничә санда) битләрендә «Исмәгыйль бәк һәм Зөһрә Гаспринскийлар» исеме белән басылган мәкаләсендә хакыйкатькә хилаф фикерләр, ялгышлар булуына, имеш-мимешләргә генә таянып язуына үкенечен белдерә. Алай икән, киләчәктә Г. Исхакый әсәрләре басмаларына бу мәкаләне урнаштырганда. аңа аңлатма-комментарий инде И. Акчурин фикерләре дә искә алынып язылырга тиеш була. Әхмәд Тәүфыйк әфәнденең хаты исә Г. Исхакый чыгарган «Яңа милли юл» журналының Япониядә яшәмәктәге милләттәшләре тарафыннан көтеп алынуы турында сөйли.*

*Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институтта саклана торган кульъязмадан (күчермә) алынган бер хат аеруча да игътибар белән өйрәнүне сорый. Ул Г. Исхакый тарафыннан Гали Хәйдәр Әмир бәккә адресланып язылган (әмма тапшырылмаган булса кирәк). Шактый күләмле бу хатта (текстында төрек теленә якынлык күренеп тора) автор татар әдәбиятының төрек (госманлы чоры) әдәбияты белән тирән бәйләнешләре турында сүз алып бара. Анда китерелгән фактик материал, аерым фикерләр бу темага караган тикшеренүләрнең дәлиллеген арттыруга хезмәт итәчәк.*

*Аксам Йосыф углының хаты да кызыклы: ул Бөек Ватан сугышы вакытларында әсирлеккә төшеп, туган иленә кайта алмый калган ватандашларыбызның Алманиядәге авыр язмышын чагылдыра булса кирәк.*

### *Мөхтәрәм Камил әфәнде!*

Башладыгыңыз эш[1] бик яхшы. Фәкать вөҗүдкә чыгарга[2] насыйб булсын.

Әгәр минга журналыңыз сәтырларында урын булса, мин әдәби кыйсемендә язарга разыймын.

Нинди шартлар-фәләнләргә һич җавабым юк. Башкаларга ничек булса, минга да шулай булыр.

Үземнең хикәяләрем, романнарымны вә бәгъзан әдәбията гаид тәнкыйдьләремне эстәсәңез[3], җибәрермен. Эстәсәңез, «Теләнче кыз» исемле романымы җибәрермен, кыскасы гына, әгәр мәйданга чыкса, мин язачакмын.

Рәсемем булмаганга күрә хәзер җибәрә алмадым, вакыты илә җибәрермен.

*Мөхәммәдгаяз әл-Исхакый*
*1905 сәнә 26 нчы гыйнвар*

Хат кулъязма «Әлгасрелҗәдид» журналының 1905 елгы 4 нче санында дөнья күргән, хат «Мәдәни хәбәрләшүләр» рубрикасында урын алган. Хат алдыннан идарә тарафыннан: «Мәшһүр әдип казанлы Мөхәммәтгаяз әл-Исхакый белән «Әлгасрелҗәдид» мөхәррире Мөхәмммәткамил әл-Мотыйгый арасында булган мәдәни мәсьәләләрдәге хәбәрләшүнең күчермәсен шатланып газетабызда урнаштырырга карар бирдек. Башта «Әлгасрелҗәдид» мөхәррире Мөхәммәтгаяз әл-Исхакыйга сотрудник булырга тәкъдим итеп бер хат җибәрелгән иде. Сотрудникларга язылган хатларның сурәте бер булганга күрә, газетабызда кабат язылуын хаҗәт күрмәдек. Югарыда әйтелгән хатка Исхакый мондый җавап бирде[4]»дигән аңлатма да бар.

### *Фазыйләтле Мөхәммәдгаяз әл-Исхакый!*

26 нче гыйнвар тарихлы мәктүбеңез васыйле дәсте ихтирамым улды[5]. Пәк гүзәл язмышсыз. Журналымыз вөҗүдә кәлүрсә

[1] Башладыгыңыз эш – башлаган эшегез.
[2] Вөҗүдкә чыгарга – гамәлгә ашарга.
[3] Эстәсәңез – теләсәгез.
[4] Аңлатма хәзерге татар теленә тәрҗемәдә тәкъдим ителә.
[5] Васыйле дәсте ихтирамым улды – хөрмәт итүче кулларыма килеп иреште.

дидекеңезе йиренә кәлтүрмәйә би-кадәре кувә чалышырыз. Рәшид әфәнде, Риза казый вә әмсале мөхәрририн, кираме тәхрират илә могавәнәтә хәзердерләр. Рәшид әфәндедән башка сыйга мәгаше икрамия хосусында шимдеядәк вәгъдәләшдекемез юкдыр.

Сабыйкда «Бай угълы», «Ике гыйшык», «Очрашу ...», «Кәләпүшче кыз» вә «Ике йөз елдан соң инкыйраз» намларында улан асаре каләмияләреңезе дәфәгатьлә нәзаре моталәгамдан кичермеш идем. Шу асаре гаҗибәләреңезе укыдыкча куәи әдәбиятеңезең фәүкыльгадә идеке мәгълүмем улыюр.

Журналымызың әсамәте 100 бөек сәхифәләрдән гыйбарәт улаҗак вә һәр ай мәйдане интишара куелып дораҗакдыр. «Теләнче кыз» намында улан романыңызы йибәрсәңез, «Әлгасрелҗәдид» нумирларының иң беренҗесенә дәреҗ улыныр. Сотрудник улаҗак мөгайен затлардан бәгъзесе хәтта сансурдан басылмасына рөхсәт вирелмеш әсәрләрени күндерделәр. Затыңыз да вакытыңыз илә «Теләнче кыз»ыны ирсаль боерырсыз. Яз фасылының ахырларында үз типографиямез эшә башлыяҗак вә шу вакытдан игътибарән идарәмездә әнваг тәхрират кабул улынаҗакдыр.

Мәгаше икрамия хосусында һәр кемең үзилә карарлашдырмайы мөнасиб күриюрым, бинаән галәйһи «Теләнче кыз»ыны ирсаль әйләдекеңез вакыт гыйвазына нә кадәр эстәдекеңезе ачык язмалысыз. Әмма әдәбията мөтәгалликъ аеруча әсәрләреңездән башка даими уларак Казан әхвалятындан ихбарате мөтәнәүвигалары язып дораҗак исәңез, мәгаше икрамияңез маһия улыр вә һәр ай башында хозурыңыза йибәрелеп дорыр. Фәкать боныда әүвәлдән карарлашдырмак тиешдер. Нә исә бу тугърыда сөһүләтлә мөгамәләдә булынырыз зан идәрем.

Постовой рәсемеңезе якында йибәрмәкеңезе халисанә тәмәнни идәрем.

Рәшид әфәнденең Казана килеп бу сырада бер һәйәте мах-

суса илә бәрабәрлекдә Петерсбурга кидәҗәке мәсмугым улды. Бәңа хәбәр китерәнең сөйләдекенчә у һәйьәтнең Петерсбурга вармакдан максудлары мөфти вә казыйларың хосусында бу көнә кадәр кулланмакда улан низаматың дикшерелмәсене таләп имеш «әл-гоһдәте галәр-рави». Әгәр бу хәбәр сахих исә, чук шәй вә пәк мөһим эш. Җәнабе Аллаһ мөяссәр итсен. Мисырда чыкан «Төрек»ең 60 нчы нумирында бу тугърыда бер мөселман тарафындан язылан бәхесләре укымыш идем вә мәгълүм, әлбәттә, әхвале хазыйрәмезең бил-көлли дигештерелмәсе лязем вә важибдер.

Безем Уральск убластындан кыргиз таифәсе дә ошбу соң вакытларда лязем мәхәлләрә гаризалар вирмешләр имеш. Гаризаларында кыргизлара махсус бер мөфти насыйб улынмасына вә яхуд казанлы мөфтисенең тәхте нәзарәтендә булынмаларына мөсагадә таләп итмешләр. Эшең башындан гизән Каратаев намында кыргиз җенесендән гаюр вә нәҗабәтле бер гәнеҗ афукатдыр. Мәзкүр һәйьәте махсуса бу Каратаевы да араларына җәлеп идәрләрсә эш даһа кәсбе куәт идәрде. Мөхтәрәм Рәшид әфәндея вә Әхмәтһади әфәндея юлыкдыкыңыз вакыт хосусый сәламләреми иблагъ идеб, әфкяре гаҗизанәләреми бәян боерырсыз.

Ляземсә даһа бу хакда язарым. Шимделек затыңыздан җаваб бәкләрем.

*M. Kamill Al-Moutigi – Touchfatoullin (Ouralsc)*

## Хатның хәзерге татар теленә тәрҗемәсе:

***Мөхтәрәм Мөхәммәдгаяз әл-Исхакый!***

26 нчы гыйнварда язылган хатыгыз хөрмәт итүче кулларыма килеп иреште. Бик гүзәл итеп язгансыз. «Журналыбыз барлыкка килсә», дигәнегезне җиренә җиткерергә кулдан килгән кадәре тырышырбыз. Рәшид әфәнде, Риза казый һәм алар кебек язучылар, язган хатларына күрә, ярдәм итәргә әзер. Рәшид әфәндедән

башкалар белән гонорарлар турында килешкәнебез юк.

Элегрәк «Бай углы», «Ике гыйшык», «Очрашу ...», «Кәләпүшче кыз» һәм «Ике йөз елдан соң инкыйраз» исемле әсәрләрегезне кабат-кабат укып чыккач, сездәге әдәби сәләтнең гадәттән тыш булганлыгын беләм. Журналыбызның күләме йөздән артык биттән гыйбарәт булачак һәм ул һәр ай чыгачак. «Теләнче кыз» исемле романыгызны җибәрсәгез, «Әлгасрелҗәдид» номерларының иң беренчесенә урнаштырылыр. [Журналда] сотрудник булачак мәгълүм затлардан бәгъзеләре, хәтта, цензура бастырырга рөхсәт биргән әсәрләрен җибәрделәр. Сез дә, вакытыгыз булгач, «Теләнче кызы»н җибәрсәгез иде. Яз ахырында үз матбагабыз эшли башлаячак һәм шул вакыттан башлап идарәбез тарафыннаан хатлар кабул ителә башлаячак.

Гонорар хакында һәркемнең үзе белән сөйләшүне кулай күрәм, шуңа күрә «Теләнче кызы»н җибәргәч, бәрабәренә күпме акча алырга теләгәнегезне ачык итеп языгыз. Әмма әдәби әсәрләрегездән башка даими рәвештә Казанның төрле яңалыкларын язып торсагыз, гонорарыгыз эш хакына әйләнәчәк һәм һәр ай башында сезгә җибәрелеп торачак. Ләкин моны да башта ук килештерергә кирәк. Ничек кенә булмасын, бу турыда җиңел килешә алырбыз дип уйлыйм.

Постовой рәсемегезне[1] тиз арада җибәрүегезне ихлас күңелдән телим.

Рәшид әфәнденең Казанга килеп бу арада махсус бер депутация белән Петербургка китәчәген ишеттем. Миңа ирешкән хәбәрләргә караганда, ул депутация Петербургка бару максатлары – мөфти һәм казыйлар хакында бүгенгә кадәр кулланылган кагыйдәләрнең алыштыруын сорау икән. Хәбәрнең дөреслеге – сөйләүчесендә. Әгәр бу хәбәр дөрес булса, бик зур нәрсә һәм мөһим эш булыр иде, Алла ярдәм бирсен.

Мисырда чыккан «Төрек» газетасының 60 нчы номерында

[1] Постовой рәсемегезне – монда: почта карточкасы зурлыгындагы фоторәсем дип уйларга мөмкин (Г.Ханнанова искәрмәсе).

бу турыда бер мөселман тарафыннан язылган мәкалә дә укыган идем, һәм мәгълүм, әлбәттә, хәзерге хәлебез тулысы белән үзгәртелергә тиеш.

Безнең Уральск областендә казах халкы да шушы соңгы вакытларда тиешле урыннарга гаризалар биргәннәр икән. Гаризаларында казакъларга аерым бер мөфти билгеләнеп куелуын, яки казанлы мөфтисенең карамагында булырга рөхсәт сораганнар. Бу эшнең башында Каратаев фамилияле кыю һәм асыл бер зат – казахтан чыккан адвокат. Ул махсус депутация бу Каратаевны да араларына җәлеп итсәләр, эшләре тагы да тизләнер иде.

Мөхтәрәм Рәшид әфәндене һәм Әхмәтһади әфәндене очраткач, хосусый сәламнәремне җиткереп, гаҗизанә фикерләремне бәян итсәгез иде.

Кирәк булса, бу хакта тагын язармын. Хәзергә Сездән җавап көтәм.

*М.Камил әл-Мотыйгый – Төхфәтуллин (Уральск)*

Хат кулъязма «Әлгасрелҗәдид» журналының 1905 елгы 4 нче санында дөнья күргән. Текст басмага кулъязма журналдан алынды.

## *Камил әфәнде!*

Мәктүбеңезне алдым. Әгәр рөхсәт булса, ничек дә килешермез.

Уральскида типография тәэсис[1] мәсьәләсен бу көнгә кадәр белмәгән идем. Әгәр рөхсәт бирмәсәләр, көтепханә ачып, «Мәгариф» нәшере фикерендәмесез? Әгәр шулай булса, Уральск ислам мәркәзләренә бик ерак булып эш эшләр өчен көч[2] булмасмы?

Журналыңыз булса да, булмаенча нәшрияткә тотынсаңыз да, Казанга күчү, мәркәзне Казан ясау мәслихәт түгелме? Минем өчен андый эш өчен иң мәслихәте – Казан, һәм иң җиңел китаб

[1] Тәэсис – оештыру.
[2] Көч – биредә: авыр.

нәшер кылыр өчен, китапны иң очуз[1] төшерер өчен мәслихәт урын – Казан. Үзеңез карарсыз. Монда типография тәэсис итү, яисә сатып алыныр, монда хәзер сатыла торган типографияләр бар. Уральскига караганда бик җиңел булырга кирәк.

«Теләнчы кызы» эстәсәңез, сез дигәнчә ясармыз. Эстәсәңез, китап тарзында[2] нәшер кылырсыз.

Казанда депутация җибәрәләр. Бик гүзәл бер прошение җибәрделәр. Шул көнләрдә Әхмәд бай, Габдулла мулла, Алкин Сәедгәрәй, Сәйдәшевләрдән мөрәккәб[3] бер һәйәт[4] Петербургга китәчәк. Вәссәлам.

*Мөхәммәдгаяз.*
*7 нче февраль 1905 сәнә*

Хат кулъязма «Әлгасрелҗәдид» журналының 1905 елгы 4 нче санында дөнья күргән.

### *Каләм аркадашым М.[өхәммәд] Гаяз әфәнде!*

7 нче февраль тарихлы мәктүбеңезә җавабым.

Типография тәэсисенә улсын, башкасына улсын, милләтә файдалы улса, тәкать кадәре тәшәббесә бән хазыйрым. Көтепханә ачмак вазыйфасыны әһле каләмдән башкалар да әда идә белерләр, зан идәрем. Аңа ялгыз парә лязем. Мәгълүмеңез йә, типография ачып аныңла мәҗәллә вә яки җәридә нәшер итмәк касдында улмак чук дөрле шәраита тәвакыф идәр. Бинаән галәйһи көтепханә ачмак кеби эшләре сәрвәт сахибләре күрмәлек, әһле каләм исә үз эшләрендә улмалы. Бәңа мәҗәллә нәшеренә рөхсәт вирмәзләр исә һәмишә көтебе мөтәнәүвига нәшерендә мөдавәмәтдә булынаҗагым, әвәт! Идарәмези Казанда япмак пәк мәслихәт, әмма бәнҗә Уральскидадауранмак даһа мәслихәтдер, әвәт! Казан бер җәһәтдән мәркәзе ислам вә бер җәһәтдән

[1] Очуз – арзан.
[2] Тарзында – рәвешендә.
[3] Мөрәккәб – торган.
[4] Һәйәт – делегация.

мәдаре тиҗарәт вә мәнбәгы һөнәр вә сәнагатьдер. Уральски кебиләр Казана бакылдыкда әз һәр җәһәт чук киредәдер. Фәкать бәнҗә Уральски кебиләрең дә Казана йитешмәләрене арзу әйләмәк икътизаи инсаниятдер. Вә мәгълүм, әлбәттә Русиядә улан ислам шәһәрләренең көллесе дә Казана йитешерсә у вакыт милләтемезең әхвале даһа сөргатьлә диешәҗәк. Бәнем фикеремчә милләт файдасыны мәнфәгате шәхсияләренә тәкъдим әйләмәк морад идәнләр үз шәһәрләрендә хезмәт итсенләр вә үз шәһәрләренең әһалисене мөмкин кадәр мәдәниятә алышдырмая мәгънәви мөхарәбәдә булынсынлар. Вә иллә һәп өдәба сыйныфы Казана тупланыр исә, Казан халкы горурланыр, башкалары исә зарарланыр, соңра инкыйраз заманы ике йөз елдан да әүвәл улыр. Әгәр, мәсәлән, Уральскидан «Әлгасрелҗәдид» журналы зоһур идәрсә Казанда кабан гәзитәләренең хосулә гәлмәсе шөбһәсездер.

Казанда хәзер сатылаҗак типографияләр вар димешсез, гаҗәбән, кемләр сатыюр? Әшьясы вә фияты хакында мәгълүматы насыл Казана белерем. Затыңыз шу сатылаҗак матбагалардан беренең адресыны язар исәңез, мәктүблә мөрәҗәгать идеб бакардым. Мөвәффәкъ исә, шу матбагалардан берене Уральския күчерер куярдык.

«Теләнче кыз» нам әсәреңез тәхрир улынып тәмамланмыш исә, йибәрсәңез, тиздән басдырып нәшер итмәя мәгальмәмнүния кабул идәрем. Һәмишә тәгатые әфкярдә булынмакызы тәмннилә хәтме кәлям әйләдем.

*К.М.*

## Хатның хәзерге татар теленә тәрҗемәсе:

### *Каләм аркадашым М.[өхәммәд] Гаяз әфәнде!*

7 нче февральдә язган хатыгызга җавабым.

Матбага оештыру булсын, башкасы булсын, милләткә файдалы булса, көч җиткән кадәре эшләргә мин әзермен. Көтепханә ачу вазифасын язучылык белән шөгыльләнгән башкалар да үти алырлар дип уйлыйм. Аның өчен акча гына

кирәк. Белгәнегезчә, матбага ачып, анда журнал-газета нәшер итүгә керешү күптөрле шартларга бәйле. Шуның өчен көтепханә ачу кебек эшләр белән бай кешеләр шөгыльләнергә тиеш. Язу һөнәре белән шөгыльләнүчеләр исә үз эшләрендә булырга тиеш. Миңа журнал чыгарырга рөхсәт бирмәсәләр, элеккечә төрле китап чыгаруны дәвам итәчәкмен, әйе! Идарәбезне (ягъни редакцияне – Г.Х.) Казанда оештыру бик мәслихәт, әмма, минемчә, Уральскида эшне дәвам итү тагы да мәслихәт, әйе! Казан, бер җәһәттән ислам мәркәзе, икенче җәһәттән сәүдә үзәге һәм һөнәр-сәнәгать чыганагы. Уральск кебек шәһәрләр, Казан белән чагыштырганда, һәр яктан бик кайтыш. Фәкать, минемчә, Уральск кебек шәһәрләрнең дә Казан дәрәҗәсенә күтәрелүләрен теләү кешелеклелек шартларыннан берседер. Мәгълүм ки, Россиядә булган бөтен мөселман шәһәрләре Казан дәрәҗәсенә күтәрелсә, ул вакытта, әлбәттә, милләтебезнең хәле тагы да тизрәк үзгәрәчәк. Минем фикеремчә, милләт файдасын шәхси мәнфәгатьтән өстен күрәсе килгәннәр үз шәһәрләрендә хезмәт итсеннәр һәм үз шәһәрләренең халкын мөмкин кадәр мәдәнияткә ияләштерү өчен көрәшсеннәр. Юкса, әдипләр сыйныфы Казанда тупланса, Казан халкы горурланыр, башкаларына исә зарар килер, соңра инкыйраз заманы 200 елдан да әүвәл булыр. Әгәр, мәсәлән, Уральскидан «Әлгасрелҗәдид» журналы китсә, Казанда «Кабан» газеталарының барлыкка килүе шөбһәсез.

Казанда хәзер сатыла торган матбагалар бар дисез, аларны кем сата? Җиһазлары һәм бәясе хакында мәгълүматны ничек табармын? Сез бу сатыла торган матбагалардан берсенең адресын язып җибәрсәгез, хат белән мөрәҗәгать итеп карар идем. Килешә алсак, ул матбагалардан берсен Уральскига күчереп куяр идек. «Теләнче кыз» исемле әсәрегез язылып тәмамланган булса, җибәрсәгез, тиздән бастырып таратыр өчен шатланып кабул итәрмен.

Туктаусыз фикер алышуыбызны теләп сүземне тәмамладым.

*К.М.*

Хат кулъязма «Әлгасрелҗәдид» журналының 1906 елгы 5 нче номерында дөнья күргән.

*Хат текстларын Гөлчирә Ханнанова әзерләде*

## Идарәгә мәктүбләр

### *Мөхтәрәм әфәнде!*

Ошбу мәктүбемезне могътәбәр[1] гәзитәңезгә басуыңызны үтенәбез.

«Ил»нең 41, 42, 43, 44 нче саннарында «Исмәгыйль бәк һәм Зөһрә ханым Гаспринскийлар» аталган Гаяз әфәнде Исхакыйның мәкаләләрене иттифакый[2] күреп һәм вакыйгаларны бәянында яңлыш һәм дә бөтенләй уйдырма нәрсәләр язылганны укып, ушбу юлларны язарга лязим күрдем.

Гаяз әфәнде Исхакыйның әйтүенә күрә, «мәгълүмат бу мәсьәләне бик якыннан күргән кешенең агызыннан алынган» («Ил», 43) булса да, безнең Русия мөселманнары галәменең беренче кешесе хакында язуга кыючылык кылганда һәм дә аның шәхси эшләрене язганда, бигрәк тә сакланып язу тиеш иде. Мәкаләләрендә минем атымны да агызга алганында, мин дә бераз нәрсә белгәнемне Гаяз әфәнде Исхакый белә икән, шулай булып та, ул миннән һичбер сүз сораганы юк, һичбернәрсә уйламаенча, «Ибраһим Акчурин шулай әйткән, Ибраһим Акчурин болай дигән» дип яза бирә. Исмәгыйль бәк берлә Зөһрә ханым үлгәнлек берлә алар өстенә ни сөйләсә дә була, мин исә, әлхәмделилла, бу көндә дөньяда бар, үлмәгән һәм минем ни эшләгәнемне, ни сөйләгәнемне миннән сорап язу кирәк иде. Гаяз әфәнде Исхакый яза торган вакыйгаларны үзе күрмәгән, бәлки ул вакытта дөньяга килмәгән булгандыр. «Бик якыннан күргән кеше»ме, якыннан күрмәгән, яхүд утыз өч ел моннан борын булган эшләрне оныткан, һәрничек тә мин ни эшләгәнне күрмәгән һәм «имеш» дип кенә ишеткән.

«Ил»нең 43 нче номерында Гаяз әфәнде «Гаспринский 81нче елда Мәкәрҗәгә килә вә Ибраһим абзыйны тавып (?)[3] мәсьәләне аңлата», ди. Бу исә бөтенләй яңлыш. Мәкәрҗәдә Гаспринский бу тугрыда минем берлә бер кәлимә сүз сөйләмәде. Мәкәрҗәдән борынмы яки соңмы Исмәгыйль миңа үзенең Зөһрәне сорау

---

[1] Могтәбәр – хөрмәтле.
[2] Иттифакый – очраклы.
[3] Чыганакта шулай язылган.

уены сөйләсә дә, аның ул уена минем иштиракь итүем–итмәвем[1] Гаяз әфәнде Исхакыйга һәм «бик якыннан күргән» кешегә дә бөтенләй мәҗһүлдер[2]. Коромысловка Африканың адәм басмаган йирләрендә түгел, шуннан анда ничек барыла дип миннән сораугa ни хаҗәт барлыгын Гаяз әфәнде Исхакый белә торгандыр. Мин булып: «Барма да, йөрмә дә, тапмассың да, булмас та» дип әйтү бәлки романнар язучылар өчен бик йиңел булса да, аннан мин шулай әйткән булу әле дә лязим булып чыкмай һәм дөреслектә бу мин әйткән сүзләр түгел.

Гаспринский миңа ни сөйләгәнене, шул тугрыда карендәшем Зөһрә берлә сөйләп, аның ни җавабы булганыны бу урында язуны һич хаҗәт күрмим. Исмәгыйль бәкнең уйдырма түгел, чын тәрҗемәи хәлене язучылар бу нокталарга да әһәмият биреп, миннән сорар булсалар, ул чакта эшләр ни рәвештә булганны тәфсыйлате берлә бәян кылырга хәзермен.

Бу берничә юлны язуга да мине ирексезләгән нәрсә укучы адәмнәрнең яңлыш нәрсәләргә күзләрен ачу булып, Гаяз әфәнде Исхакый берлә сүз көрәштерер өчен имәс каләме кулында, гәзитәсе үз боерыгында, ни теләсә шуны язсын, алай да исә үлмәгән кешеләр өстенә яла язмауны аңа тиеш дип беләм. Үлгәннәр хакында бигрәк саклану лязим икәнне югарырак та әйткән идем. Әдәпнең әлифбасы әдип булган адәмгә билгеле булырга тиеш иде. Бер дә уйламаенча каләмне йөртеп, мактау урынына тиргәү булу ихтимал, Гаяз әфәнде Исхакыйның язулары Исмәгыйльбәк берлә Зөһрә ханымның һәм Акчурин фамилиясенең кара керләре эчендә казынуга бик охшай. Бу бер атаклы язучыга мөнасиб эш икәнене түгелене укучылар үзләре тәкъдир кылырлар. Узышлый Гаяз әфәнде безнең Акчуриннар тугрысында да байтак нәрсәләр яза. Бу тугрыда үзем шул рухтан булып, Гаяз әфәнде Исхакый берлә сүзгә керешергә лязим күрмим. Безне – үлмәгәннәрне тиргәсә,тиешле күрсәк, каршы сөйләргә көчемездән килер иде. Үлгәннәремезнең гайбенә[3] кермәгән булса, күркәмрәк булыр иде. Ихтимал, болар Гаяз әфәнде Исхакыйның булмаенча, безне дөрест

[1] Иштиракь итүем итмәвем – катнашуым катнашмавым.
[2] Мәҗһүлдер – билгесездер.
[3] Гайбенә – кимчелегенә.

күрүчеләр агызыннан чыккан сүзләрдер. Шуннан: «Илаһи[1], безне дустларымыздан арала, дошманнарымызга үземез дә каршы тора алырмыз» дию дога әйләргә ярамаса, «ярабби һәм дустларымыз һәм дошманнарымыз явызлыгыннан сакла» дия сүзне бетерәм.

*Ибраһим Акчурин. Сембер, 11 декабрь, 1914.*

«Вакыт» газетасының 1914 елгы 20 декабрь (1660) санында «Ибраһим Акчурин» имзасы белән басылган. Гарәп графикасында. Гамәлдәге татар язуында беренче мәртәбә дөнья күрә.

*Текстны Эльмера Галимҗанова әзерләде*

## Ерак көнчыгыштан хат

***Фазыйләтле[2] вә мөхтәрәм әдибемез Гаяз әфәнде Исхакый җәнабләре!***

Әссаләме галәйкем вә рәхмәтуллаһы вә бәрәкатеһү.

Йибәргән «Милли юл» мәҗмугаңызны вә күндергән озын хатыңызны алдым. Рәхмәт.

Безнең шәһәрдә 11 нче майда Корбан гаеденең 3 нче көнендә бер мөселман өендә баласына исем бирү мәҗлесе булган иде. Шул мәҗлестә, шунда хазир булган халыкларга, «Милли юл» мәҗмугасының әһәмиятене беркадәре сөйләп аңлатылды, вә шуның илә бәрабәр бу вакытта Яурупада иске гарәп вә төрек хәрефе илә үземезнең ана телендә чыга торган бердәнбер «Милли юл» мәҗмугасыннан киң рәвештә мәгълүмат алырга вә бик күп файдаланырга мөмкин икәнлеге сөйләнде. Нәтиҗәсендә, «Милли юл»га абүнә[3] уларак язылырга димләнелде. Мәҗлестә хазир булган халыкларның күбесе бу фикергә куаныч берлә кушылып, каюсы берьеллык, каюсы ярты еллык «Милли юл» мәҗмугасына абүнә язылдылар. Шул кечкенә генә исем бирү мәҗлесендә «Милли юл» мәҗмугасына абүнә язылучылардан япон акчасы илә алтмыш алты (66) йен акча җыелды. Бу хакта башка шәһәрләргә дә хатлар күнderelде. Бездән дога вә үтенеч шул: «Милли юл»

[1] Илаһи — и, Аллам.
[2] Фазыйләтле – хөрмәтле.
[3] Абүнә – акча түләп.

мәҗмугаңызны берүк туктатмый дәвам итдереңез, күңелеңезгә килгән илһамнарны гайрәт илә ачык рәвештә хәзерге кебек язып торыңыз!... Мондагы халыклар сезнең «Милли юл» мәҗмугасыны бик зур шатлык вә сөенеч илә укыйлар. «Милли юл» мәҗмугасы килгәнче кайчан килер икән дип өзелеп көтеп торалар. Япониянең пайтәхете[1] булган Токио шәһәренә Төркиядән мөселманча матбага алдырылды. Бу матбаганы алырга акча Япониядәге бөтен төрек-татар сәүдәгәрләреннән тупланды. Шулай да акчаның күбрәк өлеше Токиядәге мөселманнарның үзләреннән җыйналды. Хәзерге хәлдә мәзкүр[2] матбәгада иске гарәп вә төрек хәрефләре илә бер кадәре ибтидаи[3] мәктәп китаплары басылып ятмактадыр. Япониянең Кобе шәһәрендә мөселманнар өчен бер мәчет салдырырга хәзерлек күрелә. Бу мәчетне барлыкка китерү вә тиешле булган чараларны күрү өчен, ун кешедән гыйбарәт бер һәйәт төзелеп, эшкә керешелде. Бу һәйәтнең алты әгъзасы һиндлы мөселманнардан булып, калган дүрт әгъзасы безнең төрек-татарлардандыр. Бу мәчетнең урынын алырга, бинасыны салырга дип, йитмеш биш мең йенлек бер смета тәртип кылмышлардыр. Бу мәчетне барлыкка китерергә дигән акча күбрәк һиндлы мөселманнар илә Мисыр мөселманнарыннан булачактыр. Безнең төрек-татар мөселманнары да кулларыннан килгән кадәре ярдәмнәре илә катнашачаклар. Бу мәчет бөтен Япониядә бердән бер яңадан башланып салынган мәчет булачактыр.

*Японияле Әхмәд Тәүфыйк*

Хат гарәп графикасында, «Яңа милли юл» журналының 1930 елгы 8 нче (август) санында басылган. Гамәлдәге татар язуында беренче тапкыр дөнья күрә. Текст журналдан алынды.

*Текстны Гөлназ Хөснетдинова әзерләде*

---

[1] Пайтәхете – башкаласы.
[2] Мәзкүр – әйтелгән, күрсәтелгән.
[3] Ибтидаи – башлангыч.

### ***Мөхтәрәм Гали Хәйдәр Әмир бәк!***

Могтәбәр[1] «Вакыт» гәзитәсендә нәшер итдегем мәкаләләрем зате галиерәк[2] бәгъзе бер сөальләрне җавапсыз быракмыш[3] улдыгыны кәндүем[4] дә игътираф идейорум[5]. Могтәбәр «Халык» гәзитәсендә бәңа каршы сөальләр кечек[6] бер тәнкыйдә дәреҗ иделмешде[7] дә, бән дә ике гәзитәйә берүк җавап вирмәк мәҗбүриятендә калдыгым өчен җавапларым табигатьлә икейә такым иделмешде[8]. Фәкать могтәбәр «Халык» гәзитәсе бәнем бөек бер кыйммәт гатыйф итдегем[9] шу «дил берлеге» мәсьәләсене «дөррә ...» сокагына[10] сәвекъ итдегене[11] күрдем дә, хәзерләнмеш мәкаләме гәзитәйә күндерәмәдем вә бундан тулайы[12] «Вакыт»дагы фикерем дә ... калды. Бән мәсьәләнең сәяси җәһәтен мәйдана мөзакәрәйә[13] куймак өчен мәкаләйи язмамышдым. Буның өчен у мәгъруф[14] маддә мәкаләнең иң ниһаятә уграмышды[15]. Фәкать Русиядә яшәдегем озын мөддәттә[16] [...] бән бу фикерне даимән ишетдем вә кәндемең кариэләреме[17] дәгел, иске чар[18] хөкүмәтен бөйлә «Төрек берлеге» фикерейә аз чук алышдырмышдым. Сәнәләрчә гәзитәләрдә, мәҗмугаларда мәкалә тарызында[19], мәҗлесдә нотыклар, хитаблар тарызында дәвам идән бер фике-

---

[1] Могтәбәр – хөрмәтле.
[2] Зате галиерәк – бөегрәк затларның.
[3] Быракмыш – калдырган.
[4] Кәндүем – үзем.
[5] Игътираф идейорум – гаебемне таныйм.
[6] Кечек – аз, кечкенә.
[7] Тәнкыйдә дәреҗ иделмешде – тәнкыйтькә очрады.
[8] Икейә такым иделмешде – ике төркемгә аерылды.
[9] Гатыйф итдегем – мәрхәмәт иткән.
[10] Сокагына – урамына.
[11] Сәвекъ итдегене – этәрүне.
[12] Бундан тулайы – дөресе: долайы – шуның аркасында.
[13] Мөзакәрәйә – фикер алышуга.
[14] У мәгъруф – ул билгеле.
[15] Ниһаятә уграмышды – соңына калды.
[16] Мөддәттә – вакытта.
[17] Кариэләреме – укучыларымны.
[18] Чар – царь.
[19] Тарызында – рәвешендә.

рең бурада нәшер иделмәмешдә һичбер хәләл[1] күрмәмешдем. Даһа догрусы[2], сәнәләрчә чалышдыгым бер фикерем җәрәянымың[3] фазләсене бурада тасвирсыз мәйдана атмышдым. Буңа каршы һәр дөрле тәнкыйтьләре табигатьлә кабул идәрдем. Фәкать корольдән фазлә корольчылык тарафдарларының мәгънәсез һөҗүмнәрен катгыян аңламадым вә аңламаячагым. Бәнем кирәк хөдүд[4] милли дахилендә вә кирәк хөдүд хариҗында калан төрекләрең вазифалары – кәндүләренең хөрриятләрен уграшмыш[5] вә бу мәсьәләдә бер болгарның, бер юнанның, бер фарсының катгыян хәтерен сакламамышдыр. Тамырларында төрек каны аккан берсенең чыгуын, төрек берлегенең галәйһенә сүз сөйләмәсен, хәрәкәт япмасын катгыян хәтеремә китерейордем. Вә шимди дә бу фикердә калмак улдыгым өчен мөнәкъкыйдләремнең[6] кәндүләре дидеке кеби икътисади гавамлык тәэсире илә бөйлә япдыкларына ышанмая мәҗбүрем. Бәнем төрек әсасы игътибарилә, «Төрек берлеге»не имтияза[7] калыкмак – габәсдер[8]. Вә сезең дидекез кеби Төркия җөмһүрияте мөнәвирләре арасында төрекчелек могаризе[9] бер кемсәнең булынмадыгына «имин» идем. Фәкать госманлылык зиһнияте[10] даһа тарихлара карынмыш улмалыйор мәсьәләйи җитди мәсахәдән[11] чыгармая чалышаннар, мәгаттәэссеф[12], улмышдыр. [...] Бәңа табигый күрелдеге бу хәлдән инчә сәясәтләрдән хәбәрдар улмайан безем хариҗ төрекләрнең бөек кыйсеменә шөпәсез гаять дәрәҗәдә мөтәэсир итмешдер. [...] Бик чук шималь дәверләрендә күз яшьләре дөкүлмәсенә вә актык өмидләренең сүн-

[1] Хәләл – зарар, зыян.
[2] Даһа догрусы – тагын дөресе.
[3] Җәрәянымың – агымымның.
[4] Хөдүд – чикләр.
[5] Уграшмыш – кайгырту.
[6] Мөнәкъкыйдләремнең – тәнкыйтьчеләремнең.
[7] Имтияза – башкалардан аерылып торуга.
[8] Габәсдер – файдасыздыр.
[9] Могаризе – каршы килүче.
[10] Зиһнияте – акылы.
[11] Мәсахәдән – мәйданнан, киңлектән.
[12] Мәгаттәэссеф – кызганычка.

мәсенә сәбәп вирмешдер. Төрек берлегенең билгамәл[1] мәүҗүдияте[2] хакында гөстәрән дәлилләрә кәләнчә, бәнемчә, бу мәсьәлә бәдаһәт[3] дәрәҗәсенә килмеш улдыгыннан һичбер имтияза мохтаҗ дәгелдер. Бунын өчен сөеп сайдыкларым дәлил уларак дәгел, фәкать мисал уларак гөстәрелмешдер. Вә бунда да бәк чуклары хәтердән чыкмыш. Сайдыгым әсәрләр миянында[4] иң мөһимләре калмышдыр. Мәсәлән, безем шимальдә мәрхүм Әхмәд Мидхәд әфәнденең әсәрләрене укымамыш мөнәвир юк дәрәҗәсендәдер. Безем шимальдә иске «Төрек йорды»ның кариэ һич шөпәсез Төркиядәгесеннән әксик дәгелде[5]. Безем шимальдә «Урда маршы» мөкаддәс бер милли музыка улмышде. Безем шимальдә ике дәвернең бөтен әдәби гали әсәрләре аз-чук тәгассыб иделейорде[6]. Бунлар бәянындан һич шөпәсез лисаны саф садә уланлары даһа мәкъбүл улыйорде[7]. Сезең сайдыгыңыз[8] Нәмикъ Кәмал, Зыя паша, Мөхәммәдәмин бәкләр даимән укылмышдыр, даимән бунларың инчә юксәк[9] бер мәүкыйгы[10] улмышдыр. «Ватан» сәясәте безем театруларда чукдан тәрҗемә иделмешдер. Вә бик чук дәхле тәмсил иделмешдер[11], вә Мөхәммәдәмин бәкнең шигырьләренең бер кыйсеме кыйраәт китапларына бөйлә кермешдер. Фәкать нә Тәүфикъ Фикрәт, Габделхак Хәмид бәк урада рәхмәт казанмамышлардыр. Шималь төрегенең төрек калебендә бунлар йир буламамышлардыр. Бәндәләре шәхсән әдәби тәрбиядә улан кавем кариэләренең «Тимер батыр», «Таг батыр», «Камыр батыр» хикәяләрендән соңра Сәед Баттал Гази вә Солтан хикәяләренә гәчдем вә бундан тугрыдан-тугры «Алты бармак» вә «Мөхәммәдия» китапларына башладым. Руси-

1 Билгамәл – гамәлдәге.
2 Мәүҗүдияте – барлыгы.
3 Бәдаһәт – ачыклык.
4 Миянында – арасында.
5 Әксик дәгелде – түбән түгел иде.
6 Тәгассыб иделейорде – артык сөелә иде.
7 Мәкъбүл улыйорде – яхшы дип табыла иде.
8 Сайдыгыңыз – санлаган.
9 Инчә юксәк – бик югары.
10 Мәүкыйгы – урыны.
11 Дәхле тәмсил иделмешдер – йогынты ясаучы мисал итеп китерелгәндер.

ядә табигъ ителән бер кач дөрле ләһҗәләрдәге[1] хикәяләре, романлары укыдыкдан соңра, Әхмәд Мидхәд әфәнденең, Вәҗиһинең романларына башладым. Вә бу юл илә Казанда булуы бимөмкин бөтен әдәби әсәрләре укыдым. Бунлар миянында бәк чук французымдан тәрҗемә романлар улдыгы кеби Халид Зыя, Нәмикъ Кәмал, Зыя пашаларның, Габделхак Хәмиднең әсәрләре варде. Вә Ихсан бәк тарафындан тәрҗемә иделән Жюль Вернның бөтен хикмияте[2] укылмышде. 1 нче, 2 нче, 3 нче әдәби әсәрләре яздыгым вакыт русчадан һичбер әсәрем юкдыр. Вә бөтен әдәби зәвыкым фәкать төрекчә әсәрләрдән алмышде. Вә бу госманлы, азәри, үзбәк, кыргызча язылан китаплары укымак өчен һичбер вакыт һичкемдән «төрекчә» дәрес алмамышдем. Безем дәвереңбөтен мөнәвирләренең әдәби тәрбиясе ашагы[3] югары шигырь тарызында улмышде. (Табигатьлә, буңа рус гаскәрендә хидмәтдә булунан «Солдат»ларың, Госман паша хикәяләре дә карышмышдыр.) 19 яшемдә русча тәхсил[4] өчен мәктәбә кердегем заман, даими уларак, Истанбул мәҗмугалары укыйордек. Вә гайне заманда Парисдан, ... (Болгариядән улачак) «Мизан», Мисырдан «Төрек», ..., белмим, нә газеталар тәгассыб идейордек. Буның өчен әксәриятемез[5] истибдадның[6] галәйһендә идек. Вә буның өчен Русиядә 1905 сәнәсендә аз чук хөррияте матбугат мәйдана килеп, кач сарылдыгымыз заман вазгыятемездә, кирәк Русия вә кирәк Төркиядә истибдадның галәйһендәге фикерләремезне тәлкыйнә башламышдык[7]. Вазгыятьнең вирдеге имкяндан Габдулла Тукай, Сәгыйд Рәмәй, Дәрдемәнд, Мәҗит Гафури кеби халык шагыйрьләремез мәйдана чыкдыгы өчен табигатьлә Габделхәмид Төркиясендән илһам аламамышларде. Халыкчылык вә милләтчелеккә тәмаман ябанчы[8] Габделхак Хәмид бәкнең «Тарикъ бине Зыяд»ын, Фикрәтнең гаять сүсле[9]

[1] Ләһҗәләрдәге – телләрдәге.
[2] Хикмияте – хикмәтләре.
[3] Ашагы – асткы.
[4] Тәхсил – белем алу.
[5] Әксәриятемез – күпчелегебез.
[6] Истибдадның – һичкемгә буйсынмый үзебезчә хөкем итүдә.
[7] Тәлкыйнә башламышдык – аңлатуга керештек.
[8] Ябанчы – ят, чит.
[9] Сүсле – бизәкләнгән.

инчә шигырьләре нә укылыйорде, нә аңланыйорде, нә бунлар безем рухымыза бер гыйза вирейорде. Төркиядә мәшрутиять[1] игъланы бөтен Төрек илләрендә бөек бер бәйрәм кеби кабул иделдеген ул вакытның гәзитәләре тәгассыб идәнләр, табигый белейорыз. Безем шимальнең мөхәррирләре, җәмәгать хадимләре, төҗҗарлары[2], мөгаллимләре, талибләре[3] берәрләп дәгел, унлап, йөзләп, Төркия хәрәкәтә башладылар. Вә бурадан ике гыйза, ике рух арамайа чәкдиләр. ... мәшрутиять дәверендә Төркия төрекләре нә әдәбиятта, нә гыйлемдә, нә шигырьдә, нә театруда бөек ... мәйдана китермәделәр. Хариҗда калан төрекләр русларны аңлайан бөек бер төрек әдәбияты шагыйре вирәмәделәр. Вә анлары кәндүләрендә җәрәян итдерерлек бер ... куәтә малик улмадылар. Вә билгакес[4], хариҗ төрекләрендә бу дәвер әдәбиятның иң парлак дәвере улды. Шималь Фатих Әмирхан, Фатих Кәрими, Галиәсгар Камал, Г.Ибраһим кеби бөек әдипләр вирде. Габдулла Кари, Гөлсем ханым, Кәрим Тинчура кеби артистлар вирде. Сәгыйдь Рәми кеби берни дәрәҗә шагыйрьләр мәйдана атды. Әдәби, гыйльми хәят көндән-көн байланды. Вә бунларың өнендә[5], табигый, лисаны[6] вә рухы ябанҗы улан госманлы улса да, госманлы шигырьләре шимальдә йир тотамады. Йирле мөхәррирлә мөҗадәлә[7], мөбарәзә[8] ибдамады[9]. 1909 нчы сәнәсендә истигарә башланан[10] «Төрек йорды» мәҗмугасы, төрек берлегенең тәрҗеман[11] әфкяре буларак, шимальдә гаять бөек бер җитдиятә тәгассыб иделейорде. Төрек җәрәяны бу мәҗмугаи кәндүсенең тәрҗеман әфкяре сайыйорде, матди вә мәгънән мәҗмугайа ярдәм идейорде. [...] Шул «Төрек йорды»ның ачдыгы хөррияте берлек хәрәкәте табигый хәлендә җәрәян идеп дә, уртайа 15 сәнә дәвам

---

[1] Мәшрутиять – конституциялелек.
[2] Төҗҗәрләре – сәүдәгәрләре.
[3] Талибләре – укучылары.
[4] Билгакес – киресенчә.
[5] Өнендә – алдында.
[6] Лисаны – теле.
[7] Мөҗадәлә – бәхәсләшү.
[8] Мөбарәзә – бергә-бер чыгып сугышу.
[9] Ибдамады – тудырмады.
[10] Истигарә башланан – көтелә башлаган.
[11] Тәрҗеман – тәрҗемәче.

идән җиһан мөхабәрәсе[1] тәрбиясе иде. Бүгенге көндә нә бәнем мәкаләләрем йир улырде, нә бәдиһи[2] мәсьәләләре укыячак чолук чоҗук[3] улыйорде. Фәкать ара-тирә 15 сәнәлек бер узаклык[4] вә хариҗиядән, вә Төрек илләрендәге соңгы сигез сәнәдәге рухани бушлык бунлара бер мәҗбүрият мәйдана китермешдер. Буның өчен, газизем Гали Хәйдәр Әмир бәк, сезең бу ике әдәбиятың үзара берләшмәмешендәге гөстәрдеңез әсбаби догру буламыйорум. Хариҗ төрекләрендә төреклек хариҗында тупланма хәрәкәте һичбер вакыт улмамышдыр. Шималь – Казан әтрафында, Төркестанда – мәҗари әтрафында, Кырымда – Бакчасарай, Азәрбайҗанда – Баку әтрафында фәкать кәндүсенең ... япмак тәшәббесендә[5] булынмамышдыр. Бу мәркәзләр даимән камалышта улдыклары хәлдә, даимән кәндүләрен бөек төрек ... уларак хис итмешләр. Йирләшдекләре тупраклары, суладыклары һаваның бер төрек тупрагы, төрек һавасы улдыгына канигъ улмышлардыр[6]. Вә бунлар хакында берсе инглиз тарафдары, берсе рус тарафдары, берсе гаҗәм[7] тарафдары дия чыгарылан иддигаэлар[8] – «Төрек берлеге» дошманнары тарафындан уйдырылмыш яланлардыр. Вә катгыян ... йирләре булынмамышдыр. Солтанат вә хәлифәт Төркиясенең соңгы мәҗариядәге җиһад[9] мөкаддәс игъланының Русия төрекләренең җавапсыз калдырылмасы мәйдана сөреләчәк улса, буның мәсьүлияте бездән фазлә шәүкъ[10] хәзерләнмәмеш, дөшенелмәмеш уен япанлара гаид улачакдыр. Мәҗария дәверендә Русия төрекләре шөгурлы-шөгурсыз[11] бер кач җиһад япмышлардыр. Вә шималь төрекләренең мәҗбүран алынан бөтен гаскәрләре төрекчелекдә шөпәле улдыклары өчен рус әркян хәребе

---

[1] Мөхабәрәсе – сугышы.
[2] Бәдиһи – көн кебек ачык, билгеле.
[3] Чолук чоҗук – гаиләә.
[4] Узаклык – ераклык.
[5] Тәшәббесендә – тапкырлыгында.
[6] Канигъ улмышлардыр – канәгать булганнардыр.
[7] Гаҗәм – гарәптән башка халык, иранлылар, фарсылар.
[8] Иддигаэлар – нигезсез дәгъвалар.
[9] Җиһад – сугыш.
[10] Шәүкъ – теләк,омтылыш.
[11] Шөгурлы-шөгурсыз – аңлы-аңсыз.

тарафындан Кафказ хөдүдендә[1] тәмаман алынмыш. Вә Алмания, Австриягә каршы кулланмышдыр. Вә бунларың бөек кыйсеме гаять шөгурлы уларак, әсир дөшмешләрдер. ... ана ватанны мөхафәзә[2] өчен Диҗлә-Фарат сахилләренә кадәр килмешләр вә Төркия өчен шәһид улмышлардыр. Әһалинең калан кыйсеме бөтен куәтилә төрек әсирләренә ярдәмдә булынмыш вә бунларың тәрбияләре өчен, ягъни карарлары өчен, бөек бер гайрәт сарыф итмешләрдер. Бик бөек тәгассыб уграмышлардыр. 1915 сәнәсендә төрек әмирләрендән ... Мостафа ... төрекләрә ярдәм дә итмеш. Гарәби аркадашың ... саясендә мәмләкәтнең бөтен тарафында ике йөз мөселман корбан япылмыш, 150 кеше тәүкыйф иделмеш[3]. Вә бунларың бөек бер кыйсеме сәнәләрчә ... хәлендә Сибириянең иң суык урыннарына сөрелмешдер. Бу төрек һәйәте шөгурлы-шөгурсыз гайни гая[4] өчен чалышыйорларде. Гайни гаяйа догру хәрәкәт идейорларде. Шимди шу Диҗлә-Фарат сахилләрендәге шәһидләрнең рухы сәнәләрчә ... калан шу төрекләрең калебе «син төрекчеме» дия ... бер милләтсез ... батырдысына төрек матбугатында йир булмасына ... улмасынмы?

*Г. Исхакый*

Хат ЯhММҮ мирасханәсендә, Г. Исхакый фондында, электрон күчермәсе дискларда (диск №2) саклана. Хатның язылу датасы билгеле түгел. Татар телендә, гарәп хәрефләре белән язылган.

*Текстны Фәния Фәйзуллина әзерләде*

---

[1] Хөдүдендә – чигендә.
[2] Мөхафәзә – саклау.
[3] Тәүкыйф иделмеш – кулга алынган.
[4] Гая – төп теләк.

## ***Хөрмәтле Гаяз әфәнде!***

Сезгә әллә нинди кирәкле-кирәкмәс кешеләрдән хатлар килгәнен уйлап, элгәре үземне танытып үтмәкче булам[1]. Мин сезне бик яхшы таныйм. Бөтенләй бер ЧЕКА[2] язучысы булып, сезне алдатырга, яисә монда берәр кешегә зарар итәргә дип, юри язылмаганын белдерер өчен, ике арамызда булган бер вакыйганы хәтерләтеп үтәм: 1915 нче елның көзендә Самара вокзалындан Мәскәүгә карап барган поездда, Себер ягының аксак бер сәүдәгәре берлә сез сөйләшеп утырганда, мин сезнең янга килеп кердем. Сезне элгәре күреп таныганга, кул биреп күрешдем. Ул вакыт мин, солдаттан калу юлларын эзләп, шәһәрдән шәһәргә чавып[3] йөри идем. Шундан Мәскәүгә йитәргә берничә эстанса[4] калганчы бергә чәйдәш, ашдаш булып бардык. Өченчемез Кызылъярның атаклы сәүдәгәре Кәмал абзый иде, инде хәтерләдегезме? Сез ул сәфәрегезне онытмасаңыз кирәк. Сез ул вакытда безгә «Шакир Мөхәммәдъяров өйләнде, туйдан кода булып кайтып киләм» дигән булсагыз да, хәзер мәйданга чыкган провокатор Хәнәфи Кайбишевның эшләрендән сезнең ул вакыт матбугат әһалинең җыелышын оешдырырга Сарытау шәһәр арасында чавып йөрегәнлекеңез беленде. Сезнең артыгыздан бер адым калмаенча охранка кешеләре йөргән икән. Бәлки безнең бергә барган вагонымызда да сезне сагалаучылар булгандыр. Менә аңладыңыз инде мин кем? Андан соң инде бик күп эшләр булып үтде. Ул вакытдагы япь-яшь кеше булган минем, хәзер ярты башым агарды. Башдан үткәнләрне язсак, татсыз булса да, үзенә күрә бер «Әлфе ләйлә вә ләйлә» булыр иде. Аны сөйләп тормыйм. Монда минем кебек большевикларның «сыйрат күперләре»ндән кичкәнләрнең барысында да ул гаҗәп эшләргә кытлык юк. Кызганыч, шуны яза гына алмыймыз. Язсак, кирәкмәс кешенең кулына төшәр дип куркасың. Әлбәттә, язып

[1] Бу хат төрле юллардан әйләнеп идарәмезгә килеп чыкты да, укучыларымызны таныштырыр өчен бик аз үзгәртеп басамыз.

[2] ЧЕКА – ЧК – чрезвычайная комиссия.

[3] Дөресес: чабып.

[4] Дөресе: станция.

килүчеләр бардыр. Ләкин тарихда бик аз була торган бу дәвер үзен мәңгеләндерергә татарның зур бер язучысын көтеп тора. Әгәр Аллаһы биреп кайтсаңыз, искиткеч материаллар монда тулып ята. Сүзне оныттым. Менә шул гакылга да килмәгән, хыялга сыймаган эшләрдән үтә-үтә мин картайдым. Башымны агартдым; айлар буе туйганчы икмәк күрми, атналар буе көлгән бер кешене очратмый, һәрбер дөбердәгән тавыштан җаным уч төбенә килеп елларны үткәрдем, зинданында да булдым; ЧЕКАсында да ятдым; куылдым да, таландым да, ләкин, Аллаһыга мең шөкер, илгә исән-сау чыкдым, вөҗданымны заблый[1] торган бер эш эшләмәдем. Боларны язып китәм. Каләм тоткач, кулны тыеп булмый. Тагы монда шулай үзеңне саклап тору, караклар эчендә бер кызның пакьлеген саклаудан җиңел түгел бит. Бик күп кешеләр бит элгәре Советның дусты, аннары ЧЕКАның ышанычлысы, аннары халыкның котын алган большевик шымчысы булып китделәр. Менә тамак кайгысы берлә дөнья куып йөргәндә «Милли юл» мәҗмугасының 3 нче нөсхәсен кулга төшереп алдым. Мәҗмуганың кулдан үткәнгә каралып, саргаеп, читләре тишкәләнеп беткән иде. Үз күземә үзем ышанмаенча укыдым. Башындан ахырына кадәр укыдым; тагы икенче тапкыр укыдым. Иске тормышлар җанланды, иске матбугатымыз күз алдына килде, аның артындан иске милли тартышулар, милли кычкырышулар, милли театрлар, милли әдәбиятлар... Берсе артындан берсе күз алдындан үтде. Мин үземне үзем онытып, татлы, татлы уйга чумганмын. Болар бит әле һәммәсе беткән иде, һәммәсе большевикның ялган макталуы, татсыз, тозсыз, ямьсез язулары, милли хисемезне мыскыллый торган, компартия, совхоз, авиахим кебек рус сүзләре берлә алышдырылган иде. Бу кайдан килеп чыкды? Бердән: «Бетмәгән, бетмәгән! Без генә монда албасты астында басдырылганмыз. Бетмәгән, уянасы гына бар, бар да бар» дип кычкырып йибәрдем. Мәҗмуганы тагы әйләндереп-әйләндереп карадым. Күземдән яшьләр китде. Ләкин шадлыклы яшь, бик күп вакытлар югаткан[2] кадерле бер баласын искәртмәсдән исән-сау очраткан бер ананың,

[1] Дөресе: азаплый.
[2] Дөресе: югалткан.

бер баланың башы кебек татлы, тәмле баш. Шул үземнең «әле без бетмәгән икәнмез»гә дәлил эзләр өчен тагы мәҗмуганы сөздем. Андагы көчле рух мине тагы тереләтде. Чын бит! Без бетмәгән! Безнең бөтен барлыкымыз кар астында, чүп-чар астында калса да, алар бит эреми, череми торган милли җәүһәрләр. Чукынсаң да бит, Тукайның шигырьләрен, мәрхүм Габдулла карыйның ясаган милли типларын, Фатих Әмирханның энҗе кебек хикәяләрен, сезнең татар исенә манчылган театруларыгызны бетереп булмый. Киресенчә, хәзер аларның кайберселәре күтәрелде, большевикның чүбе-чары берлә аларның никадәр зурлыклары һәркемнең күзенә күренерлек булды. Мондагы үзгәрешләрне сез инде һич күз алдыңызга китерә алмый торгансыз. Монда һәммәсе большевик, «рус өмәчесе» дип уйлый торгансыздыр. Бу дөрест түгел. Монда большевик бездә шул кадәр аз ул татар тормышында, шул кадәр көчсез, аның артында ЧЕКАсы булмаса, ике тиен бер акчалык кыйммәте булмас иде. Ләкин алар арасында шундый мәгълүматлары бар ки, Шахгалиның начарлыклары тары бөртегедәй булып калалар. Болар үзләренә рус кабагындан бирелгән җуан бер марҗа өчен сатмаган бер милли нәрсәне калдырмыйлар. Ләкин яшь коммунистлар арасында хәзер бик күп төрле бүленүләр бара. Аларны коммунист фиркасы үзе милләтчелек юлына төртә. Аларны рус, яһүди, әрмән коммунисты янында өченче, дүртенче дәрәҗәдә тотып ачуларын китерә. Аларның милли хисләрен уята; хәзер яшьләр арасында иң күп сөйләнә торган сүз – милләт мәсьәләсе. Татар коммунист яшьләре, бу эштә руслардан бигрәк, яһүдиләрдән гыйбрәт алып, милли ясамакга баса баралар. «Милли юл» алар арасында да бик күп сөальләр ачкан; бик күп шау-шуга сәбәб булган. Шуңа күрә ЧЕКА аларга, «Милли юл»ны күрсәтмәскә, укытмаска тырыша, шуның өченме, дим хәзер милләтчеләр арасында тоталар, ябалар бик күп, Казанда шул өч-дүрт ай эчендә 30-40 кеше ябылган. Уфа да өлешсез калмаган. Хәтта Мәскәү кебек җирләрдә дә әллә никадәр кеше кулга алынган. Тарихчы Һади Атласи күптән бирле зинданда ята. Ул 1910 нчы елны милли хиссиятне уята торган тарих язганга күрә ябылган диләр. Аннары шуны да әйтергә

кирәк, ул большевик берлә бер дә оешу, советлашу ягында булмады. Иске большевиклардан Солтангалиев да ябылган диләр. Теге безнең балалар мәҗмугасы чыгаручымыз Фәхрелислам Агиев та ята икән. Аны ни өчен япканлардыр, белмим. Бик күп вакытлар коммунистларга яхшы күренергә теләп Мәскәү татарларының башын бик әйләнелдергән иде. Большевик кем икәнлеген бераз танысын. Мәскәүнең [...] 15 елга Соловкига сөргәнләр. Ул да үзенчә элгәреге замандагы патша хәзрәтенең исәнлегенә кылган доганы совет хәзрәтләренә әйләндергән муллалардан бер мулла иде. Никдер большевикларга ярамады? Төрле шәһәрләрдә коммунист ыстудентлары[1] арасында бик күп тотулар, ябулар булган диләр. Боларны без яхшы белмибез; ләкин аларның араларында «русдан аерылырга кирәк дигән фикер таратылган диләр. Менә әле корбан гаете мөнәсәбәте берлә бер зур шәһәремездә булдым. Монда без бит хәзер бик динле. Сез мәчетләрне көчләп ябып, муллаларга бик күп түләү куеп, муллалыгын ташлатып, дин бетә дип уйлый күрмәгез. Большевикка каршы хәзер акча берлә тартышу бик авыр. Халык бик ярлы. Муллага куелган өч йөз, биш йөз сумларны артып киткән салымны кайвакыт түли алмыйлар, мулла урынын ташлый, ләкин дингә баглану элгәредән нык, безнең кебек элгәреге замананың кызыл авызлары намазга җиңел караучы, көндез сәхәр ашаучылар барымыз да, бер үзем генә түгел, рузаны калдырмыйча тотабыз, җомгага бармый калмыймыз. Гаедне дөбердәтеп, теге кяферләрнең котын очырып, йөрәген яндырып бәйрәм итәбез. Менә шунда – мәсҗеддә халыкның күплегеен күрсәңез иде, халыкдагы ихласны бер күрсәңез иде, исеңез китәр иде, элгәре ул юк иде. Шул көнләрдә бер якын иптәшемә бик зур бүләк итдереп, бала-чага ятып беткәч кенә, кесәнең әллә кайларындан чыгарып, «менә сиңа бәйрәм тәбриге» дип, үземнең майланган «Милли юл» тотдырам. Ул көлде дә, «бездә аның яңырагы бар» дип, миңа 5 нче номерны чыгарып куймасынмы? ... Үткән төнне рәтләп йокламаган булсак да, бер-ике дуст төн буе шул мәҗмугаларны укып кичне үткәрдек. Әллә никадәр сөйләшдек, уйлашдык, план кордык. Сугыш башлангандан бирле

[1] Дөресе: студентлары.

мондый шадлыклы бәйрәм иткән юк иде. Безгә шул шадлыкны биргән өчен сезгә барыңызга да бик зур рәхмәт укыймыз. Бу тегеләй генә әйтелгән «рәхмәт» түгел, чын күңелдән чыкган рәхмәт. Әлбәттә, читдә торып мәҗмугалар чыгару, таркау көчләрне җыю сезгә дә җиңел түгелдер. Без монда большевикларның аларга «дөнья буржуазиясе бирә» дигәнләренә ышанамыз. Андый Гаяз Исхакыйларны аңлый торган «дөнья буржуазиясе» булса иде, большевизмда дөньяга килмәгән булыр иде. Эш анда түгел. Мондан торып без берни дә сезгә ярдәм итә алмыймыз. Ләкин безнең рух сезнең берлә; безнеке генә түгел, бөтен халыкныкы .... шундан әмин булыңыз, тагы бер форсат туып, берләшергә җае чыкса, безнең халык милли байрак янында бер җан, бер тән кебек оешачак вә юл салган йитәкчеләр артындан үлгәнгә кадәр барачакдыр.

Шуны әйтеп үтим: Фуад әфәнде Туктар, Закир Кадыйри кайдалар? Садри Максуди, тарихчы Батталлар кайда? Аларның имзалары ник күренми? Әллә, качып, әллә нинди исемләрдә язалармы? Монда ачыкдан-ачык имза берлә язулар халыкның рухын күтәрә. «Большевикдан курыкмый торган безнең дә кешеләремез бар» дип, милли һавалыгын артдыра. Качып әллә нинди исемләр астында язулар эчне пошыра. Куркаклык бар икәнлеген аңлатып дәртне кайтара... Без монда мәҗмугагызны мөмкин кадәр күп укытырга тырышамыз. Хушыңыз, иптәшләреңезгә бик зур рәхмәт. Армаңыз, талмаңыз!! Тагы шулай язгалашдырырмыз, ләкин бит чыгару бик авыр, чыгару...

*Юлдашыңыз*

Хат «Милли юл» журналының 1929 елгы 13 нче санында басылган.

*Текстны, искәрмә һәм аңлатмаларны*
*Гөлчирә Ханнанова әзерләде*

***Хөрмәтле Аяз Исхакый әфәнде!***

*Оберстдорф*
*6.3.1947*

Сезгә Алманияда яшәүче мескен төркләр исеменнән сәлам.

Моңа кадәр күптән хат язарга уйласам да, төрле сәбәпләр аркасында яза алмадым.

Минем сезне үземнең мәктүбем[1] белән борчуым өчен гафу итүегезне үтенәм.

Башка мәсьәләләр турында язып тормыйм. Үзебезнең хәлне белдерергә ашыгам. Гәрчә безнең хәл сезгә мәгълүмдер. Хокукый яктан без кануннан тыш игълан ителгән адәмнәр хәлендә. Безне һичбер канун якламый, безнең мәнфәгатьләрне беркем дә сакламый. Мәдәниятле егерменче йөздә без борынгы коллардан да түбәнрәк дәрәҗәдә калдык. Безне бары да читкә куялар, хәтта коллык хокукыннан да мәхрүм иттеләр.

Икътисади яктан мескен хәерчеләр хәлендә. Безнең ашарга ашыбыз, тарарга тарагыбыз, кияргә киемебез юк. Алырга түләр өчен пулыбыз[2] юк. Һәркемнең башында бу көн бер сөаль: Ни япарга[3]? Һәрбер кем дә үз хәленнән чыгу юлын таба алмый.

Мин үзем һөнәрем белән журналист, мөгаллим һәм башка. Еллар буенча төрле авырлыкларга карамастан, телләрне һәм дөньяны өйрәндем. Минем моңа кадәр үткән юлым, тормышым, моңа кадәр дөнья әдәбиятында булган иң кызганыч романнардан да катлаулырак. Мин дөнья әдәбияты белән ни кадәр тирәнрәк танышкан саен, миндә милләтчелек хисе арта барды. Миндә төрк әдәбиятын милләтләр әдәбияты сафында җиткерү максаты күбәйде. Һәм мин үземнең бөтен көчемне бу хезмәткә куярга хәзерләндем. Ләкин усал язмыш мине бу бәхеттән мәхрүм итте. Сабый чактан бирле булган максатым, бөтен булган теләкләрем бушка чыктылар. Алар хәзер чынга ашмаган хыяллар булып кына калдылар. Инде бетте көч, сынды кылыч, шул булды эш!

Мин бу мәктүпне язып утырганда ни эчәргә, ни ашарга белмим. Мин андый ачлыкларны, авыр көннәрне күп кичердем.

---

[1] Мәктүп – хат.
[2] Пул – акча.
[3] Ни япарга – ни эшләргә.

Әмма ул вакытта минем киләчәккә ышанычым, алда милләт әдәбияты өчен хезмәт итү хыялым бар иде. Ә хәзер? Хәзер һич перспектив юк. Соң ни өчен яшәргә? Ни өчен бу хурлыкка түзәргә? Әгәр көтмәгән сәбәпләр мине коткармаса, Сез минем бу мәктүпне укыган вакытта, мин дөнья газаплары белән саубуллашкан булырмын.

Сезгә мәктүп язуымның төп сәбәбе икедер. Беренчесе – Сез минем дөньяда иң яраткан кешемсез. Икенчедән, минем язган шигырьләр җыентыгым бар. Мин аларны калдырам. Сездән үтенәм, аларны укучылар дөньясына чыгаруыгызны (мөмкинлек булганда).

Мин үткән көн бер урысны очраттым. Аның Төркиядә ниндидер таныш марҗасы бар икән. Һәм хәзер ул үзенең бөтен гаиләсе, якыннары белән бергә Төркиягә китү өчен, шул марҗа аркылы, Төркия хөкүмәтеннән официаль рөхсәт алган. Рөхсәт кәгазьләрен үзем укыдым. Төркиядә яшәүче бер марҗа, моннан 7-8 Иваннарны алганда, безнең халык моны япа белмиме[1]? Бәлки Төркиядә урысның хокукы төректән бөегрәктер?

Минем Төркиядә 18 миллион кардәшләрем яши. Күрәсең, 18 миллион кардәшем, үземнең төп Ватаным, динем, каным бер булган халкым ярдәм итә белмәс. Мин сөягемә кадәр төркче идем, әмма 18 миллион төркем булганчы, бер марҗам булуы яхшырак икәнен күрдем.

Безнең хәлне биредә калган мескен мөселманнарның тормышларының авырлыгы, тик үз башыннан кичергән әҗәлле генә аңлый алачак. Бу көнге хәлләр төрк һәм мөселман дөньясы тарихында Кара Тап булып калачак.

Сәлам белән, Сезне хөрмәт итүче Аксам Йосыф углы.

Хат ЯһММҮ мирасханәсендә, электрон күчермәсе дискларда (диск №3) Г. Исхакый фондында саклана. Татар телендә, латин хәрефләре белән язылган. Текст басмага мирасханәдән алынды.

*Текстны Илһам Гомәров әзерләде*

[1] Япа белмиме – эшли белмиме.

## Мөнир Хәсбиулла хаты

1917 елгы Октябрь түнтәрешеннән соң большевикларның гайре русларга каршы алып барылган милли сәясәтеннән риза булмаган Гаяз Исхакый, 1919 елда туган илен ташлап, гомеренең күпчелек өлешен мөһаҗирлектә уздырырга мәҗбүр ителә. Ул бу елларда Франция, Германия, Төркия, Польша кебек илләрдә сыену урыны таба. XX гасырның 20-30 елларында Ерак Шәрык дәүләтләрендә мөһаҗирлектә яшәгән татар халкының милли теле, аның киләчәктә милләт буларак яшәеш мәсьәләләренең кискенләшүе сәбәпле, 1933 елда әдип һәм публицист Япония, Корея, Кытай һәм Япония протекторатында яшәгән Манжу-Го мәмләкәтләренә юлга чыга.

Мәгълүм ки, Г. Исхакый 1933 елның октябреннән 1936 елның 1 мартына кадәр Ерак Шәрыкта Идел-Урал төрек-татар милли-мәдәни җәмгыятьләре һәм «Милли байрак» газетасын оештыру эшләре белән мәшгуль. Әдип һәм публицистның «Яңа милли юл» журналы һәм «Милли байрак» газетасында урын алган күпчелек мәкаләләре Ерак Шәрыктагы милли көрәш тарихына карый һәм алар Г. Исхакыйның 15 томлы «Әсәрләр» тупланмасының 11 томында урнаштырылды. Язмалардан аңлашылганча, Г. Исхакыйның Ерак Шәрык дәүләтләренә сәфәренә чаклы татар милли-мәдәни тормышының торышы мактанырлык булмый. Монда аеруча мөһим бер сәбәпне искәртеп үтү дә кирәктер: Октябрь түнтәрелешеннән соң үзләренең язмышларын мөһаҗирлек белән бәйләгән татар халкы, нигездә, дини берлек астында берләшергә тырыша. Ерак Шәрыкта аның башында Япониядә оештырылган «Мәхәлләи исламия» җәмгыяте җитәкчесе Габделхәй Корбангалииев тора. Г. Корбангалиев үз мөхәрририлегендә нәшер ителгән «Яңа япон мөхбире» журналында милләтне, нигездә, «ислам берлеге» идеясе, ягъни панисламизм фикере тирәсенә тупларга тели. Тышкы факторны да искә алмыйча булмый: Төнъяк Кытайның Маньчжурия җирләре 1932 елдан Япония протекторатында булса да, әлеге территорияләр ул вакытларда рус хакимлегендә яши, ягъни Көнчыгыш Кытай тимер юлы белән турыдан-туры идарә итмәсә дә, СССР хөкүмәте карамаганда кала. Ниһаять,

түнтәрешкә кадәр дә, аннан соң да рус хәрбиләре һәм урта хәлле рус байларының күпләп яшәгән төбәге бу. Һәм шулар нәтиҗәсендә, руслар коткысы астында Ерак Шәрыктагы төрек-татар милли-мәдәни хәрәкәте һәлакәт алдына килеп баса. Болар белән янәшәдә, дини яктан берләшү теләген өстен күргән Г. Корбангалиевнең идеяләрен кабул итәргә теләмәүчеләр дә табыла. Әлеге сәбәпләр Ерак Шәрыктагы милли хәрәкәттә каршылык китереп чыгаруга сәбәп бирә. Г. Исхакый нәкъ шул вакытта төрек-татарларның бергә тупланып яшәгән Хайлар, Харбин, Шанхай һәм башка шәһәрләрдә милли-мәдәни хәрәкәтне җайга салу белән шөгыльләнә. Аның «Шанхай», «Харбин», «Хайлар», «Ерак Шәрык», «Японияд ә төрек-татарларның Беренче корылтае» кебек мәкаләләре Ерак Шәрыктагы милли-мәдәни һәм дини тормыш, аның аянычлы хәлен ачык күрсәтәләр. Бу язмалар Ерак Шәрыкта яшәргә мәҗбүр ителгән төрек-татарларның фаҗигале язмышларын, аларның милләт буларак яшәү-яшәмәү алдында калуларын, барлык катлаулы проблемаларын күз алдына китереп бастыра.

Укучыга тәкъдим ителәчәк хат Харбиндагы, бер яктан, рус коткысы, икенче яктан, фәкать дини мәнфәгатьләрне генә күздә тоткан аерым төркем татарлар басымы астында калган милли җанлы халыкның хәлләре, Г. Исхакый тарафыннан язылган «Харбин» исемле мәкаләсендә гәүдәләнгән вакыйгалар да вазгыятьнең асылын ачыкларга ярдәм итә. Мәкалә беренче тапкыр «Яңа милли юл» журналының 1935 елгы 1 нче санында «Гаяз Исхакый» имзасы белән басылган.

Форсаттан файдаланып, Харбин шәһәре турында да кыскача әйтеп үтү урынлы булыр кебек. Маньчжуриядә урнашкан Харбин 1896 елда Кытай тарафыннан түләнгән компенсация буенча Россиягә күчә. Көнчыгыш Кытай тимер юлы төзелеше башлану белән, XX гасырның башларында ук татар сәүдәгәрләре дә Харбинга барып урнаша (күпчелеге Пенза ягыннан). 1904–1905 елгы рус-япон сугышы булуга кармастан, аларның саны тагын да арткан. 1901 елда – агач мәчет, 1906 елда таш мәчет төзиләр. Мәхәлләнең беренче имам-хатыйбы, шулай ук Пенза төбәгеннән Гыйниятулла Салиәхмәт (1889–1926) чакырыла. Ул вафа-

тына кадәр шул вазыйфаны алып бара. Г. Салиәхмәт вафатыннан соң аның урынына мәхәллә мулласы Мөнир Хәсбиулла вакытлыча имам-хатыйп итеп сайлана.

Г. Исхакыйга хат язган Мөнир Хәсбиулла кем? Ул Ерак Шәрык милли-мәдәни тормышында нинди роль уйнаган? Кереш мәкаләдә бу хакта да әйтеп узу комачау итмәс шикелле. М. Хәсбиулланың яшәгән еллары (1896–1944). Туган җире – Пермь өлкәсе Красноуфим өязе. Башлангыч белемне 1910 елга кадәр авыл мәктәбендә ала, 1916 елга кадәр Красноуфимскида Мирсәед бине Мөхәммәдсадыйк Динмөхәммәд ахун мәдрәсәсендә укый. 1916 елда имам вазыйфасында хәрби хезмәткә алына. 1917 елда Красноуфимскига кайтса да, 1918 елда төрек-татар гаскәре составында кабат хәрби хезмәткә китә. Генерал Каппель гаскәренә кушылып, 1920 елда Маньчжурия станциясенә кадәр барып җитә. 1922 елга кадәр Николай-Уссурийски һәм Владивостокта була. 1922 елда Владивостоктан ак армия калдыклары белән бергә Хунҗон, Гарин һәм Чинчун шәһәре аша 1923 елның 3 февралендә Харбин шәһәренә килеп җитә һәм шунда милли һәм дини эшкә тартыла. Харбин имамы Г. Салиәхмәт ярдәмчесе буларак «Гыйният» мәктәбендә дин дәресе укыта. Дәвалану максатыннан Германиягә киткән Г. Әхмәди урынында имамлык эшләрен алып бара, ә 1926 елның 4 сентябреннән, Г. Әхмәди үлгәннән соң вакытлыча имамлык вазыйфасын башкара. Г. Исхакыйның катнашлыгы белән Ерак Шәрыкта оештырылган милли-мәдәни һәм дини хәрәкәттә актив катнаша. Ул бу елларда Кобе шәһәрендә төзелгән мәчет ачу тантанасында катнаша. 1935 елның 4 – 14 февралендә Мукденда уздырылган Ерак Шәрык Идел-Урал төрек-татар корылтаена Харбиннан делегат булып килә һәм Үзәк идарәгә сайлана. Үзәкнең дини эшләр буенча рәис урынбасары итеп билгеләнә. 1938 елда, Мәдъяр Шәмгуни вафатыннан соң Үзәкнең дини комиссиясе рәисе. 1941 елда Мукденда узган Икенче гомум Идел-Урал төрек-татар корылтаена кадәр шул вазыйфаны үти. Харбинда Г. Әхмәди төзетә башлаган яңа «Мең ел мәчете»н аякка бастыруны үзмаксат итә. Аның бу хезмәтен Надир Дәүләт түбәндәгечә билгеләп уза: «1936 елда Харбинның яңа имамы

– Мөнир Хәсбиулла, Ерак Көнчыгышта татарлар яшәгән бөтен шәһәрләрне әйләнеп чыгып, ярдәм җыеп, төзелешне ахырына җиткерә. Нәтиҗәдә 1937 елның 8 октябрендә «Мең ел мәчете» зур бер тантана белән ачыла. 1939 елда шәфкатьлелек бүлеге оештыра, 1942 елда ятимнәр йорты ача.

Мөнир Хәсбиулланың кызы Мөнирә (1926 – ?) һәм улы Фуат (1928 – ?) барлыгы мәгълүм.

М. Хәсбиулла хакындагы мәгълүматлар Япониядә докторлык диссертациясе яклаган һәм Ерак Шәрыкта милли-мәдәни һәм дини хәрәкәтнең тарихын җентекле өйрәнгән Лариса Усмановадан алынды. Г. Исхакый томнарын төзегәндә аның ярдәме зур булды.

### *Мөхтәрәм Гаяз әфәнде*

Харбинда эшләр бик җайсызланды. Идарә канцеляриясе һаман бикләнгән хәлдә тора. Ачкычлар ... Кайчан гомуми җыелыш ясала, яңа идарә сайланса, шул вакытта гына ачкычлар тапшырылыр диләр. Шуңа чаклы Харбинда һичбер төрле рәсми мөселман оешмасы юк диләр. Без исә хаиннарның эшләре хөкемгә бирелгән вә хөкемнең мәгълүм бер карары булганга чаклы гомуми җыелыш җыярга ризалык бирмибез һәм ул вакытта да корылтай мәҗлесе белән байкот ителгән биш хаинның җыелышта иштиракатеннән[1] башка гына булса, ул гомуми җыелышны җыярга тиешлебез дигән ноктада торабыз.

Гаид мәрасимләре[2] дә бик ямьсез узды. Һәркөн полисәгә вә аерым шөгъбәгә[3] чакырып йөдәтәләр. Бу көн рәисебез Фәхри әфәнде аерым шөгъбәдә бик каты кыйналды. Вә бу кыйнау да вакытча гына булмыйча, иртәнге унбер сәгатьтән алып кичке тугызга чаклы өзлексез кыйнап тору сыйфатында булган. Бу соңгы мәсьәләдә дә бу көн мәркәзгә телеграмм бирдек вә моннан әүвәлге вакыйгалар хакында да телеграммлар биргәләп тордык. Вә ләкин бүгенгәчә һичбер төрле ярдәм булмыйча тора. Мәркәздән килгән беренче телеграммда военный миссиягә вә

---

[1] Иштиракатеннән – катнашыннан.
[2] Мәрасимләре – тантаналары.
[3] Шөгъбәгә – бүлекчәгә.

япон жандармиясенә мөрәҗәгать итеңез дигән хәбәр булса да, берсе артыннан берсе чыгып торган мәшәкатьләр саясында[1] ул мөәссәсәләргә[2] барып та мәсьәлә белән аңлашудан гаҗиз калдык. Табигый, бу язылганнар гомуми бер шәкелдә[3] генә язылды. Әле инде мәсьәлә ачыграк аңлашылсын өчен унөченче марттан алып, бүгенгә чаклы оешмабызның башыннан кичкән маҗараларын тәфсилле рәвештә яза башлыйм.

Чураковның, вә гомумән, хаиннарның ниндидер донослары буенча унөченче мартта рәис белән хәзинәдар Низаметдинне участокка чакыралар. Шунда Чураков та була. Шунда полисә чиновниклары унсигезенче марттан да калдырмыйча гомуми җыелыш ясаңыз дигән мәсьәләне кабыргасы белән куялар вә безнекеләр буңа риза булмагач, «алай булса абшинаңызы[4] ябабыз», диләр. Вә шул ук вакытта надзиратель Петров белән Чураков барып, ачкычларны алып китәләр. Ләкин печать салмаган. Моннан соң мәркәзгә телеграмм бирелгән иде.

Март ундүртендә өйләдән соң сәгать дүрткә Низаметдин аерым шөгъбәгә чакырыла. Дүртән алып кичке тугызга чаклы Имамато тарафыннан допрос ясала. Вә шунда кичәге [көндә][5] сезгә бирелгән телеграммның копиясе сорала. Вә бу телеграмм белән ни [...][6] бирдек дигән сүзне яздыңыз? Хөкүмәт мөәссәсәсе өстеннән андый [протест] ясарга сезнең хакыңыз юк иде, дигән придиркалар була. Вә бу вакытта [Имаматога] югарыдан зур гына тәнбиһ[7] ясалганы сизелә. Низаметдинның департаменттан кайтып керүе белән янә участокка чакыралар. Участокта да шулай ук тугыздан алып төнге уникегә чаклы төрле тарафлы допрослар ясала вә 18–20 сеннән соң калдырмыйча гомуми җыелыш ясарга тәкъдим итәләр вә [безнекеләр дә] аерым шөгъбәдәге җавапларында мөкайяд калдылар[8].

[1] Саясында – нәтиҗәсендә.
[2] Мөәссәсәләргә – оешмаларга.
[3] Шәкелдә – формада.
[4] Абшинаңызы – общинагызны.
[5] Квадрат җәяләр эченә кулъязмада танылмаган урыннарга контексттан чыгып автор сүзләре куелды.
[6] Кулъязмада бу урында берничә сүз танылмый.
[7] Тәнбиһ – кисәтү.
[8] Мөкайяд кылдылар – чикләнгән булып калдылар.

Мин үзем соңгы атна дәвамында бик каты авырып терелер-терелмәс гәрәфә көн генә аякка басып, гаидкә чыктым. Шушы көн төнге уникедә мине дә участокка чакыралар. Әле безнекеләр шундалар иде. Мин барып җитүгә Мурзенков белән Богатиев вә Суфиян килеп җитәләр. Алар да чакырылган булалар. Җыелып беткәч тә, полисә приставның могавине[1] бер япон вә шуннан Петров булганы хәлдә [иртәдән өйләгә чак] гаидне кайсы мулла укытырга тиешле. Менә икеңездә бергә сез шунда мәслихәтләшеңез[2]. Мин җавабымда шулай дидем: «Мин мәхәлләнең сайланган рәсми имамы булам. Гаидне моталәга[3] мин генә укытырга тиешлемен, – дидем. Моннан элек булган гаидкә балаларым йогышлы авыру белән авыру булулары сәбәпле чыга алмагач, ул гаидне Мурзенкадан укытырга сорасам да, бу гаидне үзем укытачакмын», – дидем. Шуннан соң Мурзенковның мәслихәтен сорыйлар. Ул шулай әйтә: «Мин старший мулла, мин имам-хатыйп, гаидне фәкать мин укытырга тиеш, Мөнирнең кулында указы да юк, мөәззин булырга гына ярый. Менә минем кулымда духовный устав бар. Аның икенче матдәсенә [язылган] мәхәлләдә 2–3 имам булса, мотлакан[4] аның старший чинда булганы укытырга тиешле. Теләсәңез, хәзер уставны китерәм». Шунда Богатиев әйтә: «Хәсбиуллин моңа чаклы да вакытлы гына имам иде. Хәзер халыкның күпчелеге Хәсбиуллинны теләми, Мурзенковны гаид укытырга сорый. Артта Суфиян дигәне һаман эт шикелле «Долой [красный мулла, коммунист]», фәлән дигән сүзләр белән өреп тора. Шулай итеп үзебезне төнге икегә чаклы тоталар. Вә ничек булса да, минем вазыйфамны Мурзенкага күчерү турында була. [Никадәр генә] вакыт узса да, нәтиҗәгә киләә алмагач, гаидне кем укыту мәсьәләсе иртә белән гаид укый башлаганчы, гаидкә җыелган халыкның күпчелеге, ягъни тавышка кую ысулында хәл ителер дигән сыйфатта таралабыз. Бу вакыйгадан соң да мәркәзгә телеграмм суктык. Ләкин без гаидне кем уку мәсьәләсен тавышка куюга ризалык

[1] Могавине – урынбасары.
[2] Мәслихәтләшеңез – киңәшләшегез.
[3] Моталәга – укырга.
[4] Мотлакан –һичшиксез.

бирмичә таралдык. Иртә белән гаидкә кадәр гаидне мин үзем укытырга тиешле булуымны белдереп, участок приставына гариза бирсәм дә, ул игътибарга алмады. Шул сәбәпле, хаиннар[1] гаидне Мурзенков белән укыдылар. Әмма безнең халык алар укып чыкканчы урамда көтеп торырга мәҗбүр булды. Гаид укылу вакытына департаменттан Имамато вә рус чиновниклары, полисәдән надзиратель Петров вә 30 лап полицейский бар иде. Мәсҗед бинасының әйләнәсе полисәләр белән әйләндерелеп алынган иде. Алар укып беткәч, мине мәсҗедкә чакырдылар. Вә без дә үз тарафлы халкыбыз белән гаид укыдык. Полисә һаман да шунда хазир иде, Имамато да беткәнче торды. Гаидтән соң сәгать бергә янә Имамато департаментка чакырды. Анда мин, Низаметдин әфәнде вә Фәхри әфәнде чакырылган иде. Шул вакытта барсак, [анда] Богатиев белән Чураков иде. Монда да Имамато: «Тиздән общий собрания җыярга тиешлесез, кайчан ясарга буласыз?», – диде. Без һаман югарыдагы сәбәпләрне тотып җавап бирдек вә һәрберебезнең аерым фикерләребезне язып, шуңа имза итәргә тәкъдим итте. Ләкин дүрт сәгатькә кадәр озын вакыт үтү сәбәпле, имза итү эше икенче көнне сәгать унбергә калдырылды. Бу вакыт Имамато: «Ни өчен син, сәяси мәүзугъта[2] гаидтә сүз сөйләдең?» - дип бәйләнде. Мин исә: «Һичбер сәяси мәүзугъда сүз сөйләмәдем вә сөйләргә теләгем дә юк», – дигәч, – «Син анда Манжу-го, Япония дигән сүзләр кулландың». Мин әйтәм: «Манҗу-го вә япон падишаһларына дога кылдым. Ул минем дини вазыйфам иде», - дидем. Имамато: «Юк, падишаһларга дога кылдырырга сездән кем дә сораганы юк. Сез үзегезнең мәмләкәтеңез булгач, үз падишаһларыңызга дога кылдырырсыз», – ди. Шуңа каршы мин әйтәм: «Монда Манжу-го химаясендә[3] вә аның миһман пәрвәрлегендә[4] яши торган халык безнең һәрвакыт аларның сәламәтлекләренә вә мәмләкәтнең тынычлыгына дога кылу дини бурычыбыз, – дидем. – Әгәр дә моннан соң сез мәңгы

[1] Хаиннар – сатлык җаннар.
[2] Мәүзугъта – эчтәлектә.
[3] Химаясендә – яклавында.
[4] Миһман пәрвәрлегендә – кунакчыл тәрбиясендә.

кылгач[1] дога кылмаскамы?» – дигән сөальне бирдем. Бу вакыт Имамато бераз гакылына килде булырга килде[2]: «Мин дога кылудан мәнгы кылам дип әйттемме, әгәр дә әйткән булсам, мин япон булуым сәбәпле ялңыш әйтелгәндер. Выражался[3], мин бит, сез, беләсез, мин рус түгел, үз телем түгел». Шуннан соң мин әйтәм: «Мин бит сезнең сүзеңезне ялгыз гына ишетмәдем, менә мәҗлестә булганнар һәркаюсы ишеттеләр бит», - дидем. Моннан соң төрлечә кыланышлары белән мине куркытып әйткән сүзен төзәттерергә тырышты. Мин инде артык каршы китәргә җөрьәт итмичә: «Алай булса, бәлки ялңыш выражался ителгәнсездер, ләкин мин үзем шулай аңлаган идем», – дип, бераз күңеленә тынычлык биргәч: «Шулай аңладыңмы, мин дигәнчә аңладыңмы, әгәр шулай аңлаган булсаң, китәргә рөхсәт», – диде. Чөнки бу мәсьәлә чыкканчы, гаид көне булуны сәбәп итеп, мин китәргә рөхсәт сораган идем. Миннән соң безнең рәис дә, хәзинәдар да, шулай ук Чураков белән Богатиев да анда калдылар. Мин киткәч артык допрос фәлән булмаган. Әмма гаиднең икенче көне сәгать унга мәзкүр[4] кәгазьләргә имза итәргә чакырган. Икенче көн Низаметдин авырып китә вә чакырылган сәгатькә Ибраһим әфәнде Акчура белән рәис баралар. Алар барганчы Богатиев белән Чураков да анда булалар. «Ләкин бу көн сезне кабул итә алмыйбыз, иртәгә сәгать унда, ягъни гаиднең өченче көнендә килерсез», – дип, Имамато кайтырга куша. Кайтып, департаментның аскы катына төшеп барганда рәис, үзенең пальтосы югарыда калуын исенә китерә дә, пальтосын алырга дип, югары менеп китә. Ибраһим әфәнде [түбәндә] көтеп кала. Озак та үтми Фәхри абзыйның бик каты кычкырган тавышы [ишетелә]. Ул да булса, пальтосын алган вакытта Чураковлар белән сүзгә килеп, шунда [Фәхри абзый Чураковка] «Син комиссар дип» кенә әйтүе була, бу Имамато якасыннан [тотып кыйный-кыйный], аерым шөгъбә бүлмәсенә алып керә. Монда бик озак кыйнагач [аерым бүлмәгә яба]. Вә

[1] Мәнгы кылгач – тыйгач.
[2] Текстта килде язылган. Дөресе: «кирәк» дип укыла.
[3] Бу сүзләр текстта кирилл хәрефләрендә язылган.
[4] Мәзкүр – югарыда әйтелгән.

аннан чакырып чыгарып, тагын кат-кат кыйный. Аннан сәгать җиделәрдә [участокка] озаталар. Анда Имамато үзе дә бара. Анда да кыйный. Табигый, руслар белән бергә кыйныйлар вә күбрәк, катрак кыйнау руслар кулыннан була. Руслар кыйнаган вакытта: «[Без] күрсәтербез сезгә Идел-Уралны. Мөһаҗирләр бюросына язылырсызмы? Безнең белән бергә эшләрсезме?» – дигән сүзләрне әйтеп-әйтеп кыйныйлар. Вә шулай [итеп] анда да кичке сәгать тугызга чаклы кыйныйлар. Вә тугыз сәгатьтә генә азат итәләр. Ниндидер [кәгазь] язып имза куйдырырга тырышалар. Ахырда Фәхри абзый үзе нинди [кәгазьгә] кул куйганын белмәсә дә, кул куярга мәҗбүр иткәннәр.

Бу көндә Фәхри абзыйның хәле бик мөшкел. Кичә бик күп кан китте. [Колаклары], арт тарафыннан башы бик шешкән. Кичә бер рус докторы карады. [Монда тагы] япон докторы чакырып караттык. Бер надзиратель белән шәһәр докторы [килеп] карап киттеләр. Әле инде япон жандармиясенә мөрәҗәгать [итәргә] дигән карарга килеп торабыз. Нәтиҗә ни булыр инде? Әлхасыйль[1], мондагы [маҗараларны] язып кына бетерә, аңлата торган түгел. Бөтенебезне шулай берәм-берәм чакырып кыйнаулары вә шул юл белән кулыбыздан эшне алу юлына керделәр булырга кирәк. Кичә гаиднең икенче көне, сәгать бердә бу мәсьәләне белдереп, кыска гына телеграмм суккан идек. Әле җавап алганыбыз юк. Һәрхәлдә ярдәмгә бик мохтаҗбыз. Японнар белән аңлашыр өчен бер дә тел белүчебез юк. Бик уңайсыз бер вазгыятьтәбез. Мөмкин булган чараларны күргәнеңезне җаннан үтенәбез. Юкса мәсьәлә бик чуалчык күренә.

Фәхрине докторлардан караттык, свидетельстволар алдык. Япон жандармиясенә һәм военный миссиягә гаризалар бирү хәзерлеген күреп ятабыз. Бүген Фәхри абзыйның җәмәгате жандармиягә мәсьәләне гарыз итәргә[2] дип, Миазаки дигән япон белән барса да, кабул ителмәгән. Бәлки, гариза бирергә кушканнар. Димәк, җәмәгате исеменнән дә гариза яздык.

Бу көн кич сәгать унда телеграммыңызны алдык. Иртәгә Чан-

---

[1] Әлхасыйль – кыскасы.

[2] Гарыз итәргә – аңлатырга.

чунга кеше җибәрәчәкбез. Хаиннарның канатланып йөрүләрен руслар бик шатланалар. Безнең халыкның рухы бик төшкән күренә. Вә хәтта, департаментка барырга уңайсызланырлык, куркырлык бер вазгыять алып бара.

Безем идарә әгъзалары унсигезенче мартка өйләдән соң сәгать дүрткә тагын чакырганнар. Табигый, барачаклар, ни нәтиҗә булыр?

Моңа чаклы тәфсилле хат яза алмавыбыз өчен гафу итеңез. Чөнки һичкемнең берәр төрле эш күрергә башына килми вә шуны эшли ала торган вазгыять түгел иде. Һәм вакыты да юк иде.

Җәнәбеңезә самими сәлам вә ихтирам илә Мөнир Хәсбиулла.

Харбин, 1935 ел, 16 нчы март.

Хатның күчермәсе Татарстан Республикасы Дәүләт архивында: саклана Р-2461 ф., 1 тасв., 26 сакл. бер. Текст шуннан алынды.

*Кереш мәкалә авторы һәм хат текстын әзерләүче*
*Зөфәр Мөхәммәтшин*

## ЭЧТӘЛЕК

**Кереш**.................................................................. **5**

**Г. Исхакый иҗат мирасыннан: көндәлек дәфтәрләре, әсәрләре, чыгышлары**.................... **10**

Мәшһүр әдибебез вә бөек юлбашчыбыз Гаяз әфәнде Исхакый җәнабләренең кыскача тәрҗемәи хәле вә иҗаты ........................................................................ 12

***Әдип көндәлекләре***.................................................. 20

2 нче дәфтәр.......................................................... 20

3 нче дәфтәр.......................................................... 41

4 нче дәфтәр.......................................................... 62

5 нче дәфтәр.......................................................... 86

6 нче дәфтәр.......................................................... 101

***Рассказ Г. Исхаки «Счастье башкира»в переводе Г. Акчурина***.......................................................... 112

***Рәсми чыгышлар***.................................................. 124

Милләт Мәҗлесенең мөһим карарлары (Милләт Мәҗлесе – 6 гыйнвар утырышы)...................................... 124

Речь редактора журнала «Милли юл» Аяза Исхаки.................................................................. 127

Аяс Исхаки. Идель-Урал.......................................... 131

**Г. Исхакый тормышы һәм иҗаты турында язмалар**.................................................................. **138**

***Истәлекләр***.......................................................... 138

Әдип юбилееН Төркиядә.......................................... 138

*А. Фадли.* Мин Гаяз агай белән ничек таныштым?.. 141
*Х. Шахмай.* Әдибебез Гаяз Исхакый....................... 146
*Әмәл.* Ерак Көнчыгышта Идел-Урал оешмалары.... 149
*К. Кафлы.* Әсир төркиләр........................................ 150
*К. Кафлы.* Бәйсезлек каһарманы.............................. 152
Мәрхүм Гаяз Исхакыйның җеназасы...................... 154
*Ф. Акйөзем.* Тууына 100 елга багышланган. Мәрхүм Гаяз Исхакый-Иделле............................................ 156
*М. Сали Әхмәт.* Г. Исхакый әсәрләрендә хатын-кыз образы.............................................................. 159
Бакый Урманче хатирәсендә Г. Исхакый шәхесе.... 163
Гаяз Исхакый турында Мөстәҗип Үлкүсал............ 165
*М. Үлкүсал* Кырым өчен багышланган бер гомер... 166
Новый документ о реакции людей на преследование властями Г.Исхаки............................................................ 174
***Тәнкыйди мәкаләләр***............................................. 178
Теләнче кызы............................................................ 179
Яңа әсәрләр.............................................................. 180
*Н. Әл-Хужҗаши.* Ике йөз елдан соң инкыйраз хакында..................................................................... 181
Кияү «Хикәя» Г. Исхаков әсәре. «Гасыр» нәшере... 188
*И. Әхмәтов.* Мәҗбүри изах..................................... 190
*И. Акчурин.* Гаяз Исхакыйның «Җавапларына» каршы... (Идарәгә мәктүб, гайнән)...................................... 191
*М. Акчурина.* Мөхәммәдгаяз әфәндәнең җавабларына җаваб............................................................................ 197
*Ш. Әхмәдиев.* Мәхмүд Фуадка тәнбиһ.................... 202
*Н. Думави.* Вөжданым көчләде................................ 205
*Ш. К.* Кечкенә фельетон............................................ 210

*Г. Ибрагимов.* Бөтенрусия мөселманнары җыелышы. Мәркәз шурага сайлау. Г.Исхакый мәсьәләсе. Зур җәнҗал........................................................................ 214

*Җ. Вәлиди.* Аңларга тырыштык, аңлый алмадык (Галимҗан иптәш Ибраһимовка җавап).............................. 220

*Кыпчаклы.* Финляндиядә милли бер утырыш.......... 225

*Ибраһим.* Гаяз Исхакыйның 20 еллык гәзитчелек бәйрәме........................................................................ 230

Русия мөселманлары турында ислам дөньясы........ 236

***Хатлар***............................................................. 239

**ДУХОВНОЕ НАСЛЕДИЕ**
**поиски и открытия**

Выпуск 5

Компьютерная верстка *Д.Р.Галиуллиной*
Дизайн обложки *А. В. Булатова*

Подписано в печать: 29.06.2018 г.
Формат 60×84 1/16. Гарнитура «Таймс». Бумага офсетная, печать офсетная
Усл.-печ. л. 16,2. Уч-изд. л.16,7. Тираж ____ экз. Заказ

Оригинал-макет подготовлен
в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12

Издательство Академии наук Республики Татарстан
420111, Казань, ул. Баумана, 20